ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2011



# ТУКАЙЛЫ ДӨНЬЯ



*Кушлавычта Тукаевларның музей-йортлары.*



*Җаекта Тукай яшәгән «Казан» кунакханәсе.*



*Уфада «Сабах» китапханәсе урнашкан йорт.*



*Элекке Клячкин шифаханәсе бинасы. Казан.*



*Казандагы «Тукай мәйданы» метро станциясе.*



*Санкт-Петербургта Тукайга һәйкәл.*



*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең медале.*



*Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе. Казан.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

**4**
**(1062)**

***ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:***
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Габдулла ТУКАЙ. Шагыйрь. *Шигырь.* ... 5
Рабит БАТУЛЛА. Апуш–Тукай. *Кыйсса.* ... 6
Тукайга шигъри чәчәкләр. М. ГАФУРИ. Ш. БАБИЧ. Н. ИСӘНБӘТ. Х. ТУФАН. Ә. ФӘЙЗИ. Ф. КӘРИМ. С. ХӘКИМ. Г. АФЗАЛ *шигырьләре.* ... 90, 95
Габдулла ТУКАЕВ. Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? ... 93
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. «Татар бәхте өчен мин җан атармын» ... 97
Бөеклек баскычлары ... 102
Зөфәр РӘМИЕВ. Тукай экциклопедиясе булырмы? ... 110
Флүрә ДӘМИНОВА. Тукай, Казан һәм Тукайның Казан төбәгендәге туганнары ... 113
Бер сорауга–бер җавап ... 119
Фәрхәт ЗЫЯТОВ. Тукай Өчиледә ... 120
Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ. Тукайның соңгы рәсеме. *Шигырь.* ... 124
Алмаз ХӘМЗИН. Оялтасың, энекәш! ... 126

БЕЗНЕҢ МУЗЕЙЛАР

Рашат НИЗАМИЕВ. Тукай белән очрашулар ... 128

САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ

Нур ӘХМӘДИЕВ. Алтын балык турында заманча әкият ... 136
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Денсезләр авылы. *Шигырьләр.* ... 140
Риф БӘДРИ. Нитәләр! ... 141

ТАРИХ

Ш. САМАТ. Матбугат йорты ... 143

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Радик ФӘИЗОВ. Инрәп ауды манара ... 147

ПУБЛИЦИСТИКА

Наил ШӘРИФУЛЛИН. Яңа мөгез, яки зиһен йокысы һәм албастылар турында ... 150

ХӘТЕР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр* ... 169

ТАТАР ГАЛӘМЕ

Мәсгут ГАРАТУЕВ. Йоклады дип бирмиләр ошбу җиһанда мәртәбә ... 154

АК ҖИЛКӘН

Бәләкәй Тукай ... 157

ЮБИЛЕЙЛАР

Рәдиф СӘГЪДИ. Аның тормышы–театр ... 182
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Рәхәт сагыну, татлы сагыш ... 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«К 125-летию Г. Тукая»: роман Р. БАТУЛЛЫ «Апуш—Тукай»; стихи Г. ТУКАЯ, М. ГАФУРИ, Ш. БАБИЧ, Н. ИСАНБЕТ, Х. ТУФАНА, А. ФАЙЗИ, Ф. КАРИМА, С. ХАКИМА, Г. АФЗАЛА, Р. АХМЕТЗЯНОВА; Г. ТУКАЕВ. «Умерла ли наша нация или она только спит?»; хронология жизни поэта; статьи Х. МИННЕГУЛОВА «Мне счастье татар дороже жизни», З. РАМИЕВА «Увидим ли энциклопедию Тукая?», Ф. ДАМИНОВОЙ «Тукай и его родственники на казанской земле», Ф. ЗИЯТОВА «Тукай в Учили», А. ХАМЗИНА «Смущаешь, брат».
«Наши музеи»: Р. НИЗАМИЕВ. «Встречи с Тукаем».
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений.
«История»: Ш. САМАТ. «Таткнигоиздат».
«Рассказы из жизни»: Р. ФАИЗОВ. «И упал минарет, плача».
«Публицистика»: Н. ШАРИФУЛЛИН. «Сон разума».
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
М. ГАРАТУЕВ. «Не принесет победы сон».
«Белый парус»: «Маленький Тукай».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: портрет Тукая—работа Ш. ЗАКИРОВА; праздник поэзии в Казани.

# IN THIS ISSUE:

«To 125th anniversary of Tukay»: novel by R. BATULLA «Apush-Tukay»; poems by TUKAY, M. GAFURI, S. BABICH, N. ISANBET, H. TUFAN, A. FAYZI, F. KARIM, S. HAKIM, G. AFZAL, R. AHMETZYANOVA; G. TUKAEV. «Did our nation die or it is only asleep?»; chronology of poet's life; articles by H. MINNEGULOV «For happiness of Tatars I'll give my soul», Z. RAMIEV «Will we see encyclopedia of Tukay?», F. DAMINOVA «Tukay and his relatives on Kazan ground», F. ZIYATOV «Tukay in Uchili», A. HAMZIN «Confusing, brother».
«Our museums: R. NIZAMIEV. «Meetings with Tukay».
«Hay Bazaar». Competition of satirical works.
«History»: Sh SAMAT. «Tatknigoizdat».
«Stories from Life»: R. FAIZOV. «And minaret fell down, weeping.»
«Journalism»: N. SHARIFULLIN. «Sleep of Reason».
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
M. GARATUEV. «Dream doesn't bring victory».
«White Sail»: «Little Tukai».
Diary of social-cultural life.
On our covers: portrait of Tukay, work by Sh Zakirov; poetry festival in Kazan.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.04.2011, график буенча 01.04.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–439. Тираж 4018.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.

Габдулла
Тукай

## Шагыйрь

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да,—
Күңлем минем яшь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз—һаман да яз:
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!»—дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә.

*1908 ел*



Рабит
Батулла

# АПУШ—ТУКАЙ

КЫЙССА

*Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен дә язасым килде.*

Габдулла ТУКАЙ
1909 ел

## Корбан

Апрель уртасында кар астына ут кермәгән иде әле. Кырларны кар каплаган. Юлның ике ягына да утыртылган озын таякларга салам учмалары бәйләнгән. Көн чалт аяз. Юл буйлап җигүле атлар ялкау гына юырта. Кайсысыдыр чанасына салам төягән, кайсысыдыр арка терәкле чанага—кашуфкыга киерелеп утырган да, айгырын көчкә тыеп бара. Айгыр дугасындагы җиз кыңгырау «зың-зың» тавыш бирә.

—Һо-оу, сак бу-ул!—дип кычкыра кемдер.

Берән-сәрән җәяүлеләр артка борылып, кашуфкыга юл саба, юл читенәрәк басып, айгыр узып киткәнне көтеп тора да ат узып киткәч, янә юлын дәвам итә.

Алда Кушлавыч авылы. Ерактан авылның мәчете күренеп тора. Аның кояш ягындагы такта түбәсе кардан арчылган. Бәлки, аның карын көрәп төшергәннәрдер.

Өйләрнең түбәләрен кар каплаган. Авыл капкасы калын көрт астында калган, атлылар да, җәяүлеләр дә капканың өстеннән йөри. Ян-яктагы өйләрне дә көрт баскан, морҗалары гына күренеп тора, төтен чыкмаса, анда—кар астында өй барлыгын белмәссең дә. Капканы күмеп киткән көрт тавында бала-чага чана шуа, балаларның кайберсе иске кайры тун кигән,

Рабит БАТУЛЛА (1938)—*прозаик, драматург; күпсанлы китаплар («Сөембикә», «Юл буйлары зәңгәр чәчәк» романнары, балалар өчен повестьлар, әкиятләр, һ.б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

кемдер бишмәттән, кемдер кырык ямаулы чикмәнен мунчала бау белән буып куйган. Чыр-чу киләләр, битләре ут яна.

Азан әйтә башладылар. Һәр капка алдына тирән карны көрәп сукмак салынган, шул сукмаклардан берәм-берәм картлар, ир урталар, егетләр, үсмерләр чыга, алар салмак кына атлап, азан ишетелгән тарафка, мәчет ягына йөриләр.

Кушлавыч мәчетенең имам-хатибы Мөхәммәд Гариф та бәләкәй капкасыннан чыгып, мәчет ягына атлады. Гадәттә Мөхәммәт Гариф мулла җомга көнне азанны үзе әйтә торган иде. Бүген мулла абзыйның эше чыкты шул, кендек әбисе ана мунча ягып китәргә кушкан иде.

Азан Кушлавыч авылы өстенә эленгән. Халык намазга бара. Мөхәммәд Гариф мулла авыз эченнән генә:

—Йа, иляһем, хәләлем Биби Мәмдүдә баладан сау-сәламәт котылсын иде!—дип теләк тели. Аннан соң ул:—Хәбир мөәзиннең тавышы моңлы гына,—дип сөйләнеп алды:—Указдан баш тартып, әллә шуны гына калдырасы инде? Беренче мәрхүмә хатынымнан бер исән бала, монысыннан тагын бер, Аллаһы боерса, сау-сәламәт туса, әле тагын Алла башка балалар да бирер, иншалла. Муллалыкны ташлап, тегермән тарттыру эшенә керешергә кирәктер... Аһәңе матур Хәбирнең, башы да, белеме дә бар, бәлки, шулай кылырга кирәктер...

Мулла Мөхәммәд Гарифнең йорт-җире, каралты-курасы зарланырлык түгел иде, урамга өч тәрәзә карый, ишегалдына таба—ике тәрәзә. Өйнең яртысын дип әйтерлек түрсәке алып тора. Түрсәкегә буйлый калын киез җәелгән. Сәкенең уң тарафында зур сандык. Сандыкның арка тарафында, китап киштәләрендә калын-калын, юка-юка китаплар, дәфтәрләр, кулъязмалар. Урта тәрәзә кашында шәмаил эленгән. Өйнең сул тарафында акшарланган мич, кучкарда ике керәчин лампасы, лампаларның берсе куыклы, икенчесе сукыр иде. Мичнең алгы кучкарында каен чыралары көлтәсе. Сәке урталай чаршау белән бүленгән.

Чаршау артындагы ятакта Мәмдүдә килен тулгаклап ята иде. Ул тешен кысып ыңгыраша.

—Түз, җаным, түз, озакламый котылырсың, иншалла! —ди кендекче Җамалия хатын.Өй эчендә ыгы-зыгы, кендекче хатын белән яшь хатын Минниса чаршау эчендә нидер кыла. Чаршауның бу ягындагы сәкедә буй житкән күрше кызы Фирүзә белән сабый кыз Газизә йомыш кушканны көтеп тора. Чаршауны ачып, яшь хатын Минниса кычкырды:

—Тиз! Мунчадан җылы су алып кайтыгыз!

Бу яктагы буй кыз Фирүзә йөгереп чыгып китте.

Чаршау артыннан тагын боерык килде:

—Чүпрәкләр! Тастымаллар!

Кызчык сандыкны ачып, чиста тастымаллар, чүпрәкләр алып, чаршау артыннан сузылган кулга сонды.

Ул арада ишектән чиләк белән җылы су күтәреп, баягы кыз керде.

—Чиста тагарак китер!—дип кычкырдылар чаршау артыннан.

Сабый кыз әзер тагаракны чаршау артына сузды.

—Көчән-көчән, Мәмдүдә балам!—дип кычкырды Җамалия хатын.

Ыңгырашу кычкыруга күчте, шулчак кендекче Җамалия хатынның шатлыклы тавышы яңгырады. Аның артыннан ук яңа туган баланың җылаган тавышы ишетелде.

—Сөбханалла, машалла! Биби-Мәмдүдә, улың бар! Бисмиллә ир-рахмән ир-рахим.

Сабый кыз ике кулын чәбәкләп, сәкедә сикерергә тотынды.

—Минем энем булды! Минем энем булды!—дип тәкрарлый үзе.

Кендекчегә ярдәм итүче яшь хатын арадагы чаршауны ачып куйды. Кендекченең кулында яңа туган бала туктаусыз җылый иде. Баладан котылган ана елмая, башкалар да куанычларын яшерә алмый иде.

Баланы юып, тәнен корытып сөртеп, каз мае белән майлаштыргалап, биләүләделәр.

Шулчак могҗиза башланды. Өй эче нур белән тулды кебек. Кендекче хатын да, башкалар да аптырап, бер балага, бер анага бактылар. Җамалия хатын дога укый башлады:

—Лә хәулә вә лә куәтә, иллә билләһи галиел газим! Сөбханалла!

Сабый җылавыннан туктады.

Әллә каян гына бер мәһабәт карт пәйда булды, ул яшел чапан кигән, яшел чалма ураган. Шулчак серле аһәң ишетелә башлады, шул серле аһәң чыңлавында әлеге мәһабәт карт баланы кендекче хатын кулыннан сак кына алды да, сабыйның колагына нидер пышылдады, аннан соң баланы кендекче хатынга кайтарды.

Күренеш юкка чыкты. Аптыраган хатын-кызлар Мәмдүдәгә якын килде.

—Бу нинди могҗиза? Әстәгъфирулла!—диде яшь хатын Минниса.

Мәмдүдә зәгыйфь тавыш белән сорады:

—Ни булды ул?

Кендекче Җамалия әйтте:

—Кояш болыт астыннан чыгып яктырткандыр!—диде.

—Мин Хозыр Ильясны күрдем шикелле!—диде Мәмдүдә-ана.

—Яз кояшы шулай могҗизалар күрсәтә булыр,—диде яшь хатын Минниса.

—Барысы да Алла кулында!—диде кендекче хатын.

Мәмдүдә ястыгыннан калкына төште:

—Атасына... сөенче...—диде.

—Газизә!—дип кычкырды кендекче.

—Әү, Җамалия әби!—диде кыз.

—Бар, мулла абзыйдан сөенче ал! Аның углы, синең энең дөньяга килде. Аллага шөкер!

—Киттем, Җамалия әби, әтидән сөенче алам!—дип Газизә чыгып чапты.

Газизә тунын кияргә дә оныткан, башына шәл каплаган көенчә генә урам буйлап йөгерә, үзе туктаусыз кычкыра:

—Сөенче... Сөенче-ее!

—Нинди сөенче?—ди малайлар.

—Энем бар!

Малайлар берьюлы кычкыра башладылар:

—Мулла абзыйның улы туга-ан! Мулла абзыйның төпчеге туган!

—Бәхете белән килсе-ен!—диләр балалар.

Җомга намазы тәмам, гыйбадәтчеләр тарала. Алар арасында башына малахай кигәне дә бар, кемдер иске бишмәттән, кемдер җилән кигән, кемнеңдер башында мескен бүрек. Кайсысыдыр каракүл бүрек кигән. Чабаталылар да, чүчинкә кигәннәр дә бар.

Мәчет капкасыннан Мөхәммәд Гариф мулла чыкты. Урам буйлап картларга каршы Газизә йөгерә, үзе:

—Сөенче, әти, сөенче!—дип кычкыра.

Кыз атасы янына килеп житте, аның тыны капланган иде:

—Сө ... ен... ч е...—дип әйтә алды ул.

Мулла абзый кызын кочаклап:

—Сөенчегә, кызым, сиңа мамык шәлъяулык!—диде.

—Минем энем бар, әти!—диде кыз.

—Машалла, төкле аягың белән, улым, үз бәхетең белән кил!—диде Мөхәммәд Гариф.—Әйдә йөгерик, кызым, салкын тигермә!

Мулла абзый кызын житәкләп, өенә таба йөгерде.

Мәмдүдә килен тиздән аягына басты. Мулла исем кушу мәжлесе жыйды. Коръән укылганнан соң авылның хөрмәтле аксакалы Шибай абзый бала колагына иелеп, өчәр тапкыр:

—Бисмиллаһ ир-рахмән ир-рахим... Аллаһунын колы Габдуллажан булыр синең исемең.

Аннан соң ике учын кушырып:

—Ля иляһә иллалаһу, аллаһу әкбәр! Колың Габдуллажанга муллык, бәхетләр юлла! Амин!—диде.

Кече якта утыручы хатыннар да, олы яктагы ирләр дә бергә дога кылдылар.

Бала туып, ярты ел чамасы узгач, сабыйларны жилкендерү йоласы уздырырга булдылар. Сөннәткә утыртылганнан соң бераз вакыт үткәч, Сөннәт туе була. Туй башланыр алдыннан ата кешеләр оланнарын ияргә алып, жилкендерү ярышы, беренче тапкыр оланның атка атлану бәйрәмен уздыралар.

Авыл капкасына озын-озын киртләрдән куелган инлекне ачып куйдылар. Басу капкасын чыккач та арыш басуы башлана. Арыш игенен ярып, ике якка ике юл киткән. Инлекнең тышкы ягында, басу юллары алдында ирләр, егетләр жыелган, авыл эчендә хатын-кызлар, бала-чагалар, жилкендерү ярышында катнашмаган егетләр, кызлар жыелган. Басу капкасы түбәсендәге аркылы агачка ике малай атланган. Алары атларның ничек барганнарын, ничек кайтканнарын күзәтергә куелган бактаннар. Атка атланган ир-егетләр юл башында тояк кыздыралар.

Яшь, гүзәл бер хатын Жиһания кочагындагы баласын юата:

—Туртай! Туртаем, бәләкәчем, жылама!

Игътибар уртасында Мөхәммәд Гариф мулла. Ул үзенең аты янында иярен, өзәнгеләрен тикшерә, кыскарта, озынайта. Аның янәшәсендә Мәмүдә килен Габдуллажанын күтәреп тора. Баланың йөзе ачык, сабыйның карашы житди һәм мәгънәле иде. Ул үзенчә нидер сөйләргә тырыша, авазлар чыгара:

—Те... те... те...

—Ие, улым, әттә-тә, әттә-тә...—ди ана кеше баласына карап.

Кайсысыдыр думбра алып килде, кемдер гармун тоткан, кайсысыдыр муенына иске бәрабан аскан. Сорнайның ярык тавышы ишетелә. Малайларның кайберләре кулларына сырлы кер бәләге тоткан да, шул сырларга таяк белән ышкып, тырылдавык тавыш чыгара. Шушы кораллардан тупланган оркестр ниндидер күнел жилкендергеч марш уйный. Ике егет мылтык тоткан.

Тамашачылар арасында кызу бәхәсләр купты:

—Кем беренче килә?—дип бәхәскә тарта бер малай.

—Туртай беренче киләчәк!—ди икенчесе.

—Юк, Габдуллажан беренче булачак!—ди өченчесе.

—Бураш беренче килә, менә күрерсез!—диде дүртенчесе.

Бишенчесе аларны бүлдереп:

—Беренче килү түгел монда шарт!—диде.—Бала жыламаса шул беренче була.

Елгыр атка атланган сөрәнче егет Тархан халыкка карап:

—Жәмәгате мөслимин!—диде.—Сөннәт туеннан алда була торган йола уеннарын башлыйбыз. Әгәр дә атта чапканда бала жыламаса, шул баланы

тормышында зур җиңүләр, байлык һәм хөрмәт көтә.

—Менә, әйттем бит!—дип төртте бишенче үсмер күршесенә.

—Сафланыгыз!—дип кычкырды сөрәнче.

Гариф мулла җиңелчә генә ияргә менеп утырды, хатыны Мәмдүдә аңа Габдуллаҗанны тоттырды.

Кинәт бер-бер артлы мылтык аттылар. Бәрабан дөмбердәде, кечкенә оркестр дәртле көй уйный башлады.

Сул кулы белән баласын, уң кулы белән тезгенен тоткан килеш, Гариф мулла атына үкчәләре белән орынды. Башкалар да ярышка кушылды. Мәмдүдә киленнең күзендә шатлык яшьләре күренде.

—Ярышыгыз уң булсын!—дип пышылдады аның иреннәре.

Башка хатыннар да:

—Бу беренче ярышың булсын, соңгысы булмасын!—дип сабыйларга изге теләкләр телиләр иде.

Атлар арыш арасындагы юл буйлап кереп югалды. Оркестр һаман уйный, егетләр-кызлар бии, бала-чага шунда качышлы уйный, әбәкле куышалар.

Басу капкасының аркылы агачына утырган ике малай җир ярып кычкырды:

—Кайтала-ар!..

—Габдуллаҗан беренче килә-ә! Мулла абзый алга чыкты-ы...

—Икенче кем килә-ә?—дип кычкыралар халык арасыннан.

—Икенче Бураш чаба-а...

—Туртай аны куа килә.

Халык биюләрне, уеннарын ташлап, капканың кыр ягына чыкты, сөрәнче Тархан аларга кычкыра:

—Китегез юлдан, атлар килә-ә... Юл сабыгыз! Балаларны алыгыз...

Ыгы-зыгы купты. Арыш юлында атлар күренде. Акыралар, сызгыралар... Авыл капкасыннан беренче булып Гариф мулла узды. Аның артыннан башкалары керде... Кайсысыныңдыр баласы җылый. Атлар килеп бетте. Узышчылар янә капка янына әйләнеп кайттылар. Һәр хатын иярдәге ире кулыннан баласын алды. Җайдаклар җәяүләнгәч, үсмерләр ярышта катнашкан атларны тезгеннәреннән тотып, читкә алып киттеләр.

Гариф мулла кочагындагы баласын хатынына күрсәтеп:

—Габдуллаҗан сынауларны яхшы узды, карчыгым. Ул бер тапкыр да шыңшып карамады!—диде.—Түзем җегет булыр, иншаллаһ!

Сөрәнче хәбәр салды:

—Беренче урынны Габдуллаҗан, икенче урынны Туртай, өченче урынны Бураш, дүртенче урынны...

Мәмдүдә бәхетле иде. Котлау авазлары янгырады, Гариф мулла һавага көмеш, бакыр акчалар чөйде. Бала-чага шул тиеннәр өчен сугыша-талаша калды.

Ярышта катнашучылар алдан, тамашачылар арттан йөреп, өйләренә таралды.

Мөхәммәд Гариф мулла йортына житәрәк сөрәнче егет әйтте:

—Теләгән барлык кеше дә Гариф мулла курасына кереп, тәгам җыя ала!—диде.

Мулла йортының эчендә дә, ишегалдында да, ачык лапасында да табын әзерләгән иде.

Капка төбенә житкәч, Гариф мулла якындагыларга:

—Иң башта балаларның күнелен күрегез!—диде.

Оештыручылар йорттан табагы-табагы белән сумса, телеме-телеме белән казы, буы күтәрелеп торган ит тутырылган табакларны алып чыгып, урамда, капка төбенә җыелган сабыйларга өләшә башладылар.

Гариф мулла мунчага кереп, тәһарәт алып чыкты да өйгә узды. Өй түрендә авылның абруйлы олы кешеләре утыра иде.

Гариф ишек катында туктап:

—Әссаләмү галәйкүм, кунаклар!—диде.—Дәстарханга килүегезгә күптин-күп рәхмәтләр. Каралты-курама сыйган кадәр углым Габдуллаҗанның сөннәт туена рәхим итегез!

Гариф мулла сәкегә—түргә менмәде, аягүрә басып калды, ул кунакларны шулай аягөсте сыйларга күнеккән иде.

Шулчак ишек катында сөрәнче егет Тархан пәйда булды.

—Мулла абзый!—диде ул пышылдап.—Сөннәтле сабыйлар хөрмәтенә су буенда, таллыкта кичке уен оештырырга ярамасмы?

—Ярый,—диде мулла.—Коръән күнел ачу уеннарын тыймый, фаразан. Миннән фатиха, олан. Ләкин бер шарт бар: хәттин ашмаска!

—Тәртип булыр, иншалла!—диде дә, сөрәнче шатлыгын яшерә алмыйча, өйдән чыгып китте.

Сөннәт туена авыл гаиләләре бик күп бүләкләр алып килгәннәр иде.

Су буендагы таллыкка авылның егетләре, кызлары, бала-чагасы барысы да җыелган иде. Кызлар да, егетләр дә бәйрәмчә киенгән. Кызлар бәбәй итәкле күлмәкләр киеп, чигешле алъяпкычлар бәйләп, чәчләрен толымлап үреп, толымнарына чулпылар, талир тәнкәләр тагып төшкән, бер-ике кызның башында энже калфак та күренә. Калфаклары булмаганнар яулыкларын почмаклап, чөеп бәйләгәннәр, матур чигеш маңгай турында нәкъ калфак кебек килешеп тора.

Кызлар әйлән-бәйлән уены оештырганнар. Уен тирәсендә сабый кызлар куышлы уйный. Әйләнә уртасында берсе гармун уйный.

Куышлы уенга катнашмыйча, калку урынга баскан бер сабый кыз күзен офыктан алмыйча әйтте:

—Анда, урман артында кара болытлар җыела!—диде.

Моны ишеткән олы кыз:

—Ул кара болыт кич саен шулай җыела да безнең авылны урап узып китә,—диде.

Икенчесе шомлы тавыш белән әйтте:

—Бу юлы ул безне урап узмас, ахрысы!

Калкулыкта басып торган кыз йөгереп төште дә уендагы апасының итәгеннән тартып:

—Айчәчәк апа, әйдә кайтыйк, яшенле яңгыр килә!—диде.

Айчәчәк түгәрәк уеннан чыкмыйча гына:

—Бар, сеңлем Зәринә, син кайт!—диде.—Мин дә озак тормам!

Кызчык кайтып китте, ул тыкрык тавыннан бер төркем егетләр төшкәнен күрде. Кемдер киереп гармун тарта. Кемдер сорнай кычкырта. Төркем артына малай-шалай ияргән. Малайларның берсе икенчесенә төртеп:

—Карале, яшенле яңгыр килә!—диде.

—Килсә соң?—диде чая малай.—Килсен! Яусын! Тоз түгел—җебемәбез, шикәр түгел—эремәбез!

Малайларның барысы да шаркылдап көлде.

Егетләр күренүгә кыз-кыркын кайсы-кая качып бетте, сабый кыз балалар гына таллык мәйданчыгында уйный калды. Егетләр таллыкка төшеп җиткәч, аптыраган булдылар, йөдәгән булдылар.

—Бәрәч! Кызлар уенга төшмәгәннәр ич!—дип кычкырды сөрәнче Тархан.

—Әйдәгез, алайса, кайтып китәбез. Кызлар булмагач, ул нинди уен була ди!—диде икенчесе.

Егетләр авылга борылып, кайтып киткәндәй итенделәр. Сабый

кызчыклар егетләргә:

—Алар таллыкка качты!—дип пышылдагач кына кире борылдылар.

Ул арада качкан кызлар да түзмәде, атылып чыктылар да көлешә башладылар.

Сөрәнче егет:

—Бүген бәйрәм, егетләр-кызлар!—дип кычкырды.—Бүген авылыбызның дүрт углын сөннәткә утырту хөрмәтенә бәйрәм! Бәхетле баһадирлар булып үссеннәр!

—Амин, шулай булсын!—дип кычкырдылар барысы да.

—Уенны башлыйбыз! Суз әргәнең, Әрдүан! Бәр бәрабан, Барыйжан! Тарт сорнаең, Сабиржан!—дип сөрән салды Тархан.

Уеннар башланды. «Чума үрдәк, чума каз», «Әй дүдәме, дүдәме»ләр, ялгыз биюләр кызганнан-кыза бара иде. Аннан такмак әйтүгә күчтеләр.

Егетләр башлады:

—Җанкай-җанаш, пумала баш, чыкма урамга җаланбаш!

Кызлар җавап бирде:

—Җөрмә, шәкерт, киләпүшсез, урыс булдың, ярамас.

Кызлар чыр-чу купты.

Егетләр әйтте:

—Кушлавычның, һай, кызлары киенмәсә дә матур.

Кызлар җавап бирде:

—Татар башы чокыр-чакыр, себермәсәң дә такыр!

Еракта, офык сызыгында яшен яшьнәп алды, бераздан соң ерак гөрелте ишетелеп куйды. Шомлы тавышлар чыгарып, каты җил исә башлады. Берничә сабый кыз белән малайлар кайтып китте. Кара болыт якыная иде. Тирә-як караңгыланды. Җил кинәт туктады. Шомлы тынлык урнашты. Күкне урталай ярып, яшен яшьнәде, дөмбердәп күк күкрәде. Җил купты. Эре-эре тамчылар шап-шап итеп яфракларга төшә башлады. Уен тукталды. Кемдер әче тавыш белән:

—Гарасат килә-ә!—дип кычкырды.

—Йа, Алла! Әстәгъфирулла! —диде икенчесе.

Яшьләр бөтенесе берьюлы тыкрык тавына таба йөгерделәр. Таллык мәйданы мизгел эчендә бушап калды. Яшен өзлексез күкне тураклый, офык кара кан төсендәге пәрдә белән капланган. Давыл башланды. Таллар суга тиярдәй булып бөгелә, атына. Яшен тагын чатырдатып сукты. Карт талларның юан ботаклары каерылып суга төште. Ишеп яңгыр ява башлады, инеш шундук су ташкынына әверелде.

Мөхәммәд Гариф мулла өендәгеләр куркышып бер почмакка җыелды. Шулчак ишек ачылып китте, бусагадан сабый Газизә белән күрше кызы Фирүзә килеп керде.

—Көчкә таптым, ул таллыкка яшьләр уенына төшкән икән,—диде буй кыз.

—Аллага шөкер, кайтып өлгердегез!—диде мулла абзый.—Белгәннәрегезне укыгыз! Барысы да Алла кулында!

Кинәт берьюлы әллә ничә тапкыр яшен яшьнәп, каты итеп күп тапкырлар күк күкрәде. Күкрәү шулкадәр каты иде ки, тәрәзә пыялалары коелып төште.

—Әстәгъфирулла! Ләхәү лә вә лә куәте.

—Бусы якын-тирәдә генә сукты!—диде Гариф.

Урам яктырып китте кебек. Бу яшен туктап тормаганнандыр, ихтимал. Бөтен дөньяда шомлы яктылык иде.

Шулчак урам буйлап кемдер кычкыра-кычкыра йөгереп узды:

—Янгы-ын! Янабы-ыз! Пожа-ар!

Гариф мулла җиләнен алып, чыгып йөгерде.

Урамда шау-шу, ыгы-зыгы, коеп янгыр ява, дүрт өй аша бер йорт яна. Янгын тирәсендә халык шау килә. Кемдер багор, колга тоткан, чиләкләр белән су ташыйлар. Акыралар, кайсысыдыр җылый.

—Малларыгызны абзарлардан куып чыгарыгыз!—дип кычкырды Гариф мулла.

Бераздан сыерлар, сарыклар, атлар белән урам тулды. Шулчак сөрәнче егет яна торган йорт капкасыннан атылып чыкты да, тамагын киереп кычкырды:

—Анда, эчтә кешеләр ба-ар! Яна торган өй эчендә кешеләр ба-ар.

Йортны бөтен яклап ялкын чорнап алган иде. Эчтә җан әчесе белән кычкырган авазлар ишетелә. Эчтә яшь хатын Җиһания төргәк кочаклаган килеш бер тәрәзәдән икенчесенә килеп, нидер кычкыра, ярдәм сорый. Ялкын аңа тәрәзә аша сикерергә ирек куймый. Урамдагы яшь ир җан ачысы белән кычкырды:

—Җиһания-ә!..—ул кешеләргә таба борылды.—Анда минем хатын белән балам! Коткарыгыз! Туртаемны коткарыгыз!

Гариф мулла сөрәнче егеткә кычкырды:

—Тарха-ан! Минем өскә су коегыз! Чикмән-бишмәтләрегезне миңа каплагыз да, өстемә су коегыз...

Бер ир Гариф мулла өстенә бишмәт-чикмән ташлады, берничәсе аның өстенә берничә чиләк су койды. Гариф мулла:

—Аллаһу әкбәр!—дип янган ишеккә сикерде.

Барысының авызыннан берьюлы:

—Аллам сакласын! —дигән тавыш чыкты.

Ишегалдына караган тәрәзәләр чәлпәрәмә килде, аннан нииндидер төргәк очып чыкты да пычракка төште. Төргәккә ут капкан иде, аны тиз генә пычрак су белән сүндерделәр. Бу—юрганга төрелгән бала иде. Ир кеше төргәкне алып, уттан ераклашты да, тагын кычкырырга тотынды:

— Җиһания-ә...

—Мулла абзый яна бит...—дип җылый халык.

Ут капкан албакча тәрәзәсе дә ватылды, аннан хатын атылып чыкты, аның да аркасындагы туны яна иде, хатын өстенә берничә чиләк су койдылар. Шул ук тәрәзәдән Гариф мулла да сикермәкче иде, аның битенә ялкын бәрде, ул башка якка күчеп китте.

—Ходаем, мулла абзый янып үлә-ә, коткарыгыз!—дип чиный хатыннар.

Кешеләр ары чаба, бире йөгерә, ялкын өйгә якынаерга ирек бирми. Өй эчен ялкын каплады.

—Кайда Гариф мулла?—дип кычкыра ирләр.

Шулчак ишектән ялкын баганасы атылып чыкты, бу Гариф мулла иде, ул кулларын болгап каядыр чаба, яна торган йорттан бераз киткәч, ул сазга егылды, барчасы аның өстенә сыек пычрак, су сибә башладылар. Тырыша торгач, ялкын сүнде, ләкин Гариф мулла аңсыз иде. Каты ялкын кешеләрне урамның аргы ягына куды, шулчак йорт ишелеп төште.

Күрше-тирәдә тагын ике йорт соңгы бүрәнәсенә чаклы янып беткән иде.

Гариф мулланы өенә алып кайттылар. Ләкин аның гомере киселгән иде инде. Маңгае, куллары янганы өстенә, аның үпкәсен ялкын өткән иде. Аңына килалмыйча төнлә җан тартты мәрхүм.

Икенче көнне үк кояш чыкты. Коточкыч янгыннан һәм давылдан соң авыл бичара хәлдә иде. Янган йортлар урынында әле һаман пыскып ята торган кисәүләр, янмаган йорларның байтагының түбәләре каерылган,

койма-капкалары ауган иде. Урамда әле һаман гөрләвекләр ага. Кешеләр аяк астындагы боламыкка әверелгән саздан атлыйлар. Алар Гариф мулланың мәетен күтәреп зиратка илтә. Җеназа артыннан бөтен авыл бара. Сабыен күкрәгенә кыскан көе, Мәмдүдә иң арттан атлый.

Матәмчеләр басу капкасын узды. Авыл башындагы күкрәп үскән арыш җиргә ятып сазга укмашкан. Ирләрдән арттарак килүче хатыннар төркемендә кемдер:

—Йа Аллам, ни белән балаларның тамагын туйдырырбыз!—дип кычкырды.

—Хатыннар!—диде аксакал.—Тавыш чыгармагыз мәет янында!

Матәм йөреше төп юлдан зират сукмагына борылды. Ирләр алмаш-тилмәш табутны күтәреп бара. Хатыннар зират капкасы төбендә туктады. Үсмерләр, балалар матәм артыннан китте.

Җиһания Туртайны баш очына күтәрде.

—Туртай, улым, карап кал! Ул сине, анаңны коткарып, үзе һәлак булган мулла бабаң. Гомерең буе син Гариф бабаңа рәхмәт укы!

Мәмдүдә җылый алмый, аңлый алмый иде. Үги анасы егылмасын дигәндәй, аның янында Газизә басып тора.

Габдуллаҗан төргәктән башын чыгарды.

—Әт-те, әт-те,—диде.

—Ие,—диде Газизә апасы.—Әттә, энем, әттә.

Габдуллаҗан атасы китеп бара торган якка карады, аның күзләрендә тирән мәгънә чагыла иде. Әйтерсең лә ул гомерлеккә ятим калганын аңлый иде.

Матәм төркеме Мөхәммәд Гариф мулланың җәсадын күтәреп, зират капкасыннан кереп китте.

## Кара ятим

Мөхәммәд Гариф мулла вафатыннан соң йортның яме китте. Каралты-куралар да ятим булып, хуҗасыз калды, тора-бара кайсысы кыегаеп, кайсысы янгыр суы үтеп, салмак кына җимерелә бара иде. Еллары да афәтле иде ул чакларда. Игенне яки боз сугып китә, яки корылык килеп, туфракка чәчкән кадәр дә игенне кайтарып алалмый калган чаклар була. Толбикә Мәмдүдә үги кызы Газизә, үз улы Габдулла очын-очка ялгап яши иде. Бар булган мал-туар да сызып бетте. Каралты-курага, араннарга, өйгә ятимлек сеңде. Балаларның өстенә алмаш кием алу, туйганчы ашау турында хыялланып кына була иде. Мәмдүдә, авызыннан өзеп булса да, балаларына каптырырга тырыша, еш кына ул мөмкинлек тә булмый.

Ходайның рәхмәте киң, көннәрдән бер көнне Мәмдүдәне хатынлыкка сорап, ерактагы Сасна авылы мулласы Мөхәммәд Шакир исемле тол ир яучы җибәргән. Сасна кешеләре: урта яшьләрдәге Мөхетдин абзый белән яшь егет яучылар сыйфатында иде. Сүзне олы яучы йөретте. Яшь яучы бары тик тыңлап кына утыра калды. Мәмдүдә бичара ни кылырга белми каушап калды. Мөхәммәд Шакир мулланы көр тормышлы дип әйтәләр, табынынннан бал-май, ак күмәч өзелми диләр. Ләкин бу ике баланы ияртеп алырмы Шакир мулла? Әллә аның шарты Мәмдүдәнең ялгызын гына алып китүме?

Баш яучы әйтте:

—Мәмдүдә килен,—диде,—син башта Шакир муллага ризалыгыңны житкер... Безнең авылга килен булып төш, остазбикә булырсың, иншалла, аннан соң иреңнең күңел кылын тартып карарсың, балаларыңны ул синең янга алдырырмы, юкмы?

«Юк, мин балаларымны ташлап кияүгә чыга алмыйм, аларны шушы

караусыз йортта ятим итеп калдыра алмыйм!.. Алса, балаларым белән алсын, юкса, бигайбә, мин аңа баралмыйм!» дип әйтергә теләде Мәмдүдә, ләкин әйтмәде. Бай кияүгә хатын булгач, аннан ризык, кием-салым алып, Кушлавычка, балаларым янына кайткалап йөрермен, дип уйлады ул һәм «риза» сүзен әйтте. Шулай итеп, Мәмдүдә үги кызы Газизәне ерак туганнарының каравында үз өендә калдырып, Габдулланы асрамага Шәрифә карчыкка ташлап, Саснага кияүгә чыкты.

Мөхәммәд Шакир мулла кырыс холыклы, эшчән, мәчеткә килгән сәдаканы үзенә түгел, мәчет файдасына тота баручы гадел имам иде. Каралты-курасын ул үз куллары белән җиткезеп, мал-туарын үз көче белән табып, аягында нык басып торучы хуҗабай иде ул. Эшкә батыр, аз сүзле ир-зат Шакир мулла Мәмдүдәне какмады, сукмады, ләкин аны иркәләп, назлап та тормады шикелле. Мәмдүдә дә иртә таңнан торып, абзар-мал арасында мәш килде. Мәмдүдә балаларын, һич югында сабые Габдулланы янына алдыру турында ел буе сүз кузгата алмый гаҗиз булды. Иреннән яшереп булса да, Кушлавыч кешеләре аша ул балаларына әз-мәз күчтәнәчләр җибәргәләде. Вәссәлам!

«Их, никләр теге чакта: балаларым белән алса, барам, юкса, мин кияүгә чыга алмыйм! дип әйтмәдем икән!»—дип күп тапкырлар ачынып җылый иде Мәмдүдә килен. Җылаганын иренә дә, мәрхүмәдән калган ике кыз балага да күрсәтмәскә тырышты. Кушлавычтан Саснага килүче яки Саснаны узып баручы Кушлавыч кешеләре сөйләвенчә, Гөлшәрифә карчык Габдуллаҗанны яхшылап бакмый, кайчакларда кыерсыта, ачулана икән. Хәтта ул сабый баланы суык көннәрдә ишек ачып кертмичә, ялан тәпи суык өйалдында да тоткалый икән.

—Күңеленә авыр алма,—диде Кушлавычтан олаучы Фарук.—Шәрифә карчык аны юри суыкта тота дип әйтәсем килми... Бәлки, ул аны оныткандыр... Һәрхәлдә, син, Бибимәмдүдә килен, аны үз яныңа алдырырга тырыш... Әле күптән түгел генә Габдуллаҗанга суык тиеп, үпкәсе шешеп, үлгәндә генә калды...

Олаучы Фарук сөйләгәннәрдән Мәмдүдә егылып китә язды, ул кич булса җылый, төн төштеме сабыен кызганып, бичараның йокысы качты. Ничек әйтергә Шакир муллага бу турыда?

Шулай да җае чыкты бит, тәки, курада мулла абзыйның сыеры игезәк бозау китерде, күп тә узмады биясе колынлады. Сарыклар бәрәнләде, каралтыда мал артты, шөкер.

Шакир мулла ул көннәрне бик шат йөрде, аның кырыс йөзендә елмаю чаткылары уйнаганын күреп, сәке түрендә, чәй табыны янында Мәмдүдә бичара кыюсыз гына сүз башлады:

—И атасы...—диде дә яшенә тыгылып тынып калды, алъяпкычы белән битен каплады.

—Ни булды?—диде хуҗабай:—Әйт сүзеңне!

Мәмдүдә үзен бик тиз кулга алды:

—Кушлавычта Габдулла ач утыра, атасы... әллә монда алдырасыңмы?

Шакир мулла дәшмәде. Ашыкмыйча гына чәен эчеп бетерде. Дога кылды. Алдындагы икмәк валчыкларын себереп, алдындагы тустаганга салды. Сәкедән җиңелчә генә сикереп төште дә әйтте:

—Бар, күрше Саттарны чакыр!—диде.

Мәмдүдә йөгереп чыгып китте, озак та узмастан ул үсмер егет Саттарны алып керде.

—Саттар энем!—диде Шакир мулла:—Минем Турайгырны кашуфкыга җик.

—Ярар, мулла абзый!—диде Саттар.

—Аннан Мәмдүдә абыстаң белән Кушлавычка барып, Габдуллаҗанны алып кайтырсыз!

—Баш өсте, мулла абзый! Хәзер киенеп кенә керим!—дип Саттар өенә йөгерде.

Мәмдүдәнең куанычы эченә сыймый иде, яратмыйча гына, мәҗбүрият кушканга гына кияүгә чыкканын ул яхшы аңлый иде, менә бу көнне, «Габдуллаҗанны алып кайтыгыз» дигән көнне Мәмдүдәнең күңел читендә ире Шакирга карата бер хис яралды. Шакир мулла аңа ягымлы, назлы булып күренде.

Ат ал аяклары белән тибенә, алгысап, ярсып тора, кучер урынында толыпка уранган Саттар аны көчкә-көчкә тыеп тора иде. Мәмдүдә кашуфкыга утырды, ире Шакир мулла Газизә белән Габдуллага, аны карап торучы Шәрифә карчыкка күчтәнәч тутырган төенчеген хатыны алдына салды, төенчек өстенә бүрек, кыска тун, олтанлы киез итекләр ташлады:

—Көне суык... Габдулланы тунга төрерсең!—диде.—Ыргып чапма, Саттар, юыртып кына йөре!

Саттар дилбегәсен бушатты, Турайгыр кар учмалары аттырып гайрәт белән кузгалып китте. Ул куштояклап алга ыргылды. Саттар атка куштояклап чабарга ирек бирми, дилбегәне тарта төште, айгыр күкрәк кагып, җитез юыртуга күчте.

Мәмдүдә Саттар ишетмәсен дип тыйлыгып җылый иде. Ул Аллага чиксез шөкерләр әйтә, иренә мең-мең рәхмәтләр укый.

Иң башта Мәмдүдә төп йортка кереп, ятимә калган Газизәнең хәлен белешергә булды. Аны ерак туганнарыннан булган бер апасы карап тора икән. Хәл-әхвәл сорашып, аларга куян күчтәнәче калдырып, Мәмдүдә Шәрифә карчык йортына китте.

Мәмдүдә бусагадан атлап керүгә фәкыйрьлеккә уранып калды. Өй тараканнар катып үләрлек суык иде. Мичтә чи усак чыш-мыш килеп, янар-янмас пыскый. Түр сәкедә ертык юрганга уранган Габдуллаҗан калтыранып утыра. Мәмдүдә толыбын салып, баласына таба атлады.

—Улым, Габдуллаҗан!—диде.

Габдулла юрганын ташлап, анасының кочагына атылды. Мич тирәсендә кайнашучы Шәрифә карчык та:

—И-и, кунак бар икән!—дип Мәмдүдә белән күреште.

Ана баласын кайнар кочагына кысып, озак дәшми торды.

—Әни, нигә болай озак килми тордың?—диде сабый.

—Менә килдем, улым, сине үзем белән алып китәргә килдем!—дип Мәмдүдә баласын сак кына сәкегә бастырды да, төенчеген чишеп, сәкегә куйды:

—Гөлшәрифә түти, сезгә күчтәнәч, сыйланыгыз,—диде.

Ул арада Саттар да ат алдына печән салып, өйгә керде.

Дүртәүләшеп бик тәмләп куян күчтәнәчләре белән чәй эчтеләр. Саттар ризыкка кагылмады, чәй генә эчте, Мәмдүдә чемченеп кенә утырды, Габдулла белән Шәрифә жылымса сумсаларны берәм-берәм юк итә тордылар. Бер таба гөбәдия белән ике таяк казыны алып, Шәрифә Мәмдүдә белән Шакир муллага рәхмәтләр әйтеп, күчтәнәчләрне чоланга чыгарып куйды.

Мәмдүдә, «Син Габдуллаҗанны юньләп карамагансың, аңа салкын тидергәнсең», дип әйтмәде. Шуннан ни файда?

«Сиңа үз балаң кирәк булмаганны, миңа ни хаҗәте!»—дип әйтсә ни кылырсың?

Ләкин Шәрифә карчык курасында берничә тапкыр үпкәсе шешеп чирләгәненең нәтиҗәсе—баланың гомерлек хаста булып китәсен Мәмдүдә

дә, Шәрифә карчык та башларына да китерә алмый иде.

—Менә, Шәрифә жинги, Габдуллажанны карап торганың өчен сиңа!—дип Мәмдүдә илле тиен көмеш бирде.

Шәрифә рәхмәтләр әйтеп, хәергә дога кылды.

Габдуллага тун, аягына итекләр, башына бүрек кигезеп, әнисе алдына утырттылар.

Шәрифә карчык капка төбендә күз яшьләрен сөртеп калды. Артык кашыктан котылуына сөенеп жылый идеме бу карчык, әллә чыннан да бу аерылышу аның өчен дә хәсрәт идеме?

Габдуллажанның кыска гына гомерендә шушы көннән дә бәхетле көне булмас, ахрысы. Кушлавычтан Сасна анасы куенында китеп барганда, жылы киенеп, тәмле ашап тамагы туйган Габдулла күкрәк кагып юыртучы айгыр жигелгән кашуфкыга утырып жилдергәндә хыял дингезенә чумды. Тирә-як ап-ак карга чумган, бу аклык, бу пакьлек күзне камаштыра, агачлар да ап-ак бәс эчендә утыра. Дөнья нурга чумган. Алар Турайгыр жигелгән жинел чанада ап-ак тынлыкта, ап-ак чиксез галәмдә гизә иде. Кашуфкыга утырган күчер Саттар абый да, «голт-голт» тавыш чыгарып юыртучы айгыр да, күкрәгенә улын кыскан анасы да нур эчендә иде.

Сасна авылына керделәр. Саттар абый Турайгырны дүрт баганалы ырыс капкага терәп туктатты. Кече капкадан аларны каршы алырга өйдәгеләр чыкты. Шакир мулла, аның кызлары Бибизәкия, Бибизәйтүнә, күрше хатыннары «айлап-шаулап» аларның исән-сау кайтуларын хупладылар. Габдулланы нindидер бер хатын Мәмдүдә кулыннан алды.

—Хуш кайттыгыз!

—Тунмадыгызмы? Юлыгыз авыр булмадымы?

—Үз бәхете белән килсен олан!—дип ду килделәр.

Аларны олы өйдә кайнар аш, кайнаган самавыр, мичтә пешкән ризыклар көтә иде. Чишенеп, юынып алгач, йортка фатиха бирделәр.

—Менә бу синең ике апаң, Бибизәкия белән Бибизәйтүнә булыр!—диде күрше хатыны.

Кызлар Габдулланы урап алдылар.

—Монысы синең атаң!—диде хатын.

Шакир мулла Габдулланы кызларыннан аралап алып, тезенә утыртты.

—Йә, жегет, ничек соң юлда, өшемәдеңме?—диде хужа.

—Юк,—диде Габдулла .—Эссе булды.

Габдулла үги атасын шундук яратып өлгерде, шул ук вакытта ул Шакир мулланың олпат, кырыс икәнен дә тойды, балада үги атасына карата ярату белән курку хисе бөреләнде. Шакир мулла да үги углын кабат беркайчан да тезенә утыртмады, аны шап-шап сөймәде, һәм ул аңа карата артык рәхимсез дә булмады. Ләкин Габдулла бу кешене изге ата кебек кабул итте. Жылы якты өй, абзар тулы мал, утырган саен итле аш, чәй эчкән саен бал белән май ягылган ак күмәч, яңа күлмәк-ыштаннар, аны үз энеләре кебек кабул иткән ике кыз Габдулланы чиксез бәхетле итә иде.

Ана белән олан бәхеткә иреште. Мәмдүдә баласы йоклаган чакта аңа сокланып карый, өстенә иелеп, Аллаһка рәхмәт догалары укый.

Габдуллага апалары белән аерым бүлмә иде.

Апалары инде күптән торган була, ул һаман, иркә бала кебек, йоклап кала иде.

Көннәрдән бер көнне Габдуллажан төш күрде.

Имеш, ул урман авызында уйный. Чәчәк жыя. Кайдадыр күке тавышы ишетелә, Габдулла күке булып кычкыра. Кинәт давыл купты, күк күкри башлады. Урманнан коточкыч кабан дуңгызы атылып чыга. Чәчәкләрен ташлап, олан йөгерә, кабан аны куа. Олан сукмактан таяк табып ала да,

кабан дуңгызын кыйный, тагын алга чаба, шулай чаба торгач, ул өйгә кайтып житә, ишектән керим дигәндә генә кабан аны куып житә, Габдулла җан ачысы белән кычкыра.

—Әни-ии...

Бүлмәгә әнисе йөгереп керде. Габдулла сикереп торып, әнисенең муенын кочаклап алды:

—Әни-и...

—Ни булды улым?—дип сорады Мәмдүдә.

—Әни, әллә нинди йонлач хайван куды...

—Нинди йонлач хайван?

—Куркыныч, йөнтәс, ике якта ике алагаем олы теше дә бар иде.

—Тынычлан, улым, син төш күргәнсең...

—Ул тагын минем төшкә кермәсме, әни?

—Юк-юк, кабат кермәс, улым...

Шулай кыш та, җәй дә узды, Сасна авылы тагын кышка кереп бара. Үктәбер аенда ук табигатьне кар каплады, зәмһәрир суыклар килде. Чатнама суык дип тормый, урамга киеп чыгарга җылы киеме булган бала-чага тауда чана шуа, кардан арчылган боз өстендә тәткедә йөри. «Тәтке» дигәне агач табанчага тимер пычак батырып эшләнгән боз шугыч була. Чанасы да, тәткесе дә булмаганнар тактага ятып тау шуа, кемдер махсус су сибеп катырылган тирес кантарына утырып, таудан аска томырыла.

Аста буа бозында анда-санда бәкеләр күренә. Бәкеләр янында киленчәкләр, яшь кызлар, хатыннар каз юа, мал эчәкләрен таптыйлар. Бүген каз өмәсе. Габдулланың әнисе Мәмдүдә дә каз юучылар арасында.

Габдулла да тау шуарга дип ишегалына чыкты, шулчак койма өстендә күрше малае Фазылҗанның башы күренде.

—Габдуллаҗан!—диде Фазылҗан:—Әйдә киттек каз каурыйлары сибәргә!

—Безнең каз каурыйларын апамнар сибеп бетерде инде. Мин дә сибештем.

—Безнекен дә сибешерсең!—диде Фазылҗан.

—Киттек!—диде Габдулла.

Алар Фазылҗаннар ишегалдына кереп, икесе дә каз каурыйлары тутырылган берәр ләгән алды. Киттеләр.

—Карале, Абдуллаҗан,—диде Фазылҗан.—Әйдә, мин сине Апуш дип йөртим.

—Әйдә!—диде Габдулла.—Алайса, мин сине «Фазыл» гына дим, җәме?

—Киттек, Апуш!

—Киттек, Фазыл!

Малайлар ләгәнне янбашка куеп, икенче куллары белән каурыйларны сукмакка әз-әзләп сибә-сибә су буена төшеп киттеләр. Үзләре туктаусыз кабатлый:

—Йа Иләһем, киләсе елда да казларыбызны шулай күп ит!

—Казлар-казкайлар, сез буада йөзегез, симез булып үсегез!

—Алай күп сипмә, Апуш! Су буена чаклы җиткез.

Каз каурыйларын сукмакка сибеп бетергәч, Апуш белән Фазыл каурыйдан бушаган тагаракларына утырып, тау шуа башладылар. Тагараклар туры гына шумый, алар бөтерелә-әйләнә. Кызык була, көлешәләр.

Хатын-кызлар бәкеләрне сарып алган. Алар сары тыгыз каз түшкәләрен сап-салкын суда юа. Су кулларны куырып ала, судан чыккан куллар тагын да ныграк туңа, хатын-кызларның куллары күгәрчен тәпие шикелле кып-кызыл. Чыдый алмаганнар кулларын уып, култык асларына тыгалар, кайнар тын белән җылытып алалар. Аннан тагын каз юуларын дәвам итәләр. Эше

беткәннәр көянтә башларына икешәр-өчәр каз асып, үргә таба йөреп китәләр. Казлар симез, казлар авыр, кызлар салмак кына атлый. Өскә таба юылган казлар күтәреп, кызлар менә, аска таба юылачак казларын күтәреп, башкалары төшә. Яз көне туган якларына кайта торган киек казлар төркеме аска төшә, көз көне Көньякка китеп баручы казлар өскә, авылга таба йөри. Казларны каклап, карындыкка төреп, чормаларга элэрләр. Кызларның бер кулы көянтәдә, икенчесе белән алар чиләк тоткан, чиләк каз башаягы: канат, бавыр белән тулган. Бүген табыннарда эч-башаяк бәлеше булачак.

—Йа Иляһем, киләсе елда да казларыбызны шулай мул ит!—дип телиләр барчасы.

Кинәт колакларны энә белән чәнчегәндәй, куркыныч аваз ишетелде. Бу Габдулла шулай кычкыра иде:

—Әни-и, Харрас бәкегә төште-е.

—Йа Аллам, Харрас бәкегә баткан,—диде кемдер.

Каз юучы хатын-кызлар тораташ булып каткан иде. Алар әле генә Харрас чумган буш бәкегә карап тора. Бәкедә баладан бушаган чана гына йөзеп йөри. Беренче булып Мәмдүдә аңына килде.

—Хатынна-ар!—дип кычкырды ул яшелле-күкле тавыш белән.—Ирләрне чакырыгыз? Багор алып килсеннәр.

—Әһә-һәй-и, суга батты-ы!—дип кычкыра-кычкыра берничә хатын авылга таба йөгерде.

Мәмдүдә көянтәсе-ние белән казларын ап-ак карга ташлады да, бәке ягына чапты, өстендәге авыр бишмәтен салып ыргытты. Килә-килешли ул суга сикерде. Башта аның тыны капланды, ул сулыш алалмыйча «ыһ-ых» итеп торды, сулышы рәтләнгәч, тирән тын алып, суга чумды. Барысы да бәке кырына җыелды. Тып-тын. Барысы да Мәмдүдәнең, сабый баланың өскә калкуын көтә. Бозлы су өстендә Мәмдүдәнең башы калыкты:

—Ул анда... турыда... алып булмады...—диде килен.

Тирән сулыш алып ул янә чумды. Тагын тынлык. Габдулла йөгереп килде дә кычкыра башлады:

—Әни-и, әнием батты... Әниемне коткарыгыз!

Су астыннан һава куыклары чыга, аннан соң Мәмдүдәнең башы күренде, ул авыр тын ала, бер кулы белән бәке кырынаябышып, икенчесе белән Харрасның бишмәт итәген тартып, өскә калкытырга тырыша, хәлдән тайган Мәмдүдә, бәке кырындагыларга сузылды. Ләкин боз кителде.

—Әнием, әниемне коткарыгыз!—дип өзгәләнә Габдулла.

Йөгерә килүче ир кеше кычкыра:

—Китегез бәке кырыннан!

Кешеләр бәкедән арткарак чикте. Ир кешенең кулында багор белән бау бәйләме иде.

Ул бәкедән читтәрәк туктап, багорны Мәмдүдәгә сузды.

—Нык тотын, килен, нык тотын!—дип кычкырды ир кеше.

—Багорга ябышыгыз!—дип кычкырды ир кеше.

Айныганнар багорны тарта башлады.

Ир кеше чананы аркылы куеп өстенә ятты да, Мәмдүдәнең икенче кулындагы бишмәт итәген алды, ул Харрасның гәүдәсен тартып чыгарды. Мәмдүдәне дә бәкедән алдылар, әллә каян гына бер карчык килеп чыкты да Харрасны тезенә корсагы белән йөз түбән куеп, аркасына баскалый башлады. Малайның авызыннан су бөркелде. Байтак кына су акканнан соң, карчык сабыйны аркасына салып, ясалма сулыш алдыра башлады. Үз авызын малай иреннәренә куеп, тын өрде, тагын тирән сулыш алып, малай авызына өрде. Малай ыңгырашып куйды, аннан ютәлли-тончыга башлады, аннан соң зәгыйфь кенә еламсырау авазы чыгарды.

Мәмдүдә аягына баса алмый интегә иде, баскан саен ишелеп төшә торды. Икенче бер олы хатын Мәмдүдәнең туңган бармакларын, битен каз мае белән майларга тотынды.

—Тиз генә киленне алып кайтып, җылы мунчага алып керегез! Нашатыр иснәтегез!—диде олы хатын.

—Харрас...—диде Мәмдүдә.

—Харраска чурт та булмаган!—диде хатын.

—Аллага шөкер!—дип Мәмдүдә аңын җуйды.

Җылы мунча да, нашатыр да, күкрәгенә, табаннарына гәрчич каплау да ярдәм итмәде, ике атна булды дигәндә Мәмдүдә килен дәрел фәнадин дәрел бәкага күчте.

Ак өйнең түр сәкесендә Мәмдүдәнең җәсады ята. Аның йөзе ачык. Бераз сулган матур йөзе теп-тере кебек. Габдуллаҗан анасының баш очында утыра. Өй эче тып-тын. Коръән укучының тавышы гына ишетелә. Коръән тәмамланды.

—Әни,—диде Апуш.—Әни, син нигә һаман йоклыйсың ул?..

Кара өйдәге хатын-кызның борын мышкылдатканы ишетелә башлады.

—Әни, уян!—диде сабый.

Мулла абзый кырыс кына әйтеп куйды:

—Баланы алыгыз!—диде.

Бибизәкия Габдулланы бүлмәдән алып чыкты.

Аякларын алга каратып, мәетне өйдән алып чыктылар. Ишегалдында аны ачык табутка җайладылар.

—Сафланыгыз!—диде мулла.

Ирләр сафланды.

—Бу хатын кем иде?—дип сорады мулла.

Арадан кемдер:

—Аллаһның колы!—диде.

—Яхшы хатын идеме?—диде мулла.

—Яхшы хатын иде!—диделәр.

—Аның бурычлары калдымы?

—Юк, аның бурычлары калмады,—диделәр.

—Аллаһу әкбәр!

Җеназа намазы укылды.

—Бәхилләшегез!—диде мулла.

Яшь кенә хатын Харрасны җитәкләп, мәет янына алып килде дә әйтте:

—Харрас улым, сине үлемнән коткарып, бу апаң Биби Мәмдүдә үзе һәлак булды. Син гомерең буе аның рухына дога кыл!

Харрас мәеттән йөз чөереп, әнисенә таба борылды да җылый башлады. Ирләр табутны күтәреп капкадан чыкты. Кешеләр чыгып беткәч, капка ябылды. Өйдән яланөс Габдулла йөгереп чыкты. Ул ялгызы калган иде. Капкага килде, капканың келәсе биек иде, коймага барды, койма да буй җитәрлек түгел, Габдулла җылый-җылый капка астындагы карны куллары белән көри башлады. Капка астында көчек сыярлык кына тишек ачылды, шул тишектән чыгып, Габдулла урам буйлап җеназачыларны куа китте, үзе туктаусыз кычкыра:

—Әни-и, әниемне кайтарыгыз! Аны кая алып барасыз? Алып кайтыгыз әниемне!

Арткы сафтан Бибизәкия белән Бибизәйтүнә аерылды.

—Кая барасың?—диде Бибизәкия.—Катып үләсең бит.

—Әни янына барам!—дип илаулады Габдулла.

—Әниең үлде!—диде Бибизәйтүнә.

—Юк, минем әнием тере, ул йоклый гына, ул уяныр...

Ике кыз Габдулланы ике ягыннан тотып өйгә алып кайттылар. Мәетне җирләп кайтканчыга кадәр бала башын бәрә-бәрә җылады. Шакир мулла кайткач кына җылавыннан туктады, ләкин ул һаман әле ярсыган, сулкылдап-сулкылдап куя иде.

Габдуллага бу өйдә кара көннәр башланды. Шакир мулла да кара көйгән, апалары да аның белән уйнамый-көлми.

Бераз вакытлар узгач, Габдулла ишегалдында уйнап йөргәндә урам якта, капка төбендә карчык-апаларның сөйләшеп утырганын ишетте:

—Мөхәммәд Шакир мулла Чишмәлектән Хасбетдинның тол калган хатынын яучылап йөри икән.

—Китчәле, аның ике баласы бар бит, монда өч бала, биш баланы кая куярга исәбе?

—Монысын кире илтергә йөри ди.

Габдулла үз исеме чыкмагач, аңлап та бетермәде.

Җәйгә чыккач, мулла абзый Саттарны чакырып кертеп, ат җигәргә кушты. Ләкин Турайгырны түгел, җирән алашаны җиктерде.

Җәйге чиллә зеңгелди. Басу-кырлар сап-сары коры үлән, кояш яндырган. Юл тузанын куптарып, җигүле ат бара. Арбада кучер Саттар белән Габдулла сабый. Сабыйның йөзе олыларныкы кебек җитди, хәсрәтле иде. Саттар абыйсы да моңлы көй шыншый...

Заманалар авыр, михнәтләр күп,
Дус-иш кирәк гомерләр итәргәй...

—Саттар абый,—диде Габдулла.—Ни өчен әтием мине Зиннәтулла бабама кайтарырга кушты икән?

—Һәйдә, алаша!—дип Саттар атка чыбык белән сукты, ат юырта башлады.—Ызначыт, яп-яланаяк, Шакир мулла сине угыл буларак кабул итмәгән.

—Алай димә, Саттар абый, ул яхшы әти, мине гел кәрәзле бал белән сыйлый иде ул.

—Алайса, ни өчен соң ул сине Зиннәтулла бабаңа кайтарта?

—Вакытлыча гынадыр.

—Уйлыйм әле мин, бөтенләйгә булыр дип... Охо-хох, Зиннәтулла бабайның үзендә сигез авыз. Син тугызынчысы булып кайтып төшсәң...

—Саттар абый, Зиннәтулла бабай да мулла бит, нигә ул фәкыйрь?

—Муллаларның барысы да бай түгел, энем. Зиннәтулла бабаң ертлач түгел...

Ат салмак кына юырта, күктә тургайлар сайраша.

—На-а, алаша!.. Габдуллаҗан, синең эшләр шулайрак тора...

—Чөнки Шакир мулла башка хатын алып кайтачак, диделәр.

—Син каян белдең?

—Капка төбендәге карчыклардан.

—Шулайдыр, дустым, шундый сүзләр йөри.

—Әнием үлмәгән булса...

Саттар җавап кайтармады, җырын сүзсез генә дәвам итте...

—Ни өчен Зиннәтулла бабайларның авылын Өчиле дип атаганнар ул?—дип сорады Габдуллаҗан.

—Чөнки анда нибары өч кенә өй диләр.

—Чынлапмы?

—Ни инде, өч кенә түгел, ләкин бик аз... Чөнки ул авылны шүрәле каргаган.

—Шүрәле каргаган? Ничек инде ул?

—Өчиледә башта өч йөзләп йорт булган... Шүрәле бит ул зыянсыз зат. Ни... шаян-шук була бит ул шүрәлеләр. Шүрәленең иң яраткан шөгыле атка атланып чабу, диләр.

Габдулла күзен йомып, Саттар хикәясен тынлый. Саттар шундый оста сөйли, сөйләгәндә шүрәле авазларын, кош-кортларның ничек итеп кычкырганнарын башкарып күрсәтә белә.

Шулай итеп, хикәят Габдулла күз алдында җанлана башлады.

Киң болында җылкы көтүе утлап йөри. Атлар чиный-чиный кешни, бер-берсен куа, тибешәләр, тешләшәләр.Урманнан үсмер шүрәле чыга. Ул житез атны тотып атлана да сызгыра, үкерә, атны куалый, яшь айгыр җан-фәрманга чаба, шүрәлегә рәхәт. Атны җан тиргә батырып, болын башыннан болын түренәчә куып йөрткәч, шүрәле җәяүләнеп, урман эченә кереп китә. Борын тишекләре кызыл итенә чаклы киңәйгән, ак күбеккә баткан ат урман кырыенда кала.

Таң аткач, кешеләр атларын алырга дип болынга чыксалар, күрәләр, иң яхшы айгыр хәлдән тайган, тиргә баткан, авызыннан селәгәе агып тора. Һәр төнне кемдер атаклы айгырны җигә, атланып чаба. Халык ду килә.

—Бу нинди эш?—дип кычкыра озын буйлы абзый.

—Кем айгырны яндыра язган?—дип өтәләнә бер ир.

Авылның бае, айгырның хуҗасы Ардаш әйтә:

—Кем дә кем минем айгырны җәберләгән затны тотып китерә, мин аңа йөз мыскал алтын бирәм,—ди.

Берсе дә теге затны тота алмый. Шуннан Зирәк атлы берәү әйтә:

—Ардаш бай,—ди.—Алтыныңның яртысын хәзер үк бирсәң, мин теге затны тотам, ди.

Ардаш илле мыскал алтын чыгарып Зирәккә бирә. Зирәк киңәше белән айгырының сыртына калын итеп сумала сылыйлар да төнгелеккә тагын болынга җибәрәләр. Икенче көнне иртән ат көтүе авылга кайта, иң алда яхшы юргага атланган шүрәле күренә. Ул тартыла, ычкынырга тели, ләкин ычкына алмый. Шүрәленең йонлы күте сумалага нык ябышкан була. Ачулары чыккан кешеләр кайсы таяк белән, кайсысы камчы белән бичара шүрәлене кыйнарга тотына. Шүрәле акыра, ялына, ялвара. Шүрәле тавышын ата шүрәле ишетеп, авылга, кешеләр арасына төшә.

—Адәм балалары!—ди карт шүрәле.—Җибәрегез улымны! Кыйнамагыз сез аны. Ул бит атларны кыргый атлар дип уйлаган. Башларында нукталары булмагач, атланган инде. Кабат алай кылмас минем улым. Зинһар, аны кыйнамагыз, җибәрегез. Ләкин кешеләр аны тыңламаганнар, тагын да катырак кыйнарга тотынганнар. Кыйный торгач, бичара шүрәле ат сыртында ярты тиресен калдырып, урманга качкан. Шуннан соң шүрәлеләр Өчиле авылы кешеләрен бик нык каргаганнар. Авылыгыз өч өйдән артмасын дигәннәр. Шуннан бирле Өчиленең йортлары азайган, үзләре гел ач икән. Өчиледән күчеп, кешеләр башка урынга, әнә без бара торган җиргә күченеп утырганнар.

Габдулла әкиятне бик бирелеп тыңлаганга күрә, Өчилегә килеп җиткәннәрен сизмәгән дә.

Өчиле авылындагы өйләрнең барысы да салам түбәле, каралты-куралары ярым җимерек хәлдә. Зиннәтулла мулланың өе кырык тирәүле, лапаслары менә ишеләм, менә ишеләм дип кенә тора кебек.

Басу капкасы янында олауны яланаяклы бер малай каршы алды. Капканы ачканда ул юлчыларның кем икәнен, кая баруларын сораштырып белде дә, капканы ябып, Саттарның аты алдыннан йөгереп китте, үзе кычкыра:

—Зиннәтулла бабай, Зиннәтулла бабай! Сөенче, сөенче!

Өйдән өерләре белән балалар атылып чыкты. Унбиш яшьлек олы кызы Сажидә, унөч яшьлек кызы—көйсез холыклы кызы Гөлчирә, берсеннән-берсе кече тагын дүрт сабый, алар артыннан Зиннәтулла мулла үзе күренде. Ана илле яшь чамасы булыр. Ябык-озын гәүдәле, ул муллага түгел, күбрәк мужикка охшаган иде. Башында искереп беткән киез эшләпә, күлмәгендә кырык ямау. Аягында тула оек белән чабата.

—Нинди сөенче, улым?—диде карт.—Нинди сөенче безнең авылга килеп кергән?

—Оныгыңгы алып кайталар, бабай!—диде яланаяклы малай.

—Әстәгъфирулла!—диде мулла.

Зиннәтулла абзыйның хатыны Латифа да капкадан чыкты. Бу хатынның усаллыгы кыяфәтенә дә чыккан иде. Ул аркылысы буе бер юан хатын булып, кешеләрдән әшәкелек кенә эзләүче, булмаса да ул әшәкелекне таба белүче җәнҗалчан зат иде.

—Һәй,—дип кычкырды Латифа сөенче китергән оланга.—Син ни кычкырасың анда, манка малай?

Гөлчирә дә анасының сүзен куәтләде:

—Ни алып килдең, саескан?

—Сөенче!—диде малай.—Габдуллаҗанны алып киләләр.

—Бирермен мин сиңа сөенченне!—дип кычкырды Латифа.

—Аттыр моннан!—диде Гөлчирә.

Ул арада кунаклар да килеп житте. Ат Зиннәтулла карт капкасына туктады.

—Әссәламү галәйкем!—диде Саттар.

—Вәгаләйкүм әссәлам!—диде карт.

Саттар Габдуллаҗанны арбадан төшереп:

—Кабул ит, Зиннәтулла абзый,—диде.—Оныгың Габдуллаҗан.

Зиннәтулла каушап калды, ул ни әйтергә дә белми «ык» итте, «мык» итте:

—Мин... ни...

Латифа алгарак чыгып, Саттарга кычкырды:

—Кире алып кит! Безнең үзебездә дә алты бала, үзебез белән сигез! Ә бу көчекне кая куйыйм мин?

—Ашарыбызга юк,—диде Зиннәтулла кыюсыз гына.—Шакирҗан мулла өендә ятим балага урын табылмаганмыни?

—Мин белмим!—диде Саттар.—Миңа егетне китереп куярга куштылар. Вакытым юк, мин киттем.

Саттар атын кайтыр якка борып куйды.

Латифа үзен ярсыта башлады:

—Миңа кеше баласы кирәк түгел!—дип кычкырды ул бөтен урамга.—Мин аны бусагамнан да атлатмам!

Саттарның да ачуы чыга башлаган иде, ул да каты тавыш белән:

—Аны мин тәрбияләргә тиешмени? Аның атасы вафат, анасы үлгән, сез аның иң якыннары! Ул кара ятимне мин үземә алып кайта алмыйм бит инде.

—Миңа чит-ят бала кирәкми!—дип һаман үзенекен тукый Латифа.

Саттар китә башлаган иде, арбасыннан сикереп төште дә чыбыгын янаулы тотып, Латифа каршысына килеп басты, хатынның чыраена карап әйтте:

—Анаң яламаган хатын!.. —Шулчак дүрт кечкенә бала капкадан чыгып, Латифа итәгенә ябыштылар да жылый башладылар.—Оныгыңа, ятим балага урын табалмыйсыңмыни? Мин үрдниккә барам, менә шушыннан ук китәм дә әйтәм, губернаторга чаклы барачакмын, Зиннәтулла абыйның

өеннән, аның анасы Мәмдүдә туган йорттан син бу ятимне куып чыгара алмыйсың!

Бу сүзләр ярсыган Латифаны бераз тынычландырды, ул еламсырап такмаклый-такмалый курага кереп китте, балалары аңа иярде.

Габдулла кая барырга белмичә, арба белән бабасы арасында туктаган килеш боек кына басып тора калды.

—Саттарҗан!—диде Зиннәтулла карт.—Мин сине чәй эчәргә өемә чакыра алмыйм, үзең күреп торасың... Кичер мине...

Саттар тынычлана төште.

—Ярар, Зиннәтулла абзый,—диде егет.—Онытып торам икән...—Саттар сәлам астыннан шактый зур төенчек чыгарды.—Шакир мулла сезгә күчтәнәч юллаган иде. Ал!

Зиннәтулла төенчекне кулына тотты.

—Анда аз гына он, бераз шикәр, бер савыт кәрәзле бал белән бер такта чәй!

Зиннәтулла оныгының иңсәсенә кулын салды.

—Кичер, Саттарҗан... Латифа бикәне... Ул шулай инде... Аннан кайта ул...

—Зарар юк, Зиннәтулла абзый!—диде Саттар.—Йә, Апуш, хуш-сау бул,—дип Саттар арбасына кырын утырды.—Мин киттем!

—На-а, бахбай!—дип Саттар чыбык белән атка кизәнде, алаша ларт-ларт юырта башлады.

Капка төбендә Зиннәтулла, Апуш, Сәҗидә белән Гөлчирә калды. Соңгысы атасының кулындагы калын төенчекне сорамыйча гына тартып алды да өйгә йөгерде.

Апуш ераклаша барган Саттарга карап, тын гына җылый иде. Сәҗидә энесенең иңнәреннән кочаклап алды.

—Сабыр бул, энекәшем!—диде апа кеше.

Ул сабыйның яшьләрен күлмәк җиңе белән сөреп алды.

—Барысы да Алла кулында!—диде Зиннәтулла.—Әйдә, улым, өйгә керик. Син өйдә тугызынчы ач җан булырсың.

## Теләнчеләр

Зиннәтулла мулла йортында көнаралаш гауга куба торган иде. Бу гауганың төп сәбәбе, әлбәттә, юксыллык, балаларның тамагы ач, өсләре ялангач булудан килә иде. Габдуллаҗан да кайтып өстәлгәч, гауга көн туугa башланып, караңгы төшкәнче дәвам итә башлады. Габдуллаҗанны сәкегә утырса, сәкедән, идәнгә ятса, идәннән, бусагага утырса, бусагадан куалар, каккалыйлар, суккалыйлар иде. Бигрәк тә әбисе Латифа белән апасы Гөлчирә аны җәберли. Бабасы юкта бу җәберләр икеләтә арта. Ләкин Габдуллаҗан бабасына әләкләми, түзә килде.

Зиннәтулла боларның барысын да сизә, кайчакларда үз күзләре белән күрә, үз колаклары белән ишетә иде. Күрше-колан да, дус-ишләре дә:

—Мулла абзый, син шул җен карчыгын балалары белән үз авылына куып җибәр, кызың, оныгың белән ничек тә ачка үлмәссең,—дип әйтә торганнар иде.

Ләкин Зиннәтулла мулла алар коткысына бирелмәде, хатынын аермады. Соңгы ел бик авыр килде шул, корылык та, давыллар да халыкны изде. Өйдә тугыз авызга түгел, бер йотарга тәгам калмады. Шуннан Зиннәтулла хәзрәт оныгын житәкләп, ерактагы авылларда хәер эстәргә, дип Өчиледән чыгып китте. Якын авылларда аны таныйлар, ерак авылларда танымаслар шәт, дип ул бик ерак авылларга барырга булды.

Хәер соранучыларның да хәлләре мактанырлык түгел иде шул ул елларда. Узган авылларда кот калмаган, ачлык үзен сиздерә. Өйләрнең барысын да салам яки дранча каплаган. Урамнарда ач этләр иснәнеп йөри. Ач булсалар да балалар туфракта уйный.

Юл буйлап озын, бөкшәйгән карт белән ябык сабый бара. Картның инсәсе аша киндерә белән тагылган буш букча, ул таякка таянган. Аның янәшәсендә бичара сабый. Болар Зиннәтулла мулла белән Апуш. Алар көне буе килде инде. Кырык-илле чакрым араны узганнардыр.

Бара торгач, алар зур гына бер авылга керделәр.

—Ярар, улым,—диде карт.—Шушы авылда бәхетебезне сынап багыйк.

Авылга кереп, бераз баргач, алар яхшы гына йорт капкасына килеп төртелделәр. Карт кыюсыз гына капканы какты. Берничә тапкыр суккач, эчтән тавыш ишетелде:

—Кайсы пычак кергересе йөри?—дип кычкырды хатын-кыз.

Бәләкәй капка ачылды, капка ачыклыгында хатын башы күренде:

—Ни дип дөмбердәтәсең?—диде хатын.

—Алла хакы өчен...—диде Зиннәтулла карт.

—Әле яңа гына хәерчеләр узды, бирергә валчыгым да юк!—дип хатын капканы шартлатып бикләп куйды.

Нәүмиз калган теләнчеләр алга таба китте. Икенче капкага төртелделәр. Капканы хуҗа ачты.

—Әссәламү галәйкүм!—диде Зиннәтулла.

—Вә галәйкүм әссәлам!—диде ир кеше.

—Алла хакы өчен бер сынык икмәк бирмәссезме? Менә оныгым кара ятим, үзем кара ятим, өйдә тагын ач балалар утыра.

—Әй, кем бар анда?—дип кычкырды хуҗа ишегалдына башын борып.—Карт белән оныгына бераз икмәк алып чыгыгыз!

Мөлаем хатын күренде, бу хуҗабайның хатыны булса кирәк. Хатын бер кыерчык ипине картның букчасына сонды.

—Ходай сезгә юмарт булсын! Рәхмәт яусын, муллыкта яшәгез!—дип Зиннәтулла дога укыды.

Алга таба киттеләр.

—Бабакай, тамагым кипте,—диде Апуш.

Капкага кагылып, Зиннәтулла:

—Зинһар, сабыйга су эчертсәгез иде!—диде.

Капка ачылды, яшь кенә бер кыз чүмеч белән су сузды. Апуш йотлыгып су эчте дә:

—Аллаһ синнән разый булсын!—диде.

Кызга сабыйның теләге бик ошады, ул елмайды:

—Син олылар кебек сөйлисең!—диде кыз.

—Кызым,—диде бабай.—Син безгә теш арасына кыстырырлык бирәр нәрсә бирә алмассыңмы, икебез дә ач.

—И, бабакай,—диде кыз.—Яңа гына дүрт теләнче узды, бирергә нәрсәбез калмады шул...

Кызның күзе Габдуллага төште. Сабый бигрәк тә моңсу карашлы, өмет белән кызга карап тора иде.

—Сабый бик тә арык...—диде кыз:—Торып торыгыз, мин хәзер,—дип кыз юкка чыкты, бераздан ике зур гына бәрәңге тотып янә күренде.—Алыгыз, иш янына куш булыр.

Теләнчеләр кызга рәхмәтләр укып, алга таба китте. Аларга бер өйдә бер уч он, икенчесендә бер йомарлап корот бирделәр.

Бу авыл артта калды. Авылны чыккач, бабай белән онык юл буенда үскән нарат күләгәсенә утырдылар. Бабай букчасыннан икмәк алып, бисмилла

әйтеп сындырды да оныгына сузды:

—Тамак ялгап ал, улым!—диде дә карт ипине янә капчыгына салды.

—Бабай!—диде оныкː—Син үзең нигә ашамыйсың?

—Ашыйсым килми әле, улым!—диде бабай.

Башка авылларда да йөрелде. Тырышып-тырышып җыласаң, сукыр күздән яшь чыга, дигәндәй, ярыйсы гына хәер тупладылар алар. Кайтыр юлга борылдылар. Юл уртасында туктап, бер авылның кырый йортына кунарга керделәр. Зиннәтулланың хәергә җыелган ризыкны ашарга кулы бармый иде. Ач карынга йокларга ятарга уйлап торганда хуҗалар аларны табын янына дәштеләр. Өч кешедән торган бу гаилә бик тату, сабыр иде. Чәй янында киптерелгән җир җиләге, бәрәңге салып бераз он туглаткан сыек шулпа, алабута кушып пешерелгән ипи. Габдулла белән Зиннәтулланың ач карынына ярап куйды. Тәгамга дога кылып, хуҗаларга рәхмәт укып, капчыкларын баш астына салып, йокларга яттылар. Күп тә узмады, хуҗабикә сарыкларын көтүгә куарга торды, Зиннәтулла да сабыен уятты:

—Улым, тор! Кояш чыкканчы юлда булырга кирәк.

## Саҗидә

Зиннәтулланың өендә колга белән болгансаң да колгага эләгерлек җиһаз-пәрдә юк иде. Сәкедә киез дә юк. Почмакларда ертык чүпрәк калдыклары, сәке уртасында балчыктан ясалган ватык савытлар ауный. Өй җыештырылмаган. Балалар юындырылмаган, чәчләре таралмаган. Алар сугыша, кычкырыша, җылашалар. Аларга Гөлчирә боерыклар кычкыра:

—Шауламагыз! Тавыш!

Ул мич кабызырга азаплана иде. Ишегалдында уйнап йөрүче Габдулла кермиме, дигәндәй Гөлчирә тәрәзәдән ишегалдына бакты да тиз генә әрбәлеккә кереп китте, анда бераз мыштырдаганнан соң нидер чәйни-чәйни кире чыкты, янә мич янына килде. Балалар аның нидер чәйнәгәнен тиз күреп алды.

—Апа... ашыйсы килә-ә...—дип кычкыра башладылар.

—Барыгыз, ишегалдына чыгып үлән ашагыз!—дип кычкырды Гөлчирә.

Балалар шаулаша-шаулаша чыгып китте. Алар артыннан Гөлчирә дә чиләк белән юынтык су түгәргә чыкты. Габдулла тиз генә өйгә кереп әрбәлеккә чумды. Буш чиләген шалтыратып Гөлчирә керде. Габдулла акырып җылап әрбәлектән чыкты.

—Гөлчирә апа, син минем сохариларны алгансың!

—Алмадым, энем, валлаһи, алмадым!—диде Гөлчирә.—Мин синең сохариларың барын белмәдем дә.

—Мин үз өлешемне яшереп куйган идем. Син ашагансың минем өлешне, син әшәке кыз!—дип Габдулла тагын да катырак җылый башлады.

Гөлчирә казанга су салды.

—Мин синең сохариларыңны күрмәдем дә!—дип аклана башлады кыз.

—Син ашаганны мин беләм, әнә, ирен кырыйларында сохари валчыклары.

—Начар малай син, Апуш!—дип кычкырды Гөлчирә.—Артык кашык булып безгә килеп төшкәнең җитмәгән, әле мине гаеплисең.

Гөлчирә учак янында кыштырдый.

—Син карак кызый!—дип кычкырды Апуш.—Син әшәке кыз! Мин сохариларны өйдә ашарга берни дә калмаган чакта бәләкәй кызларга бүлеп бирермен, дип саклаган идем. Син кяфер! Син гяур!

Гөлчирә бер уч көл алып, ачу белән Апушның йөзенә сипте. Малай әче

кычкырып күзләрен каплап, идәнгә чүгәләде.

—Күзем, күзем...—дип кабатлый үзе.

Сажидә кайтып керде.

—Ни булды?—дип кычкырды Сажидә.

—Үзе гаепле!—диде Гөлчирә.

—Күзем, апам, күзем бетте... Гөлчирә апа күземә көл сипте.

—Кабахәт!—дип кычкырды Сажидә Гөлчирәгә.

—Нигә ул гел мина мич ягарга комачау итә, йөрмәсен иде. Мин ялгыш кына...—дип Гөлчирә ишекне каты ябып чыгып китте.

Сажидә малайны кочаклап юата башлады.

—Жыла, жыла, олан... Жылагач, күз яшьләре белән юылып чыга ул көл. Жыла, энем, жыла...

Сажидә энесен мич арасына алып кереп, күзләрен салкын су белән юдырды.

Аннан соң Сажидә энесен кочаклап сәкегә утырды. Апуш әкренләп тынычланды.

Кич белән барысы да кайтып бетте. Теләнеп алып кайткан онның бер кашыгын алабута белән бутап, бер бәрәңгене турап ашка салдылар. Барысы да бик тәмләп тамак ялгадылар да йокларга яттылар. Апуш апасы Сажидә янында ята иде.

Бу йортта Габдулланы ике генә кеше какмый иде. Бабасы белән Сажидә тутасы. Сажидә тутасы аны кирәк чакта яклый, ач йөргәнендә качырып алып калган ипи кисәген аңа бирә иде. Үзен хәтерли башлаганнан бирле наз күрмәгән Апуш Сажидә апасының куенында ана назын да, апа назын да татыды. Сажидә тутасы һәр кичне ана «Мең дә бер кичә» әкиятләрен сөйли. Сажидә кыз аның зиһенендә, аның хәтерендә ак фәрештә булып сакланыр, аны исенә төшергән чакларда арык тәненә шифа, китек күңеленә юану булыр.

Шулай уйланып ятканда Апуш бабасы белән үги әбисенең сөйләшкәнен ишетте.

—Карале, карт!—диде Латифа әбисе.—Бу артык кашыкны берәр баласыз кешегә аткарыйк без.

—Кая, кемгә аткарасың инде аны?—диде бабасы.

—Без аны монда туйдырып яткыза алмыйбыз.

—Барысы да Алла ихтыярында.

—Алла, Алла! Аллага ышан, үзең дә тик ятма!

—Белмим, белмим...

—Мин беләм!—диде карчык.—Казан бае Рәҗәп асрамага бала алырга тели икән. Аларның балалары булмый, ди. Ике хатыныннан бер баласы да юк. Димәк, Рәҗәп бай үзе кысыр. Ул аны алачак. Мин Гыйльфан кучер белән сөйләштем. Бу чәүкә баласын Казанга алып китәргә риза булды.

—Барысы да Алла ихтыярында...—диде бабасы.

## Асрамага бала

Юл буйлап атлар чаба. Жигүле атлар. Иярле атлар. Пар атлар. Жәяүлеләр кайсы Казан ягына, кайсысы Казан ягыннан йөри. Тарантаска жигелгән яхшы айгырлар чабып уза, пар ат жигелгән, көпчәкләре елкыдавыклы файтуннар каядыр ашыга. Шулар арасында юл кырыннан ялкау гына алаша юырта. Аты белән кучере гына башка, утырып баручысы шул ук—Габдуллаҗан. Кушлавычтан аны шәп айгыр жигелгән кашуфкыда килеп алганнар иде. Саснадан аны алаша жигелгән гап-гади арбага печән салып, Өчилегә озатканнар иде. Менә ул тагын алаша жигелгән гап-гади арбада

Өчиледән Казанга китеп бара. Саттар кучер урынында Гыйльфан абзый.

Габдуллаҗан уйга чумып, хыялланырга ярата, ләкин йомшак йөк төялгән арбада, Гыйльфан абзый Казан базарында йон сатарга бара булса кирәк, аста йомшак, чыбылдыкка утырып барганда да аны хыялый уйлар биләде, ләкин ләззәтле хыялларга чумарга аның уң күзенә кергән көл ирек бирми иде. Әчеттерә, кыра. Гыйльфан абзый дилбегәсен ике тез арасына кыстырып, атны үз адымына куйган да моңлана. Ерак араларга олаучы булып йөри торган кешенең ни эше бар, ул җырлый.

Биеккәй генә тауларның, ай, башындай
Бөркет-шоңкар бала чыгарай,
Юлда йөргән азамат ир-егеткәй
Шул бөркетләргә карап сокланай.

—Шулай!—диде Гыйльфан абзый:—Күрәсең, синең язмышың шулдыр, дус. Синең барасы гомер юлың бик озын булыр, ахрысы.... Ләкин син, Габдуллаҗан, күңелеңне төшермә... Мин сине, Алла боерса, яхшы гаиләгә урнаштырам... Рәҗәп бай саран түгел ул.... Аның йорты—хан сарае, губернаторныкыннан да артыктыр, дип сөйлиләр... Аның балалары булмаган, булмас та кебек.... Син аның бердәнбер угылы, мирасчысы булырсың, иншалла... На-а, аргамак! Атла тизрәк... Карале, юл буе син күзеңне уасың, ни булды?.. Тррр...

Ат туктады, Гыйльфан абзый Апушны йон йөгенә яткызып күзен карады. Апушның уң күзе нык кызарган иде.

—Синдә трахум бар мәллә, Ходаем?—диде Гыйльфан шөбһәле тавыш белән.

—Юк!—диде Апуш:—Трахум түгел ул... Күзгә көл кергән иде. Кыра...

—Ә син күзеңне ума!.. Хәзер, дус,—дип кучер юл букчасыннан бер шешә тартып чыгарды:—Мин бу үлән төнәтмәсен гел юлга алып йөрим, тузан, вак таш, чүп керсә, күземә шуны салам. Бик ярдәм итә.

Гыйльфан Апушның күзенә берничә тамчы салды.

—Хәзер күзенне ачма! Ятып бар... Бераз җиңеләйдеме?

—Ие,—диде Апуш.

—Рәҗәп бай ул юмарт кеше, ул сине маминт аякка бастырачак, иншалла.

Аргамаклар гынай ыргып чаба
Ташлар салган юллар буенчай,
Кая барсам, кайда туктасам да
Син сөйгәнем минем уемдай.

Атның гел бертөрле юыртуы, кучерның гел бертөрле тавыш белән җырлавы Габдулланы изрәтте, ул йокыга китте.

Төшендә ул үзен «Мең дә бер кичә» әкиятләрендәге шаһзадә киемендә, алтынланган, асылташлар белән бизәлгән тәхеттә утырганын күрде. Аның каршында Рәҗәп бай боерык көтеп башын игән. Аннан арттарак гүзәл кызлар тез йөгенгән.

—О, бөек падишаһ Габдуллаҗан!—диде Рәҗәп бай.—Синең бөтен җирең житеш, тагын ни телисең, и падишаһым?

—Китерегез сез миңа кәгазь-каләм вә дәхи кара савыты!—диде падишаһ.

Кәнизәкләр ул сораганнарны алып килеп, өстәлгә куеп, кире чиктеләр.

Апуш падишаһ каләмен карага манып, яза башлады.

Шунда ул уянып китте. Олау Казанга килеп җиткән, Яна Бистә урамы буйлап бара. Болак арты мәчетләре Апушның ушын алды. Бистә өстендә азан авазы йөзә иде. Атка атланган полицейскийлар, башларына йөк күтәргән хатын-кызлар, гәзит сатучы малайлар...

Олау тар урамга борылды. Гыйльфан абзый узган бер кешедән сорый:

—Рәҗәп байның каралтысы кай тирәдә?

—Әнә теге якта булырга тиеш!—дип узгынчы туктамыйча гына узып китте.

—Әйт әле, агайне, Рәҗәп бай кай тирәдә тора?

—Киләсе аркылы урамны узгач та ике катлы таш йорт булыр, дүрт баганасы да буялган ырыс капка күрерсең!—дип тәфсилләп аңлатты узгынчы агай.

Бераз баргач, Гыйльфан абзый атын матур капкага терәп туктатты да тезгенне капка баганасындагы боҗрага бәйләп куйды. Аннан Габдуллаҗанны арбадан алып, җиргә бастырды. Кечкенә капка янына килеп, зур боҗраны капка тактасына бәрде. Капка артында юан тавыш белән эт өргәне ишетелде. Гыйльфан абзый тагы капка какты, эт тагын да катырак өрергә тотынды.

—Әй!—дип кычкырды кучер:—Берәрсе бармы анда?

Карлыккан тавыш ишетелде:

—Кем бар анда?—мөгаен каравылчыдыр.—Бурзай! Өрмә!

Эт туктады.

—Рәҗәп бай өйдәме?—дип сорады Гыйльфан.

—Рәҗәп бай өйдә түгел!—дигән җавап ишетелде.—Ул Ырынбурга китте... Бер айдан кайтыр.

—Без Өчиледән, Зиннәтулла мулладан килдек.

Өйнең икенче катыннан хатын-кыз кычкырды:

—Мәхмүт! Кем килгән анда?

—Зиннәтулла хәзрәттән диләр, абыстай.

—Нинди хәзрәт, хәсрәт?

—Абыстай, без Өчиленең Зиннәтулла мулладан...—дип кычкырды Гыйльфан.—Сезгә уллыкка бер олан алып килдем.

Хатынның ризасыз мыгырданганы ишетелде, ул баскычтан төшә иде булса кирәк. Бераздан кече капка тар гына булып ачылды, юан чылбыр аңа киң ачылырга ирек бирми иде. Тар ачыклыкта абыстай күренде.

—Әссәламү галәйкүм!—диде Гыйльфан.

—Без бернинди дә оланга кушмадык!—диде хуҗабикә.

Гыйльфан авып китә язды.

—Ничек кушмадыгыз? Зиннәтулла мулланың хатыны Латифа бикә әйтте: Рәҗәп бай бу оланны уллыкка алачак диде.

—Без бернинди Зиннәтулланы да, Латифа бикәне дә белмибез,—диде хуҗабикә.

Кече капка юлчылар борыны төбендә шартлап ябылды. Чылбырлар чылтырады.

—Шайтан алгыры!—дип кычкырды Гыйльфан. Ул капканы тагын да катырак дөбердәтә, эт тагын буыла-буыла өрә башлады.—Әй, ачыгыз! Бәлки сез Рәҗәп байның карарын белмисездер?.. Латифа бикә әйтте: Рәҗәп байның ике хатыныннан да баласы булмый, ул кысыр икән, диде. Алар асрамага бала ала икән, диде.

Ишегалдында шау-шу купты.

—Күрсәтермен мин сиңа, кысырыңны, авыл чабатасы!—дип дулый абыстай.—Киле-ен! Зәлидә-ә!

Өстән:

—Әү, анакай!—дигән яшь тавыш ишетелде.

—Аска төш! Мин аларга кысырны күрсәтәм! Балаларны да алып төш!

Кече капка киңрәк ачылды, юлчылар шундый күренешкә тап булдылар: юан абыстай-анакай, анын янында корсагы иягенә җиткән килен Зәлидә, алардан арттарак—каравылчы Мәхмүт, анын янында бозау хәтле эт—Бурзай баскан. Бурзай янында ике сабый бала тора иде.

—Кара, тамагыңа таш кергере!—диде абыстай.—Кара да Латифа бикәнә кайтып әйт: менә Рәҗәп байның гаиләсе. Әйе, улымның ике хатыныннан сигез ел буе балалары булмады. Китте гайбәт, имеш, Рәҗәп бай кысыр икән, дип чәйнәделәр. Әмма өченче хатыны, менә бу Зәлидә килен ел саен бала таба.

—Абыстай, сезнең анда гел кызлар гына күрәм,—диде Гыйльфан.—Бу йортка бер ир олан да кирәк, ләбаса... Карагыз сез, шундый яхшы бала, зиһенле, тәрбияле. Хәзер мин аны кая куйыйм?

—Бик тәрбияле булгач, үзеңә калдыр!—диде хатын.

—Анакай,—диде Зәлидә килен:—Әллә алабызмы?

—Кемгә әйттем! Чит-ят бала безгә кирәкми. Алла үзенә ир олан җибәрер, иншалла. Орлыгы Бохарада түгел!—дип абыстай икенче катка менеп китте.

Зәлидә килен пышылдап:

—Печән базарына барыгыз, абзый, Мөхәммәд Вәлиләр ир олан алырга уйлыйлар иде. Мин аңа язу белән кеше җибәрермен. Ул сезне базардан, кәләпүш рәтеннән эзләп табар.

—Киле-ен!—дип кычкырды абыстай.—Яп капканны!

—Хәзер, анакай!

Капка ябылды, чылбырлар салынды. Гыйльфан аптыраšта иде.

—Боларның барысы да теге карчыга Латифа эше!—дип сукранып алды кучер. Аннан соң атын Печән базарына таба борды.

Кучерга аркасы белән утырып, ике тезен кочаклаган Апуш бик боек иде, аны хәтта шәһәр күренешләре дә кызыксындырмады. Аңа карап Гыйльфанның үзәге өзгәләнә. Сабыйның иртә олыгайган чыраенда ул фаҗигале язмыш чаткыларын күрә иде кебек. Ләкин шушы сагышлы йөздә ул ниндидер якты нур да күрде.

Апуш үги атасы Шакир мулланы да, буынсыз бабасы Зиннәтулла картны да, хәтта усал әбисе Латифаны да, Рәҗәп байның усал анасын да гаепләми, аларга үпкә сакламый. Язмышында шулай язгандыр. Кәтәргә, өмет итәргә генә кала.

Олау Печән базарына килеп җитте. Апуш айнып китте. Анын каршысында берсе озын, икенчесе йомры манаралы мәчет басып тора. Мәчет алдына халык җыелган, көлешәләр, кычкырышалар, кулларын чалдый-болдый болгап сөйләшәләр иде.

Мәчетне узгач та печән сата торган мәйданчыкка килеп чыгасың. Анда йөге-йөге белән салам да, печән дә саталар. Бушаталар, төйиләр, алып китәләр, яңа йөкләр килә тора. Сатулашалар. Кым-кырыч киләләр.

Сәүдә рәтләре тезелеп киткән. Читекләр, күнитекләр, күн каталар, киез каталар, башмаклар, чүәкләр...

Баш киемнәре рәтендә каракүл бүрекләр, чигешле түбәтәйләр, кәләпүшләр өелеп тора. Шунын янында ук шәлъяулык саталар.

Казакилар, камзуллар, ыштаннар, чалбарлар...

Рәт араларыннан башларына зур табакка салынган алмалар, әфлисуннар куйган егетләр уза. Хатыннар да баш өсләрендә кайнар сумса күтәреп йөри.

Шунда ук малай-шалайлар чабыша. Рәт буйлап базар корольләре йөри,

алар яхшы киенгән, ялтыравыклы эштиблитләрдән, мыеклары өскә каратып бөтерелгән. Яннарында ялагай йомышчылары да бар.

Лафкалар тезелешеп киткән. Бер ачык лафкадан сатучы приказчик карап тора, каракүл бүреген кырын салган, камзул кесәсеннән алтын чылбыр асылынып тора. Үзе үткән-сүткәннәргә карап:

—Яңа сауган сөт, кичә оетылган катык, вак коротлар, эре коротлар! Җаның ни тели, барысы да бар...

Сатучы янына бай киемле бер ир килде:

—Бай әфәнде!—диде приказчик.—Ни телисез?

—Миңа бер тәпән катык! Минем өйгә туп-туры!

Бай кесәсеннән янчыгын чыгарып, приказчикка акча сузды да китеп барды. Приказчик якында гына утырган үсмерләргә карап:

—Әй, Колга!—дип кычкырды.

Колга дигәне озын буйлы, ябык кына бер үсмер булып чыкты.

—Тыңлыйм әфәндем!—дип приказчик янына килде.

—Менә бу бер тәпән катыкны Шәкүр әфәнденең курасына илтеп кайт. Адресын беләсеңме!

—Белмичән, ул бит палисәмистернең күршесе.

Приказчик аның башына тәпәнне куйды, тәпән Колга башына менеп кунаклады, аның ике кулы да буш иде, приказчик аның учына хезмәт хакын сонды. Колга цирк артисты сыман, башына тәпән куеп, ике кулын селтәп китеп барды.

Ташка утырган башка үсмерләр сөйләшә.

—Колга байый, егетләр,—диде берсе.

—Аның эше уңа...—диде икенчесе.

—Һәм мәхәббәттә һәм байлыкта...

—Туйга акча җыя Колга!

Шулчак алъяпкыч бәйләгән бер ир килеп, үсмерләргә әйтте:

—Туганнар, ике йөк печән бушатырга дүрт кеше кирәк!—дигәч тегеләр сикереп торды.—Әйдәгез!—дип алъяпкычлы китеп барды, егетләр аңа иярде.

Рәтләр буйлап ширбәтче килә. Аның аркасында зур кувшин, ике кулында агач касәләр. Аның артыннан сигез яшәр малай килә, малай чиләк белән су тоткан, икенче кулында комган.

—Ширбә-әт! Сап-салкын ширбәт! Яңа гына кар базыннан ширбә-әт! Нибарысы өч бакыр, ширбә-әт! Кемнең кесәсе такыр, булыр бер бакыр—ширбәт!

Узгынчы ширбәтчегә тиеннәр бирде.

—Ике касә!—диде узгынчы.

Ширбәтче ике касәне узгынчы кулына сонды да кувшиннан ширбәт салды. Узгынчы йотлыгып эчте дә касәләрен малайга тоттырды, малай аларны комгандагы су белән чайкап, атасына сузды.

—Ширбә-әт!—дип кычкыра-кычкыра ширбәтчеләр узып китте.

Шулчак кәләпүшчеләр рәтендә Гыйльфан абзыйның тавышы яңгырады, ул арбасына баскан килеш, ике учын авызына куеп кычкыра:

—Асрамага бала бирә-әм... кем ала-а! Асрамага ир олан ба-ар, кем ала-а... Алты яшьлек ир бала-а... Яхшы малай, атасы мулла иде... Мәрхүм булды, анасы абыстай иде, мәрхүмә булды...

Габдуллаҗан сатылучы товар кеби, сатып алучысын көтә иде. Ул тырнаклары белән салам кисә, Гыйльфанның тавышын ишетми дә кебек.

Апуш күктә, болытлар арасында пәйда булды. Мәчет манаралары, чиркәүдәге хачлар аста калды. Аның каршысына анасы Мәмдүдә очып

килә. Алар болытлар арасында кавышалар. Уйныйлар, очалар, бер-берсен куышалар иде. Кинәт кенә алар каршысына Хозыр Ильяс килеп чыкты да Абдуллажанга кулын сузды. Абдуллажан бөек куаныч илә аңа каршы очты. Анасы шатланып алар күрешкәнне карап тора һәм аларга кул изи.

Габдуллажан күзен ачты, аның каршысында, чыннан да, Хозыр Ильяс басып тора иде. Ул Габдуллажанны кочаклап, иркә сүзләр әйтә:

—Олан!—диде Хозыр.—Син нинди ябык! Әйдә, өйгә кайтыйк, сине өйдә гөбәдия, бәлеш пешереп анаң көтә...

Бу кеше Зәлидә килен әйткән Мөхәммәд Вәли булып чыкты. Зәлидә килен алдамаган икән, рәхмәт төшкере.

## Хозыр Ильяс

Мөхәммәд Вәли хәләле белән бик җыйнак-матур өйдә тора икән. Егерменче гасыр башындагы үз йорты белән торучы урта хәлле кешенең өе иде ул. Авыл өйләреннән аермалы буларак, бу өйдә сәке зур түгел. Аның каруы өйдә урындыклар, өстәл бар. Өстәлдә ялтыратылган җиз самавыр, самавыр камфуркысында ташаяк чәйнек фырт кына утыра. Ишектән керешли үк Вәли абзый Габдулланы җитәкләп өстәл янына алып килде.

—Анасы!—дип эндәште:—Мин улыбызны табып алып кайттым бит, каршы ал! Аллаһу Тәгалә безгә угыл бирде, машалла!.. Әйдә уз, Гыйльфан кордаш!

Гыйльфан ишек катындагы урынга утырды.

Чаршау артыннан нәкъ Апушның анасы Мәмдудәгә охшаш хатын чыкты. Апушның авызыннан:

—Әни!—дигән сүз атылды.

Бу ихлас сүз иде. Газизә дә төштәге кебек, бу баланы чын үзенеке буларак кабул итте, ул кочагын җәеп:

—Улым!—диде, бала аның җылы кочагына сеңде, икесе дә җылый иде.

Ишек төбендәге Гыйльфан үзенең малахаен әвәли.

Вәлинең дә күнеле йомшарган иде, ул да хатыны белән Апушны икесен бергә кочаклап тын калган.

—Әтием, әнием!—диде Апуш.—Мин белдем, белдем мин, сез мине табачаксыз, дидем. Мин сезне төшемдә күрдем.

—Габдуллаҗаным!—диде Газизә ана.

—Әнием, сез мине ташламассызмы?—диде Апуш.

—Юк!—диде ата белән ана икесе берьюлы.

—Беркайчан да бер кайчандамы?—диде сабый.

—Беркайчан да беркайчан да...

—Валлаһи, билләһиме!

—Валлаһи, билләһи, улым.

Газизә бикә улын кочагыннан чыгарды да:

—Юыныгыз!—дип бүлмәчкә узды.

Ата кеше Апушны юынырга аралыкка алып керде.

Ана кеше табасы белән бәлеш алып чыкты. Шунда гына ул ишек катында әвәләнеп торучы кешене күрде.

—Бәрәч, кунак бар икән,—диде.

—Мин Өчиле Гыйльфаны булам. «Кучер Гыйльфан» дип йөртәләр, ие...

—Табын янына узыгыз!—диде хуҗабикә.

Ата белән бала аралыктан чыккач, Кучер Гыйльфан да кулын сөннәтләп алды. Утырыштылар.

Вәли абзый:

—Бисмилләһ ир-рахмән ир-рахим,—дип бәлеш өстен кисте.

Сарык ите, борай һәм мул итеп әнис салынган бәлеш исе өй эченә таралды.

—Житешегез!—диде хужа.

Газизә бикә мич белән табын арасында йөренә, ирен, баласын, кунакны сыйлый.

—Аллага шөкер, бездә ризык житәрлек...—диде Газизә ана.

—Әти!—диде Апуш.

—Әү, балам!—диде Вәли.

—Беләсеңме син кемгә охшагансың? Хозыр Ильяска!

Ир белән хатын, Кучер Гыйльфан бер-берсенә карашып алдылар. Бу карашу баланың зиһенле булуына куану билгесе иде.

—Синең Хозыр Ильясны күргәнең бармыни?—диде хужабай.

—Бар!—диде Апуш:—Төшемдә гел күрәм. Әни белән бабам сөйлиләр иде... Әнием, син фәрештәгә охшагансың, минем Мәмдүдә анама бик нык охшагансың.

—Әйе!—диде Кучер Гыйльфан.—Мин дә сине күрүемә: бу Биби Мәмдүдә, дип кычкыра яздым.

—Аллага шөкер. Сөбханалла, машалла!—диде Газизә ана.

## Шаһрияр

Бу гаиләгә килгәч, Апушның хәле бик яхшырды. Ул үзе әйтмешли: Шаһрияр кеби затлы киенә, татлы ашый, тәмләп йоклый. Иң матур чигешле түбәтәй—Апуш башында, иң матур якалары чигешле күлмәк Апуш иңендә. Ул туйганчы ашый, туйганчы уйный, атасы белән анасы аны чиксез сөя. Ул дөнья җәннәтенә килеп эләккән иде. Аның анасы Газизә бикә түбәтәйләр, кәләпүшләр чигә, шул кәләпүшләрне атасы Мөхәммәд Вәли базарга чыгарып сата. Эштән бушаган араларда анасы Газизә аны укырга-язарга өйрәтә башлады.

—Бу нинди хәреф, Габдуллаҗан?

—Әлиф!

—Дөрес! Әлиф! Хәзер язып күрсәт, ничек языла ул әлиф.

Габдуллаҗан телен чыгарып әлиф яза.

—Машалла!—дип мактый анасы.—Бу нинди хәреф?

—Лям!—диде Апуш.

—Машалла. Менә бу сүзне укырга кирәк. Монда дүрт хәреф бар, аларның барысы да сиңа таныш. Укы!

—Ал—ла!—диде сабый.

—Сөбханалла машалла!—диде ана кеше Апушның башын сыйпап.

Шулчак урам яктан малайлар тавышы ишетелде.

—А-апуш! Уйнарга чык! Кузналы уйныйбыз.

—Әй, шилмалар!—диде Газизә тәрәзәне ачып:—Габдуллаҗан сабак укый. Сабагын бетергәч чыгар.

Ана янә улы янына килде:

—Менә бу китап битендә ничә «Алла» сүзе бар?

—Бер, ике... сигез...

—Машалла! Ә хәзер әлеп, би, ти, сине сөйләп бир.

Апуш бөтен хәрефләрне дә дөрес әйтте.

—Машалла!—диде ана.—Хәзер уйнарга чыга аласың, олан.

Апуш куанычыннан сикереп куйды:

—Олан, олан олама,
Сәләмә дә алама..
Сәлимә дә сәләмә,
Оланы да алама.
Усагы да карама,
Карамасы замана,
Заманасы алама.

—Шаян син, Габдуллаҗан!—диде Газизә ана.—Малайлар өйрәттеме?
—Юк!—диде Апуш.—Үзем чыгардым!
—Бар инде, бар, дусларың көтәдер.
—Очтым, әни!
Урамда аны Сабит, Габит, Гафур көтә иде.
—Апуш та чыкты!—диде Сабит дигәне.—Апуш, әйдә кузна уйнарга.
Апуш такмакларга тотынды:

Әйдә кузна уйнарга.
Байлык җыям туйларга.
Туйда булыр куй-бәрән,
Кузнам сезләргә әрәм.

—Машалла, Апуш!—диде Гафур.
—Тагын такмак чыгар әле !—диде Габит.
—Юк!—диде Сабит.—Киттек уйнарга, такмак соңыннан.
Сабит алдан йөгерде, калганнары аны куа китте. Такыр җиргә җиткәч, алар кузналарын тезеп куйды.
Һавага акча чөйделәр. Шобагада беренче ату Гафурга чыкты.
Бу уенда да Апуш бөтен кузналарын оттырып бетерде.
Габдуллаҗан оттыруын бик авыр кичерде. Ул өйгә кайтты да ашамыйча-эчмичә йокларга да ятты. Атасы белән анасы аның кәефе юклыгын күреп: «Ни булды, нигә кәефең китте, әллә берәрсе кыерсыттымы?» дип сораштырмадылар. Андый чакта Апуш төпченгәнне яратмый, киреләнә башлый.
Ата белән ана Апушның кайчан отканын, кайчан оттырганын сорашмыйча да белә торган булып киттеләр. Оттырган көнне ул ашамыйча йокларга ята. Откан көнне айга сикерә, кузналарын саный, аларны яшереп куя да:
—Әни, ашыйсым килә-ә!—дип кычкыра.

## Куркыныч төш

Икенче көнне иртәнге якта Апуш әле һаман уянмаган иде. Ата белән ана йокыдагы сабыйга карап туялмыйлар иде.
—Атасы,—дип пышылдады Газизә ана.—Габдуллаҗан бөтен хәрефләрне дә укый-яза белә.
—Машалла!—диде ата.—Ул башкавитый малай булып чыкты.
—Уятырга кызганыч,—диде ана.
—Уятмыйк, ул кичә нык аргандыр.
—Армыйча, көне буе йөгерә-уйный...
Ана кеше ирен икенче якка алып чыкты да:
—Атасы, Габдуллаҗанның уң күзендәге кызыллык һаман бетми, аның ул күзе һаман яшьләнә. Нишлик икән?—диде.

—Уйнаганда тузан да керә торгандыр, күзе төзәлмәс борын без аны чыгармыйча тотыйк, өйдә утырсын.

Ана белән ата: уянгач ашар, дип, анын өлешен өстәлгә куеп, аяк очларына гына басып чыгып киттеләр.

Апушның йокысы йокы булмады, ул борсалана, йокы аралаш ыңгырашып куя, башын әле бу якка, әле икенче якка боргалый, бәргәләнә.

Ата белән ана ишегалдындагы эшләрен бетереп, өйгә кергәннәр иде.

Бу юлы да ул төшендә артыннан кабан дунгызы куганны күрде. Кабан дунгызы сөзде дигәндә генә Габдуллаҗан кычкырып уянып китте.

—А-а-а, әни-ии...

Газизә улы янына атылып килде дә, куркып уянган баланы күкрәгенә кысты.

—Ни булды, улым?—диде ана ачынып.

Атасы да ярдәмгә атылды:

—Улым, сине кем куркытты?—дип сорады.—Тынычлан, балам.

Апуш анасы кочагын ташлап чыгарга теләмичә, байтак сыенып утырды. Анасы Апушны күтәреп, ишекле-түрле йөри башлады. Бала тынычланды, әнисе кочагыннан төште.

—Ни булды, улым?—дип сорады Газизә.

—Күзем эренләп каткан!—диде бала.

Газизә Апушны сәке йөзлегенә утыртты да күзенә бакты:

—У-у, эренләгән шул,—диде.

—Анасы,—диде Вәли:—Җылымса су әзерлә, көнбагыш мае белән майларбыз.

Газизә бүлмәчкә кереп китте.

—Хәзер йомшартабыз без аны,—дип юатты сабыйны ата кеше.

Газизә юынгычка җылы су салып, Апушны чакырды:

—Кил, балам, сак кына чылат, бармакларың белән каезлама!

Бераздан Апуш аралыктан чыкты, анасы анын уң күзен көнбагыш мае белән майлады. Майлы чүпрәген алмыйча, уң күзен бәйләп куйды.

Дәваланганнан соң өчесе дә өстәл янына утырып, юп-юка беленне сары майда йөздереп ашый башладылар, аннан соң сөтле чәйне кәрәзле бал белән эчтеләр. Аштан соң дога кылдылар.

—Әлхәмдүлиллә, әлләзи, әдгаманә вәсәканә вә җәгналәнә мин әл мөслимин... Аллаһу әкбәр!

—Хәзер без сине дәвачы әби янына алып барырбыз, улым,—диде әнисе.

—Бәлки докторга барырга кирәктер, анасы!—диде хуҗабай.

—Духтыр ни белә ул. Маһруй әби күпме кешене савыктырды.

Вәли хуҗанын шул карчыкка баланы бер дә җибәрәсе килмәсә дә, хатыны бик теләгәч, каршы килмәде. Ул аларны атка утыртып, Маһруй карчык яшәгән йортка китереп куйды да үз эшләре белән китеп тә барды.

Өшкерүче Маһруй карчыкнын өе кипкән үләннәр белән тулган. Диварлар да, киштәләр дә, шүрлекләр дә, кучкар да... Шул үләннәр арасында Маһруй карчык нидер кыла, укына, сөйләнә иде. Аңа аркасы да, күкрәге дә бөкре хатын ярдәм итә. Сәлам бирештеләр, сәлам алыштылар. Карчыкны күрүгә үк Апуш анасына сыенды.

—Чишендерегез!—диде карчык күкрәк тавышы белән.

Апуш анасынын итәгенә чытырдатып ябышты.

—Әни! Кирәкми-и!—дип җылый башлады.

—Курыкма, улым!—диде ана.


Маһруй карчык кечкенә җиз килегә кипкән үләннәр салып төя башлады, үзе мыгыр-мыгыр нидер укына.



*Кушлавыч авылының XX гасыр башында, Тукай исән вакыттагы күренеше.*



*Габдулла Тукайның Җаекта (Уральск) матбагада эшләгән вакытында төшкән фоторәсеме. 1905 ел.*



*Элеккеге «Шәрык клубы» бинасы (Татарстан урамы, 8 йорт.)*




*«Әлислах»—Тукай әсәрләре дөнья күргән басмаларның берсе.*



*Г. Тукай, Ф. Әмирхан. Икенче рәттә: Г. Коләхметов, К. Коләхметов.*



*Шагыйрьнең 1912 елда төшерелгән фоторәсеме.*




*Тукай кабере. Казан. Яңа Бистә.*

—Әнием, кирәкми-и,—дип сулкылдый бала.

—Аз гына авыртыр, түз!—диде әби.

Карчык бөкре хатынга ишарә итте:

—Баланы менә монда, аркасы белән ястыкка салыгыз!—дип боерды.

—Әни-и...—дип кычкырды Апуш.

Әлеге бөкре хатын Апушны кәҗә тиресен сәкегә җәйгән кебек ботын-чатын аерып, аркасына яткызды. Маһруй карчык Апушка менеп атланды:

—Нык тотыгыз, кыймылдамасын!

Бер кулының ике бармагы белән Апушның күзен ачып, икенче кулы белән калактагы измәне уң күзгә сылады. Бала йөрәк яргыч аваз белән кычкырды.

—Әни, авырта-а, күземне энәләр чәнчи-и...

Әпчи карчык Апушның ике күзен дә чүпрәк белән бәйләп куйды.

—Бүген күзен ачмагыз!—диде эшлекле карчык.

Аларны Вәли хуҗа ат белән килеп алды, Габдуллаҗан юл буе акырып ярсып җылап кайтты. Өйгә кергәч тә ул акыруыннан туктамады, аның тавышы карлыккан, хырылдап кына чыга иде.

—Әти, әтием, авырта-а, зинһар, күземне ачыгыз, энәләр чәнчи... үләм мин, ачыгыз күземне... Күзем агып чыга бит инде...

Ата кеше курка калды. Ул шелтә белән хатынына бакты:

—Менә синең өшкерүче убырлың баланы нишләткән!—диде.

Вәли каударлы иде:

—Мин ат җигәм, син баланы юрганга төр! Тиз бул!—дип кычкырды хуҗа.

Урам буйлап ыргып ат чаба, арбада Вәли атын чыбыркылый. Арбага Газизә белән Габдуллаҗан утырган, Габдулла һаман ыңгыраша, аның кычкырырга көче, тавышы калмаган. Ат бер капка төбенә килеп туктады, Вәли сикереп төшеп, хатыны кулыннан баланы алып капкага килде:

—Ачыгыз, зинһар! Ярдәм итегез!—дип кычкырды.—Памагите-е! Ребенок умират бит!

Болдырда ут кабынды. Кемдер йөгереп чыкты, капка ачты, Вәли йортка кереп китте. Аларга Газизә дә иярде.

Бу доктор йорты иде. Өйдәгеләр барысы да аякта. Доктор үзе дә каударлана:

—Менә монда яткызыгыз!—диде доктор.—Ни булган?—дип сорады доктор татарча.

Вәли әйтте:

—Теге әпчи Маһруе аның күзенә нидер салган!—диде.

Доктор Апуш күзендәге чүпрәкне чиште.

—Флакончик, четвертый слева! И вату, пожалуйста!—диде доктор яшь кызга.

Кыз кечкенә шешә белән мамык алып килеп, докторга бирде. Доктор Апушның күзен даруга манчылган мамык белән кат-кат чистартты.

—Спирт!—диде доктор.

Кыз аңа спирт шешәсе сузды. Доктор ике кулын да спиртлап юды да Апушның авыру күзен ачып, телен күз кабагы астына тыкты. Өстеннән дә астыннан да сак кына телен йөртеп, теленә эләккән вак чүпләрне төкерде, телен юды да тагын күзгә кереп китте. Шулай кат-кат күзен чистартты, бала тынычлана төште, сулкылдавыннан туктады. Доктор янә теге дару белән авыру күзне кат-кат сөртте.

—Марлю!—диде доктор.

Кыз марляны докторга сузды. Доктор Апушның сул күзен калдырып,

авыру күзен бәйләп куйды.

Доктор иркен сулап куйды да, урындыкка утырды.

—Ахмак карчык!—диде доктор.—Ул төйгән үләннәрен вак иләк белән иләмәгән...

Апуш тәмам тынычланды.

—Йә, герой, ничек?—дип шаяртып алды доктор.—Энә чәнчемиме?

Апуш зәгыйфь кенә елмайды. Аннан Апуш тыныч сулап йокыга китте.

—Алып китәргә буламы?—диде ата кеше.

—Ярамый!—диде доктор.—Борчымагыз аны. Ул көне буе жылап талчыккан. Йоклый алганда ул йокларга тиеш... Таң атканчы ул шушында йокласын, аннан алып китәрсез, бәйләвен өч көннән соң алырсыз... Көндез түгел, кичен алыгыз, яктылыкка аз-азлап күнексен.

Доктор Вәлине читкәрәк алып, әйтте:

—Хәзергә куркыныч юк, ләкин... сез барысына да әзер булырга тиеш, Вәли әфәнде... Улыгызның күзе электән үк зыян күргән булса кирәк. Карчык аның авыруын көчәйткән...

—Әйе, баланың күзенә көл сипкән булганнар...—диде Вәли.

—Күрәсең, көл белән күзгә металл тузаны да кергәндер,—диде доктор.

—Рәхмәт сезгә, доктор, балабызны коточкыч сызланудан коткардыгыз.

Ата белән ана таң атканчы сырхау бала янында утырып чыкты. Таң атып, бала уянгач кына докторның гаиләсенә бер каклаган каз калдырып, рәхмәтләр әйтеп кайтып киттеләр.

## Хәерчегә җил каршы

Апушның күзе рәтләнде. Ләкин аның уң күзе зәгыйфьләнеп калды. Кояшка, ап-ак карга караса, авыру күз чагыла, яшьләнә башлый иде. Тора-бара аның уң күзенә ак төшә башлады. Анысына да күнекте Апуш, сызламасын, авырмасын гына.

Бу вакыйгадан соң бистәләрдә сүз таралды: имеш, әпчи карчык Мәһруй Мөхәммәд Вәлинең асрамага алган баласының күзен сукырайткан. Шулай итеп, Мәһруй карчыкка өшкертергә, дәваланырга йөрүчеләр сирәгәйде. Кереме кимегәч, Махруй карганып йөргән, имеш: шул кәләпүшче Вәлинең килмешәге аркасында гына бөлгенлеккә төштем, ачы каһәр суккыры, дип әйтә, ди.

Атасы белән анасы аның күзе зәгыйфьләнүен бик авыр кичерделәр. Газизә үзен бик тә гаепле саный иде. Ләкин Вәли хатынын бер тапкыр да битәрләмәде. Булган эш булган. Ул җәй, ул кыш шулай узып китте. Ата белән ана Апушны сөюдән туктамадылар. Ләкин ни хәл итәсең: Габдуллаҗан өстенә киләсе бәлаләр әле бетмәгән икән.

Мөхәммәт Вәли белән Газизә бикә йортына да үлем шаукымы кереп оялады. Бер-ике көн икесе дә сырхаулап йөрде дә урынга ятты. Апуш йөрмәс хәлгә җиткән атасы белән анасы яныннан китмичә карады, су кирәксә—су, дару кирәксә—дару биреп торды. Инде озакка сузылгач, караучы хатын чакырдылар.

Шом төшкән йорт капкасы төбенә күршеләре, танышлары җыелышкан. Берәр ярдәм кирәк булса, дип алар капка янында кизү тора.

—Бичаракайларым,—диде күрше хатыны Хәмидә.—Икесе берьюлы бит...

—Нинди чир басты соң боларны?—диде аның килене.

—Мөхәммәд Вәли белән Газизә бикә пыскып торган салкын көнне утынга барганнар, кайтканда алар өстенә боз яуган...

—Ике ай интегәләр инде...

—Барысы да Алла кулында... Бүген бар син, иртәгә юк.

—Аларга бер-бер хәл булса, сабыйны кая куярга, диген син...

—Тефү-тефү, Аллам сакласын!

—Тсс, духтыр чыга...

Капкадан кулына саквояж тоткан доктор чыкты.

—Гаспадин духтыр...—дип башлады күрше хатыны Хәмидә.—Хәл ничек анда?

—Газизә бикәнең хәле әйбәтрәк...—диде доктор.—Ну... Мөхәммәд... әфәнде... бәлки җиңеп чыгар...

Доктор тарантасына утырып китеп барды.

Газизәне ялланган бер хатын, Вәлине ялланган бер ир карап тора иде. Апуш ата-ана урынга ятканнан бирле урамга чыкмый, караучылар булса да, ата-анасының баш очыннан китмичә утыра. Караучыларга кирәк-ярак биреп тора. Бу фани дөньяда Мөхәммәд Вәли белән Газизә бикәнең савыгуын теләүчеләрдән иң ихласы, иң самимие Габдуллаҗан иде.

Ул олыларча фикерли, ата-анасы вафат булса яки берсе булса да үлеп китсә, ул нишләр, аңа тагын шушындый миһербанлы ата-ана туры килерме, әллә аны янә Өчилегә кайтарып ташларлармы?

Шундый авыр уйлар уйлап, ул ике авыру гәүдәсеннән ерак түгел сандык өстендә йоклап китте.

Апуш тагын төш күрде. Һаман бер төш. Бу юлы кабан дуңгызы куа башлагач, Апуш агачка менеп котылды. Кабан агач башындагы Апушка карап-карап торды да анасы Газизәне куа китте. Газизә юкка чыкты, кабан аның атасын куа башлады. Вәли камышлар арасына кереп югалды. Камышлар арасында кабан аның атасын сөзеп үтердеме, юкмы, кабан янадан Апуш утырган агач янына кайтты.

—Әти-и!—дип кычкырганына ул уянып китте.

—Габдуллаҗан!—дип караучы хатын Апушны кочаклады.

Бала тиргә баткан, бөтен гәүдәсе белән калтырый иде. Караучы хатын аны кочагында тирбәтә башлады. Апуш янә йоклап китте.

—Бичара бала!—диде караучы ир.

—Күрәсең, аңа гомере буе ятим булырга язган!—диде караучы хатын.

Шулчак Вәли хуҗа ютәлли башлады. Газизә бикә хәллерәк иде, ул калкынып, иренә бакты:

—Мендәрен ... калкыт!—диде хуҗабикә.—Аның утырасы килә!

Караучы ир Вәлинең баш астындагы мендәре урынына ястык куйды да авыруга ютәл даруы эчертте. Вәлинең бума ютәле бетте. Ул көчкә сулыш алып әйтте:

—Анасы!—диде.

Ул арада Апуш та күзен ачты, ләкин тормады.

—Сиңа чиләк кирәкме?—диде Газизә.

—Юк,—диде хаста.—Үзебез исән чакта... Габдуллаҗанны...

—Нишләтик соң аны?—диде зәгыйфь хатын.

—Әгәр ... икебез дә... китсәк, ул урамда калачак... Өчилегә хәбәр салырга кирәк... Зиннәтулла хәзрәткә... Теге кучерга әйтсен... Гыйльфанга... Килеп алсын...

Газизә бикә:

—Бәлки...—дип нидер әйтергә теләгән иде, аның сүзен Вәли кисте:— Ашыгырга кирәк, карчык.

—Сабрия!—диде Газизә.—Син Сабынчы Сәхигә барып, Өчиле кешесенә язу бирерсеңме?

—Таң атуга ук илтермен, абыстай,—диде каручы хатын.

Вәлинең хәле китте, анын башы кыегаеп, ястыкка ятты. Апуш сикереп торды да, атасының башын кочаклап, илаулый башлады:

—Үлмә, әти, зинһар, үлмә... Мине ташлап китмә, әтием... Аллаһу Тәгалә, атамны алма, ялварып сорыйм синнән. Мине тагын ятим итмә, зинһар. Мине әбиемә кайтармагыз, теләсә кемгә бирегез, тик анын янына гына кайтармагыз.

Апуш анасы янына килде:

—Әнием, мине анда кайтармагыз, анакаем...

Барысы да җылый иде.

Карауччы хатын Апушны анасыннан каерып алгандай алды да:

—Үскәнем, хасталарны борчыма!—дип читкә алып китте.

Бер атна үтәр-үтмәстән, өйгә Кучер Гыйльфан килеп керде. Хасталар янында утырып, хәлләрен сорашты. Мөхәммәд Вәли хуҗа телсез иде. Караучылар да, җегәрлерәк Газизә бикә дә хәлне аңлатып бирделәр.

—Берни кылыр хәл юк!—диде Гыйльфан Кучер.—Җыен, Габдуллаҗан! Газизә бикә караучы Сабриягә әйтте:

—Чормадан бер каз, ике таяк казы алып төш! Иске яулыгыма төреп, балага тапшыр,—диде.—Баланың киемнәрен дә төреп үзенә бир. Төсебез итеп кияр.

Өчиледә аны берәү дә көтеп тормый иде. Көтсәләр дә нәфрәт белән, ризасызлык белән генә көткәннәрдер. Сажидә генә аны кочаклап каршы алды. Теге җен кызларының барысы да матур киенгән, бераз үскән Апушка ашардай булып карап катканнар иде. Латифа бикә бер дә үзгәрмәгән, ул һаман кычкыра, ул һаман ирен битәрли, Апушны төрткәли. Кучер Гыйльфан:

—Менә бусы Мөхәммәд Вәлиләрдән куян күчтәнәче!—дип өстәлгә бер каз белән ике таяк казы кертеп куйгач кына гаиләдә тынлык урнашты, барысының да авызлары ерылды, хуҗа хатын да елмайгандай итте.

Атна эчендә куян күчтәнәчләре ашалып беткәч, гаиләдә тагын Апушка каршы фетнә купты, тагын акырыш, тагын кычкырыш башланды. Апуш артык кашыкка әйләнде. Хәер сорашып җыйган ризыклар ашалып беткәнче, өйдә гауга булмый торган иде. Азыклары төкәнүгә өйдә тагын давыл, тагын ризасызлык калка иде. Бу юлы да шулай булды. Казан күчтәнәчләре беткәч, Габдуллаҗанга көн бетте. Сажидә тутасы булмаса, Апуш бу җәбер-золымнарга түзәлмичә, әллә кайчан асылынып үлгән булыр иде, әстәгъфирулла.

## Тагын җәннәттә

Бәхетенә күрә, бу җәһәннәмдә ул озак тормады, аңа тагын ата-ана табылды. Аны Кырлай авылы кешесе Сәгъди абзый уллыкка алырга килгән иде. Сәгъди йортында аңа язмыш ни әзерләгәндер, нә мәгълүм, әмма ул Латифа бикә җәһәннәмендә тормас өчен әллә нинди сынауларга да әзер иде.

Апушны озатырга барысы да чыккан иде. Сажидә тутасыннан башка берсе дә күз яше чыгармады.

—Онытма безне, энем!—дип Сажидә басу капкасына чаклы арба аратасына ябышып барды.

Сәгъди абзый бик шат күңелле кеше иде, ахрысы. Ул Апушның аркасыннан сөя, аңа ягымлы сүзләр әйтә.

—Аллаһы боерса, улым, Кырлайга кайткач, анда сине анаң көтә. Анда сиңа катык, сөт-ипи мул булыр. Туйганчы ашарсың...

Кырлай авылы урман уртасында утыра иде. Йортлар монда төзек, салам

түбәләр сирәк, барысы да такта яки дранча белән капланган. Сәгъди абзый атын җилкапкага каршы туктатты, болдырдан бер хатын сикереп төшеп, капканы ачты, олау ишегалдына узды.

Сәгъди абыйның йорты нәкъ Мөхәммәд Вәлинеке кебек иде, тик монда сәке киңрәк тә, җиһазлар саранрак кебек. Өй җылы, пөхтә җыештырылган иде.

—Егетнең карыны ачкандыр!—диде Сәгъди елмаеп.

Апуш кыюсыз гына сәке йөзлегендә утыра. Аны хуҗабикә Зөһрә, аның өлкән кызы Сабира, кече кызы Саҗидә җентекләп тикшерә. Табын тирәли утырыштылар. Апушның алдына зур кисәк яңа пешкән ипи, бер савыт катык, тәти кашык китереп куйдылар. Сабый ашап бетерде дә тәгамга дога кылды.

—Әлхәмдүлилләһи әлләзи...

—Аның мәкаме матур!—диде Сабира.

—Сөбханалла!—диде Саҗидә.

—Рәхмәт, Алла сезгә тагын да мул ризык бирсен!—дип Апуш кузгалды.

Барысы да шатланган иде.

—Гыйлем бала бу !—диде Зөһрә бикә дә.

—Менә бу синең анаң Зөһрә бикә, монысы синең олы апаң Сабира, монысы кече апаң Саҗидә булыр!—диде хуҗабай.

—Саҗидә апа!—диде Апуш.—Минем Өчиледәге апам да Саҗидә исемле. Ул бик яхшы апа, миһербанлы апа.

—Мин дә яхшы апа булырмын!—диде Саҗидә.

Барысына да кызык булды.

—Әнием!—диде Апуш Зөһрәгә.

—Ни телисең?—диде Зөһрә бикә.

—Урамга чыксам ярыймы?

—Ярый!—диде ана кеше.

Зөһрә анасы тавышында Апуш ниндидер корылык, кырыслык ишетте кебек.

—Рәхмәт!—дип Апуш чыгып китте.

—Тәрбияле бала!—диде Сабира.

—Киемнәре матур!—диде Саҗидә.—Тик аның уң күзенә ак төшкән бугай.

—Башыбызга бәла алып килмәсә генә ярар иде бу үксез бала!—дип көрсенде хуҗабикә.

—Алдан ук юрап куйма, карчык, бәлане үзең чакырма!—диде хуҗабай.

### Чагыр[1]

Апушның өстендәге якасы чигешле матур күлмәк, башындагы түбәсе чуклы, чигешле түбәтәй, коңгырт атластан тегелгән чалбары, аягындагы базар оекбашы белән кигән чүәкләре дә Кырлай малайларының ушын алды. Авылга яңа малай килгәнлеге турында хәбәр тиз таралды. Апушның чыкканын малайлар капка төбендә көтеп тора иде.

Менә болдырда тәти малай күренде. Ул капкадан чыгуга малайлар кунакны урап алдылар. Арадан иң озыны әйтте:

—Сәлам, олан!—диде.

—Вәгаләйкүм әссәлам!—диде Апуш.

Озын:

—Исемең ничек синең, олан?—дип сорады.

[1] Сукыр, кылый.

—Габдуллажан!—диде кунак олан.—Габдулла яки Апуш кына дисәгез дә була!.. Ә синең исемең?—дип сорады Апуш.

—Сафиулла!..—диде озын.—Сафа!

—Без аны Сапи дип йөртәбез!—диде кыскарак малай, аннан әйтте:—Минем исемем Мөхәммәд Ахун. Яки Ахун гына.

—Мин Хәлил Рахман, Хәлил дип кенә эндәшсәң дә була.

—Минем исемем Торсынтай. Турсык кына диген.

—Синең түбәтәең шундый матур!—диде Ахун.

—Күлмәгең дә чигешле!—диде Сапи.

—Мондый чигешле чүәкләр бездә юк!—диде Хәлил.

—Казанда шулай киенәләр!—диде Апуш.

—Барысы дамы?—дип сорады Турсык.

—Күбесе!—диде Апуш.

—Казан зу-урдыр инде ул!—диде Ахун.

—Аш казаныннан чак кына зур!—диде Апуш.

Малайларга кызык булды, рәхәтләнеп көлделәр.

—Әйдәгез, качышлы уйныйбыз!—диде Сапи.

—Китте-ек!—дип малайлар дәррәү кузгалды.

Апуш Сапи белән янәшә йөгерде.

Алар авыл читендәге эригегә килеп җитте. Монда өсте каплаулы эриге, аннан ерак түгел генә амбарлар, келәтләр тезелешеп киткән. Мышнаган малайлар Сапи янына җыелды. Ул кесәсеннән бер уч санагыч таяклар чыгарды.

—Такта белән аркылы вәлүк табыгыз!—дип боерды Сапи.

Ике малай тиз генә такта белән нечкә генә йомры агач алып килеп, Сапи алдына ташладылар. Сапи тактаны йомры агачка аркылы салды, тактаның бер башы җиргә тиде, икенче башы күтәрелеп калды. Җиргә тигән башына Сапи таякчыкларны өеп куйды.

—Унике таякчык!—диде Сапи.—Качкан кеше йөгереп килеп, тактаның күтәрелгән башына тибеп, таякларны чәчә дә кача, көтүче шул таякларны җыеп, янә такта башына куя, тибүче качып өлгермәсә, көтүче «оттым» дип кычкырса, типкән кеше көтүче була. Аңладыңмы, Апуш?

—Аңладым!—диде кунак олан.

—Шобага салабыз!—диде Сапи.

Ул чалбар бавын чишеп алды да:

—Бауны учлап тотыгыз!—диде.

Барысы да бауны учлады:

—Иң астагы малай йодрыгын иң өстәгесенә куя. Аннан иң аста калганы өскә менә. Бауның очына барып җиткән кеше читкә китә, иң ахырда ялгыз калган йодрык иясе көтүче була. Башладык!

Йодрыклар аслы-өсле йөри башлады, иң ахырга Сапи үзе калды. Ул бавы белән чалбарын буып куйды да:

—Мин көтүче! Алтыга чаклы саныйм, качып өлгермәгән кеше көтүче була.

Сапи ике учы белән битен каплап амбарлар ягына карамыйча саный башлады:

—Бер... мин көтәм, качыгыз бер... ике... бу йөреш минеке... Өч... качкан җирдән оч... Дүрт... качучының янбашына төрт... Биш... качкан җирдән төш... А-алты-ы... Эзли чыгам каты-ы...

Ул алтыга санаганчы барысы да келәт-амбарлар арасына кереп качты. Габдулла каравылчы алачыгы артына посты. Аның анда качканын башка малайлар күрмәде, ахрысы. Күрше келәт артына качкан малайлар Габдулла турында сөйләшә иде.

—Ну, киемнәре, малай, кәртинкәмени!

Апуш тавышыннан Хәлилне таныды.

—Киеме шәп булса да бер күзе чагыр!

Монысын Турсык әйтте. Башына күсәк белән суктылармыни? Габдулла башта әңгерәеп торды, ул уенны онытты, аның күңеле ярсыды, аның кычкырасы, рәнҗеткән кешене тотып тукмыйсы, изәсе килде.

—Кая качканыгызны беләм!—дип сөйләнә-сөйләнә Сапи каравылчы алачыгына якынлаша иде. Алачык артыннан Апуш чыкты да йөгерде. Сапи аны күреп, аркылы тактага атылды, ул Габдулла тактага тибәргә йөгерә, дип уйлаган иде, Апуш тактага җитте, ләкин ул тактага типмәде, тактаны узып, авылга таба чапты. Сапи аптырады, ул арада малайлар качкан җирләреннән атылып чыгып, тактага типтеләр, таякчыклар һавага чөелде, аннан төрлесе төрле яка сибелеп, җиргә коелдылар. Сапи таякчыларны җыярга теләмәде.

—Ни булган ул Апушка?—диде ул.

Малайлар иннәрен сикерттеләр. Хәлил белән Турсык кына эшне аңлаган иде.

—Турсык...—диде Хәлил.

—Нәрсә—Турсык?—диде Сапи.

—Турсык «Апушның бер күзе чагыр» дигәнен Апуш ишеткәндер, ул безнең янга гына качкан булган икән.

—Түмәр Турсык-Бурсык!—дип Сапи каты итеп Турсыкның башына сукты.

—Җопар Сапый, Җопар Сапый!—Турсык җылый-җылый өенә кайтып китте, читкәрәк киткәч ул:

—Сапый, Папый, салам таптый!—дип такмаклый башлады.

Уенның рәте китте.

—Тагын берәрегез Апушны «кылый» дип үчекләсә, муеныгызны борырмын!—диде Сапи.

Таякчыкларын да җыймыйча, ул авылга таба йөгерде.

Өйдәгеләр Апушның озак кайтмаганына борчыла башлаган иде.

—Йа Аллам-Ходаем!—диде Сабира.—Суга гына бата күрмәсен!

Зөһрә әйтте:

—Башлана башлады! Бәладән башаяк!—диде.—Сабира, син елга буена, Сәҗидә, син урамны ура.

—Караңгы төшеп килә бит,—диде Сәҗидә.

Аксак Сәҗидә дә Апушны эзләргә алынды, ул да урамга чыкты.

Сапи Сәгъди абзыйның каралты-курасын карап чыкты, Апушны табалмады.

—Габдуллаҗа-ан, Габдулла-а, А-апуш!—дип кычкыра-кычкыра эзләде.

Сапи ындыр артына чыкты, шунда ул печән кибәне артында мышкылдаган тавыш ишетте. Якынрак килгәч күрде: Апуш кибән белән читән арасына утырган, җылый-җылый шешенеп беткән иде.

—А-апуш!—диде Сапи... Аллага шөкер, табылдың...

Сафиулла яна дустының иңенә олы кулын куйды:

—Син шул түмәрнең түмәр сүзенә үпкәләдеңме?.. Мин аны акылга утырттым инде. Җылый-җылый кайтып китте... Исең киткән... Син аның үзенә «Чатан» диген, аның үчеге Чатан. Син ул йолкышларның сүзенә үпкәләмә!—диде Сафа.—Син аларның үзләрен үртә! Кыямга «Чулак» диген. Курыкма, мин аларга әйтеп куйдым инде. Тагын берәр сүз әйтсәгез Габдуллага, муеныгызны борырмын, дидем.

«Чагыр» сүзе аның тәне буйлап, миенә, зиһенենә барып җитте дә мәңге чыкмаслык булып, аның күңел түренә кереп урнашты.

—Әйдә,—диде Сапи.—Киттек су буена, битенне юарсың, өйдәгеләр синең җылаганынны сизмәсен.

Су буенда Апуш тынычланды, битен-кулын юды, Сапи яна дустын өйгә алып кайтып китте.

Урам капкасыннан Сабира, Сажидә кайтып керде. Сабира энесен кочаклап алды:

—Энем!—диде.

—Габдуллаҗан,—диде Сажидә.—Уф, сине югалттык бит, батып үләр дип курыктык. Табылдың, Аллага шөкер!

Өйгә керделәр. Сажидә ут кабызды. Сабира Апушка карап:

—Синең күзең кызарган, бала,—диде.—Сине кем кыерсытты, син җылагансың бугай.

—Йөгергәндә күземә черки керде, шул әчеттерде,—диде Апуш.

—Өстең тузан гына, кайда уйнадыгыз шулай?—диде Зөһрә бикә шелтәле тавыш белән.

—Без качышлы уйнадык эриге янында,—диде Сапи.

Икенче көнне дә Сәгъди абзыйның өенә Сафа килеп керде. Сафа Габдулладан җиде яшькә олы иде. Ләкин яшь аермасы алар арасына киртә булып түгел, күпер булып ятты. Наданрак Сапи укымышлы Габдуллага тартыла, чәндер, зәгыйфь Габдулла олы гәүдәле, көчле Сафага якыная иде. Алар дуслашып китте.

Шуннан соң гына Габдулла башкалар белән уйный башлады. Ләкин ул Турсыкка «Бурсык» та, «Чатан»да димәде, Кыямны да «Чулак» дип үртәмәде. Бер аягына аксаганына Турсык та, сулагай булганына Кыям да гаепле түгел бит.

Ләкин беренче тапкыр Габдуллага «Чагыр» дип әйткән Турсыкны ул дус итә алмады. Ул гел Апуш янында бөтерелә, аның дуслыгын яуламак була, әмма Габдулланың күнеле аңа эремәслек булып каткан иде.

Кырлай авылы Габдуллаҗанның күңелендә иң тирән эз калдырган авылдыр, мөгаен. Аның яңа атасы Сәгъдетдин белән яңа анасы Зөһрә, ике апасы Сабира белән Сажидәләр җуелмасылык булып хәтердә сакланачак.

Апуш бу юлы да ата-анасыннан уңды. Аның атасы сабыр, олпат, юкбарга тавыш чыгармас, каралты-курасын яхшы тота торган хәлле кеше иде. Анасы Зөһрә дә тормыш алып бара торган, булган хатын, апаларын әйткән дә юк, кышын бәйләү бәйләү, җәйләрен мал-туар карауда аларга чыккан кеше булмады.

Атасы Сәгъди абзый Габдуллаҗанны бик ярата, аны кыерсыттырмый. Ә менә анасы Зөһрә ире күрмәгәндә генә үги углын еш битәрли, тәпәләп тә ала, хәтта каты-каты кыйнаштыргалый да. Юкса, Габдулланың җәзага тартырлык яманлык та кылганы юк.

Сәгъди абзый курасында, имана жирендә эш кайный. Габдуллаҗан бәйрәм киемнәрен салып, эш киемнәрен киде. Сафиулла Габдуллаҗанны сөрелгән җирне тырмаларга өйрәтергә алынды. Сәгъди-хуҗа моңа шатланды гына:

—Өйрәнсен, кул арасына керә башлар,—диде.

Сәгъди абзыйның алашасын җигеп, алар басуга киттеләр. Арбага тимер тырма салынган. Жир башына килеп житкәч, Сапи атны тугарды. Арканга ике тырманы такты. Дилбегәне Апушка тоттырды.

—Апуш!—диде Сапи.—Син тырмага якын атлама, читтәнрәк йөре! Аягыңны имгәтә күрмә. Дилбегәнне тотып, яннан бар. Киттең!

Апуш дилбегәне тартып, атка чөнерде:

—Чу-у, на, алаша!—дип тә кычкырды.

Ат кузгалды, тырма йодрык-йодрык кантарларны ваклый башлады.

—Машалла, Апуш!—дип кычкырды Сапи.

Үзе арттарак калып бара.

—Җир башына җиткәч, атыңны кинәт борма!.. Тырмаң сөрелмәгән чирәмгә чыгып җиткәч кенә атны сул якка бор да, тырмалаган җиргә кермичә, тырмалмаган җирдән алып бар.

Чирәм җиргә тикле җиттеләр, Апуш Сапи әйткәнчә, сөрелмәгән җиргә чыккач кына атны сулга борды.

—Һәйдә, алаша!—дип кычкырды Апуш.

Сапи сөрелгән җир кырындагы чирәмгә утырып, Апуш эшләгәнне күзәтә.

—Яхшы, дустым! Машалла! Тагын ун тапкыр әйләнсәң, бер йөз егерме сутый тырмалаган буласың...

Апуш канәгать иде. Ул үзен җир хуҗасы, олы кеше итеп күзаллый иде.

—Җитте!—дип кычкырды Сапи.—Күрше ызанына кермә! Өйлә вакыты җитте. Тамак ялгарга вакыт.

Тырманы ычкындырып, атны янә арбага җигеп, ике егет авылга кайтып китте. Дилбегәне Апуш тоткан. Капкадан да атны Апуш үзе алып керде. Әлбәттә, арба күчәрен капка баганасына ничек орындырмаска икәнен Сапи өйрәтеп торды. Сапи Апушка атны да үзенә тугарттырды. Сапи әйтеп тора:

—Чөелдерекне чиш. Дилбегәңне ычкындыр. Терсәгеңә урап, чөеп бәйлә дә арбага сал. Аркалыкны чиш. Чөелдерекне чиш. Дуганы ал. Ыңгырчакны салдыр. Камытны салдыр. Дирбияләрне келәткә керт тә, атны печәнгә куш.

Кыр тузанын кояр өчен алар елгага төшеп, су коенып менде.

Өйдә бәйрәм иде. Табында яңа гына казаннан бушаткан яркалы-ярмалы бәрәңге, яшел суган, катык, мул туралган ипи. Табынга Сапи да чакырулы иде.

—Бисмилләһ ир-рахман ир-рәхим! Житешегез!—диде Сәгъди абзый.

—Йә, Сафиулла!—диде хуҗабай.—Минем малай ничек анда, булдырамы?

—Машалла, Сәгъди абзый! Жирне бетердек!—диде Сапи:—Мин аңа бер-ике тапкыр күрсәткән идем, калганын ул үзе башкарып чыкты.

Хуҗабай гаҗәпләнде:

—Шулай ук үземени?—диде.

—Валлаһи, Сәгъди абзый! Чынлап әйтәм, үзе башкарды.

Габдулла да, атасы да шат иде.

—Ярдәмче үсә, анасы!—диде Сәгъди.—Тәк шту, эшчене ныклап сыйла, анасы... Рәхмәт, Сафиулла... Рәхмәт Габдуллаҗан...

—Киләсе елга мин аны, Алла боерса,—диде Сапи,—җир сукаларга өйрәтәм әле...

—Машалла!—диде ата кеше.

Урам яктан балалар тавышы ишетелде:

—А-апуш! Чыгасыңмы-ы!—дип Хәлил кычкыра иде.

Тәрәзәне ачып, Сабира:

—Ашый әле ул, бераздан чыгар!—диде.

Шулчак Апуш чынаяктагы катыгын ашъяулыкка түкте.

—Кәкре кул!—дип ысылдады Зөһрә бикә. Аннан Апушның башына сукты.—Катыкны әрәм иттең.

Сәгъди дә, Сапи да баланы кызганып куйды.

—Ярар инде, карчык, ялгыш кына бит!—диде хуҗабай.

Тәгамга дога кылгач, Сапи белән Апуш урамга чыкты.

## Көчек

Аларны Хәлил белән Турсык көтеп тора иде.

—Сапи, Апуш,—диде Хәлил,—Турсыкның эте Муйнак балалады.

—Дүрт бала китерде...—диде Турсык.—Карыйсызмы!

—Карыйбыз!—диде Сапи.—Киттек!

Турсыклар каралтысына килеп життеләр. Лапас почмагындагы саламлыкта Муйнак дүрт баласын имезеп ята иде.

Көчекләрне күргәч, Апуш:

—Сөбханалла!—диде.

—Матур көчекләр!—диде Сапи.—Икесе кара, өченчесе чуар, дүртенчесе ак икән.

—Ике көчекне күрше авылдан килеп алачаклар,—диде Турсык.—Сайлагыз!

—Миңа ак көчек ошый!—диде Апуш.

—Мин карасын алам!—диде Сапи.

—Алар әлегә сукыр, күзләре ачылгач алырсыз!—диде эт хуҗасы.

Күзләре ачылгач, ике көчекне күрше авылга алып киттеләр, калган икесен Сапи белән Апуш алды. Габдуллаҗанның башы күккә тигән, үзенә тигән көчекне куенына кысып, ул атылып кайтты. Ул сөенечен өйдәгеләргә дә җиткермәкче булды:

—Әни, әти, апаларым, менә минем нинди матур көчегем бар!

—Матур көчек!—диде Сәгъди.

Анасы:

—Үзең ашыйсы ипиеңне шул эткә сала барырсың, миндә артык ипи юк!—дип кычкырды.

Атасы яклашмаган булса, Зөһрә хатын Апушны тукмап ташлый иде, көчекне типкәләп урамга куа иде.

—Калсын!—диде атасы сабыр гына.

—Нигә ул рөхсәт сорамыйчан көчекләр ташый!—дип кычкырды хуҗабикә.—Кире илтеп ташла шул хәшәрәтне.

Апуш боек кына көчеген кочаклаган килеш чыгарга борылды.

—Калсын көчек!—диде хуҗабай сабыр гына.—Сабый балага бер юаныч булыр. Ашарга житәр аңа, барыбер күрше этләре казларга салганны ашап чыгып китә...

Хатын:

—Ух!—дигән тавыш чыгарды, бу аның Апуштан да, иреннән дә риза түгеллеген аңлата торган аваз иде, ахрысы.

—Син, хатын,—диде хуҗабай.—Көчеккә сөт салып бир.

—Сөт-сөт!—диде Зөһрә хатын.

Шулай да ире кушканны үтәде, ул тәлинкәгә сөт салып, бусага янына куйды. Апуш көчекне сөткә кушты. Көчек кып-кызыл теле белән сөт чәпелдәтә башлады.

—Исеме ничек була инде бу бурзайның?—дип шаяртты хуҗабай.

—Акбай!—диде Апуш.—Сапи абый кара көчекне алды, ул аңа Карабай исеме кушты.

—Барысы да тәртиптә булсын, без аңа исем кушыйк.

Сәгъди абзый дога укыды да, көчек колагына өч тапкыр «Акбай» дип кычкырды.

Ак эт ишегалдында калды. Габдуллаҗанның башы күккә тиде, шуннан соң ул атасын тагын да ныграк ярата башлады. Көчек Габдулланың өйдән чыкканын көтеп ята. Кечкенә хуҗасы чыккач, үрле-кырлы сикерә, уйный, мәтәлчек ата. Көчек тә, Габдулла да бәхетле иде.

Көчек әкияттәге кебек, ай үсәсен көн үсеп, маһмай булып житеште. Апушның йомышлардан бушаган вакыты гел Акбай белән уза торды. Беркөнне Апуш Акбае хөрмәтенә такмак чыгарды.

Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

Акбай, һай, акбабай, син бик ялкау, Акбай, акбабай.
Син хөрәсән, салабай. Ялкаулану ярамай-ярамай!

Апуш белән Акбайның уйнаганын Сәгъди абзый күптәннән карап тора иде.

—Машалла, улым!—диде ата.—Син кемнән өйрәндең шулай такмакларга? Әллә үзең уйлап чыгарасыңмы син ул такмакларны?

—Уйламыйм мин, әти, үзеннән-үзе телгә төшә ул сүзләр.

—Кызык.

Апуш тагын эте белән уйнарга тотынды.

—Хәзер маһмай сөйли!—диде Апуш.

Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.
Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә.

Хәзер мин сөйлим:

Аһ, жүләр мәэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач жайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар—эш белү уңайсыз ул!

—Сөбханалла, Габдуллажан!—диде ата кеше:—Син укырга тиеш! Мин сине башта абыстайга йөртермен, аннан соң мулланың үзенә тапшырырмын!

Өйдән хужабикә тавышы ишетелде.

—Ни такылдыйсыз анда?

—Без такылдамыйбыз, анасы, без шигырь сөйлибез!

—Нинди шигырь-мигыр ул тагын? Атасы, утын яр, ә син, Габдулла, ярган утыннарны өйгә ташы.

Тагын бер кыш узып китте, тагын жәй килеп житте. Апуш жәйне көтеп алды. Кышын ул тунгак, аңа кышын томау төшә, ютәлли башлый. Жәй килсә, иң куанганы Апуштыр, мөгаен. Ул дуслары белән көне буе су коена, жиләк жыя, атасына булыша.

Кырлай мунчаларыннан төтен чыга. Сабан туе алдыннан мунча якканнар. Бала-чага су буенда. Кыз-кыркын читтәрәк, малайлар бирерәк су коеналар. Чыр-чу киләләр.

Апуш, Сапи, Турсык, Ахун, Хәлил аякләренә «сакал» чыкканчы коенып ярга чыктылар. Чишмәгә барып, туйганчы салкын су эчтеләр, янә ярга кайттылар да сузылышып яттылар. Апуш кына аягөсте басып калды. Ул тирә-якка карый, чишмә ягына, буа суына, урман тарафына бага. Үзе нидер сөйләнә.

—Ни мыгырдыйсың анда?—дип сорады Хәлил.

—Дога укый!—диде Ахун.—Габдуллаҗан мулла булырга жыена ул.

Барысы да көлде. Апуш житди иде. Ул салмак кына сөйли башлады:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шунар күрә сөям жаным-тәнем белән.

Истән чыкмас монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Сапи белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Малайлар сикерешеп тордылар, беренче Сапи аягына басты. Ул шаккаткан, кул чаба, Апушны кочаклап бөтерә. Калганнар да Апушны котлый:

—Машалла!—диде Сапи.—Сиңа кем өйрәтте?

—Үзем!—диде Апуш.

—Алдый!—диде Турсык.—Шигырьне шагыйрьләр генә чыгара аны!

—Димәк, мин—шагыйрь!—диде Апуш.

Малайларны тагын көлү буып алды.

—Каян килгән шагыйрь! —диде Турсык.

—Үләм, эчем катты!—дип кычкыра Ахун.—Берәрсе китаптан өйрәткәндер.

—Билләһи, үзем яңа гына уйлап чыгардым!—диде Апуш, аннан Сапига карап әйтте:

—Син дә миңа ышанмыйсыңмы?—диде.

—Ышанам!—диде Сапи.

—Алайса, син әнә сайрар кошлар турында да шигырь чыгарып кара!—диде Хәлил.

—Әллә кайчан чыгардым инде!—диде Апуш.

—Апуш күптәннән шигырьләр чыгара ул, кешеләргә генә әйтми,—диде Сапи.

Якында гына сандугач сайрый башлады, күке кычкырды. Апуш тагын сәер халәттә иде, ул иҗат итә иде.

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңлегезгә Аллаһ нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

Курыкмагыз—яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.

—Тагын, Апуш, тагын сөйлә!—дип кычкырды Сапи.

Башкалар да Апушны хупладылар.

—Безнең елга турында!—диде Ахун.

Апуш тамак кырып алды да әйтте:

—Кичәгенәк мин йокларга яткач, менә шушыны чыгардым.

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән,—юк янымда юлдашым.

Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага:
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.

Шуннан су анасы мине күрде, мин чаптым авылга.
Шунда куркып уяндым.
Барысы да көлә иде.
—Сөбханалла!—дип кычкырды Сапи.
—Машалла!—диде Ахун.
—Әйдәгез, су анасын тотабыз!—дип Сапи ярдан сикерде, башкалар да елгага чумды.

## Кайгы

Сабира апасының авыл егете Мортаза белән кичке уеннардан соң капка төбендә сөйләшеп торганнарын Апуш күргәләде. Таллыкта Апушны очраткач, Мортаза:

—Нихәл кайнеш?—дигән була.

—Мин сиңа кайнеш түгел, син дә миңа җизни түгел!—диде Апуш.—Менә апама өйлән, аннан никах укыт, аннан кияү мунчасына барырсыз, аннан кияү коймагы ашарсыз, менә шунда мин сиңа «җизни» диярмен, каенишең булырмын!

Тирә-яктагылар, малайлар да, кызлар да рәхәтләнеп көлделәр.

—Ай-һай, тел малайда!—диде Мортаза.

Бервакыт уеннан соң Сабираны озата кайткач, Мортаза әйтте:

—Менә, Сабиракай, сиңа миннән Сабан туе бүләге!—дип кызыл билле прәнник белән кечкенә кул көзгесе бирде.

Апуш койма артында аларның сөйләшкәнен тыңлап тора иде, түзмәде, такмак әйтте:

Кызлар суга барадыр
Басып чуер ташына;
Бер прәнник, ике канфит
Житә кызлар башына.

—Аһ, мөртәт бала!—диде Сабира.—Кеше сүзе тыңлап тору гөнаһ.

Апуш күңеле белән сизә, Сабира апасы белән Мортаза арасында нидер бар, алар көн саен кич күрешә. Икәүләп кенә уеннан аерылып урман ягына, болынга таба киткәннәрен ул әллә ничә тапкыр күреп калды. Ләкин бу турыда атасына да, анасына да әйтмәде. Мортаза абый аңа бик ошый иде. Аның җизни булуын Апуш бик тели иде.

Мортаза белән берничә авыл егетен солдатка алалар икән, дигән хәбәр таралгач, Сабираның йөзеннән шатлык качты. Сабира төннәрен мышык-мышык җылап чыга. Булачак киявенең солдатка китүе аның өчен олы кайгыдыр шул.

Чыннан да авылдан дүрт егетне солдатка алдылар. Мортаза да шулар белән китеп барды.

Иртәгә китәсе көнне алар соңгы тапкыр очрашты. Сабира тыйлыгып һаман җылый. Мортаза аны юата:

—Алла боерса, мин кайтырмын, никах укытырбыз... —ди Мортаза.

Мортаза киткәч, Сабира әллә нишләде. Табак-савыт юа башласа, кулыннан тәлинкәсе төшеп китә, урак ура башласа кулын кисә.

Көннәрдән бер көнне өйдә гауга купты. Зөһрә бикә Сабираны кыйнарга тотынды:

—Әйт, мәлгунь бала! Ни булды сиңа? Мортаза белән бер-бер эшегез булдымы?

Сабира үксеп җылый:

—Әни, башым авырта, кулым эшкә бармый!—дип илаулый кыз.

Зөһрә тагын сукмакчы иде, ике арага Сәгъди абзый керде.

—Анасы, сабыр!—диде ата кеше.

Зөһрә бикә уклавын сәкегә ташлап бүлмәчкә кереп китте.

Берничә ай узуга Мортазаның үлеме турында кара кәгазь килеп төште. Имеш, дары базлары шартлаган икән. Шуннан соң Сабира гел алмашынды. Кызу эш өсте булуга карамастан, ул урман-кырларга чыгып китә, анда максатсыз гына йөреп кайта. Өс-башын карамас, чәчен тарамас булды.

Имана жирендә арыш яхшы унды быел. Уракка төштеләр. Сәгъди гаиләсе кырда, уракта. Барысының да кулында урак уйный. Хатын-кызлар толымнарын башларына урап куйган, озын итәкләре бөрмәләргә кыстырылган. Апуш белән Сәгъди абзый башларына киез эшләпә кигән. Апуш атасы янында ура иде. Ул башкаларга караганда салмак, әкрен кыймылдый, урак белән бармагынны кисеп куюың бар. Уракчылар артыннан Сажидә учмаларны җыеп көлтә бәйли. Бер көлтә, ике көлтә, ун көлтә—чүмәлә хасил була. Чүмәләнең ин очына көлтә утыртыла. Мәчет манарасы кебек чүмәләләр кырда артканнан-арта бара. Зөһрә җене белән эшли, аның кулларына күз иярми. Сабира анасыннан да арттыра, ул шашкан кебек, башкалар хәл алырга туктаса да һаман ура да ура. Сул кулы белән арышны учмага җыя да, уң кулындагы урагы белән җәт кенә кырт итеп кисә. Анасы ярты басуга җиткәндә Сабира басу чыккан була инде. Кояш яндыра, иелеп эшләүдән башка кан бәрә. Бөтен тәннән тир ага. Кигәвеннәр, чебен-черки халкы кан эчәргә теләсәләр дә, җил-җил эшләгән кешеләрнең беләгенә куна алмый, кунса да житез хәрәкәт аларны юк итә.

Басу кырында арба тора, арбага салынган печәнне ат чемчи, ат тик кенә тора алмый, ул таптана, койрыгы белән кигәвеннәрне куа, үзе һаман печән кертләтә. Кайдадыр Акбай тычкан куа.

—Машалла!—диде атасы Апушка.—Эшкә өйрәнеп киләсең. Ял ит бераз.

Икесе дә чүмәлә күләгәсенә чөмәштеләр. Ата кеше чүлмәктән чәй агызып, Апушка сузды:

—Эч!—диде.

Ирләрнең эш ташлаганын күреп, Зөһрә кычкырды:

—Һәй, ник туктадыгыз! Кояш барында урып калырга кирәк. Янгыр килмәгәе.

—Хе-хе-хе, анаң һәрчак тавышлы, улым!—диде Сәгъди.—Ләкин ул явыз түгел.

—Беләм!—диде Апуш.

—Мин бик сөенәм синең барысын да анлаганыңа!.. Киттек...

Алар урыннан торган гына иде, басуда нидер булды. Ураклары ташлап, хатыннар йөгерешә.

—Ай, Ходаем!—дип кычкыралар.

Аксак Сажидә дә тыйтаклап чаба.

—Атасы!—дип кычкырды Зөһрә.—Атасы, Сабира, Сабира...

Килсәләр, Сабира туфракка яткан, күзе әйләнгән, авызында күбек, үзе нидер сөйләнә. Егылганда урагы кискән ахрысы, аның ике ботыннан шаулап кан ага. Сәгъди Сабираның башыннан яулыгын алып, яраны бәйләде.

—Улым тиз бул! Атны җик тә монда алып кил!—дип кычкырды ата.

Апуш атны җигеп, авыру янына алып килде. Акбай да шунда аяк астында бөтерелә иде.

Күрше ызандагы хатыннар да йөгереп килде. Кемдер Сабираның авызына су коя, кемдер аның тәнен уа, кемдер яулыгы белән Сабирага һава җилләтә.

Атасы Сабираны күтәреп арбага салды. Дилбегәне Апуш кулыннан алып, Сәгъди авылга чаптырды. Сабира юл буе нидер сөйли, сүзләрен аңлап булмый иде. «Мортаза, Мортаза җаным» дигәне генә аңлашыла. Арба артыннан Акбай чаба.

Өйне шом басты. Зөһрә илаулап җылый. Үзе туктаусыз Аллага ялвара.

—Илаһем, кызым Сабираны бу чирдән коткар...

Сабира бер торып йөри башлый, бер урынына ята да тын кала, аннан тагын:

—Мортаза! Мортаза җаным!—дип тәрәзәгә ташлана.

Апуш белән Сәҗидә сандык өстендәге ястык артына поскан.

—Илаһем, ялварып сорыйм, кызым Сабираны савыктыр...

—Житте, хатын!—дип кычкырды Сәгъди.—Юкса, Сабираны да, балаларны да куркытырсың. Тукта! Кояш кына суккандыр аны, иртәгә савыгыр!

—Бу зәхмәт!—диде хатын:—Бу ләгънәт! Бу каргыш! Сәҗидә дә гарипләнде, улыбыз Садретдин дә үлде. Менә хәзер Сабирам...

Сабира кинәт торды да тәрәзәгә ташланды, Сәгъди аны тотып өлгерде. Сабира көчле, аны тыеп торып булмый, ярдәмгә Зөһрә белән Сәҗидә килеп, Сабирага ябышты. Апуш ястыкка сеңеп бетте.

Сабира тынычланды, хәлсезләнде, бераздан ул йокыга китте. Барысы да җиңел сулап куйды. Апуш сандык артыннан чыкты.

Өйдәгеләрнең барысы да йокларга ятты. Кучкардагы лампа гына янып калды.

Тышта эт улый башлады. Шомлы тынлыкны тагын да шомландырып, эт тагын улады.

Сабира тын гына урыныннан торды, сак кына атлап өйдән чыгып китте.

Сабира яланаяк, эчке күлмәкчән генә, толымнары таралган, башында яулык юк... Ул җиңел атлый, әйтерсең лә ул авырмый, ниһаять, ул елга ярына килеп туктады да салмак тавыш белән җыр башлады:

*Җиләк җыям, җиләк җыям*
*Әниемә бүләккә...*

Җыр туктады, Сабира тыңлана башлады.

—Мортаза!—диде ул шат тавыш белән.—Мортаза, кая качтың, кил яныма...

Елганың яргы ягында аның күзенә Мортаза гәүдәсе күренде.

—Мин синең кайтасыңны белә идем, Мортаза...—дип кычкырды Сабира.

Теге яктан Мортаза җавап әйтте:

—Сабира-аа... Кил минем янга, чык бу якка-а...

Кыз шатланып көлде:

—Чыга-ам, Мортаза, синең янга чыг-ам... Каршы ал, тот мине-е...

Сабира йөгереп килеп ярдан суга ташланды. Ләкин ул өскә чыкмады, ул чумган урында бөрчек-бөрчек күбекләр генә калыкты.

Таяк-колга, багор тоткан кешеләр урядник әмерендә урманны айкап чыктылар.

—Өч көн урманны аркылы-буйлы урадык...—диде урядник:—Урманда юк!.. Димәк...

—Буада калды эш!—диде аксакал.

Башлары иелгән Апуш белән Сапи ярга утырдылар. Апуш җылый иде:

—Апам... Сабира апам...

—Шулай...—диде Сапи.—Сабира апа Мортаза абыйны озли чыккандыр ул... Ыстансага китмәдеме икән, никрутларны озаткан урынга... Шундадыр ул... Киттек ыстансага...

Алар торып басканнар иде, Сапи әйтте:

—Апуш, әнә тегендә ни ул?—диде.

—Кайда?

—Агач тамырлары янында... Ак...

Балаларның коты очты, бу суга баткан Сабираның мәете иде.

Сабираны җирләп кайтканнан соң, өйдәгеләр сүзсез генә утырдылар, Апуш баскычка чыгып чөмәште, эт тә аны бүген уйнарга чакырмады. Апушның кайгысы барысыныкына караганда да авыр иде. Хәзер үги әнисе бу кайгыларның үчен Апуштан алачак.

Чыннан да өй эчендә тавыш купты, Зөһрә бикә илаулып җылый-җылый такмаклый башлады:

—Үксез бала асраганчы үгез бозау асра! Үгез бозау асрасаң, авызын-борының май булыр! Тамагың тук, өстең бөтен булыр. Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр. Шул килмешәк бала килгәннән бирле өйнең юне китте.

—Хатын!—диде Сәгъди тыныч кына.

—Син аны һәрчак яклыйсың!—дип кычкырды Зөһрә.—Әйтерсең ул синең үз балаң!

—Әйе, ул безнең балабыз! Туктат җылавыңны!—дип кычкырды хуҗабай.

Апуш бакча артына чыгып китте дә, аулак урын табып җылый башлады.

Шуннан соң тагын бер ел яшәделәр. Кайгылар-хәсрәтләр узып китте. Йортка тагын шатлык инде. Зөһрә бикә бер олан алып кайтты. Йортка куаныч килде, әмма Апушка мәшәкать тә өстәлде. Яңа туган балага элек сабый чакта вафат булган Садретдиннең исемен куштылар. Апуш Садретдинне кимәле арбага салып, җәй буе тартып йөрергә мәҗбүр булды.

Садри тугач, Зөһрә ананың Апушка карата мөнәсәбәте тагын да кискенләште. Атасы аны һаман якын итә, иркәли. Ә менә Зөһрә Апушны бөтенләй сөймәс булды. Көне буе ул Апушка сүз катмый.

—Баланы җылатма, баланы ега күрмә, баланың күзенә кояш төшмәсен!—кебек боерыклардан башка ана үги баласы белән сөйләшми.

Үги ана белән үги бала бөтенләй чит-ят булып киттеләр.

## Катык

Кырлайдагы кебек тәмле, хуш исле җиләкне, Кырлай урманындагы кебек тәмле, сусыл балтырганны, Кырлай сыерларыныкы кебек куе, тәмле сөтне, шул майлы сөттән оетылган катыкны сезнең бер җирдә дә ашаганыгыз юктыр.

Эссе җәй көннәрендә әлсерәп, уйнап, чабып арып, ачыгып өйгә кайтып егыласың. Әниләр, апалар эштә, кайнар аш юк. Шулчак яшелчә бакчасына кереп, яшел суган кыякларын өзеп алып керәсең, кунага салып кыякларны турыйсың. Шүрлектән бер бөтен ипине аласың да, күкрәккә терәп, бисмилла әйтеп, теленне чыгарып, кибән башын кисеп аласың да, ашъяулыкка куясың. Карбазына төшәсең дә агач бадъянны тутырып сап-салкын катык алып чыгасың. Карбазының өстен каплап, капкач өстенә иске-москы ташлыйсың: карбазына җылы төшмәсен. Катыкны өйгә алып керәсең, туралган суганны катыкка салып, агач кашык белән бутыйсың, «бисмилла« әйтеп, авызны ипи белән дыңгычлап тутырасың да катык ашый башлыйсың.

Габдулла көн саен шулай өйлә ашын ашый. Сәгъди абзый йортында ипигә, катыкка кытлык юк. Оҗмах.

Көннәрдән бер көнне Габдулла уеннан ачыгып кайтты да, катык ашап утыра иде, ишек ачылып китте, бусаганы кыяр-кыймас атлап, бер хәерче килеп керде. Хәерче хатын кырык ямаулы бишмәт кигән, кулына ертык-портыклардан теккән юка букча тоткан. Малай катыкны ашап бетереп, дога укый башлаган иде. «Аллаһу әкбәр» дип догасын тәмамлауга хәерче салмак кына сәлам бирде:

—Әссәламе галәйкум!—диде.

—Вәгаләйкум әссәлам!—диде Габдулла, үзе эчтән уйлап куйды:—Капчыгы буш, сәлам бирергә дә хәле юк моның.

Хәер эстәүче бу хатын сүзсез тора. Габдулла ни кылырга белми иде.

—Хәлем юк, бусагагызда гына утырып ял итимче, тышта эссе,—диде хатын чак ишетелерлек итеп.

Габдулла катыктан бушаган савытын тотып, карбазына төшеп китте. Тиз генә әйләнеп керде. Ул катык белән тулы савытны сәкегә куеп, ипи кисеп, хатынны табын янына чакырды:

—Утыр, апа, аша!—диде малай.

Хатын бусагадан торып, сәке йөзлегенә якын килде. Үзе идәнгә тезләнеп, башын катык өстенә иеп, ипине мул кабып ашарга тотынды. Ашап туйгач, дога укыды, коелган ипи валчыкларын җыйнап, авызына капты. Рәхмәт әйтеп урыныннан торды. Ул арада Габдулла тиз генә тагын бер телем ипи кисеп, хатынның букчасына салды.

Шулчак хуҗа хатын Зөһрә җилтерәп кайтып керде. Өстәлдәге ипи кыерчыгын күреп, урагын атып бәрде дә, тотынды кычкырырга:

—Үксез бала! Әрәм тамак, үзеңнең тамагың тыгылганы җитмәгән, инде монда урам хәерчеләрен дә тыгындырып ятасыңмы? Монда Әндрәй казнасы бармы! Чагыр тәре!

Хәерче хатын эшне сизенеп, шым гына юк булды. Габдулла җене чыккан усал хатын белән бергә-бер торып калды. Ул сәкедәге ястыкларга поскан иде. Зөһрә бикә кече яктан уклау алып чыгып, Габдулланы ястыклар арасыннан тартып алып, кыйный башлады. Габдулла кычкырмады, җыламады да. Ул тешен кысып булса да түзде. Уклау аның йомшак җирендә күп биеде. Хатын хәле китеп йөзлеккә утырды, Габдулла чыгып ычкынды. Болдырга чыгуга ук аны Акбай каршы алды. Бәләкәй хуҗасының кулында ашарга берни дә юк иде. Габдулла бакчага чыкты, эт аңа иярде, бакча башындагы инеш ярына йөзтүбән ятып, ул үксеп җылый башлады. Үги ана суккан җирләр үтереп сызлый, Габдулла чалбарын бераз төшереп, уклау тигән урыннарга бакты, анда бармак юанлыгы сыр-сыр калку, кызыл урыннар кызыша иде. Габдулла янында көчеге нишләргә белми бөтерелә. Ул да хуҗасының хәлен аңлый иде, ахрысы, чиный, шыңшый иде.

Габдулла уң күт битенә утыра алмый иде. Ул сул ягына кырын ятты да, күз яшьләрен иреккә куйды. Карангы төшә башлады. Бакча башында атасының тавышы ишетелде:

—Габдулла-ау! Ашарга ка-айт!

Аңа Сажидә апасының тавышы килеп кушылды:

—Эне-ем! Кайда син?

Габдулла инешкә төшеп юынды. Күлмәк итәге белән битен-башын сөртте дә бакча сукмагы буйлап кайтып китте.

—Кайда йөрисең син, улым?—диде атасы.

—Кая югалдың төн алдыннан?—диде Сажидә апасы.

Габдулла:

—Су буенда!—диде дә табын янына утырды.

Умачлы ашның исе бик тәмле иде, ләкин Габдулланың авызыннан аш үтмәде. Анасы төксе генә караштыргалап, табын тирәли бөтерелә.

—Улым, сиңа бер-бер хәл булдымы әллә?—диде ата кеше.—Чирләмисеңдер бит?

—Юк!—диде Габдулла.—Су коенып арыдым!

Ләкин Габдулладагы үзгәреш ата кешенең күз карашыннан качып котыла алмады.

—Нишләп син туры гына утырмыйсың, улым? Сул ягына янтаеп утырасың бит.

—Уң янбашым белән агачтан егылдым!—диде Габдулла.

—Сакланып йөре, улым!—диде ата кеше.

Шуннан соң табын янында башка сүз булмады.

Сафа белән күгәрчен тотып алып кайткач та анасы Габдулланы кыйнады. Ул шул күгәрченнәрне кулга ияләштерергә уйлаган иде. Анасы чуманны ачып бар күгәрченнәрне дә очырткан.

Катык өчен уклау белән ярганына да түзәр ул, күгәрчен өчен чыбык белән сукканына да түзәр иде, түзәр иде... Ләкин үги әнисенең «чагыр тәре» дип әйтүе барлык җәзалардан да газаплырак иде. Ул абзарга чыгып, Акбаен кочаклап тагын җылады.

—Мин гаеплемени соң уң күзем сукырайганга?

Акбай бәләкәй хуҗасының хәлен бик яхшы аңлый, ләкин бичара эт ни кылсын соң? Шыңшый-шыңшый Апушның битен ялаудан башка берни эшли алмый ул?

Күзгә төшкән шушы ак, каһәр суккан ак гомере буена ияреп бара торган кимсенүе булырмы икәнни?

## Җофар

Кич утырганда атасы Сәгъди балаларына әкиятләр сөйли, татар халкының тарихы турында да әллә нинди кызыклы хәлләр турында бәян итә. Габдулла аның сөйләгәннәренә чын күңелдән ышана иде. Ут сүндереп, сәкегә тезелешеп яткач, Сәгъди абзый тагын шүрәлеләр, су аналары турында сөйләде.

—Әти!—диде Апуш.—Шүрәле ул ерткыч хайванмы? Әллә яхшымы?

Караңгыда Сәгъди абзыйның көлемсерәгәне ишетелде. Ата баласының катлаулы сораулар бирерлек зиһенле булуына куанды. Бу көлемсерәү куаныч галәмәте иде.

—Өчиле кешеләре шүрәле баласын кыйнап үтергәннәр бит,—дип өстәде бала.

—Ул шүрәле баласы гаепле бит, нигә ул кеше атына атланып, яндырганчы чаба?—диде ата кеше.—Ул Ардаш байның чабышкы аты бит, дөнья бәясе тора иде.

—Шүрәле баласы аның Ардаш байның чабышкые икәнен белмәгән бит,—диде сабый.—Башында нуктасы булмагач, хуҗасыз ат дип уйлаган...

Сәгъди абзый бераз дәшми торды, балага җавап эзли иде ул:

—Кыхым,—дип тамак кырды хуҗабай, аннан әйтте:—Хуҗасыз атны да йөгендергәнче кумыйлар, улым.

—Ярый, әти, шүрәле баласы гаепле ди, шул шуклыгы өчен нигә аны камчылар, таяклар белән ярырга, ул бит җан иясе.

—Менә анысы ярамас эш булган, улым... Шүрәленең күтен кычыткан белән әшпәрләргә иде дә, урманына җибәрергә иде... Әнә шул рәхимсезлекләре өчен Өчиле авылы каргалган бит инде.

—Әти,—диде Апуш.—Ни өчен Сафиулланы «Җопар Сапый», бабасын

«Җофарчы баба» дип йөрткәннәр ул?

—Җофарчы булганга!—диде ата.—Элек, хан заманнарында сулыкларда җофар күп булган, әле без үскәндә дә җофарлар күренә иде. Җофар ул гаҗәеп кыйммәтле җәнлек, аның тиресе дә, ите дә, койрык астындагы хуш исле бизе дә бик кыйммәт. Җофар мае дип хушбуй саталар иде. Элек ул алтыннан да кыйммәт йөргән. Шуңа күрә, җофарлар калмады да инде... Аулап бетерделәр...

Атасының гел бөртөрле тавыш белән сөйләгәненә Габдулла йоклап китте.

Йокы алдыннан булган бу сөйләшүдән соң байтак вакытлар узды. Габдулла хәтта «җофар» сүзен онытып бетерә язган иде инде, беркөнне каз бәбкәләре саклаганда Сапи, башка малайлар ишетмәсен, дигәндәй, Габдулланың колагына:

—Мин җофар күрдем,—диде.

—Кайда?—диде Габдулла.

—Тсс!—дип Сапи бармагын авызына китерде.—Кешегә әйтмә. Җофар ул бик кыйммәтле җәнлек, диләр.

—Кайда күрдең?—диде Габдулла.

Сапи алак-ялак карангалап алды да:

—Инеш урманнан агып чыга бит әле, шунда бер тугай бар...

Төш авышкач, бәбкәләрне чуман астына кертеп, алларына җим салып, Габдулла Сапига ияреп, ерак инешкә китте. Сапи куеныннан тегәр җептән үрелгән челтәр чыгарды.

—Нәрсә ул?—диде Габдулла.

—Җәтмә!—диде Сапи.

Тугайга килеп җитәрәк, Сапи кинәт иелде, Габдуллага да иелергә кушты. Габдулла Сапига елышып, тын алырга да кыймыйча, күңеле кытыкланып нидер көтә иде.

—Җофар ул ерактан күрә... Әйдә, әне теге куак артына посыйк...

Алар якындагы куак артына яшеренеп, буа кебек җыелып торган суга карадылар.

—Җофар оясына су астыннан керә, яши торган урынын ул су менмәслек биеккә казып кереп ясый. Аның оясында берничә бүлмә була, ризык бүлмәсе, йокы бүлмәсе, әбрәкәй бүлмәсе. Аннан соң төннек тишеге.

—Анысы нигә?—дип пышылдады Габдулла.

—Анысы керү-чыгу юлында бер-бер нәрсә булса, чыгып качар өчен икенче тишек... Тсс...

Сапи җиргә сеңде дә башын чак кына калкытып, суга бакты, Габдулла да шулай эшләде. Тугайдагы су тыныч, шул тыныч су өстеннән су икегә аерылып килә иде, Габдулла йөзеп баручы җәнлекне күреп алды. Җәнлекнең башы үрдәк борынына охшаган, күзләре су кумагыныкы кебек бәләкәй, чем-кара.

—Кара-кара,—диде Сапи.—Артыннан балалары килә...

Чыннан да, ана җофар артыннан кечкенә җофарчыклар йөзә иде. Кечкенә җофарчыкларны санап булмый, алар күбәү, алар артыннан тагы зуррак баш күренде.

—Монысы ата җофар, анасы алдан, атасы арттан балаларны саклый.

Ана җофар тал каршындагы уентыкка килеп җиткәч, кинәт чумды, аның кумакныкына охшаш озын койрыгы күренеп алды.

—Оясына кереп китте...—диде Сапи.

Аналары артыннан балалары, алардан соң ата җофар су астында юк булды.

—Хәзер алар чыкмый инде,—диде Сапи.

—Су астында шулай озак торалармы?

—Юк, алар өннәренә кереп йоклый, анда һава бар, аларның өне судан биеккә ясала.

Сапи сикереп торды.

—Хәзер кычкырып сөйләшсәк тә ярый,—диде Сапи.

Габдулла да аягүрә басты. Сапи җәтмәсен сүтеп, яр астына төшә башлады. Чалбарын салып суга керде.

—Нишлисең син, Сапи абый?—дип сорады Габдулла.

—Ау куям! Җофарларны тотарга! Кереп-чыгып йөри торган тишекне җәтмә белән каплыйм.

Ул ике казык табып, казыкларны таш белән кагып, шул казыкларга җәтмәне бәйләп, җофарларның чыгу тишеген җәтмә белән каплап куйды. Аннан соң судан чыгып, яр буйлап китте. Ул нидер эзли иде.

—Аларның икенче төннегә шушы тирәдә генә булырга тиеш... Менә таптым.

Ул янә суга кереп, икенче як ярда ята торган ике зур ташны алып төннек янына алып килде.

—Төннекләрен таш белән бастырып куйсаң, беркая китә алмаслар.

Сапи эшен бетереп, чалбарын киде.

—Киттек. Иртәгә килеп карарбыз, эләгерме җофарлар минем җәтмәгә? Җофар ите бик тәмле була икән ул, тиресе дә кыйммәт икән,—дип сөйләнеп кайтты Сапи.

Габдулла юл буе сүз әйтмәде. Таралыштылар. Габдулла төне буе йоклый алмады. Ул җофарларның җәтмәгә эләгеп һәлак булачаклары турында уйлап ятты, таң атар-атмаста ул тугайга йөгерде, төннекне бастырган ташларны алып атты, җәтмәне тартып алды... Юеш җепне сыгып, җилпеде дә биленә урады.

Кайтырга дип авыл ягына борылган иде, ул тугай суында йөзеп баручы җофарларны күреп алды, уртада алты нәни җофар йөзә иде.

Габдулла елмайды. Юлда кайтканда ана Сапи очрады.

—Нишләп үзең генә бардың, эләккәннәрме?—диде Сапи, Габдулла дәшмичә генә җәтмәне хуҗасына суздь.

—Юк! Эләкмәгәннәр! Мин төннектән ташларны алып ыргыттым, чыгышларыннан җәтмәне алдым,—диде Габдулла.

Сапи башта ачулангандый итте.

—Их, боздың эшне!—диде.

—Яшәсеннәр, Сапи абый, үрчесеннәр!—диде Габдулла.

Сапи җавап бирмәде, алар авылга бергә кайттылар.

## Үксез бала

Көзен бәрәңге алганда Сажидә апасы салкын тидереп урынга ятты. Бакчада анасы Зөһрә, атасы Сәгъди, Апуш—өч кенә эшче калды. Анасы казып тора, Апуш бәрәңгене капчыкларга тутыра, атасы базга ташый бара. Сукмак буенда кимәле арбада Садри йоклап ята. Әз генә йоклый да тагын уяна, уяна да кычкырып жыларга тотына, Апуш бәрәңгесен ташлап, аның янына атыла, тирбәтә, юата, көйли-җырлый, бала йокыга киткәч, янадан бәрәңге тутырырга тотына. Бала тагын уяна. Апуш бу юлы арба янына бармый, һаман бәрәңге чүпләвендә.

Зөһрә җене белән бәрәңге казый, үзе һаман сукрана:

—Сажидәсе дә эштән качар өчен генә чирлегә салыша!.. Монысы тагы... бала карый белми... җылатма баланы!

Апуш янә арба янында.

—Анасы,—диде Сәгъди абзый.—Сажидә чынлап чирли бугай ул. Аның тәне кызышкан, авызы коп-коры, ыңгырашып ята...

—Дөмекмәс әле, тирләгән килеш кар базыннан бозлы катык ашасаң шулай була ул...

Апуш баланы йоклаткач, жиргә чүгәләп ял итә иде.

—Әй!—дип кычкырды Зөһрә бикә.—Син нәрсә бүкән шикелле утырып торасың? Эшлә! Кояш баеганчы бетерергә... Өч көрәк белән казырга кирәк, ташлагыз капчыкларыгызны, кәржиннәрегезне! Өчәүләп казырбыз да бергәләп жыярбыз. Әй, килмешәк, кулына көрәк ал!

Апуш Сажидә апасының көрәген алып, казый башлады, аларга атасы да килеп кушылды. Өчәүләп казыйлар. Эш күзгә күренеп үрчи иде. Туфрак өстендә бәләк-бәләк кызыл бәрәңгеләр тәгәрәшеп ята. Егерме сутый бакчаның яртысына бәрәңге утыртып, яртысына киндер чәчкәннәр иде. Ходайның рәхмәте, бу ел бәрәңге дә, киндер дә бик унды. Бәрәңгенең вагы юк диярлек, киндер урман кебек шаулап үсте-өлгерде. Бәрәңгедән соң киндерне йолкыйсы бар.

Садри уянды, ләкин Апуш казуында булды, бала кычкырып жылый, Апуш жир казый. Берсе дә дәшми. Тиз-тиз бакча казыйлар. Садри сыны катып жылый башлагач, ана кычкырды:

—Баланың кендеге чыкканчы бар юат, әрәмтамак!

Көрәген сукмакка ташлап, Апуш бала янына килде дә, ду китереп арбаны бер тартып, бер этеп, тирбәтә башлады. Бала туктарга уйламый иде. Апуш арбаны бакча буйлап сөйрәп китте, бала туктамады, шуннан Апуш көйли башлады.

—Садертдинем, багалмам,
Куркыныч төш күрденме?
Жил-давылда йөрденме?
Жәһәннәмне күрденме?

Әлли-бәлли көйләрем,
Әкиятләр сөйләрем;
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Ни хикмәт! Садри жыр тыңлый-тыңлый йокыга китте.

Жир казылып бетте, киндер кишәрлегенә життеләр. Көрәкләрен ташлап, ата белән ана капчыкларга тутырып, бәрәңгене базга ташый башладылар. Апуш та ике кулына ике кәржин тотып, кул очыннан гына бәрәңге ташырга тотынды.

Икенче көнне киндерне дә йолкыдылар. Чүмәлә-чүмәлә итеп өеп куйдылар. Сажидә генә бу эшләргә катнаша алмады, аның авыруы көчәйгәннән-көчәя барып, кыз тәмам тормас хастага әверелде.

Кыш житте, маллар абзарларга керде, утын әзер, малларга печән житәрлек. Матур килде бу кыш. Кары да күп яуды, суыгы да таманча. Сәгъди абзыйның курасы тулы мал-туар, сыер, бозау, кышлау тана, сарыклар, ике ат. Шөкер, шөкер!

## Яңа хәлфә

Апуш быел мәдрәсәгә йөри башлады.

Урам буйлап балалар мәдрәсәгә бара, кайсысы букча аскан, кайсысы китап-дәфтәрен куенына кыстырган.

Апушны урамда, капка төбендә Сапи көтеп тора иде. Ул түземсез:

—А-апуш!—дип кычкырды.

Өй эченнән:

—Хәзер чыга-ам!—дигән тавыш ишетелде.

Кулына тоткан букчасын болгый-болгый Апуш чыкты. Алар икәүләп

тиз-тиз атлап киттеләр.

—Сонга калабыз!—диде Сапи.

Апуш олыларга охшатырга тырышып, әйтеп куйды:

—Хәбри хәлфәне аны әҗәл чакырырга җибәрергә кирәк!—диде.—Ул көн саен соңга калып килә... беркөнне сыерыбыз бозаулады, чүбен саклап тордым, диде. Икенчесендә эте Мутай анын кәвешен каядыр яшереп куйган булып чыкты.

Шулай сөйләшә-сөйләшә алар мәдрәсә капкасыннан кереп китте.

Мәдрәсә җылы, якты иде. Апуш әйткәнчә, хәлфә Хәбри килмәгән иде. Идәнгә палас җәелгән, һәр шәкерт алдында тәбәнәк өстәлчек тора. Анда рәмел такталары ята. Такта өстендә акбур кисәкләре. Алдан килгән балалар котыра, шаяра, куыша, бер-берсенең бишмәтенә сугып, тузан чыгара. Сапи белән Апуш керде. Керә-керешли Апуш букчасын үз өстәле янына ташлап, хәлфә Хәбринең ишек катындагы чөйдә эленеп торган чапанын киеп, таягын алды да калкулыкка менеп утырды. Хәлфә тавышына ошатып, Апуш:

—Ша!—дип кычкырды.

Шаяручы балалар шым калып, үз урыннарына барып утырдылар, Хәлфә урынында Апуш утырганын күргәч, егыла-егыла көлә башладылар.

—Жыен әтрәк-әләм!—дип кычкырды усал «хәлфә».—Сабакларыгызны әзерләдегезме?

Кулындагы чыбык белән Апуш кемнедер кыйнагандай итә.

—Хөрәсән! Таяк түгел ул, әлиф! Надан Гыймадинын надан малае Хәйрулла!

Шәкертләрне көлү шаукымы тотып алды, тәгәри-тәгәри көләләр.

Апуш аягына басып әйтте:

—Тик китә кайчакта кәйфең, хакимен булса ишәк,
Балаларга ят, мәхәббәтсез күсәк һәм килмешәк.

—Машалла! Сөбханалла!—дип ду килде сыйныф.

Аннан соң Апуш янә хәлфә кыяфәтен алып, урынына утырды да, күзен йомып, бер яктан икенче якка атынып, шигырь сөйли башлады:

—Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта: хәлфә булган имеш хайван!

Ишек катында кизү торучы Хәлил сызгырды. Шәкертләр урыннарына утырды. Апуш тиз генә чапанны салып, урынына элде, таягын почмакка сөяде дә үз урынына китте. Ишектән Хәбри хәлфә керде. Тунын салып кадакка элде, чапанын, фәсен киеп, кулына таягын алды да урынына менеп утырды.

—Җыен әтрәк-әләм! Сабакларыгызны әзерләдегезме?

Кемдер «пырх» итте.

—Габдуллаҗан!—диде хәлфә.—Ни өчен син узган дәрестә булмадың?

—Аның Сажидә апасы вафат булды, шуны җирләште ул көнне!—диде Сапи.

—Габдуллаҗанның теле юкмы?—диде кырыс хәлфә.

—Без апамны җирләдек ул көнне!—диде Апуш.

—Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун... Авыр туфрагы җинел булсын! Амин!.. Безем әлифбамызда ике «г» хәрефе бар, дидек. Узган дәресне ныгытабыз. Аның ике төрле әйтелеше бар. «г» гъайн, «г» айн... Языгыз!.. Габдуллаҗан, син ни өчен язмыйсың?

—Мин хәрефләрнең барысын да яза да укый да беләм,—диде Апуш.

—Язып күрсәт, алайса,—диде хәлфә.

Апуш рәмел тактасына акбур белән «айн», «гайн» хәрефләрен язды. Хәбри ирен кырыйлары белән генә мыскыллы елмайды да тактаны югары күтәрде:

—Балалар, Габдуллаҗан дөрес язганмы?—дип сорады хәлфә.

Балаларның кайсысы «дөрес», дип кычкырды, кайсылары «дөрес түгел» диде.

—Дөрес түгел!—диде хәлфә.—Хәзер Габдуллаҗан безгә ни язганын аңлатып бирә.

Габдулла шәкерт чатлатып:

—Беренче хәреф «гайн» өстендә нокта белән языла вә дә ки ул укылмый!—диде.—Икенче хәреф «айн», ноктасыз языла вә дә ки ул ачык итеп укыла. Мәсәлән, Габдуллаҗан язылса да, «Абдуллаҗан» булып укыла. «Гайн» авазсыз хәреф.

Хәбринең ачуы чыкты.

—Юк! Дөрес түгел!—дип кычкырды Хәбри хәлфә.—Габдуллаҗан дип укылырга тиеш. Алайса, ни өчен сине бөтен Кырлайда Габдуллаҗан диләр?

—Абдулла, Абдурахман, Абидулла булып укылырга тиеш,—диде Апуш.

—Каян килгән атаклы мөдәррис!—диде хәлфә.

—Мине Казанда өйрәттеләр,—диде Апуш.

—Сабан калагы син!—дип кычкырды хәлфә.—Укылмагач ни өчен соң ул языла?

Дәресханәгә мулла абзый килеп керде.

—Бу нинди тавыш?—дип сорады мулла абзый.

—Менә бу малай актыгы!—диде хәлфә.—Мине өйрәтә башлады.

—Ничек итеп ул сине өйрәтте?—дип сорады мулла.

—Ул әйтә каты «гайн» языла гына, укылмый, ди. Ул буш хәреф, авазсыз хәреф, ди.

Мулла абзый «һым» диде дә уйга калды, аннан соң әйтте:

—Балалар, тәнәфес, сез уйнап керегез!—диде.

Шәкертләр өерелешеп чыгып китте. Дәресханәдә хәлфә белән мулла гына калды.

—Хәбибрахман!—диде мулла.—Абдуллаҗан хаклы! Калын «г» укылмый. Ул авазсыз хәреф. Мин сине иртәрәк хәлфә иттем, ахрысы. Мин Сәгъдетдиндә берничә тапкыр дәстарханда булдым. Ие... Абдуллаҗан белән сөйләшкәләдем... ие... Ул ибтидаига имтихан тотардай белемле. Язуы да аның бик күркәм, бик матур, машалла! Хәбибрахман, иртәгәдән соң хәреф тану, хәреф язу дәресләрен Абдуллаҗан алып барыр. Син аннан азат.

Шуннан шәкертләр арасында мондый такмак таралды. Аны Апуш чыгарган, дип сөйләделәр.

Хәлфәмез Хәбрый, зур чалма урый,
Хәлфәмез надан—укымый калган;
Укыта ялган—аңла, дускаем.

Капкасы кыйшык, түбәсе тишек,
Ватык моржасы, тәрәзә-ишек;
Хәлфәсе кыйшык авыз, дускаем.

Бу такмакны көйгә салып, кичләрен урамнан үсмер егетләр җырлап уза. Уйнаганда да, тау шуганда да бала-чага шуны такмаклый. Ду килде халык. Хәбибрахман хәлфә шуннан соң нишләргә белми йөрде. Хәтта мулла абзыйны ул Апушның атасы Сәгъди янына барырга күндергән, имеш?

—Сәгъдетдин мелла!—дигән мулла. —Синең шук малаең бик яхшы шәкерт, бинибая... Мин Хәбибрахман мелла урынына аны хәлфә итеп

куйдым... Тик ул хәлфә турында такмаклар яза икән... Килешми, кем, Сәгъдетдин, килешми. Мөгаллим кешене, хәлфәне алай урам буйлап мыскылларга мотабигъ эш түгел.

—Хәзрәт!—диде йорт хуҗасы.—Аның язганын кулыннан таныганнармы соң?

—Кулыннан танымаганнар, ул аларны телдән чыгарып, башкаларга ятлата икән,—диде хәзрәт.

—Ихтимал, ул такмакларны Габдуллаҗан түгел, башкалар чыгарган булса?—диде Сәгъди.

—Андый такмакларны чыгарырдай истигъдатлы башка берәүне мин авылыбызда күрмим,—диде мулла.

—Шулай ук яхшымыни такмаклары, хәзрәт?—диде Сәгъди.

—Шулай шул, кем, Сәгъдетдин мелла,—диде мулла абзый.—Теле бик әче, мәдрәсәне дә хәрабәт итеп күрсәтә.

Хуҗа Сәгъди мулланы тынычландырып:

—Ярый, хәзрәт, мин аның белән каты гына сөйләшермен. Әгәр ул чыгарган такмак булса—чыбык, аныкы булмаса, прәнник ашатырмын,—дип озатып калды.

Әлбәттә, Сәгъди абзый ул такмакларны улы Апуш чыгарганын бик яхшы белә иде. Чыбык белән суктыру түгел, ул баласына тырнак белән дә чиртмәде.

Ләкин Зөһрә бикә хатыннардан хәлфәне мыскыллап чыгарган такмак ишетеп, ярсып кайтты да уклау алып, балага ташланды.

—Аһ, җүнсез килмешәк, мир алдында рисвай иттең. Хатыннар күземне дә ачырмый.

Апуш атасына барып аркаланды. Сәгъди абзый карчыгын тотып:

—Ташла, хатын!—дип кычкырды:—Аны Апуш чыгарганмы әле, юкмы? Тимә балага!

Хатын сабырланды. Уклавын кучкарга куеп, өйдән чыгып китте.

## Аерылышу

Сәгъди абзыйның йортына афәт артыннан афәт килә торды. Апуш килгәнче үк инде аларның бердәнбер угыллары вафат булган иде. Апуш килгәч, Сабира апасы да дөнья куйды. Аннан соң Саҗидә апасы чирләп үлде. Инде менә көтмәгәндә йорт башлыгы Сәгъди абзыйны да ат зәхмәте сукты. Аның бер кулы, бер аягы йөрмәс булды. Ат тугарып маташканда кинәт шулай күтәрәмгә калды атасы. Аны өйгә алып кереп сәкегә салдылар. Апуш атасы яныннан китмәде, сабакка да бармады.

—Әтием, син савыгырсың, Алла бирсә,—диде Апуш.—Һичшиксез, аягыңа басарсың...

—Рәхмәт, улым,—диде ата.—Гайфулла мулла сине хәлфә иткәнен ишеткәч, мин бик куандым, улым. Машалла! Мин сине алга таба да Казанга җибәреп укытырмын, Алла боерса.

—Әти!—диде Апуш тыңнанып.—Кемдер капка шакый.

—Бар, каршы ал, нинди кунак икән ул? Авыл кешесе капка шакып тормас.

Апуш йөгереп чыкты да, бер ят ир кеше ияртеп керде.

—Әссәламү галәйкүм!—диде ят ир.

—Вәгаләйкүм әссәлам!—диде Сәгъди.

Ят кеше:

—Йортыгызга фатиха,—дип ике учын күтәреп дога кылды.—Син, мөгаен, Сәгъдетдин абзыйдыр?

—Дөрес, мин Сәгъдетдин булам,—диде хуҗа.

—Хасталанып торасыңмы, Сәгъдетдин абзый?—диде юлаучы.

—Фалиҗ сукты уң ягымны!—диде хуҗабай.—Урманнан утын алып кайттым да... Атымны тугара идем... Ат зәхмәте китереп орды...

—Узар булсын!—диде юлчы.

—Амин!—диде хуҗа.

Ир кеше ниндидер карарга килеп, тирән сулыш алды да әйтте:

—Сәгъдетдин абзый... Мин бит сезнең кулдан бу ятим баланы алырга дип килдем.

Сәгъдинең йөрәге «жу» итеп куйды.

—Ничек? Кая, ничек алырга?—диде хаста.—Улым, бар ананны чакыр, тиз кайтып җитсен!

Апуш очты гына.

—Безнең артык балабыз юк, кем...—диде хуҗа.

—Минем исемем Бәдретдин, Сәгъди абзый,—диде чакырылмаган кунак.—Мин Кушлавыч кешесе... Казаннан Җаекка олау чабам... Безнең авыл мулласы Мөхәммәд Гарифның бертуган сеңлесе, ягъни Габдуллаҗанның тутасы Газизә бикә—Җаекның бик могтәбәр бае Галиәсгар Госмановның хатыны Габдуллаҗанны сездән алып, Җаекка алып килергә кушты.

Зөһрә бикә белән Апуш кайтып керде. Зөһрә бикә ярсыган, сәлам да бирмичә кычкыра башлады:

—Кая? Кемгә алып китәләр, кем алып китә безнең улыбызны?

Бәдретдин алда әйткәннәрен кабатлап чыкты. Ләкин Зөһрәне тыеп булмый иде:

—Ярар, менә без икмәкнең поты ун сум чагында аны өч ел ашатып торыйк та, хәзер эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрикме? Булмас!

Бәдретдин сабыр гына:

—Ул Габдуллаҗанның якын кардәше!—диде.

—Кардәше булгач, ник әүвәл аның ятим икәнен күрмәгән? Бала гаиләдән гаиләгә, авылдан авылга йөреп, безгә килеп матур гына яшәп ятканда әзер бала кирәк булдымы икәнни?.. Юк, мосафир, бездә кешегә бирерлек бала юк!

Габдуллаҗан аптырап калды. Моңарчы ачык чырай күрсәтмәгән анасы аны теше-тырнагы белән бирмәскә тырыша.

—Бездә артык бала юк!—дип тәкрарлады хуҗабикә.

Тарткалашу артыкка сузылгач, Бәдретдин кесәсеннән ике кәгазь чыгарды.

—Менә!—диде юлчы.—Бусы Галиәсгар байның хаты. Анда ачык язылган. Монысы исә урәтниктән язу. Сез не имеете права кеше баласын тотып торырга, мин урәтниккә барам, мин сезне пад суд җибәрә алам.

Зөһрә сүзе үтмәгәч, бәхәсләшү урынына алъяпкыч белән йөзен каплап җылый башлады.

—Кул арасына керә башлагач кына...

—Закун алар ягында, карчык,—диде Сәгъди абзый.

—Ярар, атасы,—диде хатын.—Кеше баласы безгә булмас, Алла сакласын, әлләниләр күрербез!—дип анасы Апушны киендерә башлады. Үзе киендерә, үзе чын күз яшьләре белән җылый.—Улым, безне онытма, җәме! Алай-болай булса, туры үзебезгә кайт! Энең Садри, атаң белән сине көтеп торырбыз.

—Ярар, әни!—диде Апуш.

Ул үги анасын кызганып куйды. Кыйнаса да, Зөһрә аны үзенчә яраткан, ләбаса!

Габдуллаҗанны капка төбендә кашуфкыга җигелгән ат көтеп тора иде.

Апуш сөекле этен кочаклап жылый башлады.

—Сау бул, Акбаем, бәхил бул!—ди үзе.

Кашуфкыга утыргач, ат кузгалды. Ләкин Бәдретдин атны чаптырмады. Аларны Зөһрә, Сапи, Хәлил, Ахун басу капкасына чаклы озата барды. Озатучыларга Акбай да ияргән иде.

—Улым, Габдуллаҗан, безне онытма!—диде Зөһрә бикә, үзе һаман жылый.

—Хат яз, Апуш!—диде Сапи.

—Сау калыгыз!—диде Апуш.

Ат юырта башлады. Озатучылар капка янында кул болгап калды. Кашуфкы артыннан Акбай чаба.

Сапи эткә кычкыра:

—Акбай, Акбай! Моһ-моһ!..

Апуш та аны кирегә куа:

—Акбай, кайтып кит, иярмә, Акбай, кайтып кит!

Ләкин хуҗасыннан аерылышасы килми, эт һаман кашуфкы артыннан теркелди. Бәдретдин атын туктатты да кашуфкасыннан төшеп, камчысы белән эткә кизәнде. Аннан юл кырындагы каты карны алып, эт тарафына ыргытты.

—Бар, өенә кайт!—дип кычкырды кучер.

Маэмай кызганыч чинап, кире китте дә, кашуфкыдан ераклашкач, хуҗасы ягына карап, артына утырды. Апуш Акбайның моңсу күзләрендә: бәләкәй хуҗам, нигә син мине ташлап китәсең, мине дә үзең белән ал, зинһар, дигән ялвару чаткысын күрде.

Апуш тыныч кына жылый иде. Кашуфкы кар бураны куптарып, алга ыргылды.

## Җайлы Җаек

Җаек шәһәрендә төп халык урыслар булып, алардан кала икенче урында татарлар санала. Җаек татарларының күп өлешен Арча, Саба якларыннан бирегә күчеп килгән гаиләләр тәшкил итә иде. Алар вак сәүдә белән шөгыльләнә, араларында хәтта миллионщиклар да бар. Урта хәлле, уртадан югарырак булып, аякларында нык басып торган байлар Җаек сәүдәсенең тотрыклы керемен бирүчеләр катлавын барлыкка китергән. Халыкның күбесе һөнәрчелек, тегүчелек, итек басу эшенә керешкән. Араларында кучерлар катлавы, ямь чабучылар, завод-фабрикаларда ялланып эшләүчеләр да бар.

Арча ягының Түбән Сәрдек авылында туып-үскән Галиәсгар бай Госманов әнә шул уртачадан баерак катлау вәкиле иде. Аның каралтыкурасы житеш: биек коймa белән әйләндерелгән, дүрт баганалы ырыс капка белән уратып алынган курада кара-каршы икешәр катлы ике таш йорт.

Галиәсгар бай Тукайның атасы белән бертуган апасы Газизәгә өйләнеп, аларның Зөһрә исемле кызлары белән Гобәйдулла исемле ир балалары туа. Хуҗабайның казакълар белән сәүдәсе бик уңышлы бара. Ул кайчакларда Казанга да, Оренбурга да олаулар йөртә. Көр тормышлы, киләчәгенә нык ышанган илле яшен тутырган ир заты иде ул Галиәсгар бай. Кура тулы мал-туар, ашарга-эчәргә мул, гаиләдә тигезлек, татулык иде.

Ләкин шушы камиллекнең чите әкрен-әкрен генә кителә башлады кебек. Күп чыгымнар белән, бөтен мөселман голәмәсен жыеп, атна буе туй ясап, олы кызы Зөһрәне ул кияүгә бирде. Әмма яшь гаилә ныгып китә алмады. Кызы кияүдән аерылып, атасы йортына кайтып төште. Галиәсгар абзыйга бу бик үк яхшы фал булмаса да, кызын ул битәрләмәде, авыр сүз әйтмәде.

Ул да булмады аның иң сөекле баласы, унбер яшьлек углы Гобәйдулла кинәт вафат булды.

Галиәсгар бай тырышып тапкан малын юкка әрәм-шәрәм итмәсә дә, зәкятен пөхтә аера, юксылларга ярдәм итә, иганә эшләренә дә буш кул белән бармый. Җае чыккан саен мул табын әзерләтеп, бәйрәмнәр ясый торган киң күңелле кеше иде. Углы үлеп киткәч, каралты-кура бушап калган төсле булып, Кушлавычта ачлы-туклы яшәп ятучы Мөхәммәд Гарифның беренче хатыныннан калган кызы Газизәне, Җаекка китертте. Газизә монда чиксез шатланып, җизнәсенә чиксез рәхмәтләр укыды.

Галиәсгар үзе ярдәм иткән мохтаҗлардан рәхмәт ишетер өчен генә яхшылык кыла кебек: бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди. Газизә җае чыккан саен, җизнәсенә рәхмәт укый, өй эшләрен җитез, пөхтә башкара, җизнәсе белән тутасы каршысында толымнары белән идән себерергә дә риза иде. Бу йортта аның өсте бөтен, тамагы тук, кайгысы юк.

Ләкин аерылып кайткан Зөһрә генә Газизәне колач җәеп каршы алмады. Беренче күрүгә үк бу ике хатын-кыз арасында, сәбәбен аңлатып бирә алмаслык, киеренкелек барлыкка килде. Ни әйтсәң дә Зөһрә үз атасы йортында, монда ул хуҗа. Ни әйтсәң дә Газизә—ул килмешәк фәкыйрь, бай хатынының туганнан туган сеңлесе генә.

Әмма олы Газизә белән кече Газизә бер-берсен бик якын итәләр, кечесе:

—Олы тутам!—дип, олы Газизә:

—Сеңелкәем!—дип кенә тора иде.

Галиәсгар бай да Газизә балдызын үз баласыдай кабул итте.

Шуңа күрә, усал Зөһрә ачыктан-ачык кече Газизәгә тел-теш тидерергә кыймый иде.

Көннәрдән беркөнне кече Газизә кич утырганда Габдуллаҗанның чит кешеләр кулында уллыкта яшәве турында апасына сөйләде. Олы Газизә озак кына уйланып утырганнан соң әйтте:

—Сеңлем!—диде.—Мин бу турыда җизнәң белән киңәш-табыш итәрмен.

Бер җаен табып, хуҗабикә Газизә иренә сак кына эндәште:

—Картым!—диде.—Казаннан Габдуллаҗанны чакыртып алыйкмы әллә? Ишек алдыбызда бер ир бала уйнап йөрсә, һәйбәт булыр иде. Абыемның баласы бит...

Галиәсгар бай ике дә уйлап тормастан әйтте:

—Чакыртырбыз, карчыгым!—диде.

Шулай итеп, бер-ике ай узуга Алты-Биш Сапый исемле күчер Габдуллаҗанны исән-сау алып килеп җиткезде дә, Галиәсгар байга тапшырды.

Ул көнне бай йортында бәйрәм ясадылар. Курада ир бала пәйда булды. Апалары Габдулланы җылый-җылый чишендерделәр. Унсигез көн, унсигез төн чанада тирбәлеп, арып беткән Габдулланы Алты-Биш Сапый мунчага алып китте. Мунчадан соң юлчы сабыйга мәрхүм Гобәйдулладан калган яхшы киемнәрен кигезделәр. Хуҗа хатын Габдулланы кочаклап, тагын җылады.

—Улым, Гобәйдуллам!—дип сөйде ул Габдулланы.

Галиәсгар байның да күңеле йомшады, ахрысы, ул йомыш тапкан булып чыгып китте.

Ун яшендә гүр иясе булган мәрхүмнең киемнәрен кигәч, Апуш Гобәйдуллага охшаган кебек күренде.

Бәйрәм табыны янына утырдылар. Бу йортта тагын бер килмешәкнең артуына бер генә кеше сөенмәде—Зөһрә. Үзенә генә ишетелерлек итеп, ул:

—Әрәм-тамаклар ишәя,—дип чәен дә эчеп бетермичә, үз бүлмәсенә менеп китте.

Габдуллаҗанга да өске каттан якты, җылы, матур бүлмә бирделәр. Гел байларча булды бу.

Йорт хуҗасы Галиәсгар бай казакъка барса да, Казанга барса да күчтәнәчсез кайтмый. Кызларга, хатынына матур алкалар, беләзекләр булса, Габдуллаҗанга кием-салым, матур кәләпүш, чалбар яки аяк киеме, монпасыйдыр, әтәч конфеттыр алып кайта. Юлдан кайтып, юынып, чәй эчеп алганнан соң, хуҗабай якты-кин залда барысын да җыеп, бүләк-санак өләшергә ярата. Ул алган бүләкне ошатып, шатланып, рәхмәт әйтеп алсалар, аның да куанычы арта, күнеле була иде.

Байтак вакытлар Габдулланың күге аяз, күнелендә яз була килде. Ул бай баласы кебек киенә, бай гаиләсе белән бер табактан ашый, урамда яшьтәшләре белән кузналы, качышлы уйный.

Олы апасы яки җизнәсе йомыш кушса, Апуш аны җиренә җиткезеп үтәргә тырыша. Кайвакыт урамда уенга бирелеп, кушылган йомышны үтәргә онытып та җибәргәли. Газизә апасы Габдулла эшләргә онытканда, җизнәсе белән Зөһрә тутасы күрмәгәндә, Габдулла өчен үзе эшләп ташлый. Зөһрә атасына Габдулланы әләкли:

—Әти, Апуш син кушканны үтәмәде, аның өчен Газизә эшләде,—дигән очракларда Гаслиәсгар бай дәшми кала, ләкин күнеленә сала бара иде.

## Мотыйгыя

Җаек каласында өч мәхәллә булып, өч мәчет янында да үз мәдрәсәсе эшли иде. Беренче мәдрәсә «Рәкыйбия» Толбай мулла кулында булып, икенчесе—«Гайния» Гайнетдин кари җитәкчелегендә, өченче мәдрәсә «Мотыйгыя» Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинныкы иде. Шулар арасында соңгысы «Мотыйгыя» иң мәшһүре санала.

Галиәсгар бай каенише Габдуллаҗанны әнә шул алдынгырак саналган мәдрәсәгә урнаштырырга исәпләде.

Мотыйгулла хәзрәт 1845 елда Казан губернасе Зөя өязе Кайбыч авылында мулла гаиләсендә туа. Мотыйгулланың атасы Төхфәтулла, аның атасы Нигъмәтулла, аның атасы Комач мулла була. Мотыйгулла яшьли ятим калып, апасы тәрбиясендә үсте.

Төхфәтулла мулла вафат булгач, Кайбычка яңа яшь мулла китереп куйдылар. Яшь мулла сабый Мотыйгулла мәхдүмнең зиһенле бала икәнен тиз күреп ала да мәхәллә халкына мөрәҗәгать итә:

—Җәмәгате мөслимин! Мотыйгулла мәхдүм зирәк бала, аны яхшы мәдрәсәгә юлларга кирәк... Ул кара ятим, апаларының аны укытырга хәле юк. Ни кыламыз!—диде.

Кайбыч халкы һичсүзсез өй саен иганә җыеп, Мотыйгулланы Кышкар мәдрәсәсенә җибәрә, укып чыкканчы аңа ярдәм итәргә алынса да, соңга таба авылдан тиешле акча килүдән туктый.

Кышкарда укыганда Мотыйгулланы аннан ике сыйныф алда укый торган Мөхәммәт Гариф исемле Кушлавыч егете үз химаясына алды. Алар бик дуслашып киттеләр. Җәйге татил вакытларында Мотыйгулланы Мөхәммәт Гариф туган авылына алып кайтып тәрбияли.

Мөхәммәт Гариф 1864 елда указ алып, туган авылы Кушлавычка кайтып мулла булды. Мотыйгулла исә мәдрәсәне 1867 елда тәмамлап, тагын авылдашлары ярдәмендә укуын дәвам итәргә Каһирәгә Әл-Әзһәр университетына укырга китте. Ун ел укыганнан соң 1877 елда Мотыйгулла университетны тәмамлап, Русиягә кайтты. Туганнары, авылдашлары белән

күрешкәннән соң, ул Жаекка, кияүгә чыккан сеңлесен күрергә килде. Берике көн кунак булганнан соң, ул Гайния мәчетенә җомга намазына китте. Читтән килгән, башкалардан аерылыбрак торган кыяфәтле мәһабәт ир-егетне күреп, аңа да Коръәннән бер-ике сүрә укырга тәкъдим иттеләр.

Мотыйгулла Коръәнне Мысыр мәкаме белән укырга тотынды. Мотыйгулланың озын тын белән укуы, моңлы тавышы, бормалары мәхәллә кешеләрен хәйран калдырды. Мәчетне үз химаясында тотып торучы Гайни бай җомга намазыннан соң Мотыйгулланы чәй бүлмәсенә чакырды. Чәй янында танышу, сораштыру башланды. Гайнетдин бай белем ягыннан да, яшь ягыннан да нык өлгергән бу ир-егетне бик ошатты һәм шундук тәкъдимен дә алга куйды.

Мотыйгулла шушы мәчетнең икенче мулласы буларак, эшкә урнашты. Тора-бара ул имам-хатип булды һәм Гайни бай Мотыйгулланы үз йортында тәрбиядә торучы уналты яшьлек Гыйззеназ исемле кыз туганына өйләндереп җибәрде. Һәм бирнә итеп, Гайнетдин бай үзенең ике катлы таш пулатын Мотыйгуллага васыять итте. Гайнетдин бай вафатыннан соң, Мотыйгулла шул йортка кереп урнашты һәм аларның бер-бер артлы балалары туа башлады. Мотыйгулла Төхфәтуллинның күп балалары арасында татар дөньясында нашир һәм җырчы буларак мәшһүрлек казаначак—Камил Мотыйгый 1883 елда, киләчәктә опера җырчысы Кайбицкая булачак кыз Галия 1905 елда шул таш пулатта дөньяга киләчәк.

Озакламый Мотыйгулланы тирә-яктагы мәдрәсәләргә ахун итеп куйдылар. Башка муллалардан аермалы буларак, Мотыйгулла ахун тирән белемле, киң карашлы, шәкертләр тәрбияләүдә дә хөррият яклы алдынгы хәзрәт иде. Аның зур йортындагы зур залда рояль, китап киштәләрендә гарәпчә, фарсыча, төрекчә, урысча, татарча китаплар, газета төпләмәләре тезелгән. Кызлары нотадан карап, рояль уйнарга, җырларга өйрәнәләр. Һәркөн диярлек, бу йортта кунаклар тарафыннан оештырылган җыр, бию, көйләп китап уку кичәләре була.

Мотыйгулла хәзрәт янына Габдулланы алып кереп, Галиәсгар бай ятимне шәкертлеккә алуын үтенде. Баланың Арча төбәге Кушлавыч авылының имамы Мөхәммәд Гариф улы икәнен белгәч, хәзрәт калкына төшеп:

—Сөбханалла! Мөхәммәд Гарифнең баласымы?—диде.—Машалла! Атасы бик яхшы адәм иде, ул 1886 елда гүр иясе булган икән. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун...

Аннан хатыны Гыйззеназны чакырып:

—Карчыгым Назбикә, менә бу мин сиңа сөйләгән мәрхүм дустым Мөхәммәд Гарифнең баласы Габдуллаҗан мәхдүм булыр!—диде.

—Машалла!—диде хуҗабикә.—Хуш килдеңез!

Аннан хәзрәт өстәп куйды:

—Аңа игътибарлы булыгыз. Ач вакытларымда Мөхәммәд Гариф мине Кушлавычка алып кайта иде, әбиең мине кыстыбый, бәлеш, каклаган каз белән сыйлый иде. Һәр татилне мин алар авылында узгара торган идем.

Шулчак залга бер үсмер керде. Ул бик кәттә киенгән иде. Аның өстендә атлас күлмәк, якалары чигүле, башында алтын ука белән чигелгән ракшын—түбәтәй, аягында йомшак читекләр. Габдулладан озын, төз буйлы иде ул.

—Бу минем улым—Камил мәхдүм!—диде хәзрәт.

Габдулла аягына басты. Камил вәкарь генә өстән карап, теләр-теләмәс кенә Габдуллага кулын сузды. Күрештеләр. Габдулла шуны сизде, Камил мәхдүм Габдулланың учыннан котыласы килде кебек, күрешүне озакка сузасы килмичә, кулын тизрәк тартып алган кебек тоелды.

—Улым Камил!—диде ата кеше.—Бу минем дустым, шәриктәшем

Мөхәммәд Гариф мулланың углы Габдуллаҗан. Аның атасы мине нык тәрбия кылды.

Камил мәхдүм:

—Мәмнүн улдым!—диде дә әңгәмәдәшләрне калдырып, китап киштәсеннән бер китап алып, укый башлады.

Габдуллаҗан залның өч дивары да китап киштәләре белән капланганын күреп, шаккатты: күпме китап!

Шулай итеп, Габдуллаҗан «Мотыйгыя» мәдрәсәсе шәкерте булып китте.

Бу 1896 елның көзе иде.

Мотыйгулла хәзрәт улы Камил белән Габдуллаҗанның дус булуларын бик теләми иде. Ләкин хәзрәт баласы, мәдрәсәдәге иң алдынгы шәкерт, өч яшькә өлкән Камил мәхдүм Габдулланы башта якын итә алмады. Гомумән, Камил бик һавалы үсмер булып үсте, авыллардан килгән әллә нинди казакъ, мажик балалары белән ул аралашмый, үзен алардан өстен тота. Аларның ятакханәсенә керергә, шәкертләр белән кул биреп күрешергә җирәнә иде кебек.

Җизнәсе белән апалары Апушны мәдрәсәгә бик тәфсилле әзерлек белән җибәрделәр. Күлмәк-ыштан, оек, читек-кәвеш, кәләпүш, камзул, яңа теккән букча эчендә кәгазь-каләм...

Мәдрәсәнең эчен-тышын карап, Апуш шаккатты, «мәдрәсә» дигәч тә, ул Кушлавыч, Өчиленең такта мәдрәсәләрен күз алдына китерә иде. Ә монда-а, җаный, унлап хәлфә, олы сыйныфларны укыта торган мөгаллимнәр ничәү, мөдәрриснең үзе? Дәресханәләр, ятакханәсе, ашханәсе, китапханәсе, таһарәтханәсе—барысы да бар.

Дәресханәгә керүгә үк ят шәкертне зур кызыксыну белән карый, тикшерә, сораштыра башладылар. Сыйныфханәгә Фәтхетдин хәлфә керде дә турыдан-туры Апушка карап:

—Фамилияң ничек?—дип сорады.

Апуш ни дияргә дә белмәде. Тып-тын. Хәлфә Апушка сөзеп карап, «бу бала колакка сак микән әллә?» дигәндәй, тавышын күтәрә төшеп:

—Фамилияң ничек?—диде.

Апуш кызарып чыкты, җавап юк иде.

—Атаңның исеме ничек?—дип кычкырды Фәтхетдин.

Тагын тынлык. Балаларга да, хәлфәгә дә бу сабыйның зиһененә зыян килгәндер кебек тоелды.

—Йа, Тәңрем!—дип авыр сулады хәлфә абзый.—Атаңның исемен сорыйм, балам!

Апуш, ниһаять, җавап бирү урынына сорарга батырчылык итте:

—Кайсы әтинеке?—диде.

Дәресханә балаларның шартлап көлүеннән зыңгылдап куйды. Хәлфә дә аптыраган: көләргәме, әллә шушындый да әңгерә шәкерт килүенә җыларгамы, белми иде.

—Синең атаң ничәү соң?—диде хәлфә.

—Дүртәү!—диде сабый.

Тагын көлделәр. Хәлфә дә елмайгандай итте. Апушның борыны тирләп чыкты, аның уч төпләре юешләнде.

—Санап күрсәт, балам!—диде хәлфә йомшара төшеп.

Апуш саный башлады:

—Туган атам Мөхәммәд Гариф мулла, ул мин тугач та вафат булган.

—Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун!—дип дога кылдылар.

—Икенче атам—Шакир мулла, ул әнием үлгәч, мине бабама кайтарып куйды... Өченче атам—Казанның кәләпүшчесе Мөхәммәд Вәли, ул үлем

ястыгына яткач, мине Сәгъдетдин атама уллыкка кайтардылар. Менә хәзер җизнәм Галиәсгар Госмановта яшим, әлхәмдүлилләһ,—дип өстеннән авыр йөк төшкәндәй, Апуш бичара пошкырып куйды.

—Исемең ничек?—дип сорады хәлфә.

—Габдуллаҗан!—диде сабый.

Берәү дә көлмәде. Хәлфә яңа шәкертенең хәлен бик яхшы аңлады.

—Утыр, Габдуллаҗан үскәнем!—диде Фәтхетдин хәлфә йомшак тавыш белән.

Аның алдында ятимнәр ятиме, әмма итагатьле, зиһенле бала басып торганын хәлфә, ниһаять, аңлады.

Апуш урынына утырды. Ханә тагын тынлык киеренкелегендә калды. Хәзер хәлфә абзый яңа шәкертне сынап караячак.

—Габдуллаҗан, ничәгә чаклы саный беләсең?

Апуш боерык та көтеп тормыйча, санап китте:

—Бер, ике, өч... йөз...

Йөгерек санап ул йөзнең аръягына чыккач, хәлфә:

—Җитте, шәкерт!—дип аны туктатты.

Тапкырлауны да Апуш Яңа Бистәдәге анасы Газизә бикә өйрәткәнчә, теле-телгә йокмый әйтеп чыкты.

Сыйныфтагылар соклану аша:

—Сөбханалла!—диделәр.

Апушның төркичә-гарәпчә дә, Коръәнне дә яхшы укыганы, «Иман шарты»н, «Һәфтияк»не яттан белгәнен күргәч, егылып киттеләр.

Беренче дәрес тәмамлануга ук Фәтхетдин хәлфәханәгә кергәч, башкалар белән киңәште: Габдулла Тукаев бу сарыфны гына түгел, алдагыларын да үзләштергән булып чыкты, аны хәзер Коръәнгә, «Кырык хәдискә» кушарга кирәк, дигән нәтиҗә ясалды.

Шулай итеп, мәдрәсәгә килгән яңа оланның даны шәкертләр арасында гына түгел, хәлфә-мөгаллимнәр арасында да тиз таралып өлгерде.

Галиәсгар бай каенишенең укуга тибеш-җәптәш икәнен аңлап, аны тагын урысча укырга школага бирергә булды. Школада да Апуш үзеннән алдан кергән балаларны куып җитеп узып китте.

Сабакка йөри башлагач, Габдулланың йорт тирәсендәге йомышларны үтәргә вакыты калмый иде. Ул сабактан кайта-кайтышлый капкалап ала да, урамга кузна уйнарга чаба.

Иртән чәй эчеп утырганда хуҗабай әйтте:

—Лапаста ярылган утын бар,—диде:—Шул ярылган утынны мунча өялдына ташып, матурлап өеп куярга кирәк. Ул эшне, каениш, син башкарырсың.

—Җизни,—диде Габдулла.—Бүген минем сабакларым күп, дәресләр караңгыга чаклы була.

—Караңгыда ташырсың!—диде бай кырыс кына.

Апуш кече Газизә апасына бакты.

—Апаңа карама, ялкау!—диде Зөһрә.—Апаңның бүген кер уасы көне... Миңа да карама, минем шәл бәйлисем бар. Аннан соң мин үз йортымда килмешәк өчен эш эшләмәм бит инде.

—Зөһрә!—диде анасы.

Галиәсгар бай Зөһрәнең шулай тупасрак сөйләвен өнәп бетермәсә дә, эчтән генә аның сүзләрен хуплады.

—Эшләп ашарга кирәк, каениш!—дип Апушның җилкәсенә җиңелчә генә сугып.—Йәгез, бер фатиха!—дип догага кул күтәрде.

Догадан соң:

—Шулаймы, егет?—диде.

—Шулай!—диде Апуш.

Габдуллажанның ашы аш булмады, укуы уку булмады. Көн буе мәдрәсәдә укып, аннан соң школага барып, ул утын өясе барын онытты. Ул караңгы төшкәч кенә, тыны капланганчы йөгереп, өйгә кайтты. Букчасын баскыч төбенә ташлап, лапаска йөгерде.

Ач булса да, арган булса да, Апуш утынны тәки ташып бетерде. Өйгә кереп ашап-чәй эчеп торырлык та хәле булмаганлыктан, ул шул килеш кенә йокларга ятты.

Хәзер Апушның тормышы школа белән мәдрәсә арасында, аннан кайткач, каралты-кура тирәсендә, алардан буш чакта урамда уенда уза башлады.

Шушы тәртипкә корылган тормышта усал тутасы Зөһрәнең кимсетүләре дә, җизнәсенең атлаган саен аны «эшләп ашарга кирәк» дип битәрләп торуына да ул күнегеп бетте инде. Ләкин ятим сабыйның күңеле сизенә иде: муллыкта яшәтсә дә, аны укытырга, киендерергә акча сарыф итсә дә, нишләптер, җизнәсенә аның күңеле ятмый иде.

Шушы шартларда ул яшәргә, укырга тиеш. Ләкин шушы шартларны тагын да катлауландыра торган вакыйгалар булып тора.

Бер җәйне Галиәсгар бай белән апасы Газизә туган авылларына кунакка кайтып китте. Кире кайтканда алар икәвесе генә түгел, дүртәвесе булып кайтып төштеләр. Киң күңелле, туган җанлыклы Галиәсгар бай үзенең ерак туганнарыннан ятим калган балаларны алып кайткан иде. Аларның берсе ун яшәр Гали исемле малай булып, икенчесе сигез яшәр Фәйрүзә исемле кыз иде.

Бу өстәмә ятимнәрнең кайтып төшүе башка ятимнәр өчен дә, ирдән аерылып кайткан усал Зөһрә өчен дә күңелле яңалык түгел иде.

Шулар өстенә бай:

—Курада кеше артты, ярдәмче куллар кирәк!—дип ирле-хатынлы Гыймади белән Гайнине каравылчы итеп эшкә алды. Алар аскы өйгә урнашты. Һәм яңа килгән ятимнәр белән бергә Апушны да каравылчылар янына төшерделәр. Гыймади абзый акыллы, юаш бәндә булып, аның Гайни исемле хатыны бик әтчәянни иде, ул йорт хуҗабикәсеннән дә арттырып, балаларга кычкыра, аларны әрли, хәтта кайчакларда, кеше күрмәгәндә генә чыбык белән суккалый да иде.

Өске каттагы олы бүлмәдә дәрес хәзерләргә, китап укырга да уңайлы иде. Аста тыгын, шау-шу. Өстән аска күчерелүен Апуш авыр кичерде. Бу—үз дәрәҗәңне бел, дигәнне аңлата иде булса кирәк.

Чыннан да, Галиәсгар бай болай уйлагандыр. Ни әйтсәң дә, Апуш аның үз канкардәше түгел, бары тик каенише генә, Гали белән Фәйрүзә исә аның туганнан туган балалары. Яки аларны да Апуш янына өскә менгезергә кирәк иде. Алай булмый, чөнки Зөһрә моңа риза булмаячак, риза булса да, балалар белән Зөһрә арасында гел гауга чыгып торачак. Иң яхшысы, аларның барысын да тигез күреп, барысын да аскы катка, каравылчылар белән урнаштыру иде.

Галиәсгар бай Галине Апуш белән бер мәдрәсәгә урнаштырды, Фәйрүзәне кызлар мәктәбенә бирде.

Ни генә булмасын, Галиәсгар бай ятим сабыйларны тигез карарга тырыша иде, олау чапканнардан ул каенише белән туганнан туган энесенә бертөрле кием, бертөрле бүләкләр алып кайта, аларны аермый, кимсетми иде. Гали белән Апушны игезәк балалар дип йөртәләр иде. Ләкин Гали укуда алдыра алмый интегә, яшьтәшләреннән күпкә артта кала. Ул үзе дә укуга дәрт түгел иде. Гали күбрәк каралты-курада маһир эшли.

Чыннан да дүрт кеше артканнан соң йортта тавыш еш чыга башлады.

Апуш ике мәктәптә укып, соң кайта, кайткач сабакка әзерләнәсе, китап укыйсы бар, йорт эшләренә ул катнаша алмый, катнашырга теләми дә иде, ахрысы. Гали эшкә чат ябышып ята, агасы алдында:

—Ни кушасың, агам! Нишлим, агам!—дип кенә тора.

Бу Галиәсгарга бик тә ошый иде. Гали белән аларның серләре килешә. Ашаганда да алар эш турында рәхәтләнеп сөйләшә. Апуш дәшми. Ашап туюга тизрәк җизнәсе күзеннән качарга тырыша.

Җизнә белән каениш арасы көннән-көн ерагая барды, хуҗабайның моңа эче бик поша, ул Апуш белән Гали туганы белән чөкердәшкән кебек якынаерга, аның белән сөйләшергә тели иде. Галиәсгар белән Апушның арасы салкынайганнан-салкыная баруын ике Газизә дә сизә, аларның да кәефен боза иде.

Шундый шартларда тагын ел узды. Апушның мәдрәсәдә һәм хәлфәләр, һәм мөгаллимнәр, һәм шәкертләр арасында абруе артканнан-арта барып, Апушның мәдрәсәдән өйгә кайтасы килмичә, ара-тирә ятакханәдә кунып-кунып та калгалый башлады. Бу хәл хуҗабайның ачуын чыгарды. Беркөнне ул хатыны Газизәгә әйтте:

—Аңламыйм мин бу Габдуллаҗанны!—диде.—Мин аңа җанымны телеп бирергә риза, ул мине чит итә.

—Атасы,—диде Газизә.—Әллә үзе белән сөйләшеп карыйсыңмы?

Хуҗабай бу сөйләшүгә бик сак кына килде.

—Каенишем!—диде ул.—Синең миңа үпкән-фәлән юктыр бит?

Апуш сагаеп калды:

—Юк!—диде.

Галиәсгар уйлап куйды: юк, җизни, дип тә әйтми, ичмасам.

—Бер-бер ризасызлыгың бармы?—диде хуҗабай салмак кына.

—Юк!—диде Апуш.

Галиәсгарның ачуы чыкты:

—Бу нинди сөмеки бала син, юк та юк!—дип хуҗабай тавыш күтәрде:— Мин синең алда иелеп гафу үтенер идем, гаебем барын сизсәм!

Апушның башын бер кырга салып, җизнәсенә яны белән басып, дәшми торуы хуҗаның җенен чыгара иде.

—Мин сине ачлыктан тартып алдым, каениш,—дип ачуын тыеп, кычкырмаска тырышып башлады ул төп сүзен:—Кучер җибәреп кайтарттым, өстеңдә миллионщик малайлары кимәгән кием, башкаларда булмаган ризык. Йомшак урын-җирең, нигә син шуларга рәхмәтле түгел, әнә, Гали белән Фәйрүзә атлаган саен миңа рәхмәт әйтә. Инде хәзер табын янында мин булсам, ашарга да утырмыйсың? Синең рәхмәтеңне ишетер өчен тагын мин нишләргә тиеш?

—Мин гел сиңа рәхмәт әйтәм!—диде Апуш авыз эченнән генә.—Ашап туйгач, дога кылганда да мин: җизнәмә, апама рәхмәт, дим.

—Ишеткәнем юк!—дип кычкырды хуҗа.

—Аллаһу Тәгалә ишетә!—диде Апуш.

—Кычкырып әйтергә ярамыймыни ул рәхмәтне?

—Ярый, ләкин кычкырмыйча әйтсәң дә ярый, дигән китапта.

—Кайсы китапта ул?

—Коръәндә!—диде Апуш.—Кешегә яхшылыкны ачык итеп эшләргә дә була, башкалар күрми калса, хәерлерәк. Мохтаҗларга хәер биргәч: менә мин шулкадәр хәер бирдем, син дә миңа яхшылык эшлә, дип кычкырган кешегә биргән хәеренең савабы булмас, дигән... Ә син атлаган саен: мин сине киендерәм, мин сине ашатам-эчертәм, дип рәхмәтне сорап аласың.

Галиәсгар мондый дорфалыкны көтмәгән иде, ул башта сүзсез торды, ух-пух килде, аннан соң каты тавышы белән:

—Аһ, атаңа нәләт!—дип кычкырды.

Боек кына, буйсынган кыяфәттә торган Апуш кинәт башын күтәрде.

—Рәхмәтсез бала! Атаңа нәләт! —дип кабатлады хуҗа.

Габдуллаҗан бер мизгелгә генә жизнәсенә туры карап алды да, кинәт борылып, букчасын күтәреп, йөгереп чыгып китте, ул капканы да узды, урам буйлап мәдрәсә ягына таба йөгерде.

Тавышка башкалар да бүлмәгә керде.

—Ни булды, атасы?—диде Газизә.

Хуҗабай һаман тынычлана алмый иде.

—Мин аны киендергәнем, ашатканыма савап түгел, гөнаһ алам икән! Аһ, мөртәт бала!.. Ярар, моннан соң мин аны ашатмыйча, савап кына җыярмын!

—Әйттем мин сезгә!—диде Зөһрә.—Ул малайның башында нидер бар, дидем.

Ул көнне дә, икенчесендә дә Габдуллаҗан өйгә кайтмады. Өйдәгеләр аның мәдрәсә ятакханәсендә башка шәкертләр янында икәнен яхшы белә, ләкин бу күнелсез хәлгә бик борчылалар иде. Хуҗабай да үзенә урын табалмады. Башкалар да аның белән ачылып сөйләшергә базмадылар. Зөһрә генә үзалдына:

—Үксез бала асраганчы, үгез бозау асра!—дип такмаклап йөрде.

Гыймади каравылчының хатыны Гайни дә:

—Ит яхшылык, көт яманлык—шул буладыр инде ул!—дип сөйләнеп алды.

Апуш мәдрәсә, ятакханә мохитен бик ярата, анда аның абруе бар, аның сүзенә колак салалар, анда аның такмакларын тыңлыйлар. Ач булса да, аңа мәдрәсәдә яшәве кызык иде. Анда аның үз тыңлаучылары бар.

Берничә тапкыр Гали яшьтәше, аннан кече Газизә апасы, аннан соң олы Газизә апасы Габдулланы өйгә кайтырга үгетләп килделәр. Кече апасы аның кире кайтмасын белгән кебек, күп итеп ашамлык алып килгән иде. Ул күчтәнәчләр шул көнне үк ятып укучылар белән уртак ашалып бетте.

Галиәсгар Госмановның кәефе кырылды. Ул үзен битәрләп тә, әйткән сүзенә үкенеп тә карады, барыбер тынычлана алмады. Аннан соң ул башкаларга ишетелерлек итеп, үзен акларга тотынды:

—Каян килгән Алланың кашка тәкәсе! Серкәсе су күтәрми икән! Аның алдында минем ни гаебем? Кимсетмәдем, барыгызга да тиң бактым. Барыгызны да яратып яшим. «Эшләп ашарга кирәк» сүзе дөрес түгелме? Эшләмәгән өчен атакайлар безне камчы белән яралар иде, минем аңа тырнак белән дә чирткәнем булмады.

Олы Газизә иренең ачуын арттырмаска тырышып, ипләп кенә әйтә куйды:

—Атасы,—диде.—Ул сиңа бик тә рәхмәтле... тик аның холкы шул инде... Гали кебек ул сиңа сырпаланмый...

—Хәерче шулай горур була инде ул!—диде хуҗа.

—Алары өчен дә түгел, ул синең «атаңа нәләт» дигәнеңне кичерә алмый,—диде бикә.

—Мине кичерергә, мин аның каршысында җинаятьчеме? —дип кычкырды бай.

Сүз шунда туктап калды.

Галиәсгар Госманов шуннан соң гел җыерык каш белән йөри башлады. Өйдәгеләргә дә ул төкселәнде. Казакъ ягына сәүдә белән чыгып кайтканнарда да элеккеге кебек шат күнел белән кайтмый. Бүләкләр дә сирәгәйде. Әллә аның сәүдә эшләре кирегә китте, әллә аның сәламәтлеге какшады, әллә каенише белән булган кайнар бәхәс аның күнелен эчтән кимерә иде,

Галиәсгар бай бик еш авырый башлады. Ул вакыт-вакыт эчен тотып бөгелеп төшә дә авыртуына чыдый алмыйча, озак кына шулай бөгәрләнеп тора. Җылкы мае да, шифалы үләннәрнең дә файдасы тимәде, сәүдәгәр Галиәсгар Госманов 1900 елның җәй уртасында җан тәслим кылды.

Авыр туфрагы җиңел булсын! Урынын җәннәттән әйләсен! Иннә лилләһиә вә иннә иләйһи рәҗигун!

Җизнәсенең җеназасына Габдуллаҗан да килгән иде. Ятим калган апалары белән бергә ул да бик нык җылады.

Хуҗабай вафатыннан соң якын туганнары арасында мал бүлеш, мирас тарткалашы да булып алды. Чыннан да Госмановның варисларына әлләни күп малы калмаган иде. Әллә каян гына кредиторлар килеп чыкты, әллә нинди кыягазлар күрсәтеп, бер урыс, ике казакъ бае, бер татар кайчандыр Госманов бурычка алган акчаларын таләп итеп, ике йортның берсен сатып, шул акчадан үз өлешләрен алып китте. Шулардан калган бер йорт мәрхүмнең тол хатыны Газизә, аның кызы Зөһрә, авылдан алдырган ятим Галигә шәригатьчә бүленеп бирелде. Габдуллаҗанга васыять язылмаган иде.

Малны таркатмыйк дип, хуҗабикә каравылчылардан баш тартып, дүртәвесе генә шул йортта яши калдылар. Озакламый кече Газизә кияүгә чыгып, ул йорттан китеп барды. Хуҗабикә Габдуллаҗанга:

—Кире кайт, энем! Бергә-бергә яшәрбез!—дип караса да Габдулла шәкерт җизнәсе йортына кайтмады, ятакханәдә калды.

### Үзбаш

Габдуллаҗанның мөстәкыйль тормышка юлы ачылган иде инде. Ятакханә хәяте аның ирек ярата торган холкына бик туры килә иде. Дәресләрдән соң мендәр сугыш, шигырь сөйләш, җырулар җырлаш башлана. Бу кичәләрнең уртасында Габдулла булыр. Аның әкият сөйләве дә, шигырь укуы да, халык җырларын җырлавы да дан казанды. Аны бай шәкертләр чәйгә чакыра, ана көнбагыш, чикләвек, корот бирәләр. Кайчаклар казы да эләккәләп куя. Бәйрәмдә, ял көннәрне аны Мотыйгулла хәзрәтнең курасына чакыралар. Ашаудан битәр ул хәзрәтнең бай китапханәсендәге китапларны укый иде.

Җыр, шигырь тамашаларыннан соң табын уртасына салынган көнбагыш, чикләвекне Тукай тартынмыйча ашый. Тик менә ул нишләптер шәкерт кешегә төшемле нәрсә—җеназага—хәмелгә бармый. Башка ярлы шәкертләр кебек, бай шәкертләргә самавыр да куймый, аларның керләрен дә юмый. Күп фәкыйрь шәкертләр җәйге татилдә казакъ далаларына барып, муллдәкә булып, бераз акча эшләп кайта. Тукай анда да бармый. Ул җәйге татилдә мәдрәсәдә ялгыз калып, Чаган елгасына балыкка йөри, шунын белән тамак ялгый. Калган вакытын хәзрәт китапханәсендәге китапларны укып уздыра.

Мәдрәсәдә ятып укуга күчкәч, Габдуллаҗан читлектән котылган кош сыман, иреккә чыкты. Ачлы-туклы яшәсә дә, ул артык кашык булып, бай йортына әйләнеп кайтмас иде.

Аның хәлен аңлап, Мотыйгулла хәзрәт Апушны бәйрәм табынына еш чакыра, җае чыккан саен ана бераз акча эшләргә мөмкинлек бирә иде. Ул җәй көннәрендә хәзрәтнең метрикә кенәгәләрен күчереп яза, анын өчен ике сум акча ала, укуда артта кала торган өч шәкертне укытканы өчен ике сум төшерә.

Һәм, ниһаять, Габдуллаҗан үзе теләгәнчә яши башлаячак. Үзе теләгәнчә китап укыр, үзе теләгәнчә җырлар, шигырь язар. Кәләпүшен салып ташлап,

үзе теләгәнчә, озын чәч үстерер, үзе теләгәнчә тәмәке тарта башлар, үзе теләгәнчә мулла-мунтагай, хәлфә-мәлфәләрнең наданлыгыннан, житешсез якларыннан көлеп, чәнечкеле такмаклар чыгарыр. Кичләрен ятакханәдә концертлар оештырыр, үзәкләрне өзә торган моңлы тавышы белән бетмәс-төкәнмәс халык жырларын башкарыр. Сыйныфташлары белән Чаган елгасы буена, сәхрага чыгып, кубыз уйнап, табындашларын биетер, аларның күңелен ачар. Аның шуклыкларын карарга, аның моңнарын тыңларга Жаек каласының башка мәдрәсәләрендә укучылар да, хәлфәләр дә «Мотыйгыя»га килә башлар. Аның жырын тыңлар өчен хәлле гаиләләр Габдуллажанны кунакка чакырыр.

Мәдрәсәдә үтелергә тиешле фәннәрне башкалардан алда үтеп, Габдуллажан өстәмә әдәбият укый башлады. Мотыйгулла хәзрәт үзенең китапханәсен аның карамагына тапшырды. Шәрык, Аурупа, рус әдәбиятыннан шактый мәгълүмат туплады, шигырь кануннарыннан хәзрәтнең үзеннән дәресләр алды.

Гомәр Хөсәенов исемле хәлфә хажга киткәч, Мотыйгулла хәзрәт аның урынына Габдуллажанны балалар укытырга куйды. Ун баланы Габдуллажан Госман хәлфә хаждан кайтканчы, алты ай дәвамында укытты һәм ул укыту ысулларына үзгәреш кертеп, беренче тапкыр мәдрәсәгә кара такта куйдыртты, аның укыту ысулы хаждагы хәлфәнекеннән бераз аерыла, ул телдән кычкырып мәгънәле укуга, матур язуга күбрәк игътибар бирә һәм башка сыйныфтагы шәкертләр Габдулла дәресләренә дәррәү йөри башладылар.

Госман хәлфә кайтып төшкәч, Габдулладан бу вазифа алынды. Дәрес вакытында Госман хәлфәдән хаждагы хәлләр турында сораштыра башладылар.

Госман хәлфә бик иркенәеп, рәхәтләнеп хаж гамәлләрен сөйли.

—Тәвафта хажилар ничек йөри? Шуны күрсәтмәссенме, хәлфәм?—диде Габдулла.

Госман хәлфә Габдулланың астыртын соравын аңламый иде, тәвафта йөргәнен күрсәтә башлады, ул ике кулы белән бөеренә таянды, чүгәләде, үрдәк йөреше шикелле алпан-тилпән атлап, кечкенә өстәлне әйләнеп чыкты, шәкертләр егылып көлә башлады.

Кичен ятакханәгә кайткач, сабакларын әзерләп бетергәч, тагын театр башланды, Габдулла жыелган тамашачы алдында, уртага кечкенә сандык куеп, Госман хәлфәнең Кәгъбатулла тирәли йөрешен күрсәтә башлады. Каты көлү тавышыннан ятакханә шартлар дәрәжәдә калтырый иде. Шулчак Габдулла:

—Әгәр Кәгъбатулла тирәсендә хажиларның ничек әйләнгәнен күрәсегез килсә, сумашедший думга барыгыз!—диде.

Монысы элеккесенә караганда да катырак көлүгә сәбәп булды. Тәгәриләр, тезләренә сугалар, эчләре катканчы, күзләреннән яшь чыкканчы көлделәр. Тавышлар беразга гына туктап тора да, көлү өянәге тагын шәкертләрне буып ала иде.

Шулчак ятакханә ишегендә полицейский пәйда булды, аның янында мәдрәсә күзәтчесе Нури хәлфә дә күренде. Шәкертләр тына калды.

—Нигә шулкадәр шашасыз?—дип кычкырды Нури хәлфә.

—Что за сборище?—дип полицейский уң янбашындагы алтатарын, сул яктагы кылычын капшап.—Против кого маевка?—диде.

—Ышу вы, ышту вы,—диде Нури хәлфә жиде кат бөгелеп:—Ниту маюфке, ниту.

—А что же есть, почему они так шумят?—дип сорады полицейский.

—Иты, гаспадин полисәмистер, иты, кансирт такуй...—диде хәлфә.

—Какай-такой «кансирт»?—дип кычкырды полисәмистер.
—Күрсәтегез!—дип боерды хәлфә.

Габдуллаҗан урысчаны хәлфәдән яхшырак белсә дә, юри кыланып сөйли башлады:

—Жантимер агай,—диде ул борынын юри тынкышландырып.—Вот вит хаҗга барганский, там чурный кәмин вокруг йөргәнский вот так...—дип Габдулла янә Госман хәлфә йөргәнен күрсәтте. Шәкертләр тагын рәхәтләнеп көлделәр.

Жантимер агай да елмайды:

—Ну да ладно, тут ничего политического нет!—дип чыгып китте.

—Патшага каршы сүз әйтергә ярамый, маюфкы оештырырга ярамый! —дип Нури хәлфә дә чыкты.

Габдуллаҗан шундук номер әзерләде, әллә каян гына каеш табып, биленә буды, шул каешка кылыч итеп ишек терәткеч озын таяк такты, бер ягына алтатар урынына чи бәрәңге кыстырды да ишекнең теге ягына чыгып, янадан полисмен булып керде дә:

—Што за сборище!—дип кычкырды.—Што за маевка?

Шундук ул Нури хәлфә булып:

—Ниту, ниту маюфке, гаспадин палисәмистер!—диде.

Шәкертләрне тагын көлү буып алды. Шундый кансиртлар атнага бер-ике тапкыр кабатланып, Жаек мәдрәсәләрендәге шәкертләрне дә «Мотыйгыя»га тарта башлады.

Бу Нури хәлфә мәдрәсәнең химаячысы Мортаза Гобәйдуллинның кияве булып, кайнатасы аркасында гына хәлфә урынын алган, һәм күзәтче булган надан бер бәндә иде. Солдаттан калу өчен, кайнатасы Мортаза байның котыртуы аркасында, ул өшкерүче-сихерчегә барып ниндидер агу эчеп, шуннан авызы кыйгаеп калган иде. Аның белер-белмәс укытуы Габдуллаҗанның күзеннән төшеп калмады, әлбәттә. Кичләрнең берсендә Габдуллаҗан сандыкка басып, шигырь сөйли башлады:

Нурый да тугры—
Кыйшык торбадан
Төтеннәр тугры
Чыкса, дусларым.

Ватык та тишек
Тәрәзә, ишек,
Хәлфәсе кыйшык
Авыз, дусларым.

Иты кансирттыр,
Ниту маюфке,
Палисәмистер
Тотса, дусларым.

Мортаза бай Гобәйдуллин Жаекның иң олы байларыннан булып, татар мохитенә тәэсире көчле иде. Бәйрәмнәрне дә ул олылап, шау-шулы үткәрергә ярата. Шәкерт халкын да онытып бетерми, аларны хәерennән ташламый. Менә бервакыт Мортаза бай улы Садыйкны өйләндерергә уйлады. Туй нижитте генә булмас, Жаекның бөтен сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре, эшчеләре, балыкчылары, кымызчылары, казагы, татары, урысы, калмыгы, шәкертләре, хәтта шәһәрнең баш палисәмистере дә чакырулы иде. Дәстархан мул, Габдуллаҗан да башкаларга ияреп, Садыйкның туена барды. Ләкин ул туйның азагынача утыра алмады, кайтып китте. Башка шәкертләр шау-шулап ятакханәгә кайтып кергәндә ул инде шигырь язып өлгергән иде.

Итчеләр, тиречеләр бик күп иде,
Ит исе, тире исе аңкый иде...
Бар да сөйли кайда нәрсә алганын,
Бу базарда күпме табыш калганын.
Шул кадәр туйдым тире, ит исенә,
Валлаһелгазим, икенче бармамын.

Чыннан да Габдуллаҗан шуннан соң, чакырулы булса да, андый мәҗлесләргә бөтенләй йөрмәс булды.

«Рәкыйбия», «Гайния» мәдрәсәләрендә укучы берничә шәкерт тагын «Мотыйгыя»гә килде. Алар тагын кансирт карадылар, тагын эчләре катканчы көлделәр. «Кансирт»тан соң таралышканда Габдуллаҗан Миңлебай Хәйруллин исемле яшьтәшен озата чыкты.

Әллә ничек Миңлебай белән Габдуллаҗан беренче танышканнарында ук үз булып китте. Эчкерсез егет Миңлебай Габдуллага якын иде. Белеме дә зур, ул инде ике мәдрәсәдә укыган, монда өченчесен тәмамлап килә. Унике яшеннән Коръәнне яттан белгән хафиз кеше. Аның киңәшләре дә төпле, акыллы иде. Алар бая гына булып узган кызыклы тамаша турында сөйләштеләр дә, икесе дә тынып калды. Габдуллаҗан сизде, Миңлебайның аңа нидер әйтәсе килә иде.

—Беләсеңме, яшьти Габдулла,—диде Миңлебай:—Синең шигырьләрең кызык, бик кызык. Ләкин артык каты чәнчәсең бугай.

Габдуллаҗан дәшмәде.

—Үзеңнең хәлфәң Госман, мәдрәсә күзәтчесе Нури, Мортаза бай Садыйгының туе турында да шәп язгансың... Мәдрәсәң турында да төртмәң бик әче...

Миңлебайның сүзләре Габдуллага бер дә ошамады, ул дустының сүзен кисте:

—Госман хәлфәнең мокытлыгы йөрешенә чыкканын белмисеңмени?—диде Габдуллаҗан:—Ә Нури хәлфәнең надanлык ханы икәнен белмиләрмени?

Миңлебай сүзен сабыр гына дәвам итте:

—Мәдрәсә синең остазың, атаңның дусты Мотыйгулла хәзрәт карамагында бит. Бу һөҗүең аңа да барып кагыла. Ул Мортаза байның атасы васыять иткән йортта яши, Мортаза байга туган кеше, Нури хәлфә Мортазаның кияве, Садыйк Мортаза байның улы, Госман хәлфә дә шул ук мәдрәсә хәлфәсе, Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенең укытучысы.

—Миңлебай, ахир,—диде Габдуллаҗан:—Әйтелгән бит инде, аны кабат җыеп алып булмас. Шәп әйттем, кабат алай әйтмәм.

Сүз шунда өзелде. Миңлебай аңлады, Габдуллаҗан тәнкыйтьне авыр кабул итә. Миңлебай кайтып китте, Габдуллаҗан йокларга ятты. Ләкин тиз генә йокыга китә алмады. Чыннан да бәлки Миңлебай хаклыдыр? Бәлки саграк булырга кирәктер?

Мәдрәсә шәкертләре һәм алдынгы фикерле хәлфәләр арасында Габдулланың гыйлемле булуы, ятакханәнең бурсыган тормышына саф һава алып килүе, уен-көлкеле мәҗлесләр оештыруы шулкадәр көчле иде ки, аның озын чәч үстергәненә дә, кәләпүшен ташлап, урыс картузы киеп йөрүенә дә, качып-посып, соңра ачыктан-ачык тәмәке тартканына да мәдрәсә идарәсе күз йома, аңа бәйләнмиләр, хәтта ниндидер бер күләмдә Габдулладан курка да иделәр, бәладән башаяк, Габдулланың әче теленә, аның чәнечкеле һөҗү такмакларына эләгеп куюың бар.

Көннәрдән бер көнне мәдрәсәдә шау купты, шәкертләр үзара:

—Чулпаный килгән! Чулпаный! Шагыйрь килгән, шагыйрь!—дип сөйләшәләр.

«Шагыйрь» сүзе Габдуллаҗанның колакларын торгызды. Аның аңында шагыйрь—ул пәйгамбәр кеби олы, изге зат булып сурәтләнә иде.

Мотыйгулла хәзрәтнең китапханәсендә Габдуллаҗан йотлыгып, «Рисали Газизә»не укып утыра иде. Китапханә йортның икенче катында, зур залда урнашкан иде. Астан менеп килүче ирләрнең сөйләшкәнен ишетеп, Габдулла җыелыбрак утырды.

—Монда сөйләшүе кулайрак булыр,—диде хәзрәт.

Бу катка беренче булып хуҗабай менеп житте, аның артыннан ят кеше күренде. Хәзрәт белән килгән кеше кордашлар кебек күренә иде, бу әфәндегә илле яшьләр чамасы булыр. Ул чалма урамаган, башында каракүл бүрек, өстендә шәкерт казакиена охшаган утырма якалы кара чикмән, аягында әле яңа гына кәвешен салган йомшак кара читекләр иде. Кулында утыз өчтән торган юл тәсбихе булмаса, бу кешенең мәчеткә катнашы юк кебек күренер иде. Кунакның йөзе борчулы иде.

—Уз, Мирхәйдәр хаҗи!—диде хуҗа.

Шунда алар китап укып утыручы Габдуллаҗанны күреп алды.

—Бу безнең шәкертебез, Габдуллаҗан Тукаев булыр!—диде хәзрәт.—Без аның атасы Мөхәммәд Гариф белән җан дуслар идек.

Габдулла урыннан торып, ят кешегә чак кына баш какты, ләкин ят кеше кинәт яктырып, җил-җил атлап, Габдулла янына килеп, ике кулын сузды:

—Әссәламү галәйкем, Габдулла шәкерт!—дип олылап сәлам бирде.

—Вәгаләйкум әссәлам!—дип Габдулла аның кулын кысты.

—Бу безем мәдрәсәдә укыган Мирхәйдәр Чулпаный!—дип таныштырды хәзрәт.—Хәзерендә Самара ягында имам-хатип...

Чыннан да Чулпаный исемле бу зат олпат кеше иде.

Хуҗабай кунакка урын күрсәтте, Габдулла аларның сүзенә комачауламас өчен, китабын киштәгә куеп, урыныннан торды.

—Юк, юк, Габдулла әфәнде,—диде кунак.—Син безгә комачауламыйсың... Бондай фәгалияттә сезнең кебекләр дә иштирак итешләре лаземдер.

—Чыннан да син укуыңны дәвам ит!—диде хәзрәт. Аннан соң култыкса янына килеп, аска:

—Әй, Миңсылу!—дип кычкырды.

—Әү, хәзрәт!—дигән тавыш ишетелде.

—Өч кешелек чәй менгер!—дип өстәде хуҗа.

Урнаштылар. Асрау кыз әңгәмәдәшләргә чәй алып менде, тустаганнар, чәйнек куелган төпсәсен өстәлгә урнаштырып, үзе аска төшеп китте. Хәзрәт өч касәгә дә чәй койды.

—Габдуллаҗан, син дә житеш!—диде хәзрәт.

Габдулла кыяр-кыймас кына табын янына утырды.

—Мөхтәрәм остазым!—диде Мирхәйдәр мулла.—Хатта яздыгымда әйттем ки, Жанбикәч исемле безем бер кызымызны поплар урлап алып китеп, ирексезләп чукындырдылар. Чукындырып кына калмадылар, аны монастырьга яптылар. Мин полисәмистергә прошениеләр яздым, унны яздым, дин эшенә катнашмыйбыз, дип эшне карамага алмадылар. Егетләр яллап, мин ул кызны монастырьдан урлап качтым.

—Ул кыз хәзер кайда соң?—дип сорады хуҗа.

—Мин аны поезд белән монда алып килдем дә ышанычлы йортка яшердем. Аның яңадан мөселманлыкка кайтасы килә, хәзер мин нишләргә тиеш, дип, остазым, сиңа киңәшкә килдем.

Мотыйгулла хәзрәт чәй уртлап куйды да әйтте:

—Янә исламга кайтыш өчен, тәүбә итәргә кирәк, тәүбә иткәннән соң, шаһәдәт догасын кат-кат укыш кирәк. Моның бер мәшәкате дә юк, син аны үзең дә беләсең, мелла Мирхәйдәр.

—Мин беләм, хәзрәт,—диде кунак.—Жанбикәч тилерер дәрәҗәдә. Зур чиркәүгә алып кереп, аны олы поплар акыра-бакыра салкын суга чумдырып чукындырганнар, аңа Анастасия исеме дә кушканнар, хәзер ул: мине олы мулла-ахун тәүбә иттерсен дә, ул миннән шаһәдәт догасын кабул итсен, дип жылый. Аның тәүбә иткәнен, шаһәдәтне укуына син шаһит булсаң иде, хәзрәт. Юкса, кызның акылына зәгыйфьлек киләчәк.

Хәзрәт озак кына дәшмәде. Аннан соң:

—Киттек!—диде.

Шулай итеп, Мотыйгулла ахун хәзрәт белән Мирхәйдәр мулла кыз яшерелгән йортка барып, Анастасияне кире Җанбикәчкә кайтарып, тәүбә иттереп, шаһәдәт догасын, вә башка сүрәләр укытып, исламга дүндереп кайттылар. Муллаларның икесе дә канәгать иде. Шулар өстенә Мирхәйдәр мулла кызны Уфага, мөфти хәзрәтләренә алып барып, аннан фәтва алып, Самарага китәргә уйлый иде.

Ахшам ашын алар бергә хәзрәт табынында ашадылар. Ашка Габдулла да чакырулы иде. Шул мәҗлестән соң илле яшьлек мелла Чулпаный белән унбиш яшьлек үсмер арасында дуслык нурлары барлыкка килде. Мирхәйдәр мулланың шәрык шигъриятен тирән белүе дә, үзенең дә шигырьләр иҗат итүе, Апуш шәкерт каршысында бер мәктәп иде кебек. Җанбикәчне мөселманлыкка кире кайтарганнан соң, Чулпаный Мотыйгулла хәзрәт үтенече буенча, берничә көн мәдрәсәнең ятакханәсендә шәкертләр арасында калырга булды.

—Мелла Мирхәйдәр!—диде хәзрәт.—Шәкертләребезгә борынгы татар әдәбияты турында бер-ике дәрес әйтсәнез, мәмнүн булыр идем. Уфага барырга үзенезгә бераз әҗере дә булыр иде.

Чулпаный бик шатланып риза булды. Хәзрәт аны үз йортында торырга кыстаса да, шагыйрь рәхмәт әйтеп баш тартты:

—Остазым!—диде ул.—Шагыйрь кеше йомшак ястыкка ятса, аның фикере израп китә, шәкертләр сырмасына ятсам, яхшырак булмасмы?

Уку тәртибен бераз үзгәртеп, олы сыйныфтагы шәкертләр вә дәхи пишкадәмнәр өчен махсус дәресләр оештырылды. Беренче дәрестән үк шәкертләр Чулпаныйны ошатып өлгерделәр. Чулпаныйның үзен бик садә тотуы, кычкырмыйча, таяк тотмыйча, кирәк чакта мәзәк сөйләп, кирәк чакта тантаналы тавыш белән нәгъръә орып сөйләгәне беркемне дә битараф калдырмый иде. Борынгы шагыйрьләребез турында сөйләгәндә аларның һәр шигырен яттан, мәгънәле вә тантаналы итеп укуы үзе бер тамашага әверелә иде. Аның беренче дәресе Мәүлә Колый иҗатына багышланган иде.

Дәресханә шыгрым тулы иде, Чулпаныйның «Мотыйгыя»да әдәбият дәресләре бирәчәге турындагы хәбәр тиз таралып, башка мәдрәсәләрдәге шәкертләр дә килгән иде. «Рәкыйбия» шәкерте Минлебай белән Габдуллаҗанның урыннары янәшә туры килде. Шәкертләр җыелып беткәч, җиз кыңгырау зыңгылдагач, ишек ачылып китте, ишектән каракүл бүрекле, кара казаки кигән, дәртле, гайрәтле ир кеше килеп керде. Башка хәлфәләр кебек ул күтәртмәгә утырмады, аягүрә калды һәм керер-кермәстән, шәкертләр алдында әрле-бирле йөренә-йөренә көчле тавыш белән сыйныфтагылар каршына шундый сорау ташлады:

—Нәрсә ул мәхәббәт?

Муллалар, хәлфәләр авызыннан Коръән аятьләренең тәфсирләрен генә ишетергә өйрәнгән шәкертләр өчен бу аяз көнне яшен сугуга тиң иде. Остаз тирән психолог иде. Аның каршысында уналты яшьтән алып, егермесен тутырып, мулла-мөәзин урыны бушаганын көтеп, хәтме көтеп—пишкадәмнәр утыра. Алар инде хатын-кызны төшләрендә күрә, алар өйләнергә яки мәгъшука табарга хыяллана. Бәгъзеләре инде тәтәйләр йортына да баргалыйдыр. Сорауны ишеткәч, сыйныф аптырап, тын калды, аннан соң чышы-пышы китте, аннан соң бөтен күзләр, бөтен игътибар остазга төбәлде, җавапны остаз үзе әйтәчәк иде.

Чулпаный соравының тамашачыга ничек нык тәэсир иткәнен, аларны тораташ катырганын яхшы аңлый иде. Тынлыкны озакка сузарга ярамый, игътибар йомшаячак, тезгенне тагын кулга алып булмаячак. Чулпаный фокус күрсәтүче сыман, үкчәсендә бер кат бөтерелеп алды да:

—Мәхәббәт алты төрле була!—диде:—Аллаһу Субханаллаһу Тәгаләгә...

Пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлламгә... Ата-анага мәхәббәт... Хатын-кызга, ягъни хәләленә мәхәббәт... Балаларыңа мәхәббәт... Халкыңа, ватаныңа мәхәббәт... Шушы мәхәббәтләрнең берәүсе җитешмәсә дә бәндә камил була алмый.

Чулпаный залга тулган халыкның дикъкатен үзенә ныклы җеп белән бәйләгән иде инде. Алга таба ул үзе хасил иткән мохиттә теләгәнчә йөзә ала иде.

—Мөселман-шәрык, аеруча болгар-татар шигърияте өч чорга бүленер имди. Әүвәл иҗат ителгән кыйссалар бары тик дини-әхлакый әсәрләр, ягъни Исламны, Коръәнне, хәдисләрне аңлату өчен язылган булсалар, икенче чор әсәрләр суфичылыкка килеп керә. Ягъни бу намәләр кешене дөнья мәшәкатьләреннән, хәяти ләззәтләрдән ваз кичеп, бары тик Илаһка табынып яшәргә өнди. Өченче чор шагыйрьләре кешенең бу тормыштагы кайгылары, шатлыклары, бу хәяттәге ләззәтләрен яктыртырга омтыла...

Остаз әйткәннәрне язып баручыларга бераз форсат биреп, язмаганнарга ташланган фикерне сеңдерер өчен, бераз тынып торды да фикерен дәвам итте:

—Беренче чор вәкилләре бихисап күп, ләкин мин сезгә аларның иң хассиятлесе, шул агымның ялтырап торган бер вәкиле турында сөйләрмен. Ул—Мәүлә Колый! Аның үз исеме Бәйрәм Гали Колыев, ул Казан артындагы бер авылда туган. 1677 елда шагыйрь Мәүлә Колый үзенең үлмәс «Хикмәтләр» китабын тәмамлый. Борынгы бабамыз Мәүлә Колый гаилә, мәхәббәт турында гаҗәеп әсәрләр калдырган. Никахлы хәләл ир белән хатын хакында Мәүлә Колый бабамыз болай ди:

Хәләл нуры нурлы торыр көнәш нурдин,
Хәләл берлә сәвешмәк татлы балдин;
Ике хәләл бер-берсенә хушнуд кылмак.
Нәзек торыр назиклектә нечкә кылдин.
Ир-хатын мәхәббәттә сөхбәт кылса,
Анлар өчен гүзәллекләр хасил булыр.

—Гаҗәп бит, җегетләр, ә! Ир белән хатын арасының назик бер сәнгать-мәхәббәт кылы икәнлеген кемнең әле болай нәфисәи сәнгатьчә әйтә алганы бар?

Кыз углан рәүшан торыр якты көндин,
Ата-анага ләззәтледер шәкәр, балдин;
Хак әмере илә хәләленә тапшырмаклык
Назиклектә нәзек ирмеш өзелер кылдин.

Искиткеч назик сәнгатьтер бу юллар! Кыз бала якты көндин дә якты-нурлы зат, диме? Гаиләдә артык түгел кыз бала. Шикәр-бал ләззәте бирә икән кыз бала ата-анага. Шул нәфисәи сәнгатьне, ягъни кыз баланы назик тәрбия кылып, Хак әмере илә кияүгә бирү ата-ананың изге бурычы, диме Мәүлә Колый бабабыз? Гүзәл бит, җегетләр, ә! Шундый шагыйрьләребезнең шигырьләрен өйрәнгән җегет белән кыз мәхәббәттән коры каламы? Юк! Алар үзләре дә мәхәббәт иясе булып, башкаларга да гыйшык ләззәте бирерлек бай табигатьле булачаклардыр! Каршыгызда ярты гасырдан артык яшәгән кеше тора. Җиңел бармады тормыш, хәзер дә җиңел түгел. Ләкин аптырыйм мин зарланган бәндәләргә. Хатыныннан зарланган ирләрне мин аңламыйм. Ирен хурлаган хатыннарны мин сөймим. Имеш, мәхәббәт юк, янәсе; ул—китаплар, шагыйрьләр уйдырмасы гына. Мәхәббәткә ышанмаган булсам, мин бу тормыш болганчыгыннан исән-аман чыга алмаган булыр идем. Мине денле булуым, сәнгатькә тартылуым, Мәүлә Колыйлар саклады... Мәүлә Колыйга карагыз сез менә, үзенә ул Мәүлә Колый кушаматы алган, ягъни Алла Колы. «Мәүла»—

Аллаһы Тәгаләнең исемнәреннән берсе. Менә шушы Алла Колы—мәхәббәт колы да. Ул колагыннан гыйшыкка баткан адәм булган. Татарда менләп шагыйрьнең исеме мәгълүмдер ки, әмма кайсысы шулай яза алган?!

Гашыйк улдыр—Хак юлында гыйшык ирсә,
Каушу теләп жан күнели фида кылса,
Бу дөньяны күзгә алмас хальгә килсә.
Гашыйклар тик Хак юлына кергүл килүр.
Гашыйк кеше Хакга лаек булса кирәк,
Мәхәббәтдин күнле аның тулса кирәк...

Хәйран бит, жегетләр, әй! Мәхәббәтне Илаһ-Хак Тәгалә дәрәжәсенә менгезгән шагыйрь—белегез—ул Мәүла Колыйдыр! Ихтимал, бу өлкәдә әле ана тиңнәр юктыр да!

Габдулла кичләрен, төннәрен укып ятар өчен, башкалар күзенә яктылык төшмәсенгә үзенә бер хөжрә әтмәлләгән иде, чаршау белән капланган шул хөжрәсен ул остаз Чулпаныйга бирде. Монысы исә «кара халыктан» аерыласы килмичә, чаршауны кырга тартып куйды. Имеш, чаршау шәкертләр белән мөзакәрә кылырга комачау итә икән.

Кичләрен шәкертләр Чулпаныйның шигырьләрен, әдәбият турындагы нотыкларын тыңлый. Чулпаный да Габдулланың башка шәкертләрдән бик күпкә өстен фикер йөртүен аңлап алган иде. Алар мәдрәсә ятакханәсеннән чыгып, су буйларына төшеп, сәхраларга чыгып, салмак кына әңгәмә кора.

Менә алар Чаган елгасы ярына утырып, ара-тирә вак ташларны суга ташлап, серләшәләр.

Алар остаз белән шәкерт түгел, әйтерсең лә тормыш тәҗрибәсе туплаган кордашлар кебек иде.

—Дустым!—дип бик гади генә эндәште мелла Мирхәйдәр:—Халыкны өч йөз илле еллык золымда нәрсә саклап тотты? Дин! Дин, әфәндем, саклады халыкны. Әхлаксызлыктан, сәрхушлыктан, хатын аерудан, балаларны ятим итүдән дин тыеп торды. Икенчесе —Ана теле!..

Габдуллаҗан бу кешегә сокланып бага, аның һәр сүзен йотып бара иде.

—Ә ни-нәрсә харап итә милләтне?—дип үзенә үзе сорау куйды мулла. Һәм үзе үк шул сорауга җавап әйтте:

Харап итте бези, һай, бу җәһаләт!
Нәләр япты безә, аһ, бу сәфаләт?

Халык нигә мескен? Чөнки ул надан! Надан кеше мескен була! Халыкны наданлыктан, җәһаләттән тартып чыгарсак, ул сәфил-мескен булмаячак.

Остаз тынып калды, аннан бераз моңланып алды да, үзалдына гына сөйләнгәндәй шигырь әйтте:

Кәфер әмрендәки мискин мөслим
Нәләр кыйлсун, кем якласун?
Элмәккә, сөрелмәккә дучар булсын.
Катыйле нәфес гөнаһ улмаз, имди.

Мирхәйдәр мулла үзенең остазлары Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки турында сәгатьләр буе талчыкмыйча сөйли, аларга соклана иде.

—Күнелдән китәрер өч нәстә кайгу:
Сөяр яр, яшел чирәм, агар су.

Өч нәстә күнелгә кайгуны китерер:
Яман юлдаш, яман хатын, яман холык!

—Каргалый әбзаң шулай әйткән, Габдуллаҗан!—диде Чулпаный.

—Хөрмәтле мелла Мирхәйдәр әфәнде!—диде Габдуллаҗан:—Синең шагыйрь булуыңда остазың кем?

Тыңлаучысы булганда Чулпаный рәхәтләнеп белгәннәрен аңарга сөйли, ул мирас тапшырырга әзер торган киң күнелле шәхес иде. Аның янында җаны белән тыңларга әзер торган шәкерт бар—ул Габдуллаҗан. Ул сөйләгәннәр җилгә очмас, ул әйткәннәр бу зирәк шәкертнең игътибарыннан читкә китмәс.

Мирхәйдәр мулла ирен кырые белән елмайды:

—Сөалең авыр, шәкерт!—диде мулла.—Алар күп, Әмрәләрне, Низамиларны, Колыйларны саный китсәң, көнең җитмәс. Ә менә Шәмсетдин Зәки иң якынысдыр, ихтимал.

—Сөйләле, зинһар, Мирхәйдәр остаз! —диде Габдуллаҗан.—Шәмсетдин Зәки турында...

—Остазым Шәмсетдин Зәки тома сукыр булса да, күнел күзе белән мангай күзлеләрдән яхшырак күргән. Әхмәтҗан Нуриман исемле бер мулла белән Зәки остазның бәхәсе тарихта калган.

Мирхәйдәр мулла иркенләп сөйләргә җыенды.

—Шәмсетдин Ярәхмәт углы Гобәйдуллин 1825 елда Оренбур өязе Зәк суы буендагы Ишмәт авылында сукыр бала булып дөньяга килә...—дип башлады остаз.—Ләкин Аллаһы Тәгалә аңа гаҗәеп шәп хәтер вә үткен зиһен биргән була. Ул мәдрәсә тәртипләреннән тыш та бик күп китапларны өйрәнә, дөнья фәйләсүфләре, суфиларның тәгълиматларын су кебек эчә, хәтта ул остазларын да, күзле яшьтәшләрен дә күпкә артта калдыра. Шуның өстенә үзе дә шигырьләр яза, мәшһүр шагыйрьгә әверелә, бик күп олы шагыйрьләргә (Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла һ. б.) остаз да була.

Узган гасырда яшәгән татар шагыйре Зәки, сукыр булуына карамастан, искиткеч хәтерле, гаҗәеп дәрәҗәдә зиһенле, кайбер күзле кешеләрдән дә тизрәк һәм күбрәк йөри торган кеше булган. Шуңа күрә кайберәүләр аның сукырлыгына шикләнеп караган.

Ашказар Балыклы мәдрәсәсендә укыганда ул егерме чакрым ераклыктагы Кара Киртә авылына берүзе кайтып йөри торган була. Анда шагыйрьнең туганнары яши икән. Шулай беркөнне Ашказар Балыклы авылының бер кешесе—Шаһимөхәммәд атлы шымчы Шәмсетдин Зәкине сынау нияте белән, ул узачак юл кырыена барып ята. Шагыйрь бу кеше турысына килеп җиткәч мышнавыннан танып:

—Әссәламегаләйкем, Шаһимөхәммәт абзый, монда нишләп ятасың?—дигән.

Шаһимөхәммәт үз нәүбәтендә:

—Сине күрми дип әйтәләр иде, күрәсең икән!—дигән.

Аңа каршы шагыйрь:

—Күнел күзе күргәч, заһир күзнең күрмәве зарар түгел,—дип әйткән дә юлын дәвам иткән.

Габдуллаҗан көлеп куйды. Мирхәйдәр мулла сөйләгәннәрне ул чынбарлык буларак күз алдына китерә, вакыйгада катнашкан шәхесләрне чынлап күрә иде кебек. Кунак шагыйрь янә дәвам итте:

Бервакыт Шәмсетдин Зәки белән Әхмәтҗан мулла Нариман телгә килә.

—Корьән-и Кәрим! Бары тик Коръән-и Кәрим!—ди Әхмәтҗан мулла.—Мөэмин адәм Коръән-и Кәримне белсә, бәгъзе һичбер китап аңа лазем түгел! Ташла, мелла Шәмсетдин, бу шөгыленне! Өйрән, укы син шәйтан сабагын, әллә

нинди китапларны, гөнаһысы үзенә булыр! Әмма син бүтәннәргә, шәкертләргә ул сабакны бирмә! Разыйлыгым юк! Бозма мөэмин мөселманнарның җаннарын!

—Әй, син, мине фәлсәфә өйрәнүдән һәм аны сөйләүдән тыйган адәм! Тыңла!—ди шагыйрь.—Ибраһим пәйгамбәрне син таныйсыңмы?

—Таныймын,—ди мулла.—Пәйгамбәрем Ибраһим галәйһиссәламгә бән инанамын. Йә, шуннан ни?

—Ибраһим пәйгамбәребезнең, күктәге җисемнәрнең яктыртуын һәм сүнүен күреп, шуларның кодрәт белән барлыкка килүләрен аңлаганнан соң, бу җисемнәрнең Аллаһ булырга хаклары юк, дигән фәлсәфи бер фикергә килүендә мин бер дә ярамаган нәрсә күрмимен. Мондый көчле дәлилләр аркылы нәтиҗәгә житү бары тик якты, бай һәм камил акыл аркасында гына булырга мөмкин. Ибраһим пәйгамбәр—Аристотель белән Әфләтунның шәкерте ул!

Мулла:

—Көфер сүз, мелла Шәмсетдин!—дип кычкыра Нариман мулла:—Әстәгъфируллаһ! Ибраһим пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләнең йомышчысы, әллә нинди Аристотель вә Әфләтуннар илчесе түгелдер кем! Без Аллаһка суфыйлык аша түгел, мотлак инану аша якынаерга тиеш!

Аңа каршы шагыйрь:

—Корьән-и Кәримдә Ибраһим пәйгамбәр турында язылмаганмы, Әхмәтҗан мулла?—дип сорый:—Инни вә җәһтү вәҗһиә лилләзи фәтарәссәмәуати уәл-арда ханифән уә ма әнә минәлмүшрики-ин, ягъни Ибраһим күк җисемнәренең янганнан соң сүнгәнен күргәч, әйтте ки: мин яманлыктан Хакка авышканым хәлдә Җир вә күкләрне төзүче Аллаһуга йөземне юнәлдердем вә мин Аллаһуга һичкемнең һичнәрсәне тиңдәш кылучы түгелмен, мин мөшрик түгелмен! Шулай түгелме, хәзрәт?

—Хак сүз, мелла Шәмсетдин,—ди Нариман.—Корьән-и Кәримдә шулай язылган.

Шагыйрь тагын тәвам итә:

—Ләкин бит бу хакта Аристотель белән Әфләтун остазлар әйткән. Күк җисемнәренең хәрәкәте Аллаһтан тора, хәрәкәтләрнең сәбәпчесе Аллаһтыр. Һәр күренеш, һәр пәйда булыш, вә юкка чыгышның сәбәпчесе—Аллаһтыр. Аллаһ ул тәнсез, матдәсез акыл иясе, шуңа күрә дә Аллаһ үзгәрүләргә, тузуга дучар түгел, ул мәңгелек, дигән Әфләтун остаз. Ягъни, Әфләтун бабай Корьән иңгәнгә чаклы мең ел алдан: Алла бар, Алла бер, Алла мәңгелек, дип әйткән.

—Сафсата!—дип кычкыра Әхмәтҗан мулла.

Шагыйрь ярым шаяру белән әйтә:

—Валлаһи, мин Аллаһы Тәгаләнең Җир белән Күк яратылышы хакында фикер йөртерләр, дигән сүзләренең мәгънәсен аңлауга—үземнең күңелемдә һәм үсешемдә Аллаһка мохтаж икәнемне аңлауга—бары тик шул фәлсәфәне өйрәнгәч кенә элгәштем.

Мулла һаман үзенекен тукый:

—Корьән-и Кәрим, бары тик Корьән-и Кәрим безгә рәһбәрдер. Башка китапларның, фәйләсүфләрнең ихтыяҗы юк!

—Үзең белмәгәннең бөтенесен дә инкарь итмә, Әхмәтҗан мулла!—ди шагыйрь.—Син начар дип уйлаган әйбердә Алла биргән бик күп яхшылыкларның булуы бар. Дөреслектән читтә йөргән мөритләр хакыйкать бик ерак дип уйлыйлар, ә хакыйкать бер дә ерак түгел, муен тамырыңнан да якынрак.

—Хакыйкать Корьән-и Кәримдә генә!—дип мыгырдана сүзен бирмәс мулла.

—Корьән-и Кәрим укырга, өйрәнергә куша,—ди Зәки.—Хәдисләр надан булмаска өнди. Ә син, Әхмәтҗан мулла, Корьән-и Кәримне дә, хәдисләрне дә инкарь итмәкчемени?

Мулла бәйләнчек чебенне кугандай кулларын бутый башлый:
— Тефү, әстәгъфируллаһ! Кяфер!
—Хакыйкатьне эзләүче кяфер бозыклык артыннан йөрүче мөселманнан хәерлерәк!—ди Шәмсетдин Зәки.
—Әлбәттә,—диде Мирхәйдәр мулла хикәясен тәмамлагач,—Әхмәтҗан мулла Нариман шагыйрь Шәмсетдин Зәкине аңламый да, гафу да итми, ул шагыйрьнең дошманына әверелә. Шәкертем, мин Сукыр суфый Зәки турында сиңа тагын бер хикәят сөйлим! Тыңла!
1865 елда Габдулла Дәүләтшаһ исемле бер ахун, дин эшен ташлап, кантун башлыгы булып китә. Элек сәдака белән халыкны имгән булса, кантун булып алгач, Габдулла ахун халыкны чыбыркылап талый, мал җыя, типтерә, урыс түрәләре белән әшнәләшә.
Шагыйрь Шәмсетдин Зәки бу гаделсезлеккә түзә алмый, әче сүзле такмаклар чыгара:

Габдулла ахун, кантун булгач,
Окружнойга таныштың.
Башындагы ак чалмаңны
Фуражкага алыштың.

Габдулла ахун кантун булган
Исәнголга, башкортка.
Өч сум акча ала икән
Полгодовай пашпортка!

Шушы такмаклар халык арасында бик тиз таралып өлгерә, телдән-телгә күчеп, бөтен ил буйлап тарала, Габдулла ахунның үзенә дә барып ирешә. Зәки остазның тагын бер олы, мәкерле дошманы арта. Дошманнары күбәйгәч, шагыйрь Шәмсетдин Зәки урын күчеп йөрергә мәҗбүр була.
Озакламый сукыр суфи Шәмсетдин Зәки хаҗ сәфәренә китеп бара, ләкин ул Рәсәйдән дә чыгып китә алмый, кырык яшьлек сәламәт шагыйрь Таганрог шәһәрендә 1865 елда сәер рәвештә үлеп китә. Әче телле, гаделлек эзләүче, рәнҗетелгәннәрне яклаучы, түрәләргә рәхимсез суфи Шәмсетдин Зәки үз үлеме белән үлә аламы?
Чулпаный туктады, ул үзе дә хикәясеннән тәэсирләнгән иде, ахрысы. Агым суга баккан килеш тын гына утырды. Габдуллаҗан кунак сөйләгән вакыйгаларның соңында: «Шәмсетдин Зәки үз үлеме белән үлә аламы?» дигән сорау Чаган-су ярына эленеп калды кебек. Ни әйтергә теләде хикәяче? Әллә ул Шәмсетдин Суфыйның әҗәл тарихын беләме?
Хикәяче үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:
—Иннә лиллһи үә иннә иләйһи раҗигун. Әллаһүме инкәнә һәдәлмәй йиту мүхеинән фәзид фи ихсәниһи үә ин кәнә мүхсиэән фәтәҗәүәз ганһ!
Икесе дә учлары белән йөзләрен сыпырды. Габдулла хикәя тәэсирендә иде. Мирхәйдәр остаз аңлады, Габдулла Шәмсетдин Зәкинең тормышын үз вәҗүде, үз зиһене аша кичерә иде.
—Сукыр Суфый булуына карамастан,—диде нотыкчы,—бу кеше безнең күз алдыбызда мескен булып, аягын чак кыймылдатып таяк белән кармаланып йөргән хәлдә килми, бәлки... юлына аркылы төшкәннәрне кырып-җимереп, җир өстен дер селкетеп, алга, үзенең максатына омтылган бер Алып батыр хәлендә килә!.. Даһилык дәрәҗәсендә истигъдатлы лирик... аны мәшһүр Иран шагыйрьләренә тиңләштерәсе килә... Соңгы ике-өч гасыр эчендә язган күп санлы борынгы татар шагыйрьләре эчендә, сүз остасы булу ягыннан, Шәмсетдин остаз дәрәҗәсенә ирешкәннәр юк! Бу чыннан да шулай.
Алар ятакханәгә кайтканда шәкертләр йоклап беткән иде инде.
Соңгы көнендә Чулпаный дәресен Кандалыйга багышлады.
—Габдел Җәббар Кандалыйның атасы 1840 елда үлеп китә. Аның урынына Габделҗәббар мулла булып кала. Ләкин яна мулла бик дәртле, гайрәтле вә бик тә иркен яши башлый. Күңел күзе төшкән гүзәлләргә атап шигырьләр чыгара, үз хисләрен ул халыктан да, динчеләрдән дә һич яшерми. Тик нишләптер,

мәхәббәт өлкәсендә ул гел уңышсызлыкка гына очрап тора. Кандалыйның күзе төшкән һәр чибәр кыз башкага кияүгә чыга бара. Кандалый өзгәләнә, бәргәләнә, мәхәббәтен аңлата алмаганына үкенә, үзен ташлаган кызга каһәр укымый, гүзәл шигырьләр яза. Һәр мәхәббәт фаҗигасе Кандалый авызыннан гөлт итеп утка әйләнеп, шигырь булып чыга тора. Кандалый шәкерт чагында Әминә исемле бер гүзәлгә үлеп гашыйк була; тормышка ашмас бу мәхәббәт шигырьгә әверелеп кала:

Ни шау-шу, мәдрәсә гөрли...
Минем кальбем сине уйлый.

Шонталы авылы гүзәле аны ташлап кияүгә чыккач, шагыйрь шундук шигырь әйтә:

Нигә булган бу Шонталы?
Минем йөрәкне тырнады:
Мин өйләнгәнче тормады,
Китеп барды бу кыз иргә.

Фатыйма исемле башка бер гүзәл Кандалый күңеленә бик тә хуш килә, тагын йөрәктән шигырь кайнап чыга:

Синен дәрдеӊ мәӊа төште кечекдин,
Газиз башым гариб булды гыйшыкдин.
Бәне кечкенә мальчиктай кимсетеп,
Олы итеп күрмәдеӊ һич, и туганым.

Кандалый гашыйк булган кызлар, аның хисләренә, шигырьләренә җитди карамаганнар, ахрысы, аны яннарыннан куганнар, аның мәхәббәтен кабул итмәгәннәр, хәтта бу сәер мулладан көлгәннәр дә:

Ки бән вардым сәне сөеп, алам дип:
Ки сән бәне кудың, «тиле малай» дип.

Мәхәббәттә шулай янып-көеп яшәүче Кандалый сәяси эшләрдә һәм дин өлкәсендә дә бимазалы, кыен тормышта яши, кыйнала, читкә тибәрелә. Кандалыйның бай, тынгысыз, гайрәтле табигате кануннарга, авылдашлары янына сыеша алмый. Аның өстеннән әләкләр, шикаятьләр, нахак сүзләр, астан да өстән дә чагулар башлана. Ләкин остаз шүрләп калмый. Борынын салындырмый. Ул һаман мәхәббәт эзли, ул һаман шигырь чыгара:

Килсен, җөмлә, берәр түрә волостьтан.
Курыкмыйм мин вә дәхи ки урыстан!

Кандалый Бәгыйдә атлы яңа бер гүзәлне сөя башлый. Ләкин Кандалый кебек күпкырлы талантлы шәхес бәхетле була алмый, юк. Андый шәхесләрне гүзәлләр сөйми, кабул итми, аңламый. Йә аны «мальчик», «тиле малай» дип мыскыл итәләр, йә бүтәннәргә кияүгә чыгып, Кандалыйны хәсрәт учагына аталар.

Кандалый Гөлстан исемле кызга гашыйк була.

Гөлстан... Исме бик матур,
Үзе гүрничәдә ятыр,—
Укырга, эшкә дә батыр,—
Аны алмый йөрәк түзми!

Ниһаять, Гөлстан Кандалыйның хатыны була. Ләкин шагыйрь Гөлстанга өйләнеп бик каты ялгышканлыгын анлый. Гөлстан шагыйрь хыялындагы бай рухлы хатын-мәгъшука була алмый. Гөлстан Кандалыйның кара кайгысына әверелә.

Кандалый Борнай авылы кызы Фәрхисорурга чын йөрәктән гашыйк була. Фәрхисорур Кандалыйга өч ел буена шигырь илһамчысы була.

Ике ел торды бул күнлем
Чыкармый гашыйк базыннан;
Өченче елны чыкардым,
Чыкардым сабрым азындан.

Ике ел яшерен сөйгәннән сон, сер өченче елны ачыла. Ләкин Фәрхисорур Рәҗәп авылы җегетенә кияүгә чыга. Дөрес, ул да бәхетле була алмый: бер баласы белән ире аны аерып җибәрә. Фәрхисорурның әче язмышы турында Кандалый поэма яза.

Кандалый бәхетсез шәхес, аның вөҗүдендә тормышка ашмас мәхәббәт:

Ки бән дәхи сәнең кеби
Һаваландым, и жанкай ла.
Үземә тапмадым тинне,
Тик эстәп кашкалы-минле,
Юлыктым аңгы-миңге,
Җүләр ярга, и жанкай ла.
Отыйм дигәндә—отылдым,
Тотыйм дигәндә тотылдым,
Соңындин көчкә котылдым—
Ки биш ел сон, и жанкай ла.

Кандалый Пәрәү кызы Сәхипҗамалга сөю хатлары яудыра башлый. Ләкин илле дүрт яшьлек Кандалый япь-яшь кыздан сөю җавабы алалмый. Әче тулы—җавапсыз мәхәббәт сагышы; җитмәсә, моңа урыска хезмәт итүче сөекле углының егерме биш елга солдат хезмәтенә алынуы өстәлә. Өендә җене сөймәс хатыны Гөлстан утыра. Урыс түрәләренең аны сөймәве, татар түрәләренең аның өстеннән әләкләр язып торулары, үзе теләгәнен эшли алмавы Кандалыйны эчтән талаcа да, ул тыштан гаять көр күнелле, шат вә шаян була белгән. Ләкин эчтәге юшкын үз эшен башкара; шагыйрь, мәхәббәт җырчысы, дин галиме бөек Кандалый алтмыш өч яшендә 1860 елда вафат була.

Аның кабере Иске Кандал (Иртуган) авылы зиратында.

Авыр туфрагы җинел булсын!

—Амин! —дип шәкертләр дәррәү дога кылды.

—Сөальләренез бармы?—диде Чулпаный.

Габдуллаҗан тамак кырды:

—Остаз!—диде ул.—Кандалыйның бәгъзе бер әсәрләрендә матбугатка язарга ярамаган, телгә алырга тыелган әдәпсез сүзләр бар. Һәм дин ягыннан, һәм гомум әдәп ягыннан моны ничек аңларга?

—Табигый сөаль, шәкертләр!—диде остаз.—Кандалый алда саналган шагыйрьләргә, муллаларга караганда чын халык телендә сөйли, чын халык телендә яза. Ул халык телендә булмаган бер генә кәлимә дә кулланмый. Коръәнне яттан белүче хафиз утыра арагызда, ул Колбай Мораса авылында туып-үскән егет—Миңлебай Хәйруллин, хәзерендә «Рәкыйбия» шәкерте, сез дә Коръәни Кәримне яхшы беләсез... Без—муллалар Коръәнне сабыйларга сигез-ун яшьтән өйрәтә башлыйбыз. Шәкерт Миңлебай!—диде остаз.

—Мин монда, остаз!—диде шәкерт.

—Хаҗ сүрәсенең бишенче аятен укып бирче, зинһар!

Миңлебай аягына басып, һич тотлыкмыйча, аятьне укып күрсәтте.

—Машалла, шәкерт!—диде остаз.—Син ничә яшьтә хафиз булдың?

—Уникедә, тәкъсир!—диде Миңлебай.

—Димәк ки, муллалар, ата-ана сигез-ун яшьлек сабыйга баланың ничек яралганын аңлатырга тиеш, нинди сүзләр белән аңлатырга тиеш? Ир җенес белән хатын-кыз җенесе кушылганнан бала ярала, ул бала ана карынында өч пәрдә сагында үсә, аннан соң дөньяга килә. «Хатыннарыгыз сезгә иген кыры кебек, сез шул иген кырына теләгәнегезчә якыная аласыз», ди Аллаһы Тәгалә. Без моны шәкертләргә ничек аңлатырга тиеш? Ир белән хатын мөнәсәбәтләре турында Коръәни Кәримдә бик күп язылган. Бәс, Габдуллаҗан әфәнде, Кандалыйның бәгъзе сүзләрен әхлаксызлык байрагы итеп болгамаска кирәктер.

Мәдрәсә диварлары арасында моңа кадәр ишетелмәгән нотыкны тыңлау шәкерләр өчен генә түгел, анда утырган хәлфәләр, мөгаллимнәр өчен дә олы ачыш иде.

Соңгы көн булгангадыр, ахрысы, берәүнең дә иртә ятасы килмәде. Яткач та шәкертләр Чулпаныйны сораулар белән тинтерәтеп бетерделәр. Таң алдыннан гына алар йокыга китте.

Икенче көнне таң атар-атмаста ятакханә ишеге артында тавыш купты. Ул да булмады, ишек каерылып ачылды, аннан ике околоточный[2] белән бер жандарм дөберләп керде, аларның артында Хәйрулла Гаделшинның шәүләсе күренде.

Шәкертләр куркынып, кайсы җылый, кайсысы калтырана башлады.

—Гражданин мулла Мирхайдар Чулпани!—дип кычкырды жандарм.

—Мин!—диде кунак.

—Одевайсь!—дип кычкырды околоточный.

Шагыйрь юрган астыннан чыгып, киенә башлады.

—Минем ни гаебем бар, гаспадин жандарм?—диде мулла.

—Разговоры прекратить! Вопросы не задавать!—дип кычырды жандарм.— Арестовать!

Околточный алтатарын чыгарып, кунакка төзәде дә:

—Руки за спину! Шагай!—дип кычкырды.

Аптыраган кунак ике кулын артка куеп, ятакханәдән чыкты. Каушап калган Габдуллаҗан да башка шәкертләр белән урамга атылды. Урам буйлап, берсе алдан, икенчесе Чулпаныйның артыннан, берсе кылычын ялангач тотып, икенчесе алтатарын Чулпаныйның сыртына терәп, участокка алып киттеләр.

—И ходаем, нинди гаебе чыккан ул кешенең? Алла сакласын!—дип капка төбендәге кешеләр куркышып, әсирне карашлары белән озатып калдылар.

Габдулла җанын кая куярга белмәде. Ары чапты, бире йөгерде, аннан соң Мотыйгулла хәзрәтне мәчеттә эзләп тапты.

—Эшләр шәп түгел,—диде остаз.—Чулпаныйны кулга алырга Самара политсәмистереннән безнең полисәмистергә срочный телеграм килгән. Имеш, Чулпаный мулла рус хатыны Анастасияне ирексезләп алып киткән. Имеш, ул рус хатынын ирексезләп исламга кертергә уйлаган.

Дөрестән дә, эш зурга китте. Бозаулык шәһәре мулласы, шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаныйга җинаять эше кузгатылды. Мотыйгулла хәзрәтнең дошманнары, өченче отделениенең ялчылары Хәйрулла Гаделшин белән әнчек Госман хәлфә әләкләве аркасында жандармнар Жанбикәчнең качып яткан йортына басып кереп, кызны тарткалап, йолыккалап частькә алып киткәннәр. Урамдагы халык кызның:

—Мин мөселман! Минем янадан чукынасым килми! Әшһәдү ән лә иләһә иллаллаһу вә әшһәдү әннә Мухаммәден габдүһу вә рәсүлуһ! Лә иләһә илләлләһү Мөхәммәде рәсүлулла! Лә иләһә илләләһу Мөхәммәде габдуһу вә рәсүлуһ!—дип илаулап барганын күргәннәр. Тикшерү эшләрен озакка сузмыйча, Чулпаный белән Жанбикәчне этап белән кире Самарага, зинданга алып киттеләр.

Бу вакыйга татар бистәсенә бик авыр тәэсир итте. Алга таба бу күңелсез

[2] околоточный—кишәрлек полицейские

хәлнең тагын да олы фаҗигагә әверелүен әле берсе дә белми иде. Окружной судка Мотыйгулла хәзрәтне дә чакырганнар, шаһит буларак түгел, гаепләнүче—җинаятьче буларак.

Хәзрәт шул китүеннән ике атнадан соң гына әйләнеп кайтты.

Окружной судта прокурор Чайманов Чулпаныйны рус хатыны Анастасияне урлап, Ислам диненә кертергә маташканы, Анастасиянең поп кушкан исемен алмаштырып, Җанбикәчкә әверелдерү йоласында катнашканы өчен Мотыйгулла хәзрәтне дә хөкемгә тартканнар.

—Ярый әле яхшы адвокат табылды!—диде хәзрәт.—Юкса, китә иде башлар.

Илья Рудольф исемле адвокат, түләү алмыйча, Чулпаныйны якларга алынган.

Прокурор Чулпаныйны каторгага җибәрергә, Җанбикәчне монастырьга кайтарырга, Мотыйгый хәзрәтне ике елга вострогка ябарга тәкъдим ясый. Яклаучы Рудольф Илья салмак-сабыр гына яклау нотыгын башлый.

—Господин судья, господин государсвтенный обвинитель, господа присяжные! Щекотливые отношения продолжались по делам магометан России. Синод жаловался, что в Казани, в Саратове, в Самаре и в Сибирьских городах России мусульмане строят мечети и усердно исповедуют ислам. Протестуют против насильного крещения инородцев. И Синод крепко обвинил в этом Самарского губернатора Квашнина, за то, что он позволял мусульманам строить мечети во ввереной ему губернии. Самарский губернатор Квашнин сказал Синоду, что это было сделано по устному указу императрицы. Великая царица Екатерина Вторая на что велела отвечать: как всевышний Бог на земле терпит все веры, языки и исповедания, то и она из тех же правил, сходствуя его святой воле, и в сем поступает, желая только, чтоб между подданными ее всегда любовь и согласие царствовали; а впрочем, ее величество приказать соизволили Сенату объявить, что губернатор Квашнин-Самарин дозволение строить каменные мечети сделал в сходственность данного большого наказа 404, 495 и 496 статей!

Назначая этим невинным людям суровое наказание, мы нарушаем Российские законы. Она не русская женшина, вот ее истинные документы, она рождена татаркою в татарской семье, но ее родители умерли с голоду и она осталась сиротой и деятели церкви силой захватили ее и перекрестили против ее воли, назвав ее Анастасией, во-первых, она не добровольно приняла християнство, ибо она еще почти ребенок, во-вторых, нет такого закона, чтоб насильно обращать инородцев в христианство. Нет вины и господина Мирхайдара муллы, он зная, что Джанбикеч татарка и ее насильно увезли в монастырь, решил освободить ее. Мутыгулла хазрет невиновен, ибо он не обращал русскую девушку в мусульманство, только был свидетелем ее возвращения в свою религию. Ибо в Исламе нет призыва насильному обращению людей в свою веру, Коран запрещает Могамеду неволить немусульман. Это большой грех для мусульманина.

Господа присяжные, вскоре после Пугачевского восстания Великая царица всея Руси Екатерина Вторая издала указ о веротерпимости. Покамест этот указ не отменен, господа вершители судеб!

Хәзрәт хикәясен тәмамлады да, уйга калды. Аның уе авыр, газаплы иде.

—Чулпаныйны аклады адвокат, аңа чиксез рәхмәтләр укыдык!—диде хәзрәт.—Ләкин Җаек мунтагайларыннан килгән жалулар аркасында аны өч айга төрмәгә яптылар. Имеш, Мирхәйдәр мулла Чулпаный Җаек мәдрәсәләрендәге шәкертләргә патшага каршы сүзләр сөйләгән!

Чулпаный чыгар, иншалла! Әмма Җанбикәч кенә манастырдан чыга алмас.

—Нигә?—дип сорады Габдуллаҗан.

—Поезддан аны туры манастырга алып китеп ябалар. Качканы өчен настаятельница аны бик каты кыйный. Аны манастырдан азат итәргә, дигән суд карарын китергәндә ул инде катиле нәфес булган. Үз толымына асылынган.

Тынлаучылар бер авыздан «аһ» иттеләр. Кемдер жылый, кемдер кара кайгыда иде, кемдер мәрхүмәнең рухына дога кыла башлады.

Габдуллаҗан Чулпаныйнын шигырен исенә төшерде:

Көфер әмрендәки мискин мөслим
Нәләр кыйлсун, кемнәр якласун?
Сөргенгә, элмәккә дучар булсын.
Катиле нәфес гөнаһ улмаз, имди.

Җанбикәчнең җәсаден монастырьга, христиан каберлегенә җирлиләр икән, дигән хәбәр Самара мөселманнарына ишетелгәч, мәхәллә-мәхәллә ирләр монастырь янына килеп, кызның мәетен таләп итәләр, монастырьдагылар капкаларны ачмый, жандармнар чакырта. Жандармнар озак көттерми, алар мөселманнарны урап алалар. Мөселманнар белән берлектә рус газеталарыннан журналистлар, адвокат Рудольф суд башкаручысы белән килеп, окружной суд карарын күрсәткәч кенә, Җанбикәчнең гәүдәсен татарларга алырга рөхсәт итәләр.

Шулай итеп, мөселман анадан туган кыз Җанбикәч өченче тапкырында мөселманлыкка кайта, аны ислам йолалары буенча татар зиратына җирлиләр. Шөкер!

Җәй җиттеме, гаиләсе булган шәкертләр өйләренә тарала, бәгъзеләре казакъ далаларына китеп, казакъ балаларына дәрес бирә, мулдәкә булып йөри. Габдуллаҗан җәйге татилдә беркая да бармый. Ул мәдрәсәдә ялгыз кала, Мотыйгулла кушкан йомышларны үти, метрикәләрне күчереп яза, шуңа аз-маз акча ала иде. Ләкин Габдуллаҗан ялгызлыктан тилмерми, киресенчә, ул ялгызлыкны ярата, китап укый, нидер яза, вакыт-вакыт салмак кына моңлана иде. Шундый моңлы кичәләрнең берсендә Мотыйгулла хәзрәт ятакханәгә бер егетне ияртеп керде. Бу егет кай төше беләндер озын буйлы Минлебай Хәйруллинга бик тә охшаш иде. Озын, төз буй, төзек матур чырай, иңсәсенә бер генә каптырмалы җилән элгән, кулына кечкенә бер юлкапчык тоткан бу егет итагать белән сәлам бирде.

—Кабул ит, Габдуллаҗан!—диде хәзрәт.—Төркия ватандашы Габдел Вәли Әмрулла, Истамбул дәрелфөнүне шәкерте.—Аннан Габдулла ягына ымлап.—Бусы Габдуллаҗан Тукай—безем алдынгы шәкертемез!—диде.

Мотыйгулла шәкертләрнең икесен генә калдырып чыгып китте. Унайсыз тынлык хасил булды.

—Хәзер чәй куям!—диде Апуш.

—Юк-юк!—диде кунак.—Хафаланман, лутфән! Мин хәзрәт софрасында сыйландым инде.

Апуш ни әйтергә белмәгәннән кунакка урын күрсәтте:

—Монда урыннар күп, җаның кайсын тели, шунда урынлаш!

Тора-бара бу ике егет инде иркенләп сөйләшә башлады. Апуш үзенең хәлләрен аңлатты. Габдуллаҗан аның гаять белемле кеше икәнен беренче җөмләсенән үк аңлап алган иде инде. Затлы нәсел баласы Габдел Вәли Әмрулла французча да, гарәпчәне дә мөкәммәл белә, француз әдәбиятын мактап туя алмый. Төрек шигъриятеннән атлаган саен үрнәкләр китерә иде.

—Дустым, Габдуллаҗан!—диде кунак.—Төркия Габдел Хәмит солтан

табанында изри, тилмерә. Без—яшь төрекләр солтанны бәреп төшереп, заманави хөкүмәт төземәкче булабыз. Ләкин солтан шымчылары безнең яшерен оешмабызны басты, бик күбебезне зинданга аттылар, башларын кистеләр, мин качып котылдым. Солтан барда миңа Төркиягә кайту юк, әфәндем. Солтанны аткарганчыга кадәр мин Русиядә мөселманнар арасында сәяхәт кылырмын. Моннан казакъларга, үзбәкләргә, уйгырларга, Әфганга, Кытайга, Иранга, аннан Иракка, аннан Мисырга, Мисырдан Франциягә булыр сәяхәтем.

Әмрулла бу җәйне мәдрәсә ятакханәсендә Апуш белән бергә уздырды. Көз җитеп, укулар башлануга шәкертләр килеп тулды. Чит ил кешесен карт шәкертләр баштук өнәп бетермәде. Бигрәк тә пишкадәмнәр аңа бәйләнә башлады. Әмрулланы аннан куалар, монда куалар, Габдулла яклашмаса, бичара Төрек Вәлинең хәлләре мөшкел булыр иде.

Ни өчен соң пишкадәмнәр үзләре белән бер яшьтәге бу егетне кабул итә алмыйлар? Мәһабәт буйлы булганы өчен. Үзләренә караганда киң белемле булганы өчен. Коръән, фикъһ, хәдис, гаруз кыйсмен мөгаллимнәрдән дә күп белгәне өчен. Бу тар караш мокытлыкка якын наданлыктан, хөсетлектән килә иде. Чокырбаш пишкадәм Әмрулланың каталарын яшереп куйган, янәсе, кызык ясый. Иртән торып тышка чыгарга Әмрулла каталарын тапмый, аның зур аякларына ярарлык ката берсендә дә юк. Әмрулла аптырап калмый, чатнама суыкта яланаяк чыгып, йомышын йомышлап керә, керсә күрә, аның каталары нәкъ юл өстендә ята. Пишкадәмнәргә кызык, буыла-буыла көлгән булалар. Әмрулла каталарны кем алганын белә, ул гауга куптармыйча гына дошманына шигырь белән җавап бирде:

—Адәми зат адәмнәргә көфер кыйлса,
Бәндәчекләр олы затка хыйлаф кыйлса,
Бу милләтнең кыйсмәтенә хәтәр килсә,
Ни кыйлурсән җаһилләрнең бу эшенә?
Гыйлем укудан килер, кеше үзен белмәктер;
Нәҗес җанын белмәсән, бер хайванга үрнәктер.

Ятакханә тып-тын калды. Кызык урынына пишкадәмнәр үз башларына шигъри тукмак алды. Шул көннән соң Әмрулланы кимсетергә, аннан көләргә маташучылар бетте.

Әмрулла төрек җырларын җырласа, Истамбул мәкаме белән Коръән укый башласа, төрек шагыйрьләре турында сөйләсә— барысы да тын кала. Әмрулла тыңлаучының дикъкатен яулый ала иде.

Кич утырышуларда, гыйльми мәҗлесләрдә Әмрулла сикереп торып катнашмаса да, Габдуллаҗан белән Миңлебай кебек атаклы шәкертләр үтенече белән дәресләр биргәли иде. Иртәгә китәсе кичне Әмрулла шәкертләргә Юнис Әмрә турында сөйләде. Башта ул сүз әйтмичә генә мәгънәле итеп, көр тавыш белән шигырь әйтә башлады:

Ошбу вөҗүд каласына һәрдәм китәсем килә;
Эчендәки гүзәлнең йөзен күрәсем килә.
Ишетердем сүзене, күрмәсәм дә йөзене,
Йөзене күрер өчен җаным бирәсем килә.

Төрек шигырендә колагыннан гашыйк өч кенә шагыйрь бардыр ул, аларның иң беренчесе Юнис Әмрә, моннан 600 ел әүвәл иҗат иткән кеше. Икенчесе моннан 237 ел элек мәрхүм булган—Мәүлә Колый, өченчесе—моннан илле ел элек вафат булган Габделҗаббар Кандалый...

Сират кылычтан нечкәдер,
Кылычтан да үткердер,
Басып анын өстенә
Йортлар корасым килә.
Ачуланма осталар,
Жаныгыз тыныч булсын,
Җәһәннәмгә кереп мин
Бераз янасым килә.
Аннан җәннәткә барам,
Җәнәттә Хакны күрәм,
Хур кызларын мин анда
Бераз кочасым килә.

Шәкертләр һушсыз иде. Әмрулла мәхәббәт турындагы бу шигырьләрне жыр итеп, төрек көенә салып, шундый матур башкарды ки, шәкертләр башта өнсез торды, аннан соң «машалла, кабатла» дип кычкырырга тотындылар.

—Юныс Әмрә!—диде Әмрулла.—Үзенен даhи шагыйрь икәнен бик яхшы белгән. Төрек халкы анын шигырьләренә бик күп, чуктин-чук көйләр ижат иткән, ул җырлар халык арасында кин таралган. Менә бусы аеруча мәшһүр...

Әмрулла тамагын көйләп алды да йомшак моңлы тавыш белән җырлый башлады:

Сорадым сары чәчкәдин:
Атаң-анаң бармыдыр?
Чәчәк әйтте: дәрвиш баба,
Атам-анам туфрактыр.

Лә иләһә илла аллаһ,
Аллаһ!
Лә иләһә илла аллаһ.

Сорадым сары чәчәкдин:
Кардәшләрең бармыдыр?
Чәчәк әйтте: дәрвиш баба,
Кардәшләрем яфрактыр.

Ләл иләһә иллаллаһ,
Аллаһ!
Лә иләһә илла аллаһ.

Сорадым сары чәчкәдин:
Ничөн йөзен сарыдыр?
Чәчәк әйтте: дәрвиш баба,
Үлем безгә якындыр.

Лә иләһә илла аллаһ,
Аллаһ!
Лә иләһә илла аллаһ!

Сорадым сары чәчкәдин:
Ничөн муйның кәкредер?
Чәчәк әйтте: дәрвиш баба,
Күнлем Хакка тугрыдыр.

Лә иләһә илла аллаһ,
Аллаһ!
Лә иләһә илла аллаһ.

Сорадым сары чәчәкдин:
Син мине белермесен?
Чәчәк әйтте: дәрвиш баба,
Син Юныс Әмрәдерсен!

Юныс Әмрәнең сүзләре, халык моңы, аны гүзәл башкаручы Вәли Әмрулла татар шәкертләренең хиссиятенә шулкадәр якын иде ки, шәкертләрнең бер өлеше Әмрулланы күтәреп һавага чөя башладылар. Ярсыган, алгысаган хисләр бераз тынычлангач, Әмрулла әйтте:

—Төрек-мөселман әдәбиятында,—дип башлады Габдел Вәли,—Юныс Әмрә кебек шагыйрьләр бик сирәк. Әмрә үзен «мин бөек шагыйрь» дими, Әмрә шулкадәр мәшһүр ки, аны юл буенда үсеп утыручы сары чәчәк тә таный икән. Үзең гарип булсаң да, күнлең Хак Тәгаләгә тугры булсын, ди Әмрә.

Бу кичне шәкертләрнең күбесе йокламады. Алар төне буе шигърият турында сөйләшеп ятты.

Ватаныннан качып, чит җирләрдә каңгырап йөрүче дәрвиш хәлендә калган егет бер ел ятакханәдә яшәгәннән соң сәяхәтен дәвам итеп, казакъ далаларына китеп барды.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ТУКАЙГА ШИГЪРИ ЧӘЧӘКЛӘР

## Мәҗит Гафури

### Г.Тукай вафатыннан соң

Көтмәгәндә кайгы салды безгә
бу көндә фәләк[1]:
Әй сөекле яшь шагыйрькәй,
син югалдың иртәрәк.

Тар күреп бу чикле тормышны
үз башына,
Кайтты «нәфсе мөтмаиннәң»
инде үз «Алласына».

Гали рухың бу түбән дөньяны
һич тиңсенмәде,
Тик бүтән дөньяга китте, ул
бөтенләй үлмәде.
Үлмәдең син, чөнки бу көн һәр татар
күңелендә син,
Бетмәдең син, һәр кеше сүзендә син,
телендә син...

Һичвакытта чыкмас истән монда
кыйлган эшләрең,
Һәрвакыт сөелеп укылыр бар
«Күңел җимешләре»ң[2].
Син сөеклесең, сине шулай сөя
һәрбер татар,
Сиңа каршы ихтирам һәрбер татар
күңелендә бар.

Югалуың—зур авырлык, һәммәбезгә
син әрәм,
Бар кешеләрдән дә артык мин
елап хәсрәтләнәм.

[1] Фәләк – язмыш.
[2] «Күңел җимешләре» – шул исемдәге шигырьләр җыентыгы.

# Шәехзадә Бабич

## Габдулла әфәнде Тукаев

**Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь,**
**Габдулладай.**
**Ул—караңгы төндә яктырткан матур,**
**ак тулган ай.**

**Ул бөек уй, нечкә хис тәгъризләргә[3]**
**бик бай, диям,**
**Бар урыннардан аның урыны кадерле,**
**дәү, диям.**

**Бакыр эчендә көмешләр ялтырап**
**яткан кебек,**
**Ап-ачык, ап-ак булып, тик ак күңел**
**аккан кебек.**

**Күп китапларның арасында**
**аның китаплары.**
**Ап-ачык нурлар чәчеп, күренеп тора**
**һәр яклары.**

**Алса, укыса халык шигырен аның—**
**истә кала**
**Һәм аның шигыре халыкның күңеленә**
**зур хис сала.**

**Галиязи Габдулланың хәзер**
**Казанда мәскәне.**
**Ул—уяткыч, ул—юаткыч, ул—**
**терелткеч хәстәне.**

**Билгеле, безнең мабиһельифтихар[4] ул,**
**мөхтәрәм,**
**Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә**
**дип шатланам.**

**Тәсбих вә тәһлил[5] итеп җырлап йөримен**
**җырларын,**
**Җырлаганда, нечкәрә күңелем, эри**
**һәр җирләрем.**

---

[3] Тәгъриз—тасвирлау.
[4] Мабиһельифтихар—мактаныч,горурлык.
[5] Тәсбих вә тәһлил—монда: иң изге,иң кадерле сүз.

## Нәкый Исәнбәт

### Тукай остаз

**Зур шагыйрьләр дөньясына күзне салганда туры,**
**Анда оҗмах төсле татлы көн күрүләр ялтырый.**

**Мин дә кермәкче буламын шул иҗат дөньясына,**
**Гомерың, Байроннарың йөзгән шигырь дөньясына.**

**Тик җыен көндәш белән тулган минем арт-алларым,**
**Шул теләгемнән көлә барча минем дошманнарым.**

**Барча азгын, барча дошман булса ни дә торса—чурт!**
**Зур шагыйрьләрдән Тукаең булса хәлфә, мин—шәкерт!**

## Хәсән Туфан

### Кемнәр сез?

**Һәр елда**
**Бөек Тукайның**
**Бәйрәме таңы туса,**
**Эндәшә сезгә—яшьләргә**
**Һәйкәлдән Җәлил Муса:**

**—«Кемнәр сез?**
**Безнең дәваммы?**
**Һәм безнең нәселме сез?**
**Тукайлар изге җоласын**
**Үтәргә әзерме сез?!.**

**Якладым соңга кадәр мин**
**Туган ил гадәтләрен,**
**Кулымны бәйләсәләр дә,**
**Телемне бәйләтмәдем!**

**Сез балык баласы түгел,**
**Сез халык баласы бит.**
**Киләчәк көнгә Тукайны**
**Сез алып барасы бит!**

**Киселде башлар... тиделәр..**
**Тик телгә тидертмәдек;**
**Агабыз Тукай йөзенә**
**Каралык китертмәдек!»—**

**Һәр елда бөек Тукайның**
**Бәйрәме таңы туса,**
**Эндәшә сезгә һәйкәлдән—**
**Эндәшә шулай Муса.**

# БЕЗНЕҢ МИЛЛӘТ ҮЛГӘНМЕ, ӘЛЛӘ ЙОКЛАГАН ГЫНАМЫ?

Һәртөрле мөхәррирләр вә ярты мөхәррирләр милләтемез үлгән вә яки йоклаган дип язалар. Вакыйгъдә безнең милләт үлгән үкме, әллә йоклаган гынамы? Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлауларына уяныргa кирәк иде.

Чөнки йокының, әлбәттә, бер чиге булырга кирәк. Бәр тәкъдир (әгәр) милләтемез үлгән булса, без, үлгән милләтнең башы очында бер кәгазь кисәге булган гәзитәләр шытырдатып, аны уята алырмызмы? Болай булгач, безнең гәзитәләр укымакымыз үлгән милләт, рәхмәтуллаһи галәйһи рухына ясин шәриф укуга гына охшап калмасмы? Әллә милләтнең йокысы Гозәер пәйгамбәр[1] йокысы кеби микән? Әллә Мәксәлмина, Мәслина, Дөбернуш, Шаднуш, Кәфәштатыюшлар[2] йокысы кеби микән? Соң ничек икән?

Минем уемча, болай булырга кирәк: борын заманда безнең милләт, үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләтләр илә, фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән. Берничә гасырлар безнең милләт алар илә казандаш һәм чәйдәш булып, барчасы бергә ачлы-туклы гына булса да, тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр. Шулай тыныч кына торганда, ни хикмәттәндер, башка милләтләр, һәрберсе бер Сөләйман мөлкен алып, үзләренә җилләрне, парларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр; һәртөрле җан-җанвар, кош-кортларны мөсәххәр иткәннәр, хәтта тәхеткә утырып, күкләрдә очып, су төпләрендә балыклар илә бергә йөри башлаганнар. Безнең милләт, мискин, шул вакытта йоклаганмы, ни эшләгәндер, мин анысын белмим, ләкин безнең милләт баягы иптәшләренең кисәктән генә болай ук югары китүләренә тәкать тота алмаган, дәрхаль (кинәт) һушы китеп егылган; «Сагълүк» китабынча әйтсәм, мөгаммә галәйһи булган. Менә шул ятудан безнең милләт һаман да ятадыр.

Соң, инде аны ничек һушына китерик?

Бу тугърыда минем фикре касыйрым болай дип әйтә: без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифакъ (бергәләп эшләү) сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын; шундин соң бу вәгазьләрне сөйлик: «И бичара милләт, син ул иптәшләреңнән курыкма. Аларның хәленә исең китмәсен; әгәр алар эшләгәнне эшләсәң, алар күргәнне күрсәң, алар белгәнне белсәң, син дә алар дәрәҗәсенә менә аласың; Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һичкемгә хас түгелдер, һәм бу галәм—галәмел-әсбабтыр (сәбәпләр дөньясы) һәм дә ялган сөйләмәси мөхаль вә мәмнугъ булган (мөмкин булмаган һәм тыелган) мөхбире садыйк (пәйгамбәр) әфәндемез дә: «Кеше тырышса, табар»,—боермышлардыр. Тырышкан вә тырмашкан вакытларында синең бабаларың булган Бәгъдад вә Әндәлес әһалисе бик каты тәрәкъкый иттеләр. Аларны күргәндә, башка милләтләр, синең кеби, һушлары китеп егылалар иде...»

Менә бу сүзләр илә милләтне җуатып, милләтнең һушы китеп, гакылсыз ятканда, милләтне ашаган, кабыргаларын тишкән оятсыз ак башлы каргаларны, кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле Бохара козгыннарыны[3] куып җибәрик. Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвештә ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең

[1] Аллаһы тарафыннан йөз еллык йокыга талдырылган пәйгамбәр.
[2] Дошманнардан качып тау куышына кергән һәм анда 309 ел йоклаган җиде егетнең бишесе.
[3] Бохара ягында иске ысул белән (кадимчә) укып кайткан муллалар һәм ишаннар күздә тотыла.

үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны муенынан кысып, борынгы ашаганнарын карылдатып чыгарсын; шулай бит! Андин соң Бохара чапаны эченә төрелгән хәйләкәр төлкеләрне чапан җиненнән өстерәп, көзге каршысына китерик; көзгегә каршы авызларын каерып ачыйк та, милләткә көзгедән канлы авызларын күрсәтик; милләт күрсен, ашаганнарына инансын, икенче мәртәбә та кыямәт алданмасын.

Бәс, безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән. Мәзкүр рәвешләр илә һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем—милләт үзе аерыр.

**Габдулла ТУКАЕВ**
*«Фикер» газетасы.*
*1906, 17 апрель.*

---

## *Тукай әйтсә, хак әйткән*

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?—
Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!

---

## *Бөекләр сүзе*

**Гаяз Исхакый:**

*—Казан кулдан киткәннән бирле юксыллыкка, үксезлеккә баткан милләтенең кайгысы, моңы Тукайның үзенең шәхси кайгы-хәсрәте төсене ала вә Тукай милләт моңыны көйли торган, милләт бәхетсезлегене җырлый торган әллә никадәр шигырьләр мәйданга китерә, милли моңны шигыренең эченә ашлый. Ләкин ул мескен булып моңланмый, өмидсезләнеп зарланмый...*

**Галимҗан Ибраһимов:**

*—Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле вә галәбәле[1] рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗәдә ки, татар шагыйре диелүгә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була[2]. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә, халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр. Татар шигыре мәйданында Тукаев иң гали ноктада тора.*

---

[1] Галәбә – җиңү, өстен булу.
[2] Мәүҗүд булу – гәүдәләнү.

# ТУКАЙГА ШИГЪРИ ЧӘЧӘКЛӘР

## Әхмәт Фәйзи

### Габдулла Тукайга

Белмим, кайсы таулар күкрәгеннән
Һәйкәлеңнең ташы, тимере,—
Тик син үзең халык йөрәгеннән.
Халык мәхәббәте—синең исемең,
Халык гомере—синең гомерең.

## Фатих Кәрим

***

Мин Тукайдан үрнәк алам, дисең,
Бу түбәнлек түгел, һич түгел,
Чөнки Тукай—халык моңнарының
Бакчасында тибрәп үскән гөл.

## Сибгат Хәким

***

Борынгы, иске Веймарда—
Йортында мин Гетенең.
Чыкты да әйтте карт Гете:
Бераз гына көт, энем.

Көтәмен татар малае,
Мин кечкенә тавышлы,
Өйрәндем бары өченче
Телдән укып « Фауст» ны.

Кердем, адаштым, зур дөнья,
Менә сиңа, укып үс...
Адаштым... Әйе, яшәгән
Бүлмәләре утыз өч...

Веймарда үзем... Ерактан
Номерда утын күреп,
Тукайны уйлыйм, уйлата
Һәрвакыт үкендереп.

Тарихы мәшһүр бай «Болгар»
Номерның иң өтеген
Биргән аңа, бер бүлмәсе
Кадәр дә юк Гетеның.

Бу—шулай. Беләм, Тукайга,
Беләм, авыр булганын;
Алыштырмас иде барыбер
Читкә салкын «Болгар»ын.

Гамил
Афзал

## Йөрәгемдә йөртәм сине

...Ял иткәндә,
Ятып укыйм кичтән сине,
Тору белән, алып укыйм иртән сине.
Ак кәгазьдәй намусыма судья итеп,
Гомер буе йөрәгемдә йөртәм сине.

Тукай—остаз, Тукай—шагыйрь,
Тукай—ага,
Кызыл гөлләр башын игән сиңа таба;
Идел суы, синең яннан узган чакта,
Дулкыннарын әкрен генә ярга кага.

Җырларыңа хозурланып, ил шатлана,
Бүрек салып керәбез без җыр бакчаңа;
Яшең белән сугарылган бу гөлләргә
Баккан саен, сабыйлардай, җан сафлана.

Күңелләрдә озак еллар, озак еллар
Янып торган, уйнап торган нурларың бар;
Туган илнең ташларына хисең белән
Ядкарь итеп уеп язган юлларың бар.

Туган халкым йөрәгенең ярасы син,
Ил алдында ил күзенең карасы син;
Токымнарның юлларында юлдаш булып,
Халык белән мәңгелеккә барасың син.

# «ТАТАР БӘХТЕ ӨЧЕН МИН ҖАН АТАРМЫН»

Тукай турында төрле телләрдә гаять күп санлы мәкалә-хезмәтләр, әдәби әсәрләр язылган. Әгәр дә аларны бергә тупласаң, мөгаен, бер китапханәлек булыр иде. Без фәкыйрегезгә дә бөек шагыйрь, аның шәхесе, иҗаты, әсәрләре, әдәбият тарихында һәм гомумән рухи тормышта тоткан урыны хакында илледән артык мәкалә язарга, күпләгән доклад-чыгышлар ясарга туры килде. Әмма, «күпме карасам да карап туймыйм» җырындагы кебек, Тукай турында һаман да әйтәсе сүзләр, укучыларга җиткерердәй фикерләр табылып тора. Моның ике мөһим сәбәбе бар. Беренчедән, Тукай—Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән олуг, табигый талант, кабатланмас шәхес. Икенчедән, аның иҗаты—татар һәм гомумән кешелек яшәешенең олы, магистраль юлында туган күренеш. Шагыйрь үзенә кадәрге һәм үз чорындагы рухи казанышларны, яшәеш тәҗрибәсен үз иҗатына сеңдергән, аларны күңел казанында, бәгырь утында кайнатып, үзенең уй-кичерешләре рәвешендә халыкка кайтарып та биргән. Аның мирасы—шәхси һәм гавами башлангычларның табигый бер кушылмасы, синтезы яшәеш тарихыбызның гаять мөһим бер хәзинәсе. Шуна күрә ул кешелек белән бергә яши. Һәр буын аңа, үз ихтыяҗларыннан чыгып, үзенчә якын килә, шагыйрь мирасын үзенчә барлый, үзенчә кабул итә һәм аңлата. Шулай итеп, шагыйрь турындагы күзаллаулар, белем-мәгълүматлар, икенче төрле әйткәндә, «Тукай фәне» (тукаеведение) елдан-ел тулылана, байый бара.

Адәм баласы никадәр генә табигый талантка ия булмасын, аның сәләте ачылу, җитлегү, җимешләр бирүе өчен тиешле шартлар, зәмин-җирлек, рухны кузгатырлык иҗтимагый-мәдәни вәзгыять кирәк. Тукай яшәгән чор—моның гыйбрәтле бер мисалы. XX йөз башы—татар яшәеш-мәгыйшәтенең кайнап торган дәвере. Бер-бер артлы мәктәп-мәдрәсәләр, гәҗит-журналлар ачылу, меңнәрләгән татар китапларының дөнья күрүе, театр-спектакльләрнең күпләп куелуы, татар эшмәкәрләренең Евразия киңлекләрендә кыю эш итүе, Шәрык белән генә түгел, Гареб белән дә диалог-сохбәтләрнең көчәюе, иң мөһиме—милли үзаңның ныклап кузгалуы, татарның башка кавемнәр арасында үз урынын табарга, билгеләргә омтылуы—шагыйрь яшәгән елларның асыл сыйфатлары. Аның белән бергә Г.Исхакый, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Г.Кариев, С.Максудый һәм башка бик күп олуг затларның нәкъ менә шушы дәвердә ачылып, үсеп китүе нәтиҗәле эш-гамәлләр кылуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

С.Рәмиевкә язган бер хатында Кушлавыч егете (4.03.1911) болай ди: «Мин поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә....» Бу сыйфатларның күпчелеге Тукайга гына түгел, XX йөз башының кайбер башка каләм әһелләренә дә хас. Әмма мәшһүр «Шүрәле» авторы үзе хакында үзе ни дип кенә әйтмәсен, ул, иң беренче чиратта, шагыйрь. Бу изге төшенчә аның бөтен барлыгын, эш-гамәлләренең асылын, яшәү максатын билгели. Элеккеге традицияләрне дәвам итеп, ул шигъри сүз, әдиплек турында үзенең уй-кичерешләрен дә бәян итә, Ходай Тәгаләдән үзен шагыйрьлектә мәңгелеккә кадәр нык итүен үтенә («Әйлә шагыйрьлекдә сабит та әбәд, Тәңрем, бәни»). Тукай фикеренчә, «шагыйрьлек тажы»—бетмәс-төкәнмәс байлык. Син,—ди, шагыйрь үз каләмдәшенә дәшеп,—«Баш имә,—зур син,—бу әдна (түбән.—Х.М.) җанлылар дөньясына; Падишаһ син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа». Тукай үз тереклегенең бөтен ямен, тәмен шигърияттә күрә. Юкка гына ул бу сүзләрне язмый:

*Мин сизәм: дөнья йөзе дузәх (тамуг.—Х.М.), җәһәннәмдер миңа;*
*Бер шигырь язсам гына, җәннәт вә ризваным килә.*

(«Тәрәддед вә шөбһә»).

Шагыйрьлекнең асыл максатын Тукай милләткә, халыкка хезмәт итүдә күрә. Миллилек хосусияте аның бөтен язганнарын сугарган. Шагыйрь өчен милләт «дөнья бәрабәренә» дә сатылмас, «бар нәрсәдән изге һәм хөрмәтле нәрсә». «Милләт хыялы»,—ди ул,—һәр хыялдан татлыдыр; «Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем», ягъни «Синең саулыгың—минем саулык, авыруың—минем авыруым» («Милләтә»). «Үз-үземә» шигыре—Тукай иҗатының төп шигаре, көзгесе.

*... Күңел берлән сөям бәхтен татарның,*
*Күрергә җанлылык вактын татарның.*
*Татар бәхте өчен мин җан атармын;*
*Татар бит мин, үзем дә чын татармын...*

Кушлавыч егетенең милли фикерләвенә офыклар киңлеге, тарихилык хас. Шагыйрь татарның «мәгъмур» Болгар чоры шәһәр-авылларын, «бихисап гаскәрле» Чыңгыз дәверләрен искә төшерә. Әмма халкыбызның үз башына үзе хуҗа булган вакытлар артта калган. Инде татар «өч йөз» (хәзер инде 450 елдан артык) «мискин» хәлдә, «тәкъдир» изүендә. Бу хәлгә әрнеп, сыкранып автор болай ди:

*... Күпме михнәт чиккән безнең халык,*
*Күпме күз яшьләре түгелгән....*
(«Милли моңнар»).

Тукай үз халкын авыр, «мискин» хәлдән чыгарырга, аны бәхетле итәргә омтыла. Бу гаять кыен, әмма игелекле юлда ул чын каһарманнарча, фидаиларча эш итә.

*Җырлап торам, торган җирем тар булса да,*
*Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;*
*Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт*
*Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.*
*Уңга, сулга аумыйм, һәнүз (һәрчак.—Х.Ю.) алга барам,*
*Юлда маниг (киртә.—Х.Ю.) күрсәм, тибәм дә аударам;*
*Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә*
*Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү хәрам.*

«Бер татар шагыйренең сүзләре» дип исемләнгән бу парчаның лирик герое алга таба үзен батырлыкта «Гали, Рөстәмнәргә» тиңләштерә. Көрәш,хәрәкәт мотивы Тукайның «Шагыйрь» шигырендә дә гәүдәләнеш тапкан:

*Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;*
*«Без китәрбез, сез каласыз!»—дип җырлармын,*
*Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә.*

Дөрес, вакыты белән шагыйрь күңел төшенкелегенә дә бирелеп китә, үз «җырлар»ының халыкка файдасы барлыгы-юклыгы хакында уйланып та куя. Әмма, гомумән, Тукай—оптимист, иманлы, яшәеш рухы көчле булган шагыйрь. Юкка гына ул меңәрләгән укучысын күздә тотып язылган парчасын мондый юллар белән тәгәлләми:

*... Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар;*
*Ал җәсарәт (батырлык.—Х.М.), алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!*

Гомеренең соңгы айларында, Әҗәл-Газраил белән якадан-яка килеп ятканда да шагыйрь үз халкын онытмый, аңа дан җырлый, аның хокукларын даулый:

*...Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*

*Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк—*
*Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!*

Тукай дөньяга татар күзе белән карый, аның агышын, ыгы-зыгыларын татар йөрәге аша кичерә. Шуңа күрә дә аның һәр милләт өчен хас булган «туган авыл», «туган жир», «туган тел», «ата-ана», «мәхәббәт», «ватан» турындагы әсәрләре дә милли яңгырый, татар дөньясының табигый һәм зарури бер өлеше, кыйсеме рәвешендә кабул ителә. Кемнеңдер «бөеклек—гадилектә» дигән сүзләре бар. Тукайның бу төр шигырьләре дә шулкадәр гади, үтемле, аларны һәрчак укыйсы, тыңлыйсы гына килеп тора:

*... Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.*

(«Туган авыл»)

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы!*

(«Туган тел»)

Шагыйрь мирасында бөеклек рухы белән язылган бу төр үтемле, дулкынландыргыч юлларны күпләп очратырга мөмкин.

Тукай иҗатында миллилек инсаният, әхлак мәсьәләләре белән тыгыз һәм табигый бәйләнешле. Шагыйрь кешеләрне намуслы, иманлы, вөҗданлы итеп күрергә тели. «Күңел» шигырендә ул болай ди:

*...Яхшы аңла: юк сафа (рәхәтлек, хозурлык.—Х.М.)*
*инсанлыгыңны җуймыйча,*
*Шуны саклау юлында күп газапланган күңел.*

Тукайның идеалы—унай сыйфатларны, игелекле эш-гамәлләрне үзенә туплаган камил инсан. Моның үрнәкләрен ул татарның Ш.Мәрҗани, З.Бигиев, Х.Ямашев кебек улларында күрә, аларны мактау аша үз халкының дәрәҗәсен күтәрергә тырыша.

Антитеза, ягъни капма-каршы кую алымы белән шагыйрь үз идеалына туры килмәгән икейөзлелек, әхлаксызлык, «алтынга табыну» кебек күренешләрне кискен тәнкыйтьли:

*... Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра;*
*Ялтырап күзләрне чагып, тугъры юлдан яздыра—,*

ди ул «Алтынга каршы» шигырендә. Шунысы мөһим: инсанилык, әхлак турында сүз барганда, автор үзен дә аямый, үз шәхесенә югары таләпләр куя. «И каләм» парчасында шагыйрь, үз-үзенә дәшеп, болай ди:

*Караны яз кара диб һәм игътираф ит акны ак;*
*Җөпне җөп дип язмалый (язма.—Х.М.) син һәм ушандак такны так.*

Тукай яшәештә һәм татар шигъриятендә элек-электән гаять зур урынны биләгән мәхәббәт темасын эшкәртүгә дә үзеннән зур өлеш кертте. Аның «Бер рәсемгә», «Мәхәббәт», «Булмаса», «И матур...» һәм кайбер башка парчалары—сөю-мәхәббәт лирикасының гүзәл үрнәкләре.

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас—төшми яңгыр тамчысы;*
*Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы...*

Бу төр юлларга хәтта җиһан сүз сәнгатенең бөек лирикы Хафиз да «афәрин» дияр иде.

С.Сүнчәләйгә язган бер хатында Тукай: «Мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче!... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам»,—ди. Шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләрен укыганда, чыннан да, Тукайның бу сүзләрендә хаклык барлыгына янә бер мәртәбә ышанасың. Аның, мәсәлән, «Татар кызларына» шигыре үзенең аһәңе, сурәт-детальләре һәм гомумән эчтәлеге белән татар рухына, татар образлы фикерләвенә туры килеп тора.

Тукай иҗаты идея-тематик яктан гына түгел, ә сурәтлелек, сәнгати җәһәттән дә татар әдәбиятын яңа баскычка күтәрде. Анда без жанрларны һәм шигъри шәкел-формаларны, строфа һәм рифма-үлчәм төрләрен иҗади куллануның матур-матур үрнәкләрен очратабыз. Тукай әсәрләрендә еш кына житди аһәң белән сатира-юмор бергә үрелеп бара, шигъри сөйләмнең гаҗәеп күп төрләре тудырыла.

«Шүрәле» авторы,—иң беренче чиратта, лирик. Әмма ул эпик һәм лиро-эпик төрләрдә, публицистикада да иркен эш итә. Аның оригиналь рухын иҗади торгызган тәрҗемә әсәрләре дә бар. Тукай балалар әдәбиятының да классик үрнәкләрен бирде. Аның бу төр парчалары яшь буынны тулы канлы һәм мәгънәле итеп яшәргә, хезмәтне сөяргә, матурлыкны күрә һәм тоя белергә, әхлаклы һәм инсанлы булып үсәргә ярдәм итә.

Соңгы шигырьләренең берсендә Тукай: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»,—ди («Кыйтга»). Әмма шагыйрь бераз ялгыша. Ул «дөньяны пакьләү»гә, татарның милли үзаңын кузгатуга һәм үстерүгә, әдәбиятны тәрәккый кылдыруга гаять зур өлеш кертте. Чирек гасырдан бераз гына артыграк җир йөзендә яшәгән, «какканны вә сукканны» күпләп күтәргән, «җиһанның эссесен, салкын, бозын, карын» күргән, «ниләр күргән бөтен үксез»—шуларның барчасын кичергән Тукай үзенең «гүзәл эзен», ялкынлы һәм инсани рухлы әсәрләрен дөньяда калдырып китте. Аның иҗаты—шагыйрьлекнең, милләткә хезмәт итүнең күркәм бер гәүдәләнеше. Юкка гына шигърият, татарлык, Тукай бер-берсен алыштыручы атамалар булып йөрмиләр. Мөһаҗирлектәге татар әдәбиятында, матбугатында, мәсәлән, Тукай еш кына татарның символы рәвешендә кулланыла.

Шагыйрь иҗаты үз чорында да, аннан соң да татар сүз сәнгате үсешенә гаять көчле йогынты ясады. Тукай традицияләренең дәвам ителешен без Ш.Бабич, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким, Р. Гаташ, М.Әгъләмов һәм башка бик күп каләм әһелләренең иҗатларында ачык күрәбез.

Кагыйдә буларак, чын мәгънәсендә милли сүз сәнгате башка кавемнәр өчен дә кызыклы. Тукай иҗаты—моның гыйбрәтле бер мисалы. Шагыйрьнең әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Тукай аеруча төрки халыклар өчен үз һәм якын. Минем шагыйрь парчаларын яттан сөйләгән үзбәк, казакъ, кыргыз зыялыларын очратканым булды. Башкортлар өчен Тукай тәмам үз һәм якын әдип. Шагыйрьнең тугандаш әдәбиятларга йогынтысы хакында үзбәк Гафур Голәм, төрекмән Бирде Кербабаев, казакъ Сабит Муканов һәм кайбер башка төрки әдипләренең кызыклы фикерләре бар.

Тукайның тууына 125 ел тулуга хәзерлек уңаеннан, гәрчә житәрлек булмаса да, күп төрле чаралар уздырыла һәм эшләр башкарыла. Иң мөһиме: әсәрләренең басыла торуы. Алар оригиналда гына түгел, урыс, төрек, инглиз һәм кайбер башка телләрдә дә дөнья күрде. Шагыйрьнең мирасын гыйльми өйрәнү юнәлешендә дә житди генә адымнар ясалды. Ниһаять, «Тукай энциклопедик сүзлеге»нең төп өлеше тәмамланып килә. Музейлар, гомуми белем бирү мәктәпләре, көндәлек матбугат, радио-телевидение Тукай иҗатын халыкка житкерүдә нәтиҗәле генә гамәлләр кылалар.

Юбилей алды елларында үкенечле, аяныч хәлләр дә булды. Шундыйларның берсе—Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсенең юк ителүе. Бу унай белән татар җәмәгатьчелеге үзенең кискен мөнәсәбәтен дә белдерде. Әмма мәсьәләнең икенче ягы да бар. Ә бит бу бина ничәмә-ничә еллар буе бөтен кеше күз алдында җимерек хәлдә торды. Каршыда гына «халыкка дәрсе гыйбрәт», «мөкаддәс», «бөек», «гали зат» дип Тукай мактаган мәшһүр татар театры. Әгәр дә «яктылыкка, нурга илтүче» бу театрның без хөрмәт иткән артистлары, «Болгар» язмышын үзәккә куеп, берничә минутлык кына берәр акция оештырган булсалар да, хакимият бина язмышы хакында

тиешле чаралар күргән булыр иде. «Болгар»ның янәшәсендә генә татар мәгариф һәм гыйлем мәркәзенең берсе булган, Р. Йосыпов, В.Гайфуллин, Ф.Галимуллин, Ә.Хужиәхмәтов кебек күренекле профессорлар эшләгән педагогика университеты барлыгын да онытырга ярамый. Тарихи бинаның аянычлы хәлен меңәрләгән татар зыялылары, шул исәптән Тукай бүләге лауреатлары да белеп, күреп торды. Әмма битарафлык сакладык, нәтиҗәле чаралар күрмәдек. Әгәр дә без бу тарихи бина җимерелгәннән соңгы активлыкны элегрәк күрсәткән булсак, «Болгар» инде күптәннән реставрацияләнеп, яисә янадан төзелеп, мәдәни тормышыбызда үзенең тиешле урынын тапкан булыр иде.

2011 ел Татарстанда гына түгел, бөтен төрки дөньяда «Тукай елы» дип игълан ителде. Әйткәнебезчә, Тукай ул—татарның бер символы да. Аны өйрәнү, пропагандалау, зурлау ул татарны, аның бөек вәкилләре Кол Гали һәм Сәйф Сараиларны, Мөхәммәдьяр һәм Утыз Имәниләрне, Исхакый һәм Гафуриларны, Такташ һәм Җәлилләрне, газиз телебезне һәм рухи мирасны өйрәнү, олылау дигән сүз. Бу хакыйкатьне истә тотып, безгә тагын да нәтиҗәлерәк, кыюрак эш итү, гамәл кылу сорала. Бөек шагыйрьнең үлеменә тиздән 100 ел тулуын да истә тоту зарури. Тукай инде менә йөз елдан артык татарның милли байрагы, арка терәге булды. Киләчәктә дә ул шулай булып калсын иде!

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

---

*Тел дәрьясы*

# РУСЧАДАН ДӨРЕСТ ТӘРҖЕМӘЛӘР[1]

*Русча:* Я перешел через мост.
*Тәрҗемә:* Мин чыктым аркылы күпер.

*Русча:* Соглашение между Францией и Испанией будет подписано в конце текущей недели.
*Тәрҗемә:* Килешү арасы Франция һәм Испания булыр имза ителгән ахырында агып барган атнаның.

*Русча:* Лев Толстой умер.
*Тәрҗемә:* Арыслан җуан үлде.

*Русча:* Дай сюда поднос!
*Тәрҗемә:* Бир монда борын астын!..

Русчадан тәрҗемә итдегем бу үрнәкләрне мин үземнең мөтәрҗимлек эшендә маһарәтемне гаммәгә күрсәтер өчен яздым.

Ничә еллардан бирле «Баянел хак» кеби милли вә олугъ көндәлек гәзитәләрнең хәбәрләр кыйсьмендә югарыдагы үрнәкләрдән бик күп начар дәрәҗәдә тәрҗемә ителгән сәтырларга очраганым булганга, үземне, билифтихар вәлгорур, бөтен татар гәзитә вә журналлары идарәсенә мөтәрҗим буларак тәкъдим итәмен.

**«Гөмберррт[2]», «Ялт-йолт» журналы.**

---

[1] Кыскартып бирелә. Ред.
[2] Гөмберррт – Тукай тәхәллүсләренең берсе.

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1913 ел

**Ел башы.** Сәламәтлегенең көннән-көн начарлана баруына карамастан, Тукай күп эшли. «Ялт-йолт», «Аң» журналларында, «Кояш» газетасында әледән-әле аның әсәрләре чыгып тора. Басылачак «Мәҗмугаи асарь»ен хәзерли. Авыруы көчәюгә дә карамастан, күп яза, күп эшли.

**1 гыйнвардан—26 февральгәчә.** «Амур» номерларының 9 нчы бүлмәсендә яшәвен дәвам итә.

**1 гыйнвар.** «Суык» шигырен яза.

«Шиһаб хәзрәт» шигыре басылып чыга.

**10—25 гыйнвар.** «Ялт-йолт» журналының редакторы Әхмәт Урманчиевка хат яза.

**10 гыйнвар.** «1912 елның онытылганнан гына калган хисабы» исемле мәкаләсе «Счет төймәсе» имзасы белән басылып чыга.

**12 гыйнвар.** «Хәстә хәле» шигырен яза.

**15 гыйнвар.** «Хәстә хәле» шигыре басылып чыга.

**22 гыйнвар.** «Яңа басылып чыккан әсәрләр» исеме астында «Вакыт» газетасы «Җан азыклары» китабы басылып чыгу турында хәбәр бирә.

**28 гыйнвар.** «Әнвәр бәк» шигыре басылып чыга (Төркиянең хәрби һәм сәяси эшлеклесе Әнвәр паша (1881—1922) турында язылган).

**21 гыйнвар.** «Идел»дә Тукайның «Җан азыклары» исемле китабы басылып чыгып, сатыла башлавы турында игълан бирелгән.

**1 февраль.** «Даһигә» шигыре басылып чыга.

**1 февраль.** «Толстой сүзе» (Зур бәхет инсанга) шигыре басылып чыга. Үләр алдыннан язылган ике генә юлдан торган бу шигырьдә Тукай үзенең фәлсәфи-этик карашларын гәүдәләндерә. Бөек рус язучысы кебек, ул да кешеләрне әхлакый камиллеккә чакыра:

*Зур бәхет инсанга—һәр көн, һәр сәгатьтә яхшыру;*
*Яхшыру юк, булса анда:—Яхшы мин!—дип лаф ору.*

**14 февраль.** «Кояш»та түбәндәге игъланны укыйбыз: «Габдулла Тукаевның адресын сораучыларга:—«Кояш» адресын язып, «Габдулла Тукаевка» дип арттырасыз».

**17 февраль.** «Җан азыклары» китабы чыгу турындагы игълан («Вакыт», № 1078) кабатлап басылган.

**21 февраль.** Казанда «Сабах» ширкәте нәширлегендә, Шиһап Әхмәров (1884—1966) редакторлыгында (барлыгы 25 сан) чыккан «Мәктәп» журналының 1 нче саны дөнья күрә. Бу журналның берничә санында Тукайның әсәрләре басылган.

Февраль ахырына таба Тукайның саулыгы тәмам начарлана. Бу вакыттагы физик һәм рухи халәтенең ни рәвешле булганын дусты Ф. Әмирхан истәлегеннән беләбез. Шагыйрьнең көндез дә, төнлә дә горык-горык йөткергәне аермачык ишетелеп тора.

«Һәрбер көн генә түгел, бәлки, һәрбер сәгать, һәрбер йөткерүнең аның гомереннән бер кисәген кубарып алганлыгын без генә түгел, ул үзе дә белә вә анлый иде. Ләкин бу турыда ул тел белән сөйләргә яратмый иде.

Соңгы көннәрдә ул ялгызлык сөя вә ялгыз дәкыйкаләрендә тирән бер уйга батып утыра вә шул уйланудан үзенә бер итмиэнане калеп тапкан шикелле була ки, уйлану дәкыйкаләреннән соң, тереклек хакында якты вә өметле_нәрсәләр

сөйләп куя иде».

**25 февраль.** Больницага китәр алдыннан, дусты Фатыйх Әмирхан белән саубуллаша. Ф. Әмирхан болай искә ала:

«Иртәгә иртә белән больницага илтеләчәк дигән төнне ул минем белән күрешергә кергән иде. Сабыйларчарак шат йөз белән ул: «Мин иртәгә Клячкинга керәм, мин киткәндә, син тормаган булырсың... Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде!»—диде. Докторлар аркылы миңа инде аның бер ай, күп булса, ай ярым гомере калганлыгы мәгълүм иде. Бу «хуш»ның да ахыргы «хуш!» икәнлеге билгеле иде. Алай да мин аңар: «Тиз терелеп чык, тиз күрешик!»—дидем. Ул, бүлмәдән чыга башлап: «Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә»,—диде һәм чыгып китте».

**26 февральгә кадәр.** Ш. Әхмәров истәлегеннән күренгәнчә, Тукай шифаханәгә кереп ятар алдыннан аңа: «Ике-өч төн йокламыйча, «Мәҗмугаи асар»емне тәртипкә салдым, шул мине бөтенләй эштән чыгарды»,—дип сөйләгән булган. Бу басманы, тулысынча булмаса да, башлыча, үзе башкарган.

**26 февраль.** Иптәшләренең киңәше белән, айга 150 сум хак түләргә килешеп, Тукай Казанда Клячкин шифаханәсенә керә. (Казанның хәзерге Кави Нәҗми һәм Островский урамнары чатындагы шифаханә.) Биредә шагыйрьне врач Р. А. Лурия дәвалаган.

Бу турыда үзе «Ике ихтар» дигән мәкаләсендә дә яза. «Могътәбәр табибләрнең катгый киңәш вә карарларына буйсынып, 26 нчы февральдә Казанның Клячкин шифаханәсенә кереп яттым. Шунар күрә үзем тәэсис итешкәннән бирле эшләп килдегем «Ялт-йолт» журналының секретарьлеген башка кешеләргә тәслим иттем. Шунар күрә журналда моннан соң басылган һәммә мәзмуннар өчен үземне мәсьүл күрмәячәкмен».

**Февраль.** Клячкин больницасына кергәч тә Фатыйх Әмирханга хат яза.

«Больница хадимнәре миңа: «Ник алданрак больницага кермәдегез?»—диделәр. Мин аларга: «Без больницаны үлемнең әүвәл стансасы дип беләмез. Аз булса да дөньяда торып калыйм, дип әйттем»,—дидем» дип беллерә.

**26 февральдән соң.** Шифаханәдә профессор Клячкин белән берничә мәртәбә очраша.

Клячкин үзенең истәлегендә аның гаять киң карашлы, фикер алышу өчен күңелле кеше булуына басым ясый:

«Дәвалау өчен кергән вакытларда мин аның белән танышып, тиздән мин аның башкалар белән тиңләштермәслек кызыклы, киң карашлы, акыллы бер кеше икәнлеген белдем.

Больницада ихтыярсыз эшсез ятарга мәҗбүр булган Тукай миңа җитди әдәбият табып бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте. Мин аңа Һейненең русчага тәрҗемә ителгән шигырьләренең кулымда булган җыентыкларын бирдем. Болардан тыш, таныш адвокатым О. аркылы политик әдәбияттан да кайбер китаплар табып бирә алдым. Бу китаплар арасында «Колокол»ның аерым номерлары, Герценның «Былое и думы» дигән әсәре, Чернышевскийның «Что делать?» әсәре һ. б. барлыгы хәтеремдә. Ул бу әдәбиятны зур кызыксыну белән укый иде».

**1 март.** «Юбилей мөнәсәбәте белән» дигән мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Мәкалә Романовлар нәселенең Россиядә патшалык итүенә 300 ел тулу уңае белән уздырыла торган бәйрәмгә багышланып язылган.

«Аң» журналының 6 нчы саны дөнья күрә. Биредә «Шөһрәт» һәм «Кыйтга» («Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым...») дигән шигыре урнаштырылган. «Кыйтга» шигыре үкенеч тойгысы белән сугарылган. Шагыйрь гомеренең соңы житүен аңлый кебек.

*Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.*
*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.*
*Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч, шул булды эш,*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*

**3 март.** «Кояш» газетасы «Авыруларыбыз» дигән баш астында Г. Тукай һәм Г. Камалның (ул Төркиядән авырып кайта) больницада ятуларын һәм аларның сәламәтлекләренең торышын хәбәр итә.

**10 март.** Больницада ятучы шагыйрьнең хәле турында газеталар, шул исәптән «Кояш» үз укучыларына хәбәр биреп торалар, «...эсселеге 38°, тамыр тибүе 103. Моннан элекке көннәрдә эсселеге 36,6 белән 39,7 арасында, тамыр тибүе 96 белән 120 арасында булды. Соңгы көннәрдә алмашынулар элеккегә караганда азрак. Үзен яхшы вә элеккегә караганда уңайрак хис итә. Укымый тора алмый. Газеталар укый».

«Мөхәрриргә» шигырен яза. Тукайның соңгы шигырьләреннән берсе. Бу шигырьне үлеменә 23 көн кала язган. Сөргеннән кайткан Гаяз Исхакыйны лаеклы каршылау өчен барган кампания уңае белән язылган. Мөхәррир Г. Исхакый 6 ел сөрген, төрмә һәм качудан Казан шәһәренә керә алмаган.

*И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!*
*И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!*
*Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргаймале!*
*Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!*
*Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях,*
*Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.*
*Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,*
*Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.*
*Алты елда торды чупансыз, аерылышты яшь көтү,*
*Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.*

**Март.** Тукайның хәле начарлана, температурасы гел югары тора. Үзе һаман көндәлек матбугатны күзәтеп, укып барырга тырыша.

Дусларыннан Шиһап Әхмәров истәлегеннән түбәндәгеләрне укыйбыз: «Барганда һәрвакыт матбугат хакында сүз ача вә төрле мөляхәзәләр булына иде, рус газеталарын да моталәгә иткәли иде. Фәкать соңга таба күзем арый, ятып каршы тотып укыганда кулларым тала, дип зарлана башлады.

Шифаханәгә хәлен белергә баруны бик ярата иде, барган вакытта яткан булса, торып утыра вә янындагы кеше киткәнче, утырып сөйләшә иде.

Соңгы көннәргә кадәр ашау-эчүендә бер дә алмашыну булмады, яхшы ашый һәм эчә иде. Температурасы 38° илә 38,5° араларында, пульсы 100—105 тирәләрендә иде».

**14 март.** «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсен яза. Бу аның Клячкин шифаханәсендә язылган озын һәм иң ахыргы мәкаләсе. Мәкаләдә ул үзенең иҗатына тәнкыйть ясый. Кайбер уңышсыз шигырьләр язуына ачына, аларның меңләгән халык кулында укылып йөрүенә уңайсызлана. Киләчәктә һичбер нәрсәгә карамый, фәкать үзенең җаны сөйгән шигырьләреннән генә җыеп мәҗмугасын бастырырга вәгъдә бирә.

**15 март.** «Толстой сүзе» (Кирәк анчак...) шигыре басылып чыга. Яшәү фәлсәфәсен чагылдырган бу ике юллык шигырьнең нигезендә халык мәкальләре традициясе һәм Толстойча беддерелгән фәлсәфи-этик карашлар ята. Кешеләр җирдә ни өчен яшиләр? Әллә байлык туплау өчен генәме? Мондый сорауларга Тукайның җавабы болай:

*Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга,*
*Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.*

Җирдә яшәүнең максаты, Тукай фикеренчә, халыкка хезмәт итү идеалларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән булырга тиеш.

**18 март.** Фатыйх Әмирханга Клячкин больницасыннан хат яза.

«Фатыйх!

Мәкаләне бик сирәк нәрсәне баскан кеби зурлап баскансыз. Рәхмәт. Тагы да

язмый булмас, ахры, дип торам әле»,—дип, секретаре Ф. Әмирхан булган «Кояш» газетасында (74 сан) басылып чыккан «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсе өчен рәхмәт белдерә. Шунда ук «Кояш»ның редакторы Зәкәрия Садретдиновка сәлам күндерә. Вакытлы матбугат белән системалы кызыксынуы да күренә хаттан: «Кояш» тәртипсез килә. Соң килә. 72 нче номер бер көндә өчәү килде. Бу көнге номер икәү килде. 73 не исә бөтенләй күргәнем юк. Зинһар, хәзер бер номерын җибәрсәгез иде»,—дип үтенә.

**24 март.** «Мөхәрриргә» шигыре «Бер кыйтга» исеме белән басылып чыга.

**28 март.** «Толстой сүзләре» шигырен яза. Социаль эчтәлекле бу шигыре мәснәви жанрында язылган. Тукай, Толстой кебек, фәкыйрь кардәшләрен изгән байлар дөньясын күралмады, аларны кешелексезлектә, әхлаксызлыкта гаепләде.

*Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,*
*Күп вакыт борчы, тозы—мискин гидайлар яшьләре.*

«Буш вакыт» шигырен яза. Шифаханәдә язылган иң соңгы шигырьләреннән. «Толстой сүзләре», «Мәктәп» шигыре дә бер үк кәгазьдә язылып, азагына 28 апрель дип куелган. Вафатыннан соң (10 апрельдә) басылып чыга.

Шигырьнең кульязмасы Мирасханәдә саклана.

«Мәктәп» шигырен яза. Бу шигырь шагыйрьнең теләге, васыяте—милләтен мәгърифәткә өндәү. Тормышның матди ягын кайгырту белән генә чикләнмичә, рухи алгарышка, үсешкә, аң-белемгә омтылып, рухи, көр яшәргә чакыру булып яңгырый:

*Мәкаль бардыр: «Урыс байса—сала аулында дәү чиркәү;*
*Татар байса—хатын асрый, була хатыны өчәү-дүртәү».*
*Гүзәл тасвир кыйлынса, бу мәкальдән ушбудыр матлаб:*
*«Урыс байса—сала чиркәү, вәләкин әүвәле—мәктәп».*

«Кыйтга» («Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш...»), «Казан» шигырьләрен яза. Болар, шулай ук үзе үлгәч, 20 нче апрельдә басылып чыгалар. Шигырьнең ахырына «Соңгы шигырьләреннән» дип куелган.

**31 март, көндез сәг. 1—2ләр.** Доктор Р. А. Лурия килә, авыруны бик дикъкать белән карап, сорашып, аны өметләндерә торган сүзләр белән юата. Тукай яныннан чыккач, аны көтеп торган иптәшләренә (Ш. Әхмәров, Әмин Мостафин, Габдулла Кариев), авыруның хәле ничек, дип сорауларына каршы доктор: «Сездән яшерүне кирәк дип тапмыйм, авыруның хәле яхшы түгел, бик күп торса, 3—4 көн торыр, авыруның үзенә белдермәгез, ялгызын гына калдырмагыз»,—ди. Дуслары, фикердәшләре аның янына еш килеп йөриләр, моннан соң чиратлашып яныннан китмичә саклыйлар.

**31 март, кич сәг. 5ләр.** Авыруның хәле кинәт начарлана. Температурасы күтәрелә, пульсы ешая, тын алуы авырлаша. Ашаудан калып, бу төнне йоклый алмый чыга. «Бердән авыраеп, ашау-эчүдән вә йокыдан тәмам киселде... Хәлен белергә килүчеләр белән бәхилләшә, аз сөйләшә вә сораган сөальләргә дә бер сүз яхуд баш ишарәсе илә генә җавап бирә башлады».

**1 апрель.** Тукай янына больницага аның хәлен белергә шагыйрь Габдулла Харис белән татар журналисты Шәриф Байчура баралар. Бераз, 15—20 минут сөйләшеп, тизрәк сәламәтләнү теләп саубуллашып чыгалар.

Маһруй Мозаффария дус кызы Фатыйма Дәүләтгилдиева белән Тукайның хәлен белер өчен Клячкин шифаханәсенә киләләр һәм Тукайның тизрәк сәламәтләнүен теләп, саубуллашып китәләр. Истәлектән күренгәнчә:

«Сәгать өчне узган иде. Иптәшләреннән икесе аның янында иделәр... Без якынрак барып утырдык һәм: «Шәкерт туташларымыз сезнен сәламәтләнүегезне теләп калдылар. Сезнең шигырьләрегезне укып бик тәэсирләнәләр»,—дидек.

...Аның яныннан без инде бик авыр тойгы белән аерылдык».

**1 апрель, иртән сәг. 11 тирәсе.** Ш. Әхмәров сөйләве буенча: «...хәлегез ничек» дип

соравыма «әҗәл» диеп бер сүз илә җавап бирде дә, бераздан соң: «Хәлем авыр, болай булса, өч көннән артык чыдый алмам»,—диде. Шул ук көндә доктор да: «Авыруның хәле начар, озак торса, өч көн торыр, алайга да бармас, сез инде аны ташламагыз, дуслары җыелышып, бер тәртип илә һәрвакыт берегез янында булыгыз»,—диде.

**1 апрель, өйләдән соң.** Хәле кискенләшкәнне күреп, дуслары Тукайның рөхсәте белән фотограф Г. Якобсонны чакыралар, һәм ул шагыйрьне урын өстендә тезләрен кочаклап утырган килеш һәм кулларын баш астына куеп, ике мендәр өстендә яткан көенчә рәсемгә төшерә.

Тукай башлыча рәсемнәргә дуслары, танышлары, фикердәшләре белән төшәргә яраткан. Бу—исән чактагы соңгы рәсемендә дә ул дуслары белән. Баш очында утырганнар—халкыбызның атаклы артисты Габдулла Кариев, күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Сәйфи-Казанлы, журналист Шиһап Әхмәров. Нәкъ менә алар шифаханәдә Тукайның соңгы көннәрен күргәннәр, соңгы сулышынача янында булганнар.

Үләр алдыннан Тукай нәширләрдән алачак биш йөз сум акчасын бер ятим татар баласын стипендия биреп укыту өчен тотарга кушып, телдән васыять әйтә.

**1 нче апрельдән 2 нче апрельгә каршы төн.** Докторларның кинәшен тотып, бу төнне аны дуслары Ш. Әхмәров һәм Ә. Урманчиев саклап чыгалар. «Бу төндә хәле беркадәр яхшыланды: кыска-кыска, өзеп-өзеп булса да йоклады. Үзе дә: «Бүген беркадәр йоклый алдым, кәефем ярыйсы»,—дип сөйләде, ди Ш. Әхмәров».

**2 апрель, иртән.** Иртән чәй эчәргә утыргач: «Бергә эчик»,—диеп, Ә. Урманчиев һәм Ш. Әхмәров (алар авыру шагыйрь янында төн үткәргән булалар) белән сөйләшә-сөйләшә чәй эчәләр. Чәйдән соң: «Без китәбез»,—дигәч, «Кичкә тагын килсәгез, бик яхшы булыр иде, бүген уңай булды»,—диеп саубуллашып кала.

**2 апрель.** Кичке сәгать алты. Больницага Тукай янына «Ан» журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни килә. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Тукай, гадәтенчә: «Актык корректура кайчан?»—дип сорый. Хәсәни, ул сораган корректура янында булса да, йә хәзер үк торып төзәтә башлар дип, аны кызганып: «Иртәгә була»,—ди.

Бу вакытта Тукай янында дусларыннан Әмин Мостафин була. Ә. Хәсәни Тукай янында 7 сәг. 30 минутка кадәр була һәм саубуллашып чыга.

**2 апрель, кичке 8 сәг. 15 мин.** Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның йөрәге тибүдән туктый. Җан биргән вакытында аның янында Әмин Мостафин була.

**3 апрель һәм аннан соң.** Тукайның үлеме турында газета-журнал редакцияләренә һәм бүтән шәһәрләрдәге дусларына-иптәшләренә хәбәр ителә, телеграммалар җибәрелә.

Татарлар яшәгән күп төбәкләрдән, Петербург, Мәскәү кебек шәһәрләрдән газета-журнал редакцияләренә Тукайның үлеменә тирән кайгы белдергән чиксез күп тәгъзия (кайгыны уртаклашу) телеграммалары, хатлар килә. Вакытлы матбугатта шагыйрьнең үлеме мөнәсәбәте белән дусларының, аны белгән, аралашкан иптәшләренең язган шигырьләре, мәкаләләре басыла. Профессор Н. Ф. Катанов: «Шагыйрьнең үлеме бөтен халык өчен зур бер милли хәсрәткә әйләнде. Мәрхүм шагыйрьнең биографиясе һәм хатирәләр белән, шигырьләренең һәм талантының кыйммәтен тәкъдир итеп язылган мәкаләләр белән бөтен татар газеталары тулды»,—дип яза.

**4 апрель.** Г. Тукайны күмү көне. Ул көн чыккан газета битләре кайгылы мәкаләләр белән тулы. «Сабах», «Мәгариф», «Гасыр», «Юл» көтепханәләре ябык. Тәрәзәләренә кара рамка эченә Тукайның матәм рәсемнәре куелган. Газета-журнал идарәләре дә иртәдән үк ябык, эшләми.

Тукайның җеназасы өйләдән соң сәгать бердә Клячкин шифаханәсеннән чыгачагы бөтен шәһәр халкына таралып өлгергән.

Иртәдән үк шагыйрь белән соңгы мәртәбә хушлашырга халык төркеме җыела башлый. Тукайны күреп калырга теләүчеләргә кереп, күреп чыгарга рөхсәт бирелә.

Көтепханәләр, газета-журнал идарәләре, дуслары, иптәшләре, студентлар, «Сәйяр» труппасы артистлары, «Шәрык» клубы вә башкалар тарафыннан Тукайга соңгы бүләкләре итеп әзерләнгән чәчәкләр килә башлый, һәркайсы чәчәкләргә ефәк ленталар бәйләп, үзләренең сөекле шагыйрьләренә әйтеп калачак соңгы сүзләрен язганнар.

Халык чыгып беткәч, Тукайның йөзе ачык хәлдә ахыргы рәсеме һәм маскасы алына.

**4 апрель.** Көндез 1 сәг. 30 минутта Тукайның гәүдәсе табутка салына, табут өстенә ак ефәк лентага үзенең шигыреннән:

*Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә;*
*Бирдең арканңны моңарчы, инде бир бит әмреңә!—*

юллары язылган, кырые укалаган кара хәтфә ябыла.

Шифаханә ишегалдында, җеназа җирдән күтәрелгәч, рәсем алдырыла. Кузгалып, җеназа укыла торган мәйданга юнәләләр. Биредә биш-алты меңләп халык көтеп торалар. Шулар арасында Казанның барлык имамнары була. Зариф хәзрәт Әмирхан (әдип Фатыйх Әмирханның әтисе) тарафыннан җеназа укыла. Җеназа сонында табутны имамнар күтәреп алалар (бу мизгел дә рәсемгә алына), һәм меңләгән халык төркеме, җеназаны озатып, Яңа бистә зиратына юнәләләр. Тукайның гәүдәсе кабергә иңдерелә (бу вакытта тагын рәсем чыгарыла), һәркем туфрак салырга ашыга. Күмү тәмам була. Кабер өсте чәчәк өеменә әверелә. Зариф хәзрәт Тәбарәк укый. Догадан соң, мәрхүмнең васыяте буенча, Касыйм хәзрәт «Васыятем» шигырен укый. Соңыннан берничә кеше тарафыннан нотыклар сөйләнә.

Нотык сөйләүчеләр, Тукайның табутын күтәреп баручы якын дуслары, күмү комиссиясе башында йөргән Гыйльметдин Шәрәф, Шиһап Әхмәров, Габдулла Кариев, Гафур һәм Каюм Коләхметовлар була. Гафур Коләхметов Тукайның каберенә үз исеменнән венок та куя.

Якын дусты Ф.Әмирханның Тукайны күмүгә багышланган мәкаләсе шул көнне «Кояш»та басылып чыга: «Шималь төрекләре бүген үзләренең иң мәшһүр, иң сөекле шагыйрьләрен күмәләр. Шималь төрек әдипләре бүген үз иптәшләреннән халык күңеленә иң якын тора торган берсен араларыннан югалталар. Без бүген халык шагыйре Тукайны озатамыз».

**4 апрель.** Тукайның җеназа мәрасимен, күмү күренешләрен чагылдырган биш фоторәсем алдырыла.

Тукайның үлемен хәбәр итеп, барлык газета-журналларда некрологлар басыла.

Шушы кайгылы хәбәр билгеле булганнан соң, редакцияләр адресына дөньяның төрле почмакларыннан телеграммалар килә башлый. Петербург, Мәскәү, Харьков, Симферополь, Уфа, Тамбов, Саратов, Кунгур, Красноуфимск, Верхнеуральск, Екатеринбург, Астрахань, Семипалатинск, Әндижан, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләреннән, Польша һәм Төркиядән кайгы телеграммалары алына. Хатын-кызлардан бигрәк тә күп телеграммалар килә. Халык Тукайга багышлап язган шигырьләрен җибәрә, киңәш-тәкъдимнәрен әйтә. «Вакыт» газетасының 1913 ел, 30 апрель санында күренгәнчә, Семипалатинск шәһәреннән берәү Тукайга һәйкәл куярга кирәклеген яза. Шагыйрь истәлеген мәңгеләштерүдә бу беренче тәкъдим була.

Вакытлы матбугатта берничә ай буена һәр газетада, һәр санында мәрһүмнең фотолары, кайгы телеграммалары, тәгъзия хатлары, Тукайга багышланган шигырьләр, мәкаләләр басылып тора. «Мәктәп» журналы 4 нче санын тулысынча мәрхүм шагыйрь Тукайга багышлап чыгара. Якын дуслары аны сагынып хатирә-истәлекләрен уртаклашалар.

«Тукай безнең олуг милли шагыйребез иде. Тукай безнең иске тормышның черегән чүбе өстенә үскән матур чәчәгебез иде. Тукай безнең мәктәп балаларыбыз өчен, яшь буыныбыз өчен милли бер каһарманыбыз. Тукай безнең киләчәктә татар әдәбиятына салына торган таза бер нигезебез»,—дип яза «Ил» (39 нчы сан) газетасы.

Бу көннәрдә һәркем югалткан кешенең кем икәнлеген төшенә, аңлый. Татар милләте тирән кайгы кичерә.

# БЕР РӘСЕМНЕҢ ТАРИХЫ



Бу—Габдулла Тукайның 1911 елда Әстерханда төшкән фотосы. Аңа 25 яшь. Карап торырга 15-16 яшьлек үсмер дип уйларга була. Казаннан көймә белән Әстерханга төшкәндә Тукай озын чәчле, баш киемсез икәнен яза. Әстерханга төшкәч, ул чәчен ялтыратып кырдыра, шәрә баш белән йөрисе килмичәме, модага иярепме, башына картуз кия. Ул вакытта кырылган башлыларны «гололобый татарин» дип мыскыллап йөрткәннәренә күрәдер, бәлки.

Бу—төп фото түгел, Тукай шуннан аерып алып кына бирелгән.



Бу фотосурәт китаптан-китапка күчеп йөри. Әмма ул да тулы сурәт түгел. Тукай янында—актер Зәйни Солтан.



Шул ук фотоның сигез кеше сурәтләнгәне дә китаптан-китапка күчә. Алгы рәттә Тукай хөрмәтенә оештырылган тамашада Тукай шигырьләрен сәхнәдән сөйләгән ун яшьлек ир бала—Рәхим Солтанов, Зәйни Солтанның туганнан туган энесе (җәгәне), шул ук алгы рәттә артист Басыйр Габдуллин. Уртада утырганнар (сулдан): Зәйни Солтан, Тукай, С. Рәмиев.

Артта басканнар (сулдан): Габдрахман Сәмәки (Әбүбәкеров), Тукайның дусты, алар Жаекта бергә укыганнар, артист, мөгаллим Габдрахман Басыйрый, Шәһит Гайфи, укытучы,Тукайны кымыз эчәргә алып барган кеше.



Фотоның тагын да киңрәген алып карасак, шәхесләр өстәлә бара. Икенче рәттә, уңнан өченче Әстерхан театрын оештыручыларның иң активы Давыт Мөхәммәдов (Гөлсем Мөхәммәдованың атасы), аның хатыны Һажәрхан Мөхәммәдова, Әстерхандагы татар хатын-кызларыннан беренче булып сәхнәгә чыгучы ханым, аның янында театрның киендерүчесе Зәйнәп Диникәева. С. Рәмиевнең уң ягындагы кеше Әстерхан театры артисты Биккинин, арттагы шәхесләр: мөгаллим (соңыннан мулла булып китә) Әбүбәкер (Хәлилов) һәм артист Зөлкарнәй Байкин (1936 елда вафат).

Бу фотодан да бер шәхесне кисеп калдырганнар, менә фотоның тулысы, чыны.



Икенче рәттә, сул яктан беренче, бер чибәр ир кеше утыра, ул—Касыйм Туйбахтин. Касыйм бик талантлы оештыручы кеше булганга, Ленин аны 1918 елда Әстерхан губернасына гадәттән тыш эшләр комиссары итеп җибәрә. Контрреволюцион фетнә вакытында зинданда җәзалап үтерелә. Үләр алдыннан ул каны белән диварга: «Зинһар, кызымны укытыгыз», дип язып калдыра.

Алгы рәттәге үсмер Рәхим Солтанов та егет булып өлгерә һәм 1920 елда аклар аны да атып үтерә. Урыннары җәннәттә булсын! Аның уң ягындагылар: Басыйр Абдуллин, Габрахман Адаков, Туктар Диникиев (фельдшер, артист).

Фотоларны төшүчеләр саны арту тәртибендә күрсәттек. Чынлыкта киресенчә була: вакыт үткән саен фотодагылар кими бара. Бу асылда вакыт иләгенең киләчәккә чын олы затларны гына калдыруы, ягъни табигый сайланыш. Ләкин тоталитар заманда «артыкларны» репрессияләп, аннары фотолардан кисеп ату яки буяп куюлар да гадәти хәл булган.

**Р. БАТУЛЛА.**

# ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ БУЛЫРМЫ?

Тукай энциклопедиясен төзү кирәклеге турында сүз чыкканга, ялгышмасам, өч дистә елдан артык гомер үтте инде. Узган гасырның 70 нче елларында Украинада ике томлы «Тарас Шевченко сүзлеге» (Киев,1978; асылда, энциклопедия) басылгач, аның сәхифәләрендә бөек украин шагыйре иҗаты белән татар әдәбияты вәкилләренең дә шактый бәйләнешле булуларын да (тәрҗемәләр, мәкаләләр, шигырьләр) күреп, Әбрар Кәримуллин һәм Нил Юзиевләр без татарларда да мондый энциклопедик характердагы хезмәтләр тудырырга вакыт җиткәнлеген язып чыктылар (ләкин, ни өчендер, андагы татар әдәбиятына караган мәкаләләрне Резеда Ганиева язганлыгын әйтмәгәннәр иде). Бу мәсьәләне бераз соңрак Флүн Мусин да кузгатты. Әмма бу елларда без әле Татарстаныбызның автономияле республика рәвешендә «чәчәк аткан»ын күреп, «шөкерана кылып» яшәп ята идек. Татар филологиясе буенча гыйльми эшләргә дә СССРда академик фәнне оештыру өчен җаваплы Мәскәү түрәләре татарларда энциклопедия кебек фундаменталь хезмәт булдыруга унай карадылар дип әйтеп булмый. Мәсәлән, элегрәк тә алар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең шактый тулы 15 томлы басмасын әзерләүгә хәерхаһлык күрсәтмәделәр. Нәтиҗәдә, ул сигез томлы булып кына гамәлгә ашырыла алды.

Ниһаять, 90нчы елларга аяк бастык. Яңа иҗтимагый вәзгыятьтә Институт үз эшчәнлеген уйлабрак, шактый дәрәҗәдә мөстәкыйль рәвештә оештыра, планлаштыра башлады. Мәсәлән, әдәбиятчылар, текстологлар алдына күп гасырлык татар әдәбияты тарихын янача, объектив критерийлар кулланып язу, җитмеш ел буе хәтта исемен дә телгә алырга ярамаган Гаяз Исхакыйның күпкырлы, бай мирасын кайтару, әсәрләренең унбиш томлы басмасын әзерләү мәсьәләсе килеп басты. Институттагы аз санлы фәнни хезмәткәрләр көче белән генә Тукай энциклопедиясен төзүгә алыну мөмкин түгел иде, билгеле. Бу урында ул чактагы кульъязмалар һәм текстология бүлеге мөдире, күренекле әдәбият галиме, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Нил Юзиевнең иҗтиһадлы гамәлләргә баруын әйтергә кирәк. Тукай энциклопедиясе кебек күләмле, фундаменталь хезмәтне бөтен татар әдәбиятчы галимнәре катнашында гына, ягъни координацияләү юлы белән генә тудырып булачагын истә тотып, ул аны Институтның фәнни тикшеренү планнарына кертү мөмкинлеген көтеп тормыйча, вакытлы иҗат төркемнәре төзеп, килешүләр юлы белән эш итү карарына килде. Яңа төзелгән Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчелегендә, аның әдәбият бүлемендә дә бу фикер хуплау тапты.

Татар телендә аерым күренекле шәхескә багышланган, ягъни персональ энциклопедия моңа кадәр бер генә тапкыр да төзелмәгән иде әле. Тәҗрибә дә тупланмаган. Әмма ки рус әдәбият белемендә үрнәккә алырлык хезмәтләр, барыннан да бигрәк, Лермонтов энциклопедиясе (Мәскәү, 1981) инде бар иде. Нил Юзиев бөек Тукаебызга багышланган энциклопедияне «энциклопедик сүзлек-белешмә» дип кенә атап эш башлау ягында торса да, аның нәкъ менә Лермонтов энциклопедиясе тибында эшләнергә тиешлегенә басым ясады. Беренче эш итеп анда бирелердәй мәкаләләр нинди характердагы мәгълүматларны эченә алачагын билгеләргә кирәк иде, һәм Н. Юзиев эшне сигез юнәлештә (бүлектә) оештырырга булды.

Беренче бүлектә Габдулла Тукай әсәрләре—шигырьләр һәм поэмалары, прозасы, публицистик мәкалә һәм фельетоннары, балалар өчен язылган шигырьләре, чәчмә парчалары—һәрберсе турында аерым-аерым фәнни фикер әйтелә.

Икенче бүлектә Тукай иҗаты татар әдәбият белеме мәсьәләләре белән бәйләнештә өйрәнелә (гаруз, жанрлар, вәзен, Коръән мотивлары, эстетик идеал, сатира, пейзаж, тарихилык, халыкчанлык, романтизм һ. б.)

Өченче бүлектә Тукайның туганнары, дуслары, атаклы замандашлары белән

мөнәсәбәтләре турында мәгълүмат бирелә (Зиннәтулла, Газизәләр, Сәгъди, Мотыйгулла хәзрәт, Сәгыйт Рәмиев, Габдулла Кариев һ. б.).

Дүртенче бүлектә Тукайның аерым татар әдипләренә тәэсире турында сүз бара, шулай ук шагыйрьнең татар вакытлы матбугат органнары, нәшриятлар белән бәйләнешләре тикшерелә.

Бишенче бүлек «Тукай һәм татардан тыш дөнья» дип исемләнгән иде. Бөек шагыйребез иҗаты кайбер төрки халыкларга оригиналда, ә, гомумән алганда, башка милләтләр укучыларына тәрҗемәләрдә барып ирешә. Бу изге эшне шагыйрь-тәрҗемәчеләр үти. Энциклопедиядә алар эшчәнлеге дә яктыртылырга тиешле була.

Алтынчы бүлектә Тукай темасының сәнгать төрләрендә—театрда, телевидениедә, кинофильмнарда; рәссамнар иҗатында, сынлы, декоратив сәнгатьтә; музыкада чагылышы өйрәнелә.

Җиденче бүлектәге мәкалә һәм белешмәләрдә Тукайның тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннар турында сөйләнә. Монда Тукай иҗатындагы әдәби топографик материал тәфтишләнәсе, ягъни шагыйрь әсәрләрендә Төркия, Уральск (Җаек), Мәскәү, Болгар, Кушлавыч, Кырлай кебек шәһәр-салалар, илләр, мәмләкәтләр урын алуы күзәтелә.

Сигезенче бүлек. Тукай тормышын һәм иҗатын өйрәнү белеменең йөз еллык тарихы бар. Бик күп татар галимнәре Тукай феноменының асылын ачарга, әсәрләрен интерпретацияләргә омтылдылар, хәзер дә әһәмиятен югалтмаган фикер-бәяләр дә әйтелде, сәяси вәзгыять басымы астында кайбер әсәрләр ялгыш та аңлатылдылар. 7-8 еллык иҗат дәверендә 750 әсәрен 65 ләп ачык һәм яшерен имза (псевдоним) кулланып укучыга җиткергән Тукай. Бу мәсьәлә дә игътибардан читтә калмастыр.

Татарстан Фәннәр академиясенең Гуманитар фәннәр бүлеме каршында оештырылган вакытлы иҗат коллективы 1995-1997 елларда әлеге бүлекләр өчен язылачак мәкаләләрнең исемлеген төзү белән мәшгуль булып, ул (исемлек) 1998 елда брошюра сыйфатында басылып чыгып, әдәби һәм гыйльми җәмәгатьчелеккә җиткерелде, хупланды. Хәзер инде җиң сызганып энциклопедиягә керәсе мәкаләләрнең үзләрен язарга кирәк иде.

Югарыда искәрткәнемчә, Тукай энциклопедиясен Г. Ибраһимов исемендәге институт фәнни хезмәткәрләре катнашында гына төзү һич тә мөмкин түгел иде. Икенче кыенлык: ул вакытларга Гали Халит, Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев, Рәшат Гайнанов кебек күренекле тукайчы галимнәребез инде бакый дөньяга күчтеләр. Бераздан Тукай энциклопедиясе төзүне кайнар хуплаган Әбрар Кәримуллин, Рәфыйк Нәфыйковлардан аерылдык. Тукайчылар сафы сирәкләнеп калды... Әмма шулай да Тукайны аңларга, яңача аңлатырга омтылучы галимнәребез, эзләнә торгач, табыла торды. Бу урында Казан университетыннан Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов, Резеда Ганиева, Таһир Гыйлаҗев, Дания Заһидуллина, Рифә Рахманнарның, хәзерге гуманитар-педагогика университетыннан Фоат Галимуллин, Фәрит Яхин, Эльмира Галиева кебек галим-галимәләрнең исемнәрен атарга кирәк. Институтыбызның үз фәнни хезмәткәрләре дә кадәри хәл көч куялар, билгеле.

Хөрмәтле укучыларыбыз, галимнәрнең Тукай энциклопедиясен төзү эшенә керешкәннәренә инде дистәдән артык ел үткәнлеген белгәч тә, «Кайда соң ул энциклопедия?» дигән сорау бирерләр һәм бу гаҗәп тә булмас. Безнең җавап әлегә укучының кызыксынуын канәгатьләндерерлек түгел: Тукай энциклопедиясе төзелеп бетмәгән һәм шагыйрьнең 125 еллык юбилеена да ул укучы кулына килеп кермәячәк.

Сәбәпләр күп төрле. Беренчесе, һәм иң мөһиме дә дияргә була: бу— аны төзүгә игътибарның аз булуы (бу хакта элегрәк матбугатта да әйтелде, Татарстан Президентына хат та юлланды). Җитәр-җитмәс бюджет акчасына утырып кына фәнни тикшеренүләр алып баручыларга мондый фундаменталь хезмәтне башкарып чыгуга сарыф ителәчәк ресурсларны табу—үзе зур мәсьәлә. Дөрес, сигез-тугыз ел дәвамында Татарстанның Фәнни тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фондыннан, «Мирас» фондыннан беркадәр акча бүленеп килде (хәзер бусы да туктады). Энциклопедиягә дигән 2800ләп мәкаләнең (һәрберсенең күләме ярты

биттән 4 биткә кадәр) 1500ләбе генә язылган. Күренә ки, эш һаман да шушы тизлектә генә дәвам итсә, аларны язып тәмамлау һәм тиешенчә редакцияләп, Тукай энциклопедиясен бер бөтен итеп нәшер кылу өчен тагын ун еллап вакыт кирәк булмагае.

Күптән түгел Тукайның быелгы 125 еллык юбилеена энциклопедия өчен язылган мәкаләләрнең беркадәресен китап рәвешендә бастырып чыгару уе туды, һәм вакытлы иҗат төркемендә бер карарга килендe: шагыйрь әсәрләре турындагы мәкаләләр белән укучыларны таныштыра торырга кирәк. Бу китап-җыентык якынча 750 ләп мәкаләне эченә алырга тиешле (Тукайның төрле жанрда язылган әсәрләренең гомуми саны—750). Алар теге яки бу әсәрнең идея-эстетик табигатен, сәнгати үзенчәлеген бүгенге фән күзлегеннән җентекле тикшереп, дәлилләп ачуга хезмәт итәрләрдер. Табигый ки, һәр мәкалә, әсәрләргә элекке тикшеренүчеләр хезмәтләрендә очрый торган бәяләрне дә истә тотып язылса гына, энциклопедиядә урын алуга хаклы. Анда әсәрләрнең башка телләргә тәрҗемә ителүе турындагы мәгълүматлар китерелә, кыскача гына сәнгать дөньясында чагылышы да әйтелә. Ахыр чиктә, мәкалә Тукай каләменнән чыккан һәрбер текст турында җыйнак, әмма тирән эчтәлекле, фикерле фәнни хезмәт булып әверелер дип уйлыйбыз.

Моннан ун еллар элек, Тукайның 115 еллык юбилее вакытында бу юлларның авторы энциклопедияне төзү эшен 120 еллыгына төгәлләү фаразын биреп караган иде. Булмады, өлгермәдек. Хәзер инде аны төзеп төгәлләү вакыты итеп 2016 елны—шагыйрьнең тууына 130 ел тулу юбилеен билгеләргә тиешбез сыман. Ни язгандыр тагын...

**Зөфәр РӘМИЕВ,**
*вакытлы иҗат төркеме җитәкчесе,*
*филология фәннәре докторы*

---

## *Бөекләр сүзе*

### Максим Горький:

*—Мир этот не для художников, им всегда было тесно и неловко в нем,—тем почетней и героичней их роль. Очень хорошо сказал один казанский татарин—поэт, умирая от голода и чахотки: «Из железной клетки мира улетает, улетает юная душа моя...»*

### Мостай Кәрим:

*—Башкорт халкына килгәндә, башкорт халкы Тукай алдында муеннан бурычлы. Ул башкорт халкы мөгаллимнәренең, мәгърифәтчеләренең берсе һәм иң күренеклесе булды. Башкорт әдәбиятына остазлык итүчеләрнең иң атаклысы һәм иң якыны булды. Үземә кагылганда, шуны әйтәсе килә: инде менә ничә еллар Тукайга сокланып туя алмыйм.*

# ТУКАЙ, КАЗАН ҺӘМ ТУКАЙНЫҢ КАЗАН ТӨБӘГЕНДӘГЕ ТУГАННАРЫ

*Бөекләр булган. Җуйганбыз.*
*Гасырлар—ерак ара.*
*Кайта-кайта: «Тукай!»—дибез,—*
*Ул шул яңарак яра...*

Р.Фәйзуллин

Тукайның тәрҗемәи хәле—дөнья әдәбияты тарихында иң гыйбрәтлеләрдән берсе. Бакыйлыкка күчкәндә ана нибары 27 яшь була. Шагыйрь тормышы 1886 елның апреле—1913 елның апреле белән чикләнә.

Беренче карашка, шагыйрь үткән юллар озын түгел. Анын маршруты да күп очракта Кушлавыч, Кырлай, Өчиле авыллары, Казан, Җаек шәһәрләре һәм кабаттан Казан арасында уза. Ләкин шушы кыска юлларда да язмыш аңа никадәр фаҗига әзерләп куйган.

Бүген безгә анын тышкы кыяфәте, гадәтләре, даирәсе, туганнары, ягъни Тукай исеме белән бәйле һәр нәрсә кызыклы.

Г.Тукай әдәби музееның беренче директоры Госман Әкрәм улы Хәбибуллиннан шагыйрьнең апасының улы Хөсәен Зәбиров турында мин күптәннән ишетеп белә идем. Еллар узганнан соң, мин дулкынлану белән Г.Тукайның апасы Газизә Зәбированың кече улы Хөсәен төзегән альбомны кулыма алам. Нәкъ менә шушы альбомда шагыйрь турындагы кыйммәтле мәгълүматлар: Казанда анын исеме белән бәйле, схема-сызымнары белән күрсәтелгән урыннар, шәҗәрәсе, борынгы фоторәсемнәр бергә тупланган.

2006 елда, Тукайның тууына 120 ел тулуны бәйрәм иткәндә, миңа шагыйрьнең бертуган апасының оныклары—Суфия Гали кызы Зәбирова, анын кызы Гөлнара Җумәбәк кызы Ансаганова һәм альбом иясе Наилә Хөсәен кызы Зәбирова-Шаповалова белән танышу һәм эшләү насыйп булды. Татар милләтенең бөек улына багышланган тантаналарның һәммәсендә катнашып, без бергәләшеп Тукай эзләре буйлап үттек...

Тукайның кыска гына гомер юлында Казан аерым бер урын алып тора. Апуш шәһәр белән беренче тапкыр тома ятим калып чит кешеләр тәрбиясендә яшәгәндә таныша. Икенче тапкыр ул татар мәркәзе белән 13 елдан соң очраша. Бу юлы инде ул Казанга шагыйрь күзлегеннән чыгып карый. Әле Җаекта яшәгәндә үк Габдулла дулкынлану белән:

*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!..*
*Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;*
*Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.*
*Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур...—*

дип яза.

Казанда Тукай зур шагыйрь булып җитешә, гомеренең соңгы сәгатенәчә кулыннан каләмен төшерми. Анын беренче тапкыр басылып чыккан әсәре «Белем бакчасында» һәм иң соңгысы булган «Мәктәп» арасында нибары җиде ел вакыт ята. Тукай халык авыз иҗаты, татар әдәбиятының күп гасырлык традицияләре һәм көнчыгыш поэзиясе йогынтысында рухланып иҗат итә. Бу иҗат чишмәләре анын таланты белән бергә кушылып, Тукайга халык уе белән яшәргә, милли әдәбиятны бөтенроссия киңлекләренә чыгарырга, аны дөнья әдәбияты дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итә.

1958 елның 9 августында Казанда Кабан күле буендагы мәйданда халык шагыйренә һәйкәл ачыла. Мәрмәр Тукай безгә гүя дәшә:


*Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;*
*Саулыгың—минем саулык, авыруың—минем авыруым.*
*Синеке дип исәпләсәләр—бәхетле мин;*
*Игелекле шагыйрең булырга ниятлимен!*
*Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы;*
*Шаша калсам, тик шул хыялдан гына булыр.*
(«Милләткә»)

Әйе, безнең белән шагыйрь-гражданин сөйләшә. Сынчылар С.Ахун, Л.Кербель, Л.Писаревский һәм архитектор Л.Павлов Тукайны әнә шулай мәңгеләштерә. Шигърият сөючеләр бирегә Тукай рухын яд итү өчен килә.

Кабан—күп санлы халык риваятьләренә кергән гаҗәеп күл. Кечкенә Апуш аны беренче тапкыр биш яшендә күрә. Кабат Казанга әйләнеп кайткач, ул күлдән ерак түгел урнашкан «Болгар» номерларында алты ел гомер кичерә.

*Кай заманда, кайсы телдә булса да мәзкүр Казан,*
*Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл—Кабан.*
*Бу шәһәрне һәм бу күлне җырлыйдыр милләт теле*
*Бик яратып, әллә инде иске шөһрәт аркылы.*
*Ул шәһәр—гади шәһәр, алтын-көмеш, гәүһәр түгел;*
*Күл дә тик бер күл генә, әлбәттә, ул кәүсәр түгел...*

«Шәрык» клубында татар халык җырлары концертларда гына түгел, «Сәйяр» труппасы спектакльләренең антракты вакытында да башкарыла. Йөзләп тамашачыны сыйдырган икенче каттагы унайлы бүлмәдә спектакльләр куела, лекцияләр укыла. 1910 елның 15 апрелендә Тукай халык иҗаты турында лекция белән чыгыш ясый. Бу шагыйрьнең сәламәтлеге нык какшаган көннәрдә була һәм ул моның өчен нык борчыла. Әмма халык алдында җаваплылык тойган Тукай барыбер очрашуга килә. «Белергә кирәк ки, халык җырлары—халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгеседер. Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».



*Хөсәен Зәбиров тарафыннан төзелгән Тукай белән бәйле истәлекле урыннар (карта-схемалары белән күрсәтелгән).*

Татар профессиональ театр сәнгатенә нәкъ менә «Шәрык» клубында эшләгән «Сәйяр» труппасы нигез сала. 1908-1918 елларда аңа Тукайның яшьлек дусты—реалистик татар театрына нигез салучы Габдулла Кариев җитәкчелек итә. Тукай труппаның тугры дусты була, артистларның уңышларына ихлас сөенә, алар кыенлыкларга очраса, чын йөрәктән көенә. Труппаны «Сәйяр» исеме белән атарга да Тукай тәкъдим итә. Шунысы игътибарга лаек: элек җыйнак кына «Шәрык» клубы урнашкан йортның каршысында хәзер Г.Камал

исемендәге татар театрының мәһабәт бинасы балкып утыра.

Казанда Тукайга бәйле урыннар бер-берсенә якын урнашкан. Элеккеге «Болгар» номерлары да шул тирәдә.

Тукай шигырьләре илаһи моң белән сугарылган. Бу—шагыйрьнең халык җырларыннан илһам алып иҗат итүе белән дә аңлатыла. Ул аларны еллар буена җыя һәм соңыннан «Милли көйләр» дигән җыентыкта бастыра. Замандашларының истәлекләренә караганда, Тукай үзе дә җырларга яраткан; аның җырлавы халыкка профессиональ җырчыларныкына караганда да ныграк тәэсир иткән.

Инкыйлабка кадәрге чорда милли музыканы пропагандалауда «Шәрык» клубы һәм «Болгар» кунакханәсе мөһим роль уйнаган. Шагыйрь «Болгар»да 1907 елдан 1912 елга кадәр яши. Баштарак ул төрле номерларда торса, соңрак замандашлары истәлекләрендә күп тапкырлар телгә алынган кырыгынчы бүлмәдә гомер итә.

«Номерга керү Евангелистлар урамы ягыннан булган (хәзер Татарстан ур.—Ф.Д.), ал яктагы ишектә кунакларны Закир исемле швейцар каршы алган. Кырыгынчы бүлмә өченче катта, ресторан янында, ун яктан ин кырыйда урнашкан. Бүлмә хуҗасы чыккан вакытта ишеген бикләмәгән. Анда—соры юрган белән капланган тар тимер карават, сулда—Кабан күленә караган бердәнбер тәрәзә янында язу өстәле булган. Тәрәзә төбе, өстәл, өстәл асты—һәммәсе дә китаплар, кульязмалар, кәгазьләр белән тулган. Бүлмә кечкенә, кысан, бүгенге үлчәм белән ун квадрат метрдан да зур түгел». И.Нуруллинның «Габдулла Тукай» исемле китабында шагыйрь яшәгән чордагы бүлмә шулай тасвирлана.

«Болгар»да яшәгәндә Тукай Г.Камал, С.Рәмиев һәм башка татар зыялылары белән таныша. Аның рухи үсешендә Ф. Әмирханның тәэсире зур була. Алар беренче тапкыр 1907 елда Әмирханнар йортында күрешә. «Әлислах» гәҗите редакциясендә хезмәттәшлек итә башлагач, ике әдип якын дусларга әйләнә. Кызганыч, ул биналар бүген юк инде.

Әлеге дуслык Тукай өчен кояш җылысына тиң була. Эштән соң алар аз очраша. Тукай оялчан булу сәбәпле, Әмирханнар йортына сирәк килә. Фатих исә инвалидлар коляскасына береккән...

Казан тарихына кереп калган тагын бер кызыклы урын—ул Юныс мәйданы. Моннан халык шагыйрен соңгы юлга озаталар. Очлы түбәле «Шамил йорты» (хәзер анда Г.Тукайның Әдәби музее урнашкан) һәм киң балконлы-фонарьле ак бина (сәүдәгәр Апанаевларның соңгы йортларыннан берсе) мәйданның тарихи йөзен билгели. Бу мәйдан шагыйрь исемен йөрткән урамның башланган урыны булып тора.

Элеккеге Мәскәү урамы (хәзер ана шул исем кайтарылды). Кайчандыр монда атаклы Печән базары гөрләгән. Аның иң кайнаган урыннарыннан берсе Базар мәйданы була (хәзер бакча белән бүленгән). Базарда вак һөнәрчеләрнең һәм сәүдәгәрләрнең төрледән-төрле товарлары сатылган. Шушында ук чәйханәләр, трактирлар, атлы юлчылар кереп куна торган йортлар урнашкан.

1908 елда Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемле атаклы сатирик поэмасын иҗат итә. Ул аны биш көн эчендә язып тәмамлый. 14 октябрьдә аны Сәүдәгәрләр клубында (К.Нәҗми ур. 2/10) укый. Әсәр зур уңыш казана, тыңлаучыларның тыела алмый көлүләре сәбәпле, шагыйрь еш кына укуыннан бүленергә мәҗбүр була.

Печән базары тирәсендә типографияләр Кәримовларның Мәскәү урамындагы 66 нчы йортта урнашкан зур типографиясе, гәҗит редакцияләре («Йолдыз», «Кояш»), нәшриятлар («Мәгариф», «Гасыр», «Юл») һәм китапханәләр урнашкан.

Якында гына Тукай һәм башка шәхесләр исеме белән бәйле «Болгар», «Амур», «Мәскәү» кунакханәләре була.

«Амур» кунакханәсе (Мәскәү ур, 70). Тукай монда хастаханәгә киткәнче, ягъни 1913 елның гыйнвар-февралендә яши. Ана инде үлем авыруы йоккан. Шуна да карамастан, ул кырык сум хезмәт хакына «Кояш» газетасында эшли. Бу редакция аның өчен «Амур» кунакханәсенең тугызынчы бүлмәсен вакытлыча файдалануга ала. Уникенче бүлмәдә исә Ф.Әмирхан яши. Хәзер дуслар көн саен күрешә. Бу чорда Тукай гаять уңдырышлы иҗат итә.

1913 елның февралендә Тукайның сәламәтлеге бик нык какшый. Әмирхан стена аша дустының көн-төн бертуктамый йөткерүен ишетеп тора.

Шагыйрьнең соңгы сыену урыны—Клячкин хастаханәсе. 2(15) апрель кичендә Тукай биредә мәңгелеккә күзләрен йома. Әмма ул халкы хәтерендә мәңгегә илһамлы, үткер карашлы булып сакланып калды.

Татар халкының бөек шагыйре пайтәхетебез Казан тарихының кабатланмас бер өлешен тәшкил итә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле дә аның исемен йөртә. Коллектив бик еш чит илләрдә була һәм һәр концертта Тукай шигырьләренә язылган һәм күптәннән халыкныкына әйләнгән—«Тәфтиләү», «Пар ат», «Туган тел» җырларын башкара.


М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры—Казандагы иң матур биналарның берсе. Театр урамы ягыннан керү ишеге алдында Тукай һәйкәле тора (сынчы—Е.Шулик). 26 апрельдә, шагыйрьнең туган көнендә монда республиканың танылган каләм әһелләре һәм сәнгать эшлеклеләре катнашында шигырь бәйрәмен уздыру күркәм гадәткә әйләнде.

Әлеге театр сәхнәсендә инде күптәннән Тукай әкиятләре буенча куелган «Шүрәле», «Кисекбаш», «Су анасы» балетлары бара. Композитор Ф.Яруллин иҗат иткән «Шүрәле» балеты исә Россиядә генә түгел, дөньяның күп илләрендә абруй казанды. Бу җәһәттән мәшһүр М.Плисецкая болай дип яза: «Мин бу балетта биергә яратам. Тукайның искиткеч әкияте шигъри һәм милли генә түгел, күпкырлы да!» (1976). Композитор Ә.Бакиров иҗат иткән «Су анасы» балеты исә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Казанның бер урамы Тукай исемен йөртә, башкалабыздагы үзәк мәйданнарның берсе—элеккеге «Божра»—Тукай мәйданы дип атала башлады.

Ә хәзер Габдулла Тукайның туганнарына, төгәлрәге, шагыйрьнең Хөсәен Зәбиров төзегән шәҗәрәсенә һәм аның аңлатмаларына әйләнеп кайтыйк.

Шәҗәрә шагыйрьнең бабасының әтисе белән башланып, бүгенге көндә дә исән варислар белән тәмамлана.




*Хөсәен Зәбиров төзегән Тукай шәҗәрәсе. 1986 ел.*

Шагыйрьнең бабасының әтисе—Шәмсетдин. Шәмсетдиннең әтисе—Мортаза, Мортазаның әтисе—Туктулла.

Мөхәммәтгалим—Тукайның әтисе ягыннан бабасы.

Зиннәтулла Әмиров (1829-1909)—Тукайның әнисе ягыннан бабасы.

Камилә—Тукайның әнисе ягыннан әбисе.

Мөхәммәтгариф Тукаев (1843-1886)—Г.Тукайның әтисе. Ул атаклы «Кышкар» мәдрәсәсен тәмамлый. Әтисе исән чагында, 22 яшендә үк аннан Кушлавыч авылының указлы мулласы вазифасын мирас итеп ала. Мөхәммәтгариф хәзрәт, күпмедер өлеше әтисеннән калган зур гына китапханәгә ия була, кечкенә мәсәлләр иҗат итә. Дин вәкилләренең кайберләрен тәнкыйтьли һәм еш кына «улларымны беркайчан да мулла итмим» дип әйтә торган була. Хәзрәт крестьян хезмәте белән дә шөгыльләнә, үрнәк гаилә башлыгы була, житеш тормышта яши.

Мәмдүдә (1864-1890)—Г.Тукайның әнисе, Зиннәтулланың кызы.

Газизә Усманова—Мөхәммәтгариф Тукаевның бертуган сеңлесе, Җаек шәһәрендә яшәгән Галиәсгар Усмановның хатыны. Тукайның Кырлайдан соңгы үсмерчак еллары Усмановларның бай гаиләсендә үтә. Әлеге гаиләдә булачак шагыйрьгә уку өчен барлык шартлар тудырыла.

Газизә Зәбирова (28.11.1876-6.02.1963)—Г.Тукайның бертуган апасы. Г.Тукай һәм Г.Зәбирова бергә егерме елдан артык яши (Кушлавыч, Җаек шәһәре).

Вәли Зәбиров (7.01.1899-1941)—Газизә Зәбированың олы улы, большевик (1919 елдан), Гражданнар сугышында катнаша, губернадагы (хәзер Жаек өлкәсе) әйдәп баручы партия һәм совет эшлеклеләреннән берсе була. Бер үк вакытта өлкә башкарма комитеты рәисе урынбасары һәм Жаек шәһәренең өлкә профидарә мөдире итеп билгеләнә. Өлкәнең милли мәгариф бүлеге мөдире, ВКП(б) өлкә комитеты секретаре булып эшли. Казакъ телендә чыга торган (Кустанай шәһәре) «Аул» гәжитен оештыра һәм аның беренче мөхәррире була. В.Зәбиров 1936 елга кадәр СССР Фәннәр академиясенең ижтимагый фәннәр бүлеге учреждениеләре ассоциациясенең (Санкт-Петербург шәһәре) гыйльми сәркәтибе вазифасын башкара.

Гали Зәбиров (1901-1981)—Газизә Зәбированың уртанчы улы, Чапаев дивизиясе солдаты, чекист (Казакъстан-Уил), хужалык эшчесе.

Гайшә Зәбирова (1903-1927)—Газизә Зәбированың олы кызы, Казанда укый, комсомолка, өлкә мәгариф бүлеге әгъзасы, профком сәркәтибе. 1927 елның 30 мартында «Кызыл яшьләр» гәжитендә дөнья күргән «Зур югалту» исемле кайгынамәдә болай дип әйтелә: «Гайшә Зәбирова 12 яшеннән үк ижтимагый эшләргә алынды һәм соңгы көннәренәчә башкаларга үрнәк булды...» Ул Казандагы туганнар каберлегендә жирләнә.

Фәизә Зәбирова (Кондратьева) (1905-1980)—Газизә Зәбированың кече кызы. 1932 елда Ташкенттагы Урта Азия университетының көнчыгыш факультетын тәмамлый. Гомере буе Санкт-Петербург шәһәрендәге Эрмитажда эшли. Шунда башкарган соңгы вазифасы Кытай мәдәнияте мәсьәләләре буенча өлкән фәнни хезмәткәр була. Ул гаилә истәлекләрен үзендә саклый һәм бай китапханәгә ия була.

Хөсәен Зәбиров (1907-1991)—Газизә Зәбированың кече улы. 1932 елда Ташкенттагы Урта Азия университетының төзелеш институтын тәмамлый. «Башпроект» оешмасының баш инженеры (Уфа шәһәре), «Гипротатнефть» проект оешмасының баш конструкторы, «Татнефтепроект» (Казан шәһәре) проект институтының баш инженеры булып эшли. Сугыш ветераны, 12 орден һәм медальләр белән, шул исәптән «Мәскәүне саклаган өчен» медале белән бүләкләнә. Казанда яшәде.

Вәли Зәбировның балалары:

Ражия Зәбирова (1917-1987)—шәфкать туташы, Фрунзе шәһәрендә (хәзер Бишкек) яшәде. Ике ул (Рөстәм Зәбиров 1940 елда туган, Бишкек шәһәрендә яши; Олег Сәгыйтов 1941 елда туган, Бишкек шәһәрендә яши) үстерде.

Сәлим Зәбиров (1928)—су асты көймәсе капитаны, Санкт-Петербург шәһәрендә яши, пенсиядә, ике ул (Герман һәм Игорь Санкт-Петербургта яши) үстерде.

Рөстәм Зәбиров (1935)—заводның баш конструкторы (Махачкала шәһәре), ике бала (Нажия һәм Марат Санкт-Петербургта яши) үстерде.

Гали Зәбировның балалары:

Суфия Зәбирова (1935)—Казан химия-технология институтын тәмамлый, Кустанай



*Басканнар: Мәгъмүрә Зәбирова (Гали Зәбировның хатыны), Фәизә Габдрахман кызы Кондратьева (Зәбирова, Тукайның апасының кызы), Владимир Васильевич Кондратьев (Фәизәнең ире), Сара Гани кызы Садыйкова (Вәли Зәбировның хатыны).*

*Утырганнар: Гали Габдрахман улы Зәбиров (Тукайның апасының оныгы, кызы Суфия белән), Газизә Гариф кызы Зәбирова (Тукаева, шагыйрьнең апасы), Сәлим Вәли улы Зәбиров, Вәли Габдрахман улы Зәбиров (Тукайның апасының улы, малае Рөстәм белән).*

шәһәрендә яши һәм эшли. Өч кызы (Гөлнара, Динара, Жанна) бар.

Рәшит Зәбиров (1937)—төзүче, өч кызы (Айгөл, Әлфия, Нелли Кустанай шәһәрендә яши) бар.

Рафаэль Зәбиров (1950)—механик, ике баласы бар, Кустанайда яши.

Рәисә Зәбирова (1948)—химик, Кустанайда яши.

Фәизә Зәбированың (Кондратьеваның) улы Георгий Санкт-Петербургта яши, инженер-механик булып эшли.

Хөсәен Зәбировның балалары:

Әлфия Зәбирова-Белостоцкая (1941)—«Гипронииавиапром» институты Казан филиалының баш архитекторы, 1988 елдан «Татпромстройпроект» институтының баш архитекторы булып эшли. 1977 елгы Владимир исемле улы бар.

Наилә Зәбирова-Шаповалова (1947)—Казандагы «Татагростройпроект» институтының баш архитекторы, 1968 елгы Олег һәм 1975 елгы Антон исемле уллары бар.

Диләрә Зәбирова-Ганина (1956)—Мәскәү архитектура институтын кызыл дипломга тәмамлый, «Казгражданпроект» институты архитекторы.

Хөсәен Зәбиров искәрмәләре:



*Басканнар: Суфия Гали кызы Зәбирова (Тукайның апасының оныгы), Әлфия Хөсәен кызы Зәбирова (Белостоцкая, Тукайның апасының оныгы). Утырганнар: Хөсәен Габдрахман улы Зәбиров, Наилә Хөсәен кызы Зәбирова (Шаповалова), Диләрә Хөсәен кызы Зәбирова (Ганина), Сания Гыйззәтулла кызы Зәбирова (Хөсәен Зәбировның хатыны).*

Г.Тукай шәҗәрәсен төзегәндә шагыйрьнең апасы Газизә Зәбирова истәлекләреннән файдаландым.

Суфия Гали кызы белән Наилә Хөсәен кызы әбиләре Газизә Зәбирова турында «кечкенә буйлы, киң күңелле, аягы авырту булса да очрашуларга, бәйрәмнәргә йөрергә яратучы, Тукай турындагы истәлекләре белән телəп уртаклашучы» дип яратып сөйли. Газизә Зәбирова 1963 елда, 86 яшендә Наилә Хөсәен кызы кулында бакыйлыкка күчә.

Суфия Гали кызы 1953-1958 елларда Казан химия-технология институтында укый.

Хөсәен Зәбиров төзегән альбом—зур мәгълүмат чыганагы. Ул тәҗрибәле тукайчыны көтә.

Тормыш бер урында гына туктап тормый. Хәзер Наилә Хөсәен кызы шәҗәрәне алга таба дәвам итә. Аның улы Олегның Артём (1995), Антонның—Настя (2004) һәм Тимур (2007) исемле балалары туган. Диләрә Хөсәен кызының Таня (1986) һәм Наташа (1988) исемле кызлары дөньяга килгән. Алар һәммәсе дә—шанлы Тукай нәселенең дәвамчылары.

**Флүрә ДӘМИНОВА,**
*ТР Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре,*
*ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# *Бер сорауга—бер җавап*

*—Бернičә ел элек сезнең башлангыч белән Казанда «Тукай фонды» төзелгән иде. Ул шагыйрьнең иҗатын мәңгеләштерү, аның тәрҗемәи хәленә кагылышлы сәхифәләрне баету белән шөгыльләнүне максат итеп куйды. Бүгенге көндә фондның эшчәнлеге нидән гыйбарәт?*

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ,** *«Тукай фонды» рәисе:*

—Бу эшкә без 2008 ел ахырында тотынган идек. Шул вакыттан алып яшь журналистлар Гөлназ Галимҗанова, Рамилә һәм Альбина Газизуллиналар белән бергә шактый гына эш башкардык кебек. Иң беренче итеп Тукай яшәгән истәлекле урыннарга «Тукай—тур» сәяхәте оештырылды. Дөньяның төрле кыйтгаларыннан башкалабызга килеп белем алучы егерме яшь милләттәшебез Казан-Әтнә-Кушлавыч-Арча-Кырлай маршруты буйлап татар авыллары белән танышып йөрде. Бу сәяхәт аларның күңелләренә бик тә хуш килде. Хәзер без Татарстан районнары буйлап милли маршрут төзү турында уйлыйбыз. Татарстандагы һәр район башкалардан үзгә ягы белән аерылып тора. Тукай ул—татар, татар ул—Тукай. Без әлеге ике сүзне тәнгәлләштереп эш итәбез. Читтән килгән кунакларыбыз «Татар кем ул?» дигән сорауга җавап табып китсен иде.

«Тукай фонды» тәкъдиме белән 2009-2010 уку елында мәктәп укучылары арасында «Сөекемле Шүрәле» исемле гамәли сәнгать әсәрләренә бәйге үткәрелде. Аны оештыруга Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Республика матбугат һәм гаммәви мәгълүмат чаралары агентлыгы, Рәссамнар берлеге ярдәм итте. Катнашырлармы, битараф калмаслармы кебек шикләр белән башласак та, аның нәтиҗәсе бик куанычлы булды: 3 мең бала бәйгегә үз әсәрен тәкъдим итте. «Кырлай» мемориаль комплексында, «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә җиңүчеләрнең иҗат үрнәкләреннән төзелгән күргәзмәләр оештырылды. Ул конкурсны быел да үткәрдек. Аның әһәмияте гаять зур. Нәрсәдер ясау, эшләү өчен әдипнең әсәрләрен уку, аның белән таныш булу да кирәк бит әле. Шушы бәйгене милли сәясәтнең зур бер өлеше дип саныйм. Бала кечкенәдән Тукайны белә һәм аның күңелендә шагыйрь иҗатына мәхәббәт уяна икән, димәк, ул киләчәктә дә милләтен хөрмәтләп яшәячәк. Бәйгегә 16 апрельдә йомгак ясалды. Киләсе елда без аны Халыкара конкурс итеп игълан итәргә уйлыйбыз.

Тагын бер зур эшебез—Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре белән берлектә шагыйрьнең үсмерлек чоры үткән Җаек шәһәрендә фәнни экспедициядә булып кайттык. Бу шәһәрдәге Тукай музееа көн саен 100ләп кеше килә. Ул шагыйрь яшәгән йортта урнашкан. Әлеге калада Тукай урамы да бар. Юл читләрендә Тукай рәсеме куелган баннерлар, рекламалар очрады. Иң сөендергәне һәм гаҗәпләндергәне—монда һәр татар йортының түрендә Тукай портреты эленеп тора. Без Тукай белән бәйле урыннарны барлап чыктык, фотоларга төшердек. ТӘҺСИнең өлкән гыйльми хезмәткәрләре Зөфәр Мөхәммәтшин белән Рәшит Казнаров татар зиратындагы кабер ташларын өйрәнде. Шунысы кызык: андагы каберташларга кешенең төп чыгышы—Татарстанның кайсы авылыннан күчеп килүе турында язып куелган. Алар үзләре бер тарих.

Шулай ук Казакъстан шәһәрләре—Кустанай, Астана, Караганда, Алматы, Чимкент, Кентауда булдык, Кытайдагы Голҗа, Өремче, Чогычак шәһәрләрендә яшәгән милләттәшләребез белән күрештек. Бу сәяхәтләребез «Читтә яшәүче татарларыбыз күңелендә Тукай ни дәрәҗәдә саклана икән?» соравына җавап табу максатыннан оештырылды. Шинҗан университетында укыткан, татар әдәбиятын өйрәнгән уйгыр галиме Тукайның Кытайда булып китүен тарихи фактларга таянып, исбат итте. Бу хакта үзебезнең галимнәр белән фикер алышасы бар әле. Тукайның «Эшкә өндәү» шигыре кытайчага тәрҗемә ителеп, алтынчы сыйныфлар өчен мәктәп дәреслегенә дә кертелгән. Шушы сәяхәтләргә багышлап «Истә калганнар» исемле китап әзерләдек. Инде Тукай турында фильм төшерергә җыенабыз. Икенче китабыбыз «Тукай туганнары» дип аталачак.

# ТУКАЙ ӨЧИЛЕДӘ

Олуг бәйрәм мөнәсәбәтләре илә укучылар белән шагыйрь тормышында яктыртылып бетмәгән кайбер мәсьәләләр хакында фикер уртаклашасым килә.

«Яктыртылып бетмәгән мәсьәләләр» дигәнем Тукайның Өчиле авылындагы яшәеше белән бәйле вакыйгалар хакында. Шагыйрь тормышындагы бу чор мәктәп дәреслекләрендә дә, фәнни хезмәтләрдә дә, матур әдәбият әсәрләрендә дә тиешенчә һәм дөрес чагылыш тапкан дип булмый әле. Менә, бәлки, «Исемдә калганнар»дагы бер җөмлә сәбәп булгадыр. Менә ул җөмлә:

*Үги әбинең алты күгәрчене эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам—юатучы, иркәләним дисәм—сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.*

Ә нигә менә бу җөмлә игътибардан читтә калган соң?

*Мин әле хәзер истисна итдекем Сәҗидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине җуатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм. Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә.*

Тукайның тормышын һәм иҗатын тирәнтен өйрәнүче галимнәр, язучылар бу авылның нәни Габдулланы дүрт тапкыр ач үлем тырнагыннан алып калуын ассызыклап үтәргә тиешләр иде. Болай да бик кыска гомерле шагыйрьнең күпмедер дәрәҗәдә тормышын саклап калган, иҗатына илһам биргән авыл бит бу Өчиле!

Ә хәзер нинди язмыш җепләре Тукайны Өчиле авылы белән бәйләвен карап китик. Иң мөһиме шул: булачак шагыйрьне дөньяга тудырган, ана күкрәк сөте имезеп, яшәү көче биргән һәм, ниһаять, баласына шагыйрьлек таланты бүләк иткән изге ана—шушы Өчиле авылында туып-үскән. Ул—шушы авылның Зиннәтулла хәзрәт белән Бибикамилә абыстай кызы Бибимәмдүдә.

Әйе, чыннан да, Тукайга шагыйрьлек таланты әнисеннән күчкән булырга тиеш, чөнки Мәмдүдә апа үзе дә кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган, сүзгә-телгә оста хатын булган. Атасы Зиннәтулла хәзрәт тә шигырьләр язгалаган. Ул үзенең яраткан кызы Мәмдүдәнең яшьли үлеп китү уңае белән дә, аңа багышлап, мәрсия чыгарган. Менә ул шигырьдән бер өзек:

*Исме Бибимәмдүдәдер гаилә ирде гаян,*
*Дыңлап ирде төшкилә вәгазь мөсәгыйль һәм мөган.*
*Ни сәбәптер, и ходая, ризкы аз, гомре тәмам.*
*Күрмәдем күзем туйганчы, улды бәңа кальбәнам.*
*Дәре михнәт, дәре хәсрәт, дәре залим бу мәкам,*
*Шунда мәхбүбә мөрәссагы дөрне кылды инкыйзам.*

Кызыксынган кешеләргә шигырьнең мәгънәсен дә китереп үтик: «Газиз нурымның кабере бу урын. Дөньяның туктаусыз әйләнеп исә торган җилләре аның нәфис-гүзәл гәүдәсен туфрак итте. Ул бик акыллы булып, аның исеме Бибимәмдүдә иде, ул төрле мәсьәлә һәм үгет сүзләрен тирән теләк белән тыңлый торган иде. Ни сәбәптер, и хода, аның дөньядагы ризыгы аз булды, гомере өзелде. Мин аны күзем туйганчы күрә дә алмый калдым. Аны күрүем төштә генә төсле булды. Бу дөнья, газап, кайгы, изү йорты булып, тезеп куйган энҗе күк яраткан кызымны юкка чыгарды».

Ә хәзер Тукайның кайчан һәм нинди шартларда Өчиледә булуына күчик.

Мәгълүм ки, Мәмдүдә апа 1885 елда, 19 яшендә Кушлавыч авылының 43 яшьлек Мөхәммәтгариф исемле мулласына тормышка чыга. Бу никахтан 1886 елның 26 апрелендә булачак шагыйрь дөньяга килә. Шул ук елның 29 августында

каты авырудан нәни Габдулланың (ә аның тулы исеме Габдуллаҗан) әтисе Гариф мулла вафат була. Ире вафатыннан соң, күрәсең, Мәмдүдә апа белән аның улына инде биредә урын калмый, шул ук елның декабрь салкынында ул, Габдуллаҗанны күтәреп, Өчилегә, әтисе Зиннәтулла хәзрәт гаиләсенә кайтып сыена.

Габдулланың Өчиле белән беренче танышуы әнә шулай була. Әмма әлеге вакыйга дәреслекләрдә дә, Тукай турындагы башка истәлекләрдә дә бөтенләй искә алынмый.

1888 елның 22 декабрендә Балтач районы Сасна пучинкәсенең 69 яшьлек Мөхәммәтшакир мулла 23 яшьлек Мәмдүдәгә өйләнә. Никахлашу мәҗлесе Өчиле авылында була, никахлашу язуын Зиннәтулла хәзрәт үзе тутыра. Ә нәни Габдулланы әнисе Кушлавычның «үтә дә рәхимле» Шәрифә карчыкта калдырып тора.

Бәп-бәләкәй Габдуллаҗан ничек бөтен нәрсәне дә төгәл хәтерләп һәм аңлап бетерсен ди? «Исемдә калганнар»дагы бер җөмләне шулай ук бәхәсле дип саныйм: «Мин бу карчыкта торган мөддәттә анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк, ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән».

Минемчә, бу дөреслеккә туры килми. Соң, нинди әни үзенең яраткан бердәнбер улын алып килергә кешеләргә кушсын. Әлбәттә, ул үзе дә килгән булырга тиеш. Сраснадан Кушлавычка барганда, телисеңме-теләмисеңме, кышкы юл Өчиле аша уза. Ә хәзер нәни Габдулланың Яңа Бистәгә килеп эләгү тарихына тукталыйк. Мин заманында Габдулла Тукайны күреп белгән Миңлекамал әби һәм Җиһангир бабайдан шагыйрь турында истәлекләр тыңлаган идем. Шулай ук Әсхәдулла бабайның әтисе сөйләгән истәлекләрне дә хәтерләп язам.

«Исемдә калганнар»дагыча, Габдулланы Казанга очраклы бер ямщикка утыртып җибәрмәгәннәр икән бит. Югарыда телгә алган, инде мәрхүм авылдашларымның сөйләвенчә, аның тарихы болай булырга тиеш.

Исеменнән үк күренгәнчә, Өчиле кечкенә авыл булган, җире дә аз булганлыктан, бу авыл халкы элек-электән һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Житештергән товарны исә кая да булса урнаштырырга кирәк. Әнә шул халык житештергән әйберләрне җыеп, аларны Казан каласына алып барып сатучы Гыйльфан исемле уңган-булган алыпсатар яшәгән бу авылда. Ул һәр баруында калада Әхмәт бай исемле кешедә тукталган. Әхмәт байның балалары булмаган. Бер сөйләшү вакытында Гыйльфан агай Әхмәт байга Өчиледә шундый ятим бала барлыгын, әтисе һәм бабалары муллалар булуын сөйли, Габдулланы уллыкка алырга тәкъдим итә. Бай абзый бер килүендә аңа бу баланы да алып килергә куша. Бу турыда Гыйльфан, әлбәттә, Зиннәтулла хәзрәт белән дә киңәшләшә һәм җәйге бер матур көндә үзе белән Габдулланы да алып китә.

Гөнаһ шомлыгына каршы, алар килгән көндә Әхмәт бай үзенең хатыны белән башка шәһәргә китеп барган булалар, ә өйдә калган асрау алардан башка гына бу ятимне алып калырга ризалашмый. Ә Гыйльфанның үзе белән алып килгән товарларны базарда (Печән базарында) сатасы һәм авылдашлары кушкан нәрсәләрне дә аласы бар бит.

Базарга килгән кала халкы исә сала мужигын сораулар белән тинтерәтә, «Бу эсседә улыңны тилмертеп нигә алып килдең?»—дип шелтәли. Гыйльфан абзый, баланың ачы язмышын сөйләп, теләүчеләр булса, Габдулланы биреп калдырачагын әйтә. Яңа Бистәнең Мөхәммәтвәли һәм Газизәләр гаиләсенә килеп эләгү тарихы әнә шулай булган. Биредә ул ике ел чамасы яши, 1890-92 елларда.

Печән базары вакыйгасын кемнәр ничек кенә тасвирламады! Мәсәлән, шактый танылган бер рәссам менә болай сурәтли. Базар уртасында чанага җигелгән ат, чана түрендә кышкы киемнәрдән кечкенә генә бер бала, ә алгы планда өстенә тун һәм толып кигән ямщик. Бу картинаны ясарга алынганчы, Тукай турында язылган әсәрләрне, истәлекләрне укып кына чыгасы бит югыйсә. Шулай булса, җәй көне чана җикмәүләрен, тун кимәүләрен генә белер иде!

Булачак шагыйрьнең Яңа бистәдәге тормышына тукталмыйча, янә Өчилегә кайтыйк.

1892 елда Мөхәммәтвәли белән Газизә икесе дә берьюлы авырый башлыйлар, Габдулланы алып килгән Гыйльфанны табып (ә аның базар көннәрне калага киләсе

билгеле) баланы янадан Өчилегә, бабасы янына кайтарып җибәрәләр. Шулай итеп, Габдулла өченче тапкыр Өчиледә...

Әлбәттә, Габдулланы биредә колач җәеп каршы алмаганнар, чөнки көчкә җан асраган гаиләдә алты бала, әби, бабай, нәни Апуш тугызынчы «авыз» булып, кайтып төшә...

Кырлайдагы Сәгъди абзый белән Зөһрә апа гаиләсенә килеп эләгү тарихы да «Исемдә калганнар»дагыча түгел. Мәмдүдә апа белән күршеләр генә булып Өчиледә Нәфисә исемле кыз яши, бер-берләренә керешеп, бергә уйнап үсәләр алар. Буйга җиткәч, Нәфисә апа—Кырлай авылына, Сәгъди абзыйлар күршесенә, ә Мәмдүдә апа Кушлавычка кияүгә чыгалар...

Нәфисә апа Өчилегә килгән саен дус кызының улы Габдулла турында сораша, аның ятимлектә яшәвен дә күреп йөри. Шул бала турында ул Зөһрә апа белән Сәгъди абзыйга да сөйли, ә бер килүендә үзе белән Зөһрә апаны да Өчилегә алып килә. Күрәсең, Зөһрә апа нәни Габдулланы ошаткандыр, уллыкка алырга риза була, бернечә көннән исә Сәгъди абзый нәни Апушны үзләренә алып китә[1]. Биредә ул 1892-94 елларда яши. 1893 елда аны бик яраткан Саҗидә апаны кияүгә бирәләр, никах һәм туй мәҗлесе Өчиледә үтә, әлеге мәҗлескә Кырлайдан Габдулланы да алып киләләр. Борынгыдан калган гадәт буенча, Габдулла җизни булачак Әхмәтсафаны ишектән кертми тора, ә кияү ишек бавын тотучыларга акча өләшергә тиеш була.

Бу вакыйга аның күңелендә онытылмаслык истәлек булып кала, һәм инде танылган шагыйрь булып җитешкәч, ул бу турыда «Ишек бавы» дигән шигырендә искә ала. Апасына язган бер хатында Тукай болай дип яза: «Бервакыт, Кырлайдан Өчилегә җыенга килгән вакытымда, бабайларда җизнәмнең яңа кияү вакыты иде. Исендәме, мин икегезнең хәлвәт бүлмәсенә кереп чәй эчтем... Мөшфика (шәфкатьле) апаем! Синең сабый вакытта һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам».

Ә хәзер—шагыйребезнең Өчиледә соңгы тапкыр булуы турында.

1911 елның кышында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый, аны Клячкин хастаханәсенә салалар. Аны дәвалаучы докторлар Тукайга авыл һавасында булырга, яңа сауган җылы сөт эчәргә, тынычлыкта калырга тәкъдим итәләр. Ул шушы вакытта, тормышы өчен иң хәлиткеч көннәрдә, кайсы авылны сайлый соң? Туган авылы Кушлавычнымы, әнисе күмелеп калган Саснанымы, әллә «дөньяга күзем ачылган урын» дип атаган Кырлайнымы?!

Юк шул, бу авылларда аның беркеме дә юк, анда шагыйрьне берәү дә көтми.

Үзенең нинди хәлдә булуы турында хат язып, бик ашыгыч рәвештә Өчиледәге Кәбир абыйсын (ул аны берадәрым муллам дип атый) чакыртып ала. Ә Кәбир Мәмдүдә апаның әтиләре бер, әниләре башка булган энесе. Хатны алган көнне үк Кәбир мулла (бу вакытта инде Зиннәтулла хәзрәт вафат, муллалык эше аның улы Кәшфелкәбиргә калган була) Казанга, Тукай яткан әлеге Клячкин хастаханәсенә килә. Шагыйрь абыйсыннан: «Җиңги нинди табигатьтә, әгәр дә беркадәр вакыт мин сезгә кайтып ятсам, миннән тарсынмасмы?»—дип сорый.

Әнә шулай 1911 елның декабрендә Тукай, дәваланып яту өчен, Өчилегә, Кәбир мулла белән Рәбига абыстай гаиләсенә кайта.

Бу кайтуыннан шагыйрь бик канәгать кала, дусты Гыйльметдин Шәрәфкә язган хатында мондый юллар бар:

«Ниһаять, авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, нараттан салган ак өй үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм. Иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Гомумән, тегенди сөтне дә күбрәк эчәргә тырышам. Фәкать әле авылларда сыерлар бозауламаган икән. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм.

[1] Нәфисә апа үзе сөйләвенчә,Зөһрә апаның шул килүендә үк алар Габдулланы икәү Кырлайга алып китәләр. Кара: Татар халык шагыйре Габдулла Тукай турында чордашларының истәлекләре. К. Утлары,1944,№ 4 яки «Сүнмәс утлары балкышы»,72 б. *Ред.*

Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек...»[2].

Өчиледә Габдулла Тукай җанына, тәненә дәва гына түгел, иҗатына да илһам таба. Үзе булган авылларда ул беркайчан да иҗат белән шөгыльләнмәгән, ә бу соңгы кайтуында Өчиледә 13-14 шигырен дә яза.

Ибраһим Нуруллин шагыйрьнең Өчиледә булуын «Чуар киез итек» хикәясендә бик матур сурәтли.

Бу юлы Тукай безнең Өчиледә 1911 елның декабреннән 1912 елның март аена кадәр була, туганнары җәйгә кадәр торырга бик кыстасалар да, ул: «Җәйгә янадан кайтырмын. Җиңгинең болай тарсынмаслыгын белгән булсам, узган җәй үк кайткан булыр идем»,—дип, Казанга кайтып китә. Ни кызганыч, бу аның Өчилегә соңгы кайтуы була.

«Исемдә калганнар»дагы тагын бер нәрсәгә ачыклык кертергә кирәк.Әлеге әсәрдә менә нинди юллар бар: «Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чакта ук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны анар ияреп килгән 6 баласы илә алган булган».

Юк шул, Зиннәтулла хәзрәт беренче хатыны Бибикамилә абыстай вафат булгач, Өчиледән ерак түгел Наласа авылыннан Алтынчы Фәтхулла дип йөртелгән кешенең Латыйфа исемле кызына өйләнә.Тукай искә алган алты бала да Өчиле авылында туганнар, һәм аларның әтиләре—Зиннәтулла хәзрәт, һәм ул бу балаларның туу турында таныклыкларын үз кулы белән тутырган. *(Зәкия Рәсулева. Тукай эзләреннән.—Казан.—1985.—85 б.).*

**Фәрхәт ЗЫЯТОВ,**
*Өчиле урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

---

[2] Шагыйрьнең Өчиледә авырып ятуы турында җиңгәсе Рабиганың (ул—1886 елгы,ягъни Тукайның яшьтәше,ире Кәбир,Тукайның абыйсы 1885 елгы,ягъни шагыйрьдән бер генә яшькә олы) үзе сөйләгәннәрне укый аласыз («Сүнмәс утлар балкышы»,74 б.). Шунысы да дикъкатькә лаек: үләр алдыннан бөегебез Клячкин хастаханәсендә Рабига җиңгәсе биреп җибәргән мендәрләрдә яткан. (Соңгы фоторәсеменә—125б.—тагын бер багыгыз әле!). Ред.

---

## *Бөекләр сүзе*

### Сергей Михалков:

*—Габдулла Тукай был страстным публицистом и лириком, журналистом и ученым, он был основоположником татарской профессиональной детской литературы и создателем нового всенародного литературного языка. Вместе с тем Тукай был беспощадным и страстным сатириком. Сатире Тукая я хочу уделить особое внимание. В его произведениях, созданных в этом жанре, хорошо представлены и тонкий юмор, и иносказания, и беспощадная эпиграмма, бичевавшие бесчинства эксплуататоров всех мастей.*

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Тукайның соңгы рәсеме

*Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч...*
Г. Тукай

**Күзләр—кара кояш! Гамь яктысы...**
**Гөлҗамаллар төнлә җеп эрләр.**
**Иреннәрдә сүзләр: «Сынды кылыч...**
**Бар ышаныч сездә, тереләр!»**

**Кайтмаган үч булып, һаваларда**
**Яшен балкыр... яңгыр кояр күк.**
**Күз йомарга курка,—**
**Кара төндә**
**Столыпин кеше суяр күк.**

**—Үлеп аңлатам,—ди,—яшәр өчен,**
**Көтмә, татар, шәфкать патшадан.**
**Юккамыни бабаң әкиятендә**
**Тере килеш кеше ашаган**
**Аждаһаның башын өзә батыр...**
**Суккан җирдән сез дә өзегез!**

**Күрәсегез килсә үзегезне—**
**Кылыч йөзе булсын көзгегез.**
**Юкса алар һаман кеше суя...**
**...Ютәлли дә Тукай... туктала.**
**Өши ләса,—**
**балкып чык та, кояш,**
**Бер генә уч җылы бир аңа!**

**Бер генә уч җылы, бер генә нур**
**Тиештер бит инде бу җанга—**
**Яна-яна... янып беткән өчен,**
**Нурын бирә-бирә җиһанга.**

**Карурманнар уртасында калып,**
**Тарихларның кылын тарткан бар:**
**Асрамага бушлай бирсәләр дә,**
**Тукай булгач, шактый сатканнар!**

**Көн дә үтергәннәр әкрен генә,**
**Кага-суга торгач—бер үлгән.**
**Әмма җирдә күпме телсезләргә**
**Тел ачкычы биреп өлгергән...**

**Халкым булып күзләренә багам:**
**Күз нурлары иңә җаныма.**
**«Китмибез»не ясин итеп укыйм,**
**Иелеп мин шагыйрь алдына.**

**—Телдән калмагыз,—ди,—җанкаралар**
**Йөрәк туктаганын чамалар,—**
**Ильминскийлары балта бирер,**
**Ишмиләре башны чабарлар!**

**Күзләр—кара кояш,**
**Гамь утыннан**
**Кем кабынып китәр, кем дөрләр?!**
**Иреннәрдә сүзләр: «Сынды кылыч...**
**Бар ышаныч сездә, тереләр!»**



---

## *Бөекләр сүзе*

### Педер Хузангай:

*—Мин үзем Тукайны беренче тапкыр Павел Радимов тәрҗемәсендә укыдым. Ләкин миңа «Шагыйрь» исемле шигырьнең чуашча тәрҗемәсе ныграк тәэсир итте. Бу шигырь матбугатта безнең шагыйрь С. Чегесь тәрҗемәсендә 20нче еллар башында басылып чыккан иде. Мин шушы көнгә кадәр ул шигырьне сүзен сүзгә диярлек яттан беләм. Бу шедеврның соңгы ике юлы минем күңелдә искиткеч югары гуманистик һәм көчле аккорд булып яңгырый:*

*«Без китәрбез, сез каласыз!»—*
*дип җырлармын,*
*Җәсәдемне туфрак берлә*
*күмгәндә дә.*

*Бу оптимизм, яшәүнең үлем өстеннән тантана итүе минем аңымны киңәйтеп, күңелемдәге иҗат тойгысын көчәйтеп, тормыштагы урынымны билгеләде.*

## ОЯЛТАСЫҢ, ЭНЕКӘШ!

Даһи булыр өчен егетлек тә кирәк икән бит. Миллионнарның язмышы (адәм балаларымы ул, акча-мөлкәт бәхәсеме—анысы Русия хөкүмәте өчен беркайчан да әһәмиятле булмаган) хәл ителгәндә Тукайның бу мәсьәләләргә тирән анализ ясап, вакытында һәм бик тиз җавап белән чыгуы—шаккатыргыч мисал. Сүз 1904-05 елгы Урыс-Япон сугышы турында бара. Ничек җаен тапкандыр, әмма «Сугыш һәм Государственная Дума» мәкаләсен ул бастырып чыгарырга җөрьәт иткән. Тукай язса яза бит инде, хөкүмәтнең дә тетмәсе тетелгән, Думаның да измәсе изелгән.

Безнең чорның кайсы гына мәсьәләсенә бакма, Тукайда аңа җавап бар. Димәк, Тукаебыз—безнең замандаш. «Заманабызның язучы һәм журналистлары турында» дигән мәкалә турында» исемле мәкаләсендә ул: «Һәр язучы үз язганнарының сибирияле бер татарга ошамаячагына яки Садыйк мулланың кяфер дип әйтүенә карап, каләмен чылбырлап куйса, газета битләренә кемнәр язар?»—ди. Тукай әйткәннәрнең чыңга ашканы, хөрмәтле җәмәгать, инде үзегезгә дә мәгълүмдер. Чыннан да, кайсыдыр хакимият башлыкларының нинди дә акчага патшаныкы кебек сарайлар салдырганы яки хәрәм ысул белән дәрәҗә яки урын яулаганы турында язылганы бармы татар матбугатында?

Тукай яшәгән чорда татар газеталары аз булмаган. Цензура яки башка сәбәпләр аркасында алар ара-тирә ябылып торсалар да, туры сүзгә ихтыяҗ булганга күрә, яисә популярлык казаныр өчен алар Тукайга мөрәҗәгать иткәннәр. Тукай да бурычлы булып калмаган. Надан динчеләрне, кыйбласыз милләтчеләрне, акылсыз мәгърифәтчеләрне, каләм тибрәтә белмәгән шагыйрь-голәмаләрне, сукыр тарихчыларны тәнкыйть табасында биеткән. Ул әлеге дә баягы сибирияле Мәхмүдев әфәнде хәзрәтләренә «Фикер» газетасында болай дип җавап яза: «Сез үзегез милләткә нәрсә эшләдегез? Милләтнең хәзергесе һәм киләчәге өчен файдалы чәчмә яки тезмә бирәр нәрсә бармы?.. Әгәр, үткәндәге кебек, киләчәктә дә үзегездән бөекләргә озын телегезне озайтып үткәрсәгез, вай хәлегезгә, вай!»

Җә, кайсыбыз Тукайча тәнкыйть юнәлешендә каләм тибрәтеп карый? Сибирияле Мәхмүдев кебек язучыларны хәзер дә шәйлим мин. Язучылар берлегенә соңгы елларда өерелеп кереп тулдылар алар. Анда хәзер гади язучы, шагыйрьләр генә түгел, язган-сызган булып азапланучылар: бизнесмен-шагыйрь, хаким-прозаик, директор, председатель, тагын әллә кемнәр.

Тукайның каләме дин башында торучыларны да сыйпап үтми. «Язучылар юләр түгел,—дип яза Тукай,—алар Алла йортын кимсетмиләр, хурламыйлар, «кимсетте, хурлады» дип әйтүчеләрнең, инсаф чикләреннән чыгып, кирелек, тискәрелек белән генә сөйләүләре акыллы булган һәр кешегә билгеле хакыйкать бит». Тарих тәгәрәп һаман кабатланып бара. Җә, кем әйтер дингә хезмәт итүчеләрнең кылмыш гамәлләре нык үзгәргән дип? Һәй, Тукай! Каян белеп язгансың син шулай! Язып, көрәшеп арыгансыңдыр, эчтән янып көйгәнсеңдер—27 яшең тулыр-тулмас якты дөньядан китеп тә баргансың. Менә без инде алтмыштан уздык. Оялтасың, энекәш! Үлгән килеш оялтасың. Бездә хәзер синдәй батырлар юк.

Мин бары тик Тукай аркылы хәзерге вәзгыятькә җавап кына эзләдем. Аның кебек шәһәр урамнарында йөрим, авылларга кайтам, ерак юллар үтәм, кешеләр белән аралашам. Дөнья гүли, тормыш дәвам итә. Берәүләр елый, берәүләр көлә, кемнәрдер талаша, икенчеләре татулаша, кайдадыр сугыш, кайдадыр тыныч. Аерма ни Тукай чорыннан?

Бюрократлар заманы. Ничек төгәл сизгән Тукай!

«И, гыйззәтлү, өтелгән халык!

Крестьяннарга җир бирергә ярамый, чөнки җир бирелсә, элгәредәй күп мәртәбә фәкыйрь булмаугыз ихтимал. Тигезлек мөмкин түгел. Әгәр халыкка тигез хокук бирелсә, инсанның кадере бетәчәк.

Тагы да министрларның хөкем каршысында җавапны кылынса, сукырлар да күрә башлап, төрле фәннәр туачак».

Бюрократларның бу сүзләре әбиләрнең: «Май ашама, сукыр булырсың»,—дигән сүзләренә бик охшый икән.

Шулай, Тукай, шулай. Менә демократик җәмгыять төзи башлаган идек, «чи капитализм» килеп чыкты. Ваучеризация үткәреп, демократ-бюрократлар бездән «өтелгән халык» ясадылар. Тигезлек тигезсезлеккә әверелде, министрлар—олигархларга. Таладылар, бөлдек. Ниһаять, үзебезнең хәерче икәнебезне белдек. Кычкырган булабыз—безне кем ишетә? Язабыз—кем укысын, кем бастырсын? Әчәбез—ә менә монысын тыючы юк. Син, Тукай, сәламәтлеккә туя алмыйча изаланып гомер иткәнсең. Кымыздан дәва булмасмы дип ерак казакъ далаларына кадәр барып җиткәнсең. Ә хәзер айнымас «Тукайлар» башка нәрсә эчәләр. Шигърият миңгерәүләнә. Яшендәй чатнап сугардай үткен сүз юк, күкрәп явардай мул фикер әйтелми. Әле һаман синең белән мактанабыз. Хакимнәр дә сиңа тиң тапмый. Ләкин үз канаты астында яңа Тукайлар тәрбияләми, үстерми.

Шул уңайдан Тукайның «Алмаз» дигән хикәясе искә килеп төште.

«Тимерчедәге иске тимер кисәкләре арасында бер Алмаз кылыч ташланып, бу Алмаз шуннан базарга чыгарылып, базарда бер мужикка сатылган иде.

Мужикның гыйлеме ни дәрәҗәдә икәне билгеле инде. Ул Алмазны саплап, аның илә урманга барып, чабатага юкә агачлары кисә башлады. Шулай ук самовар куйганда чыралар яру, мич якканда чыбыклар кисү, көз көннәрендә бакчада бәрәңге, шалкан казу—барчасы Алмаз хезмәте иде.

Шул рәвешчә мужикка бер ел кадәре хезмәт иткәч, Алмаз кителеп, теш-теш булып беткәч, балалар Алмазыбызга атланып, ат итеп уйный башладылар. Ахырда Алмазның сабы да төшкәч, аны сәке астына ташладылар.

Шул ук сәке астында бер бәрән бар икән. Бу бәрән Алмазның болай түбән дәрәҗәдә изелгәнен күргәч:

—И бичара Алмаз! Синең бөтен дөньяны тоткан шөһрәтең кайда? Син чабата юкәләр хәзерләп, балчыклар казып, иң ахырда балаларга уенчык булып йөрергә ояламыйсыңмы?—диде.

Алмаз анар каршы: «Әйе, мин гаскәрләр кулында заманында дошманнарга Арысланнан гайрәтлерәк идем, әмма бу мужик кулына төшкәч, дөрес, начар хезмәтләрдә йөрим. Ләкин бу тугрыда оят миңа булмый, бәлки минем ни эшкә яраганлыгымны белмәгән хуҗамадыр»,—дип җавап бирде».

Нишлисең бит, шундый дөньяда, шундый илдә, шундый җәмгыятьтә, шундыйрак хуҗалар белән яшибез. Шулай да Тукайчарак эш кылып: «Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш», дигән шигъри юлларга да туры китеребрәк яшәсәк, кешечәрәк булыр, бәлки, җәмгыяте дә үзгәрер иде.

Әле бит Тукай заманында радио-телевидение булмаган. Йә, Хода! Ни уйлыйм мин? Юк, юк, Тукайны хәзерге яшьләр кебек 27 яшенә хәтле телевизордан мультик карап утырыр иде дип күз алдына китерә алмыйм. Тукай үзе телевизордан чыгар иде дә, андыйларның маңгаена шалт итеп сугып: «Уян, татар!» дияр иде.

**Алмаз ХӘМЗИН**

# ТУКАЙ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

*Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?*
*Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;*
*Күңелемдә көн һаман аяз—һаман да яз:*
*Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.*

Г. Тукай

## Габдулла Тукай музееның визит карточкасы

*Музей, хөкүмәт карары белән, шагыйрьнең туууна 100 ел тулу уңаеннан 1986 елда ачылды. Ул Иске Татар бистәсендә, XIX гасыр архитектура үрнәге—купец йортында урнашкан. Халыкта бу бинаны «Шамил йорты» буларак беләләр. Биредән кул сузымы гына җирдә—элекке «Шәрык» клубы, «Болгар» һәм «Амур» номерлары гөрләп торган.*

*Музей фондында барлыгы 1201 экспонат саклана. Күргәзмә һәм экспозиция заллары 630,2 кв. метр мәйданны тәшкил итә.*

*Узган ел (2010) музейда барлыгы 25 меңнән артык кеше булган.*

*Адресы: 420022, Казан, Тукай урамы, 74.*

*Телефоннар: 293-17-66 (факс), 293-17-50.*



**Рәмис Кыям улы АЙМӘТОВ,**
***шагыйрь, музей директоры:***

*—Бүген татар иленең йөрәк тибеше булган Казанда Тукай хәтерен саклаучы изге урыннарның иң соңгысы, мөгаен, шагыйрьнең әдәби музее гына калгандыр. Музей үзенең 25 еллык тарихында Тукай өчен, гомумән, халык өчен лаеклы хезмәт итте. Ә хәтер утравы бүгенге көн таләпләренә җавап бирәме? Киләчәктә аны нинди үзгәрешләр көтә? Бүген бөтен төрки галәм шагыйрь исеме белән шаулаганда күңелне әнә шундый уйлар да биләп ала.*

***

Тукай иҗаты. Тукай дөньясы.

Безнең әле бу дөньяны һаман да колачлап бетерә алганыбыз юк. Һәм бу мөмкин дә түгелдер. Еллар узган саен Тукайны без ныграк ачабыз, аның зурлыгын һәм пәйгамбәрлеген ачыграк тоябыз. Тукай безгә һаман саен ныграк якыная, без үзебез дә аңа ешрак тартылабыз. Шагыйрьнең үлемсезлеген, татар халкы өчен бәгырь кебек кирәк булуын, бәлки, менә шуның белән дә аңлатыргадыр...

Укып карыйк: Тукайның күп кенә шигырьләре нәкъ менә бүгенге көнебезгә, милли һәм сәяси вәзгыятебезгә бөтен рухы, барлык җепселләре белән тәңгәл килә. Шуңа да аның иҗаты, шигъри авазы көр яңгырый һәм халык күңелендә теләктәшлек таба. Ул һаман да безнең замандаш.

Алай гынамы, (әүлиялек дип кенә әйтү аз булыр шикелле) аның пәйгамбәрлеге публицистикасында да ачык ярылып ята. Сүзебезне раслар өчен, әйдәгез, ике генә өзекне укып китик.

«Беренчедән, бу Дума һәрбер кирәкле эшләргә катнаша алмас, ул бер эш турында

хөкем чыгару яки бер мәсьәләне хәл итү өчен чакырылмый, тик бер төрле эшләр хакында үз фикерен сөйләү өчен генә чакырыла».

«Фәкыйрьлек, мохтаҗлык бик авыр. Аны җиңеләйтүче юк... Бу күз яшьләренә, бу гөнаһсыз адәмнәрнең хурлыклы хәлләреннән барчасына шул социаль төркемнәрнең тырышмавы, кайгыртмавы һәм кешелексезлеге сәбәптер».

Сизәсезме: баймы яки ярлымы ул, әлеге сүзләрдә нәкъ бүгенге көн кешеләребез өчен тирән борчылу ята кебек. Моннан йөз еллар элек язылган сүзләрдә–бүгенгенең дә ачы хакыйкате. Тукайның тәнкыйть уклары, оста мәргәннеке шикелле, «мишень»нең кыл уртасына барып кадала! Бүгенге каләм әһелләре өчен көнләшерлек хәл түгелмени бу?

Табигатьнең зирәклегеме, әллә саранлыгымы–кешегә гомер дигәнең бик тә чикле, үлчәп кенә бирелгән. Ул менә шушы вакыт арасына сыярга, кешелек тарихында үзеннән билгеле бер өлеш–күнел хәзинәсен калдырып китәргә тиеш. Гаҗәп хәл: Тукайга моның өчен нибары егерме җиде ел вакыт җиткән. (Ватан сугышында һәлак булачак композитор Фәрит Яруллин да үзенең «Шүрәле» балетын Тукай яшендә тәмамлый).

...Тукай музеена аяк басканда күңелне иң әүвәле әнә шундый уйларның биләп алуы табигый булса кирәк.

***

Шагыйрьнең музее–асылда изге, тылсымлы йорт. Аның һәр почмагыннан безгә Тукай күзләре карап тора сыман. Каядыр якында гына шагыйрьнең аяк тавышлары да ишетелә кебек... Ошбу язманың исеме дә юкка гына «Тукай белән очрашулар» дип аталмады.


Музей бинасы.

Хыялыбызда тарих пәрдәсенең бер читен ачып карыйк булмаса. Төрле авыллар һәм шәһәрләрне кичеп, 21 яшьлек Тукай 1907 елның 10 октябрендә Уральскидан Казанга кайтып төшә. Ашкынып килүенең сәбәбен ул мәгълүм бер шигырендә инде әйтеп, тәгаенләп тә өлгергән: «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» Шушы урам һәм почмакларда (элекке Екатерин урамы) Тукай тормышының Казан чоры башлана. Журналист һәм публицист булачак, ул Фатих Әмирхан житәкләгән «Әлислах» газетасында, «Ялт-йолт» һәм «Аң» журналларында эшли. 1910 елда чыга башлаган «Ялт-йолт» журналы белән гомеренең соңгы көннәренә кадәр диярлек җитәкчелек итә.

Музейда экспозиция һәм күргәзмә заллары эшли. Андагы байлык, хәзинә, экспонатлар–тан калырлык! Боларның бит берсе дә күктән төшмәгән яисә тәлинкәгә салып әзер килеш китереп куелмаган... Әйтик, Тукайның шәхси әйберләрен, безнең бәхеткә күрә дип әйтик, шагыйрьнең замандашлары яисә туганнары кадерләп саклый белгәннәр... Музейның фактик һәм булачак хезмәткәрләре экспонатлар туплауда, экспозицияләр төзүдә, ремонт-төзелеш һәм реставрация юнәлешендә, текстлар төзүдә, бирелдәге интерьерны нәфисләп бизәү эшләрендә ифрат зур хезмәт куйганнар...

Ремонт-төзелеш димәктән, бу эшләрне дә аерым бер рәхмәт хисләре белән билгеләп үтү урынлы булыр. Хикмәт шунда ки, әлеге «Шамил йорты» (ягъни элеккеге особняк) мона кадәр гади бер коммуналка рәвешендә яшәп яткан. Хөкүмәтебез карары белән бу йорт Тукай музее дип тәгаенләп бирелгәч тә музейны оештыра башлаучылар мең квадрат метр биләмәсендәге тар бүлмәләрне һәм чоланнарны йөреп-карап чыкканнан соң баштарак аптырап-югалып та калалар... Өстәвенә, 4–5 елга сузылырлык бу колачлы эшләрне башкарып чыгар өчен әкияти кыска срок бирәләр (Тукайның 100 еллыгына өлгертергә кирәк!). Реставратор, проектчылар һәм төзүче-подрядчиклар белән эш итү, бәхәсләр, аларны үзара килештерүләр

дисенме–болар үзләре генә дә тулы бер «эпопея».

Сүзне шушында кыскартыйк, чөнки әлеге мәшәкатьле айлар-еллар хакында ТАССРның Берләштерелгән музее (бүгенге Милли музейнын ул чактагы атамасы) генераль директоры Люция ханым Вәлиева истәлекләрендә тәфсилләп язылган.

Үземнән өстәп шуны гына әйтә алам: музейны оештыру, бүгенге матурлыгына китереп житкерү өчен аның беренче директоры Госман Әкрам улы Хәбибуллин да күп көч куйган кеше. Ул–икебез бер партада утырып укыган классташым, аннары Казан дәүләт университетында да биш ел буе бергә белем эстәдек. Аспирантура тәмамлады (кызганыч ки, арабыздан вакытсыз китү сәбәпле, кандидатлык диссертациясен якларга өлгермәде). Очрашканда ул миңа кая-нинди хатлар язылуын, дәүләт оешмаларының ишеген күп шакырга туры килүен, кыенлыклар, йокысыз төннәре турында зарланып түгел, горурланып һәм тәфсилләп сөйли торган иде. Киев, Ульяновск һ. б. шәһәрләргә йөрүе, Ленинградка барып фототукымалар юллавы–болар үзләре бер тарих.

Булачак музей бинасын реконструкцияләүдә «Казгражданпроект» институты, «Казремстрой» тресты, «Татмебель» берләшмәсе хезмәтләрен дә билгеләп үтәргә кирәк. Гомумән, күп тармаклы бу эшчәнлектә турыдан-туры катнашучыларның фамилияләрен санап чыксак, озын бер исемлек килеп чыгар иде. Бу очракта Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев, Яхъя Абдуллин, Нурмөхәммәт Хисамов, Гали Халит, Илбарис Надиров кебек әдип-галимнәребез исемнәрен атап китү белән чикләнәбез.

Ап-ак култыксалы баскычлардан күтәрелү белән безне Тукайның ике метр чамасы биеклектәге ап-ак сыны каршы ала (В. Рогожин һәм Р. Нигъмәтуллина скульптурасы). Экспозиция залындагы материаллар безгә шагыйрьнең балачагы, эти-әнисе, Кушлавыч, Кырлай, Өчиле авыллары, андагы күренешләр һәм табигать турында сөйли. Менә «Бәләкәй Апуш»ның әтисе Мөхәммәтгариф мулла үз куллары белән язган метрика кәгазе... Мулла йорты интерьерындагы фрагментларны күздән кичергәндә андагы чалма-кәләпүш, тәсбих, шамаил, күмер үтүге, жиз самавыр, жиделе лампа, каурый каләм белән кара савытларын күргәч, ирексездән XIX гасыр авыл йортының бер почмагына аяк баскандай хис итәсен үзенне.

1903–1913 һәм аннан соңрак елларда Бертуган Кәримовлар басмаханәсендә, «Гажур» нәшриятында гарәп хәрефләре белән басылган дини китаплар, Тукайның күпсанлы шигырь мәжмугалары киштәләрдә аерым урын алган.

Тукайның Жаектагы (Уральск) тормышы шулай ук киң һәм тулы яктыртылган. Кечкенә генә мәкаләдә боларның барысын да колачлау-шәрехләү мөмкин түгел, билгеле, бер генә фоторәсемгә аерым тукталып китик. Бу–Тукайның Камил Мотыйгый белән төшкән сурәте. Әлеге рәсем күпләрдә бәхәс тудырган иде: мөгаллим, мәшһүр жырчы, бай баласы, европача яхшы киенгән Камил әфәнде фәкыйрь генә шәкерт белән фотога төшмәс, янәсе. Тирәнгә кереп тормыйк, әмма үтә сизгер һәм күзәтүчән Батулла «Сәхнә» журналында (2005), бу, һичшиксез, Тукай, дип язып-исбатлап чыкты. Аның исбатына, дәлилләвенә икеләнмичә ышанырга мөмкин.

Казанда яшәгән елларында Тукайга шактый сәяхәт кылулар насыйп була. Атап әйткәндә, болар–Түбән Новгород, Мәкәрҗә ярминкәсе, Петроград, Троицк, Самара, Уфа, Әстерхан. Үпкәсендә туберкулез чире булуына карамастан, ул иҗади эшчәнлеген дәвам итә, каләмен кулыннан ташламый.



*Шагыйрьнең каләм савыты, юл кәрҗине, бәрхет түбәтәе...*

Тукайның соңгы көннәре... Клячкин хастаханәсендә төшерелгән 14 апрель, 1913 елның тарихи фотосы... Соңгы рәсем. Кулларын баш артына куеп, ак мендәргә сөялеп яткан шагыйрьнең тирән күзләрендә сагыш-моңсулыктан да битәр–иман нуры, эчке бер яктылык, үзенең үлмәс киләчәгенә ышаныч төсмерләре ныграк ярылып ята. Аның үлеме–яшәүнен, халык күңеленә күчә баруның башы гына. Арткы планда

Мусиннарның «Азиатские обуви» дигән кибет вывескасы шәйләнә... Халык дингез кеби җыйналган. Тукайны күмү мәрасиме Юнысовлар мәйданында дәвам итә...

Шагыйрьнең музейда саклана торган шәхси әйберләре–кара бәрхет түбәтәй, үреп ясалган юл кәрзине (ул шуны тотып Уральскидан Казанга кайтып төшә), Петербургның 200 еллыгы уңаеннан чыгарылган бокал рәвешендәге каләм савыты, фаянс тартмачык (беренче гонорарыннан апасы Газизәгә сатып алынган бүләк), көмеш йөгертелгән төймә-запонка, вафатыннан соң алынган гипс битлек–музейдагы уникаль экспонатлар! Бәяләп бетергесез бу ядкарьләр бүгенге көндә Тукайның 125 еллык юбилеена багышланган «Ашкынамын... мәңгелеккә» дигән күргәзмә белән дөнья гизә.



*Вафатыннан соң алынган маска.*

Күргәзмә залларының берсендә без сынчылар ясаган агач шүрәлеләр, Тукайны сурәтләгән төсле картиналар, «Шүрәле» балеты (Япония, Америка кыйтгаларына хәтле барып житте ул), «Алтын тарак», «Кисекбаш», «Кырлай симфониясе»нең афишалары белән дә танышабыз. Шагыйрьнең иҗаты күп кенә рәссам һәм композиторларга әнә шулай илһам биргән, бүгенге заманыбызда яши, үзенең әһәмиятен югалтмый.

Әйтергә кирәк, Җаекта, Кушлавыч һәм Кырлайда оешкан музейлар да Тукай истәлекләрен дистә еллар буе кадерләп саклый. Шунысы игътибарга лаек: үзләренең эчке һәм тышкы корылышы белән алар бер-берсен кабатламыйлар.

1976 елны Кырлайда ачылган музей ике экспозициядән: мемориаль-көнкүреш һәм әдәби-нәфис комплекстан тора. Соңгысы атаклы сынчы-рәссамыбыз Бакый Урманче проекты буенча эшләнгән. Шагыйрь Кырлай турында: «Бу минем дөньяга иң элек күзем ачылган урын»,–дип язган икән, хакыйкать, чыннан да, шулай. Кырлай урманыннан, дөресрәге, халык әкиятләреннән килгән Шүрәле образы аның күңелен мәңгегә әсир итә. Сабый чак тәэсиреннән килгән әкият каһарманы хәтта аның шәхси гамәленә дә үтеп керә: аркадаш дусларына язган күп кенә хатларына, мәкаләләренә һәм әсәрләренә ул «Шүрәле» дип имза куярга яраткан. Ә инде янәшәдәге янбакчага, аллеяларга да «ташып» чыккан Шүрәле темасы, андагы агач сыннар музейга тирән бер эчтәлек биреп тора. Казандагы музее кебек, мондагы Шүрәле образының да музыкадагы, декоратив-гамәли сәнгатьтәге, китап графикасындагы гәүдәләнеше ачык чагылыш тапкан.

Әлбәттә, без әйтеп киткән Тукай музейларының һәркайсы янарышка, үсеш-үзгәреш һәм нәфисәи бизәлешләрен өр-яңадан карап чыгуга мохтаҗ. Аларны заман таләпләренә җавап бирерлек югарылыкка күтәрү өчен оештыру эшләреннән дә битәр акча, чыгымнар тоту кирәк.

Шагыйрьнең Казандагы музеен яңарту, мәдәни-күңел ачу комплексын төзү, аны яңа тема һәм экспозицияләр белән баетуның эш планы бар. Ләкин монысы инде–бүтән тема.

Тукай кыска гына гомерендә яшен булып яшьнәде! Аның яшәү-януларын бары шулай гына аңлап һәм аңлатып була. Яшен бит үзенең бер ялтыравы белән дә күкләр галәмен колачлый ала. Шагыйрь дә татар галәмендә әнә шундыйрак колачлау, яктырту сәләтенә ия булды. Тукай дәвам итә. Ул–бүген дә безнең арабызда, аның шигъри авазы һаман да халык күңелендә яңгырый.

**Рәшат НИЗАМИВ**

## «Казан утлары» архивыннан



*«Өчиледә авыру Габдулла янында яраткан апасы Сажидә». Рәссамы Б. Әлменов.*



*«Бәләкәй Габдулла һәм Сәгъди абзый». Рәссам Л. Фәттахов эше.*



*«Габдулла Тукай». Рәссам Е. Симбирин эше.*



*«Батыр һәм Шүрәле». Скульптор Г. Зяблицев эше.*



*«Шагыйрь. Тәфтиләү». Рәссам Илдар Әхмәдиев эше.*



*Бакый Урманченың Тукайны мәрмәр ташта эшләгән һәйкәл-бюсты.*



*«Бөекләр арасында». Рәссам Абрек Абзгильдин эше.*



*Казанда Тукай һәйкәле.*

### Сабит Муканов:

*—Хезмәт ияләренең хөрлеге һәм бәхете өчен армый-талмый көрәшкән Габдулла Тукайны бер татарлар гына үз шагыйрьләре дип санамый, ул XX гасырның беренче ун елында илебезнең барлык төрки телле халыкларының мәдәниятен һәм әдәбиятын үстерүдә биниһая роль уйнады. Шәрык поэзиясенең ошбу баһадиры яшәгән һәм иҗат иткән чорда Россия империясендәге һәр халыкның үз Тукае бар иде. Бу—казакъ Абай, кыргыз Токтогул, үзбәк Фуркат, таҗик Айни һ. б. Әмма төрле сәбәпләр аркасында боларның берсе дә Тукай кебек зур халыкара популярлыкка ирешә алмады. Тукай исә бик кыска гомере дәвамында ук ул чактагы Россиянең барлык төрки халыклары арасында зур һәм җете дан-шөһрәт казанды.*

### Гафур Голәм:

*—Габдулла Тукайны татар халкының бөек шагыйре, сөекле улы дип әйтү генә җитми. Тукай—күп кенә башка төрки халыклар арасында да киң танылган, яратып укыла торган зур әдип. Инкыйлабка кадәрге Россиядә яшәгән халыклар, патша хөкүмәтенең аз санлы милләтләрне кол итүгә юнәлтелгән милли сәясәтенә каршы барып, бер-берсе белән якынлашырга, Тукай сүзләре белән әйткәндә, бер-берсе белән «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәргә тырышалар иде.*

*Үзбәк укымышлыларының өендә татарча китаплар, газета-журналлар, шәхси китапханәләрендә Тукай әсәрләре һәрвакыт булган. Күренекле үзбәк мәгърифәтчесе Габдулла Авлони шул елларда Тукайның «Туган тел» шигырен үзбәк теленә тәрҗемә итеп, мәктәп дәреслегенә дә кертә. Тукайның «Шүрәле», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Япон хикәясе» кебек сюжетлы әсәрләре үзбәк китапханәләрендә аеруча яратып укылган һәм хәзер дә укыла. Ташкент өлкәсенең Яңа Юл шәһәренә якын бер урынның «Шүрәле» дип аталып йөртелүе очраклы түгел.*

### Турсун Каһари:

*—Габдулла Тукайны уйгыр халкы үз шагыйре дип саный. Мин аның бер китабын Шәркый Төркестанның Голҗа шәһәрендә яшәгәндә уйгыр теленә тәрҗемә кылдым.*

*Мәктәп ишеген ачканым исемдә минем.*
*Шуннан бирле туган телем гел нурлар җыя.*
*Шул тел белән Тукайны мин сөйдем көн вә төн,*
*Тукай дип ачылды чөнки иманлы дөнья.*

### Сәхип Җамал:

*—Талантлы татар халкының бөек улы Габдулла Тукайга мин бөтен кальбем белән гашыйк булдым вә ошбу юлларны тетрәнү кичереп язам. Күңелем аның өчен горурлык белән тулып ташты. Тукай сәяси битлекләрсез яшәде. Ул үзенең бөтен көч-гайрәтен, киләчәге өчен тамчы да курыкмыйча, халкына бирә торган затлардан иде...*

*Тукай тар милли шагыйрь генә түгел иде. Миңа, гарәп кешесенә, Тукай, үзенең бөтен иҗаты белән халыкны азатлык өчен, гаделлек өчен актив көрәшкә чакырган кеше буларак та кадерле.*

### Луи Арагон:

*—Мондый бай әдәбиятның үткәндәге бай мираска нигезләнмәгән булуы мөмкин түгел. Моннан егерме ел элек миңа Кави Нәҗми царизм золымы астында иҗат иткән классик шагыйрь Габдулла Тукай турында сөйләде. Тукай «Үтенеч» исемле шигырендә болай ди:*

*Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары,*
*Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.*
*...Ул—түгел күңлем эшеннән, тик ялан кулның эше;*
*Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем.*

*Әнә шундый кырыс башлангыч бүгенге Татарстан язучыларына юл әзерләде.*

### Джованни Жерманетто:

*—Казанга беренче килүемдә үк, мин атаклы халык шагыйре Габдулла Тукай турында ишеттем. Аның турында безгә профессиональ язучылар белән журналистлар гына түгел, бәлки заводлардагы һәм төзелешләрдәге эшчеләр дә, студентлар һәм мәктәп балалары да сөйләде. Шунда мин гасырлардан килгән бай мәдәни традицияләре булган татар халкының бөек улы Тукайга нинди эчкерсез мәхәббәт хисләре белән каравын һәм шигъриятне ничек яратуын бөтен йөрәгем, вөҗданым белән аңладым.*

---

*Кайтаваз*

## ЯЛГЫШ ТӨЗӘТЕЛЕРГӘ ТИЕШ

Заманында мин «Без китәбез, сез каласыз» дигән пьесамда Тукайның фабрикант Акчуриннарга кунакка баруы турында язган идем. Анда Тукайны озату сәхнәсендә, шагыйрьнең Хәсән Акчурин биргән акчаны алмавы язылган иде. Күптән түгел генә мондый мәгълүматны укыдым. Тукай, Гурьевкада фабрикант Акчуриннарда булып кайтканнан соң, апасы Газизә Зәбировага хат яза. Хатның сәфәргә кагылышлы өзеге вафатына бер ел ел тулу уңае белән басылган мәкалә эчендә китерелгән: «Казаннан бер дә читкә чыкканым юк дияр идем, әле шул арада гына Сембер янындагы Хәсән Акчурин дигән фабрикантка барып, биш кич кунып кайттым. Бер дә көтмәгәндә, ансыздан хәбәр бирделәр... Сыйлауларыннан каләм гаҗиз. Бару-кайту расходы алардан. Шуның өстенә, киткәндә 50 тәнкә акча һәм киемлекләр биреп җибәрделәр. Бер белмәгән, танымаган кешенең кисәктән шундый хөрмәт күрсәтүе гаҗәп түгелме?»

Пьеса язылганда мин бу фактны белми идем, шуңа пьеса ахырында тупас ялгыш киткән. Аны миңа, ни кызганыч, әйтүче булмады. Тукайның бу сәяхәте турында сорашсам да, белүче табылмады, баруы гына мәгълүм, диделәр. Мин Тукайның байларга мөнәсәбәтен үз язмаларыннан укып белгәнгә, Акчуриннар белән саубуллашканда аны кырысрак итеп сурәтләдем. Өстәвенә, үзенә шагыйрьне кунакка чакырган Хәсән Акчурин шәхесен сурәтләүдә дә хилафлык киткән. Ярый әле исән чагымда ялгышымны төзәтеп өлгерәм. «Без китәбез, сез каласыз»ның финалын төзәтеп яздым. Үземнең китапханәмдә саклана торган унтомлыкта пьесаның үзгәртелгән варианты саклана.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

Нур
Әхмәдиев

# АЛТЫН БАЛЫК ТУРЫНДА ЗАМАНЧА ӘКИЯТ

**Беркөн, гөнаһ шомлыгы,
Бераз салып кайтканмын.
Чишенеп тә тормыйча
Йокларга да ятканмын.**

**Иртән ярыла башым,
Тамакка үтми ашым.
Хатын сүгә үземне,
Һич ачырмый күземне,
Әйттерми гел сүземне:
Мин бер сәрхуш ир икән,
Ир түгелмен, чир икән!**

**Түздем, түздем дә аннан
Ирлегемне ир иттем:
Гөлйөземгә үч итеп,
Балыкка төшеп киттем.**

**Бер кулда ничә бармак,
Алдым шул санда кармак.**

**Биш кармакка бишәрләп
Симез селәү кидердем.
Әпсен-төпсен шул булыр:
Иренемне тидердем.**

**Балык күп бу тугайда,
Эшләр барсын уңайга.**

**—Балык, балык, кап,—дидем,—
Яр башында ят!—дидем.**

**Балык ишетте әллә,
Күз ачып йомган мәлдә**

**Бер кармакның тәлтәве
Чумды китте тирәнгә.
Тартып чыгарган идем,
Нидер очты чирәмгә.**

**Шапылдап барып төште,
Әһә, димен, эш пеште.**

**Ялтырапмы ялтырый,
Үзе дер-дер калтырый.**

**Челт-челт йома күзләрен,
Көчкә аңлыйм сүзләрен:**

**—Нәфсемне тыйган булсам,
Кармакка капмас идем.
Хәзер синең каршыңда
Чирәмдә ятмас идем...**

**Әйтсәм, ышанмас халык,
Валлаһидыр, бу юлы
Тотканмын алтын балык.**

**—Җибәр,—ди алтын балык,—
Теләгеңне телә дә.
Алтын балык, белеп тор,
Йөз елга бер эләгә.
Мин—балыклар патшасы,
Теләгеңнең икесе,
Ант, дим, чынга ашасы.**

—Әй, син, балык, туктап тор,
Ачыклык кертү кирәк:
Ник ике теләк кенә,
Ник үтәлми өч теләк?

—Пушкин яшәгән заман
Ул бит нинди чор иде:
Сулар бар да саф иде,
Чиста ялан, кыр иде.

Үзгәрде бит һәммәсе,
Бүген яман бик күпкә.
Хәзер бөтен җир шары
Әверелде чүплеккә.

Чыраеңны сытсаң да,
Әйтми булмый дөресен:
Сезнең авыл халкы да
Суга түгә тиресен.

Кислотасын, селтесен—
Агызалар барсын да.
Сез, кешеләр, гаепле
Без балыклар каршында.

Шакшы суларда яшәп,
Кодрәтең саклап кара.
Ул—алтын балык, дигән
Исмеңне аклап кара!

Көч-куәтем җитә тик
Ике теләк үтәргә.
Әйт кенә, туры килмәс
Артык озак көтәргә.

Телисеңме, Касыймҗан,
Бүтән чыкмас андый җай—
Итәм сине шундый бай!
«Җитми» сүзен онтырсың,
Долларыңны, евроңны,
Алтыныңны, көмешеңне
Теләгәнчә тотарсың!

Куркып калдым бу сүздән,
Калтырау узды тездән.

—Чү, ашыкма, туктап тор,
Уйлау кирәк мең тапкыр!
Балык, кил акылыңа,
Җирдәге бар әшәкелек
Акча өчен кылына.

Акчаң күпме—дошманнар
Ни эшләргә белерләр.
Киноларда күргән бар:
Саклап тора киллерлар.
—Йә, алайса, әйт үзең,
Боерчы, көтәм сүзең!

Ни сорарга белмичә,
Уйлап, башлар катты соң.
Бәлки, җиңел машинаның
Сораргадыр затлысын?
Утырып йөрер идем,
Дөньялар күрер идем.

Машина йөртер өчен
Сорыйлар шул таныклык.
Ә таныклык алырга
Кирәк бик зур танышлык.
Минем исә ГАИда
Бернинди дә таныш юк.

Әле аның багына
Бензин салырга кирәк.
Бәясе көн дә арта,
Кайдан алырга кирәк?

Карап торган бар өмет—
Бер пенсия акчасы.
Ярый, ачтан үлмәскә
Бар бәрәңге бакчасы.

Урамнарга карасаң,
Чебеннән күп машина.
Кагыйдәне санламый,
Барысы да ашыга.

Юк, кирәкми машина,
Кычытмаган җиреңне,
Касыйм дускай, кашыма,
Җитәрсең үз башыңа.

Тынгы бирми икән ул
Нәфсе дигән яман корт.
Бәлки, миңа сорарга
Кәттиж дигән берәр йорт?

Ким дигәндә өч катлы,
Бүлмәләре ун булсын.
Тәвәккәлләп, әйтимче,
Теләгәнем уң булсын.

Алтын балык кодрәтле,
Салып бирде ди,ярар,
Аны кем җыештырыр да,
Ул зур йортны кем карар?

Алтын балык тотканга
Шаһиттыр Ходай гына.

**Интектермим мескенне,**
**Җибәрим болай гына.**

**Инде суга ыргыттым**
**Дигән чакта балыкны,**
**Күңелемнең түрендә**
**Ата шайтан калыкты:**

**—Үч ал,—ди,—хатыныңнан,**
**Аз гаепне күп итеп**
**Сүкте сине эт итеп!**
**Ул явызның явызы,**
**Сине тиргәргә дисәң,**
**Һич ябылмый авызы.**

**Хаталандың, Касыймҗан,**
**Кул селтәдең алтынга,**
**Дус итеп әйтәм сиңа:**
**Алыштыр карт хатыныңны**
**Ике яшь-яшь хатынга!**

**Нинди әйбәт фикер бу,**
**Ошаттым шайтан сүзен,**
**Хуш, бәхил бул, Гөлйөзем!**

**Алып кереп таллыкка,**
**Әмер бирдем балыкка:**

**—Карт хатыным урнына**
**Ике яшь кызны давай,**
**Мин түгел беткән бабай!**
**Алтын балык: «Баш өсте» ,—**
**Диеп суга сикерде.**
**Тыныч торган тугайның**
**Астын өскә китерде.**

**Вакыт бара, кызлар юк,**
**Әллә соң алдап качты.**
**Шунда балык су өстенә**
**Чыгып, авызын ачты:**

**—Үтәлде,—ди,—теләгең,**
**Ошбу кызлар—бүләгем.**
**Әйдә, танышып җибәр:**
**Сары чәчлесе Дилбәр.**
**Каракае Гөлназдыр,**
**Мондый кызлар,мондый кызлар**
**Дөньясында бик аздыр.**

**Булды, Касыйм, бигайбә,**
**Саубуллашыйк без, әйдә!**

**Тагын бер теләгеңне**
**Әйтәсең килсә әгәр,**
**Кулларыңны чәбәкләп,**
**Сана син өчкә кадәр.**
**Син икәнне белермен,**
**Яр буена килермен!..**

**Шулай диеп әйтте дә**
**Алтын балык юк булды.**
**Кызларга бер карадым—**
**Дөньяларым онтылды.**

**Алар гүзәлдән гүзәл,**
**Алар чибәрдән чибәр.**
**Бер кашык су кирәкми,**
**Сусыз да йотып җибәр!**

**Ярымшәрә үзләре,**
**Ымсына, шайтан, күңел.**
**Кочаклап алыр идем,**
**Якын барырлык түгел.**

**Кулларында шешәләр,**
**Минем яңа бичәләр,**
**Тәмәкене тарта-тарта,**
**Авызыннан эчәләр.**

**Телләрендә мат кына,**
**Йә Ходаем, һушларымнан**
**Язмый калдым чак кына.**

**Шешәләре бушагач,**
**Минем янга килделәр:**
**—Син бит безнең ир,—диләр,—**
**Башлар чатный, ир булсаң,**
**Төзәтергә бир!—диләр.**

**—Кайдан алыйм икән соң?**
**—Ансы безнең эш түгел.**
**Законлы хатыннарыңны**
**Тилмертү тиеш түгел!**

**Җибәрделәр кибеткә**
**Айга-вайларга карамый.**
**Пычаксыз суя болар,**
**Пычаксыз да яралый.**

**Алып кайттым шешәләр**
**Кызылын да, агын да.**
**Аны эчеп бетергәч,**
**Йөгерттеләр тагын да.**

**Кызлар тәмам кыздылар,**
**Менә дигән кәефне**
**Ахыргача боздылар.**

Эшләр узды уеннан:
Хатыннарым икесе дә
Кочып алды муеннан.

—Хәләл иребез,—диләр,
Үбеп тә алды Дилбәр.
Пышылдады Гөлназы:
—Яратам,—диде,—назны...

Ни эшләргә белмим мин,
Качарлык җир эзлим мин.

Чабып киттем су буйлап,
Котылдым диеп уйлап.

Йөз метр да китмәдем,
Мине куып җиттеләр.
Куып җиткән уңайга
Арт ягыма типтеләр.

Чиратлап та, парлап та
Туйганчы тукмадылар.
Үзләре аргач кына
Тукмаудан туктадылар.

Күз төбе кара янды,
Борынымнан кан тамды.
Бу юньсезләр нишләде—
Икесе ике ягымнан
Колагымны тешләде.

Инде беттем дигәндә,
Хәлдән тайган бичәләрем
Гөрс ауды чирәмгә.

Башлары җиргә тигәнче,
Шундук йоклап киттеләр.
Башкаең ике булмаса,
Тай тизрәк, карт юләр!

Карамый алны-артны,
Элдердем мин тугайга,
Җил дә исте уңайга.

Кулларымны чәбәкләп:
—Бер,ике,өч,—дидем,—
Алтын балык, мин килдем!

Кузгалды кинәт давыл,
Басты җирне караңгы,
Күренмәс булды авыл,
Үзгәрде төсе суның;
Ишетелде тавышы
Шулчак су патшасының:

—Ни телисең Касыймҗан?
Әйт дөресен, тартынма.
Мөселманга фарыз бит
Өйләнү дүрт хатынга.

Әмереңә буйсынам,
Намазлар укымасаң да,
Өммәтең бит мөселман!

Боер гына, кирәксә
Тагын ике кыз бирәм.
Икесе дә суперлар,
Ут кызлар менә дигән!..

— Балыккаем, алтыным,
Сүзләреңне җил алсын.
Дилбәр белән Гөлназың да
Күз алдымнан югалсын!

Исерекләр авылда
Болай да бит җитәрлек.
Алып кайтсаң аларны,
Башлар Себер китәр бит.

Бүтән берни сорамыйм,
Кире кайтар карчыгымны,
Аннан башка торалмыйм!

Диде балык: «Ярый ла
Килгәнсең акылыңа,
Нәрсә җитсен гомер иткән
Бер дигән хатыныңа...

Һич борчылма, йом күзеңне,
Әмерең, дим, үтәлер.»
Күземне кабат ачканчы,
Күпме вакыт үткәндер.

Көн яктырган, бер болыт юк,
Өебездә мин үзем.
Табада коймак пешерә
Җанкисәгем Гөлйөзем.

## Фәнил Гыйләҗев

# ДЕНСЕЗЛӘР АВЫЛЫ

### Гаеткәчә!..

Авыл.
Бәйрәм киче.
Иртәгә—Ял.
Барысы...
Барысы кайткан авылга.
Шул хөрмәткә клуб ишеге ачык:
Даңгыр-доңгыр «моңнар» агыла...
Туганнарың, дус-иш, сыйныфташлар,
Күрше-күлән—бар да
Бирегә
Изге йола үтәр өчен кайткан:
Тәүбә итеп сәлам бирергә...

### Ә бүгенгә?..

Ә бүгенгә әле
Урысчалап кирәк биергә...
Бүген әле бары бәйрәм киче:
Азан түгел—хәмер агыла...
Бер кардәшнең туган көне икән,
Чучка мае менгән табынга...
Бүгенгесе әле гает түгел:
Гаеп итми һичкем ләбаса!..
Син дә—күтәр: «Исәнлекка!»—диеп,
Кабып җибәр майлы колбаса!..
Син дә кайттың туган авылыңа...
Килмешәктәй торма!
Уз түргә!
Әллә безне хөрмәт итмисеңме?
Тот чәркәнңе! Әйдә!! Күп күрмә!!!

### Гает көне!..

Гает көнне бар да күзен ертып
Уяныр да иртә-таң белән
Баш авырткан көе тәкъбир әйтеп,
«Иманына» кайтыр...
Мин беләм:
Кичәгесен бар да тәүбә итәр,
Кабат бозар өчен...
Аннары...
«Дөнья авыр!
Харамнан да, зинһар.
Аерма!»
Дип, алар ялварыр.

## Ә син?..

**Гает көнне син дә алар белән**
**Бер үк сафта басып торырсың,**
**Махмырлылар хәмер сораганда**
**«А-а-а-м-и-и-и-н!»—диеп,**
**Дога кылырсың...**
**Син дә—шуннан!**
**Син дә—шул кавемнән!!**
**Син дә—хәзер шулар сафында!!!**
**Шатлыкларын син дә бүлештең, бит,**
**Һәм ашадың алар ашын да...**
**Син дә—шул ук дәрәҗәдә бөек,**
**Син дә—шулар кебек тәбәнәк:**
**...Аягүрә тостлар, хәмед әйттең**
**Һәм...**
**Сәҗдәгә төштең—тәгәрәп...**

---

Риф
Бәдри

---

## НИТӘЛӘР!

*(Татар интеллигентының*
*бәдрәфтә сөйләгән ярсулы нотыгы)*

**—Нигә менгәч, болар тәмам нитте!**
**Бу—нителгән! Теге—өтелгән!..**
**Йә, ни соң без хәзер? Бер нимени—**
**Нитек-мәтәк нимәләтелгән?!**

**Ниләр нине ние белән нитә!**
**Алар нитә!—Безгә әмәл юк!**
**Нитәм, нитәм, нитәм, нитеп бетәм—**
**Ә кесәдә сукыр нәмә юк!**

**Өйгә кайтып керсәм, хатын нитә!**
**Төнлә ниен куя, нәмәләт!**
**Ниләрем ни сорый. Каян алыйм?**
**Нитиммени нидән әвәләп?!**

**Өстә Фәлән ниләр нитеп утыра.**
**Безнең ниләр аңа—төкерек!**
**Нигә чыгып, их, нитәсе иде!**
**Нитәрләр шул, ием ниткере!**

**Нәфрәтемнән шашып, йодрык изәп,**
**Күлмәгемә сыймый утырам.**
**Җаннан-тәннән ташкан гайрәтемне**
**Шатыр-шытыр аска тутырам...**

## ИҢ ЯХШЫ САТИРИК ӘСӘРЛӘРГӘ КОНКУРС:

## «ПЕЧӘН БАЗАРЫ»

Инде язганыбызча (2010 ел, №9), бөек сатиригыбыз Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан, бүгенге татар әдәбиятында сатира жанрын тагын да үстерү, үткен сүз эстетикасын күтәрү һәм язучыларның иҗади эзләнүен тагын да активлаштыру максаты белән

*Татарстан Мәдәният министрлыгы,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*«Казан утлары» журналы редакциясе*

иң яхшы сатирик әсәрләргә конкурс игълан итте. Иҗади ярышта күләме унбиш стандарт биттән артмаган яңа хикәяләр, шигырьләр, фельетоннар, пьесалар, скетчлар, пародияләр, эпиграммалар, такмаклар һ. б. кабул ителә. Авторлар конкурста берничә әсәр белән берничә кат катнаша ала. Түбәндәге премияләр билгеләнде:

**I урынга—50000 сум (бер премия)**
**II урынга—30000 сум (ике премия)**
**III урынга—10000 сум (өч премия)**
**5000 сумлык ике кызыксындыру премиясе.**

*Әсәрләр 2011 елның азагына чаклы кабул ителә. Йомгак ясаганда әсәрләрнең басылып өлгермәгәннәре дә искә алыначак.*

**«ПЕЧӘН БАЗАРЫ» СЕЗНЕ КӨТӘ!**

**P.S.** Бу сүз исә—укучыларыбызга. Укучылар гына түгел, хөкем чыгаручылар да булыгыз. Махсус жюри ясаган йомгактан тыш әсәрләрне журналдан укучылар—үз җиңүчеләрен, матбугат ру.дан укучылар—үз җиңүчеләрен билгеләсен (1-3 урыннар). Конкурс тәгәлләнгәндә хәбәр салырбыз, тавыш бирерсез, моны ни рәвешле эшлисен дә әйтербез. Әлегә исә күңелләрегезгә хуш килгән әсәрләрне теркәп барсагыз иде.

# МАТБУГАТ ЙОРТЫ

## «Бауман урамы, 19»

*Моны укыгач, күпләрнең генә түгел, бик-бик күпләрнең күңелендә хатирәләр уянып. Чөнки бу—элекке Матбугат йортыбызның адресы. Биредә—газета-журнал редакцияләре, Татарстан Китап нәшрияты, К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты, Язучылар союзы, Тукай клубы һәм иң зур китап кибетебез гөрләп эшләп ята иде!.. Язучылар берлеге белән «Казан утлары» журналы бинаның уң канатында, икенче катта иде. Биредә, коридордагы Тукай бюсты янында (хәер, бу олы бинаның башка урыннарында да), кайсы гына бөекләребез гәпләшеп тормаган!*

*Баш калалар кебек баш йортлар да билгеләнсә, татар мәдәниятенең баш йорты, һичшиксез, шушы йорт иде.*

*Бу бинада киләчәктә ни булыр? Һәм—сакланып калырмы әле ул? Күп кенә үтә кадерле, мәңгелеккә төбәлгән йортларны кирпеч өемнәренә әйләндергән кебек, аны да юк итмәсләрме?*

*Хәзер исә, укучыбыз, без сине Матбугат йорты әле хыял гына булган чорга кайтармакчыбыз. Хыял, әмма аның инде төп-төгәл сызымнары булган бик тә төгәаене.*


*Ошбу язма «Казан утлары»ның элгәре булган «Яңалиф» журналының 1931 елгы 1нче санында басылган.*

Татарстандагы вакытлы һәм даими матбугатның Татарстан Дәүләт нәшриятында берләштерелүен, биш еллык план буенча аның искиткеч дәрәҗәдә үсүен (ул биш еллыкның ахырына басма табак саны буенча 100 процент артыграк үсәргә тиеш). Кулдагы матбага базаларының җитешсезлеген, газит-журнал һәм китап редакцияләренең төрле-төрле биналарда бик уңайсыз эш шартларында эшләүләрен игътибарга алып, Татарстан җөмһүриятенең юлбашчы партия һәм совет органнары, профсоюз оешмаларының съезд һәм конференцияләре, партия һәм совет җәмәгатьчелеге күптән бирле инде матбагачылык һәм редакция эшләрен үзендә җыйный торган бер матбугат йорты, тагы да дөресрәге матбугат фабригы салырга кирәклекне әйтеп килә иде. СССР Матбугат Комитеты да Казанда матбугат йорты салынырга тиешлек турында берничә рәт карарлар кабул итте. Татарстанның партия һәм совет юлбашчы органнары соңгы вакытларда матбугат йортын салуны ашыктыру кирәклек һәм бу эшне 1931 ел төзү сезонында практик рәвештә эшкә ашыру тиешлек турында кискен директивлар бирделәр.

Хәзерге вакытта матбугат йортының промстрой заданиесе (програмы) эшләнеп тәмам булды һәм ул СССР Совнархозының Полиграф Комитеты янындагы гыйльми-техника совет тарафыннан әсасән кабул ителде.

Йорт өчен кирәкле булган урын алынды һәм тиешле тикшерүләр ясалып, ул урынның матбугат йортын салырга яраклыгы беленде.

Матбугат йортын салыр өчен 1931нче елда тотылачак акча мәсьәләсе дә чишелде: йортны салу эше 1931нче елда кирәкле акча белән хәзер тәэмин кылынды дияргә ярый.



Матбугат фабригын салыр өчен сайланган урын Зур Проломный урамда, телефон стансасы янындагы 19, 21 һәм 23 капкалардан тора. 21 белән 23 капкалар арасыннан Зур Проломный урамын аркылы кисеп үтә торган Международный (элекке Молочный) урам уза. Йорт урынының икенче кырые исә Профсоюз урамы буена сузыла.

Матбугат йорты (матбугат фабригы) үзендә барлык цехлары белән «Татиздат»ның матбугат базасын, вакытлы һәм даими матбугат редакцияләрен (21 гәзит-журнал һәм 6 китап редакцияләре), кәгазь китап складларын, правление һәм сәүдә секторын, китап, язу җиһазлары, наглядной пособие, радио, фото кирәкләре һәм музыка кораллары белән күмәртә һәм ваклап сату итә торган үрнәк магазин, почта һәм тарату бүлекләрен җыйнаячак.

Йортның зурлыгы 18 мең дүрткел метр булып, эчендәге машиналарыннан башка гына ул ике миллион сумга төшәчәк. Матбага өлешен җиһазландыру өчен 851 мең сумлык машиналар куелачак.

Матбугат фабригының матбага өлеше 1933нче елда 1385 исемдә 9149 хәреф табагы һәм 168 миллион басма табак китап-журнал, гәзит эшләп чыгарачак. Анда эшләүче эшче һәм хезмәткәрләрнең саны 1400ләп кеше булачак.

Рәсемдә күрсәтелгәнчә (69 бит), матбугат фабригы өч төп һәм ике ярдәмче корпустан тора. Бу корпуслар үзләренең әйбер эшләп чыгаруда тоткан урыннарына, үти торган хезмәтләренә карап, баскычлар, коридорлар һәм күперләр аркылы берберсе белән тоташалар.

Беренче корпус Зур Проломный урамы буенча 115 метр озынлыгына сузыла. Аның күп өлеше, подвалыннан башка, дүрт катлы, тик Международный урамының ике ягындагы читләре генә бишәр катлы. Бу корпус Международный урам белән икегә бүленсә дә, алар дүрт катлы һәм һәр каты балконнар белән бизәкләнгән коридорлар аркылы тоташтырылганнар. Бу корпусның телефон стансасы кырыендагы өлешенә, 2, 3 һәм дүртенче катларына гәзит, журнал һәм китап редакцияләре урнашачаклар. Калган өлешенә исә правление, сәүдә секторы, финанс һәм план бүлекләре кебек, «Татиздат»ның матбага белән турыдан-туры багланмый торган өлешләре булачаклар. Кыскасы, бу корпусның иң зур өлеше матбаганың хәреф җыю, цинкография

цехларына эшләп чыгару материаллары әзерли һәм алар белән бик нык бәйле булган редакцияләр кулында булачак. Шунар күрә аның һәрбер каты матбаганың формалар хәзерли торган хәреф җыю һәм цинкография цехлары белән турыдан-туры тоташалар.

Төп корпусларның икенчесе Международный урам буенча сузыла. Ул, үзенең яртылаш торган этажын кертеп хисаплаганда, биш катлы булачак. Бу корпуска матбаганың гәзит, журнал һәм хәреф җыю цехлары, цинкография, стереотип бүлеге кебек форма хәзерли торган өлешләре куелачак. Бу корпус бер яктан редакция белән тоташса, икенче яктан басу һәм брошюра цехлары белән кушыла. Озынлыгы 70 метр.

Төп корпусларның өченчесе Профсоюз урамы буйлап сузыла. Озынлыгы җитмеш биш метр, киңлеге егерме метр, фабрик корпусы атала торган бу корпус ике ярым кат булачак. Аның иң югары катына басу цехы, урта катына брошюра һәм китап төпләү цехы урнашачаклар, ә иң аскы каты исә кәгазь һәм материал складлары хезмәтен үтәячәк. Югарыда сөйләнгәнчә, бу корпус үзенә формалар хәзерли торган набор-стереотип цехлары һәм цинкография урнашкан икенче төп корпус белән турыдан-туры тоташа.

Ярдәмче корпусларның беренчесе подвал белән дүрт катлы. Анда котельный, кләй кайнату бүлмәләре, слесарно-механический һәм столярный мастерскойлар урнашачаклар. Шунар күрә ул беренче һәм өченче төп корпусларның икесен бер-берсенә куша торган кушымта рәвешендә куелган да. Ярдәмче корпусның икенчесе Международный урамның икенче ягына урнашкан ике катлы корпустан тора. Ул корпус эшче һәм хезмәткәрләрнең тормыш теләкләрен үтәүгә хезмәт итәчәк. Анда ашханә, ясле, партколлектив, завком, амбулатория, ябык кибет һәм почта бүлеге булачак.

Кыскача гына итеп әйткәндә матбугат йортының планы әнә шул сөйләгәннәрдән тора. Ул китап, гәзит һәм журнал эшләп чыгара торган, Казан күләмендә зур гына бер фабрик булачак. Анда редакцияләрдән торган беренче төп корпус кульязмалар хәзерли, икенче төп корпус ул кульязмалардан китап, гәзит һәм журналлар, клишеләр рәвешендә формалар эшли, ә өченче төп корпус исә шул формаларны басу машиналарында баса, брошюра цехында бөкләп һәм төпләп, китап, гәзит, журнал итеп дөньяга чыгара. Әгәр дә матбугат фабригында шул сөйләнгән корпуслардан берәресе, мәсәлән, редакцияләр корпусы булмаса иде, матбугат йорты тулы фабрик булмас һәм ул рациональ рәвештә өзлексез эшли алмас, аксап барыр иде.

Матбугат йортының һәрбер катлавының деталь планына килгәндә, ул түбәндәгечә:

Іnче планда күрсәтелгәнчә, иң түбәнге катлау булып подвал һәм полуподвал катлавы тора. Ишегалды (двор) һәм Зур Проломный урамы буендагы төп корпусның иң түбәнге катлавы тоташ подвалдан тора. Бу подвал саклык китап склады булып хезмәт итәчәк.

Международный һәм Профсоюзный урам буйларындагы икенче һәм өченче төп корпусларның түбәндәге катлаулары яртылаш подваллардан тора. Аларның беренчесендә эшчеләрнең кием саклау (гардероб), эшләнеп чыккан китапларны бүлү һәм юыну бүлмәләре (душ), ә икенчесендә кәгазь һәм башка материал складлары булачак. Бу складлар югарыгы катлаулар белән күтәртке (подъем) машиналар белән бәйләнеләчәкләр.

IIнче планда матбугат йортының беренче катлавы күзәтелә. Зур Проломный урамы буйларындагы беренче төп корпусның бу катлавы универсаль культура магазины булачак. Международный урам буендагы икенче төп корпусның бу катлавында матбага конторасы, китап һәм журналларны җибәрә торган экспедиция, шулай ук гәзитләр экспедициясе урнаштырылачак. Профсоюз урамы буендагы өченче төп корпусның бу катлавында зур тиражлы гәзитләрне баса торган ике роликлы ротация цехы һәм брошюра цехы урнашачаклар.

Международный урам буендагы беренче ярдәмче корпуснын бу катлавында ясле, амбулатория, почта бүлеге, ябык распределитель урнашачак. Икенче ярдәмче корпусның бу катлавында механик слесарьлек һәм столярлык мастерскойлары урнашачаклар.

IIIнче планда матбугат йортынын икенче катлавы күрсәтелә. Зур Проломный урамы буендагы беренче төп корпусынын бу катлавында китап һәм журналлар редакцияләре һәм эшләп чыгару бүлеге урнашачак. Международный урам буендагы икенче төп корпуснын бу катлавында матбаганың китап һәм журналлар өчен хәреф жыю, стереотип цехлары, Профсоюзный урам буендагы өченче төп корпуснын бу катлавында китап һәм журналларны басу һәм бөкләү цехы булачак. Басу цехында китап баса торган ике ротация, 8 данә зур һәм кечкенә кулдагы басу машиналары, төрле буяудагы рәсемле китапларны, плакат һәм карталарны басар өчен 5 данә офсет машинасы, басылып чыккан китаплар бүлекләү өчен 5 данә фальцовка машиналары куелачак.

Ярдәмче корпусларнын беренчесенең бу катында 400 кешелек столовый, кухня һәм буфет, икенче корпусында клееварка, краскотерка, вольсеварка урнашачак.

IVнче планда матбугат йортынын өченче катлавы күрсәтелә. Проломный урам буендагы беренче төп корпуснын бу катлавында «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» редакцияләре урнашачаклар. Международный урам буендагы икенче төп корпуснын бу катлавында гәзитләр өчен хәреф жыю цехы, гартоплавка һәм словолитня урнашачак. Цехта хәзерләнгән формалар басу цехына махсус лифт белән төшереләчәк.

Ярдәмче икенче корпуснын бу катлавында кладовойлар, техника бюросы, лаборатория кебек ярдәмче бүлекләр булачак.

Vнче планда матбугат йортынын дүртенче катлавы күрсәтелә. Бу катлау бары беренче һәм икенче төп корпусларда гына булачак. Беренче төп корпуснын бу катлавы көндәлек булмаган гәзит редакцияләре өчен билгеләнә. Икенче төп корпуснын бу катлавында цинкография һәм офсет хәзерлеген күрү цехы булачак.

VI нчы төп корпус өстендә тагын бәләкәй генә бишенче катлау төзелә. Ул катлау конференц-зал, анын фойесе, китап-гәзит-журналлар выставкасы, көтепханә өчен билгеләнә.

Зур Проломный урамдагы беренче төп корпуснын бер башы бөтен катлаулары белән правление, сәүдә һәм счёт-финанс бүлекләренә билгеләнә.

Матбагачылар һәм матбугатчылар союзынын киңәйтелгән правлениесе утырышы һәм «Камил Якуп» фабригы эшчеләрнен производство киңәшмәсе матбугат фабригынын шушы проектын жентекләп тикшереп кабул итте.

**Ш.Самат**
*«Яналиф», 1931, № 1*

---

## *Тукай әйтсә, хак әйткән*

Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри.

# ИҢРӘП АУДЫ МАНАРА

Менә Советлар хакимияте елларында мәчет манараларын кисеп төшерү турында сөйлиләр. Хәзерге заманда бу гадәти бер вакыйга кебек кенә кабул ителә. Ә ул вакытта авыл халкы өчен гайре табигый, куркынычлы бер хәл, чын мәгънәсендә фаҗига булды Совет хөкүмәтенең бу карары. Башта халык арасында «мәчет манараларын кисеп ташлыйлар икән!» дигән шомлы хәбәр таралды. Әлбәттә, моңа беркем дә ышанмады. Һәр татар авылын бизәп, күкрәп утырган ошбу манараларга каршы кемнең генә кулы күтәрелсен икән? Әмма тиз арада бу кеше ышанмаслык хәбәрләр чынга да аша башлады. Безнең Әтнә районы Дусым авылыннан тирә-як авылларда шушы вәхшилекнең эшләнгәнен күреп кайтучылар булды, һәм афәт, әлләни озак та көттермичә, безгә дә килеп җитте. Авылда, бар халыкны тетрәндереп, «мәчет манарасын кисәләр икән!» дигән хәбәр таралды.

Мин, ул вакытта әле җиде-сигез яшендәге бер малай, бу вандаллык актының шаһите булдым, башыннан ахырына кадәр карап тордым. Безнең мәчет авылның нәкъ уртасында, нибары йөз хуҗалыклы авыл өчен бик зур, ике катлы, тәрәзәләре иркен һәм якты, түбәсе яшелгә буялган калай, манарасы биек, авылдагы барча урыннан, хәтта без яшәгән түбән очтан да күренеп тора иде. Мин бу Алла йортын әле дә ап-ачык итеп күз алдына китерәм, аннан бөтен авылга ниндидер нур сибелеп тора сыман иде. Халык арасында да «безнең мәчет тирә-якта иң матуры!» дигән горурлану сүзләре йөри иде. Безгә, малай-шалайларга бу йорт тагын бер ягы белән кадерле, дини бәйрәмнәрдә, өлкәннәр намаз укыганда без дә анда керәбез, ә намаз укып бетергәч безгә искитмәле тәмле кипкән йөзем җимеше бирәләр. Авылдан бер чакрымда үр астындагы Ашытта су коенеп өйгә кайтканда без иң әүвәл манара очындагы ярымайны күрәбез. Бөтен авыл халкы өчен кадерле йорт иде бу.

Кисүчеләр үзләре авылга кичтән килделәр. Берсеннән-берсе таза, кызыл чырайлары бүртенеп торган өч ир-ат һәм чистарак киемле, төскә-биткә дә ару гына бер адәм. Башлыклары, күрәсең, шулай сөйләшә. Милиция киеме кигән, бик озын буйлы, ябык гәүдәле бишенчесе дә бар. Барысы да татар кешеләре, саф татарча сөйләшәләр. Кичтән алар каршысына очлы бер терсәк килеп чыкты—беркем дә төн кунарга үз йортына кертмәде. Боларны авыл Советы рәисе Рәхимҗан абый үзе дә үгетләп карады. Җайлы сүзле, миһербанлы бу кешене бүтән вакытта берсүзсез тыңлыйлар иде. Бу юлы исә аяк терәп каршы төштеләр. «Мондый имансыз бәндәләргә йортыбызда урын юк!»—диделәр. Тегеләр бишәүләп авыл башындагы тар гына каравыл йортында, урын-җирсез йоклап чykканнар.

Әле дә бик ачык хәтерлим, көзнең аяз, җылы, тын бер көне иде. Иртә баштан авылның бар халкы: ирләр, карт-карчыклар, хатын-кызлар, бала-чага мәчет янындагы иркен мәйданга җыелды. Ул арада кисүчеләр дә килеп җиттеләр. Бар халык курку катыш нәфрәт белән аларга текәлде. Тегеләрнең икесе кулларына балта-пычкылар тотып мәчетнең чормасына, түбә астына,

ә өченчесе, биленә аркан бәйләп, түбәсенә менеп китте. Алар барысы да тиз маташтылар. Түбәгә менгән әзмәвер кулындагы озын саплы кадак суыргыч белән манара төбеннән түбә калайларын шатыр-шотыр каерды, әллә ниткән кара, ямьсез итеп ачып куйды. Әчтәгеләр пычкы белән нидер кистеләр, балта тукылдаттылар.

Гомер-гомергә күркәм булып, бөтен торган Аллаһ йортының болай тупас каһәрләнүен күреп, жыелган халык бердәм төстә авыр итеп ыңгырашып, иңрәп куйды да, тынып калды. Тимерче Каюм абзый, пәһлеван сыны белән калкынып, алгарак чыкты. Дәү башына түбәтәй кигән, озын мыеклы күркәм бу агай бик эшчән, көндезләрен тимерчелектә чүкеч сукса, кичләрен бөтен авыл халкы өчен кизитекләр баса, бик динле. Хөкүмәт тарафыннан тыелган булса да, авылда яшертен генә муллалык итә. Рәхимҗан абый аны кисәтә, куркытып та карый. Тимерче аның сүзен җөпли һәм... үзе һаман да Аллаһ юлын дәвам итә. Менә хәзер дә ул шунда йөренеп торган Рәхимҗан абыйга усал итеп карады.

—Инде бүтәне житмәгән, хәзер Аллаһ йортына кул сузасызмы, Рәхимҗан? Инде Аллаһ йортын да шушылай мәсхәрә итәсезме? Ходайның каргышы төшмәсме соң үзегезгә?—диде ул салмак кына, әмма мәйдандагы бар халык ишетерлек итеп. Үзе дә борчулы кыяфәттә йөренгән Рәхимҗан абый уңайсызланып калды.

—Безгә өстән кушалар шул, Каюм абзый. Өстән бик каты кысалар. Без дә ни хәлләр итик соң?—диде ул сузып кына.

Ул арада читтәрәк торган теге фуражкалы адәм җилтерәп килеп житте.

—Нәрсә ди бу агай, контр мәллә? Аяк чалып маташырга исәп тота мәллә?—диде ул Каюм абзыйга ишарәләп.

—Ниткән контр ди ул сиңа, Рафаил. Безнең бер дигән тимерчебез ул, алтын куллы оста. Динне дә тота. Нәрсә, дин тоту да тыела мәллә инде?—диде Рәхимҗан абый да бер дә курыкмыйча.

—Дин тоту тыелмый анысы. Тик ул монда безнең эшкә аяк чалып тормасын. Без шанлы партиябез, даһи иптәш Сталин үзе кушканны башкарабыз!—диде теге һәм үз урынына китеп барды.

Өстәгеләр бик кызу күренсәләр дә, эшне шактый озакка суздылар. Инде төшке аш вакыты да житте, үтеп тә китте. Ә халык таралмый көтә. Менә тегеләр барысы да түбәгә чыктылар. Манара хәзер моннан нечкә генә булып күренгән ялан баганалар өстендә утыра, хәтәр күренә. Тегеләр азан әйтә торган тәрәзәдән бераз өстәрәк тишек ясап, шунда озын аркан башын бәйләделәр. Берсе һаман түбәдә калды, икесе жиргә төште һәм манарага бәйләнгән аркан башына тотынды.

Беркем бер сүз дә әйтмәде, әллә нинди авыр, шомлы тынлык урнашты. Тегеләрнең башлыгы халык алдына чыкты.

—Җәмәгать, абыйлар, апалар, сез артка чигенегез инде. Хәзер без манараны жиргә егабыз. Өстегезгә килеп төшүе ихтимал. Зинһар, чигенегез,—диде ул йомшак итеп.

Халык ни эшли ала соң? Күндәмлек белән артка чигенде. Тик менә Каюм абзый гына бер карыш та чигенмәде. Олпат гәүдәсе белән калкып, баскан урынында калды. Хәзер ул халык гаскәре башында басып торган командирны хәтерләтә иде.

—Нәрсә, агай, безнең кисәтү сезгә кагылмыймы әллә? Өстегезгә манара төшүе бар бит,—диде башлык.

Бүтән чакта йомшак, жай сүзле тимерче бу юлы кискен итеп җавап бирде.

—Мин курыкмыйм, шушында торам әле. Манара кая төшәсен үзе

белер ул. Менә үз өстегезгә килеп төшмәсме әле... Аллаһы боерса!— диде.

Теге адәм көлде дә китеп барды.

Ул арада очынып фуражкалы килеп житте, чеяйгән күзләрен тимерчегә текәде.

—Син, агай, безнең хөкүмәтебез, партия карарларына каршы кеше, ахры. Аяк чалмакчы булып торасың. Хәзер үк китеп бар моннан!—дип жикеренде..

—Китмим мин беркая да! Менә шушы урында басып тик торам, һәлак булсам шаһит китәрмен, ичмасам!—диде Каюм абзый һәм кискен итеп фуражкалыга таба борылды. Тегесе, әллә шүрләп калды инде, авыз эченнән нидер мыгырдап үз урынына, халык төркеме артына китеп барды.

Кисүчеләр хәрәкәткә килде. Өстәгесе, балтасын ялтыратып, нидер чапты, астагылары, манарага бәйләнгән бауга тотынып, бик яман тарта башладылар. Бу минутларда мәйдан өстендә ниндидер тоташ каргыш тора сыман иде. Каюм абый, кулларын колаклары артына куеп, көчле һәм моңлы тавышы белән догалар укый, хатын-кызлар, хәтта ирләрнең кайберләре дә кычкырып елый. Тегеләр арканны тарта торгач, манара очындагы ярымай хәтәр чайкалып куйды, көчле чатырдау ишетелде һәм дөбер-шатыр килеп, инрәп, яман гөрселдәп манара жиргә килеп төште. Шартлап, бер-берсенә ышкылган калайларыннан очкыннар чәчрәтеп, урталай сынды. Пыялалары чылтырап коелган тәрәзәләреннән бер көтү күгәрченнәр очып чыкты. Ул бичара кошкайлар соңгы чиккә кадәр шунда утырганнар икән бит.

Барча халык «аһ!» итте, куркып читкә сибелде. Тик тимерче Каюм абзый гына үз урыныннан кузгалмаган, шул көе басып тора, һаман да кычкырып догаларын укый. Шунысы гажәп, жирдә жәйрәп яткан манараның очы аның турысына житкән, үтеп тә киткән, әмма ике адым читкә төшкән иде...

***

Хәзерге көндә безнең авыл башында кызыл кирпечтән жыйнак кына итеп, бик матур итеп салынган яңа мәчет күтәрелеп тора. Аны салдыруда үзебезнең авылдан чыккан, күп еллар буена колхоз рәисе булган Наил Закир улы Сабиров башлап йөрде, һәм авыл халкы аңа ихтирам йөзеннән Алла йортына «Наил мәчете» дигән исемне бирде.

Никадәр гажәп тоелмасын, элеккеге мәчетебез бинасы да әле дә булса исән-сау. Теге елларда аны шул ук авыл башына күчерделәр, башта ул авыл мәктәбе булды, хәзер исә клуб хезмәтен башкара, һаман да нык тора әле. Безнең бабайлар Аллаһ йортларын мәңгелек итеп сала белгәннәр.

**Радик ФӘИЗОВ**

*Күптән түгел генә дөнья куйган Р. Фәизовның калган тормыш хикәяләрен киләсе санда бирәчәкбез.*

# ЯҢА МӨГЕЗ,

яки

# ЗИҺЕН ЙОКЫСЫ ҺӘМ АЛБАСТЫЛАР ТУРЫНДА

*Дөньяга бөек сәяхәтчеләрне, рәссам, язучыларны биргән халык— испаннарда элек-электән үк килгән, кешеләрне уяу булырга өндәгән бик тә гыйбрәтле мәкаль бар. «Зиһен йокысы албастылыр тудыра» («Сон разума рождает чудовищ»). Данлыклы Франциско Гойя үзенең мәгълүм гравюрасын да шулай дип исемләгән. Һәм бу мәкаль, миңа калса, бүген дә бик актуаль булып, аерым кешеләргә генә түгел, үз кадерләрен үзләре белмәгән, йокылы-уяулы, һәм шуның аркасында бәхетсез язмышлы халыкларга, җәмгыятьләргә, милләтләргә дә кагылмыймы икән?*

## Иртә уңмаган кич уңмас

Зиһен йокысы... Рәсәй бүген дә йокыда әле. Үзенә бик тә лаек булган хакимиятләрне, тиран йә салмышбаш, булдыксыз яисә авторитар җитәкчеләрне, паразитар бюрократияне ул әле бүген дә йокы аралаш үзе тудыра, тормышына сыйдыра, үз табагыннан тукландыра. Үзен кимсетергә, таларга да күбесенчә үзе хәер-фатиха бирә килә. Бирелдәге халыкның аяныч һәм ләгънәтле язмышы шул уянмаган зиһен, миңгерәүле халәт, җитлекмәгән аң, үзенә нәрсә кирәклекне үзе төгәл белмәү, яхшырак, гаделрәк тормыш теләмәү нәтиҗәсе, җимешедер дип аңларга кирәкмиме икән?

Ил ифрат та зур, иләмсез. Гөнаһлы ил. Изелгәннәр каны, алар бәддогасы белән каргалган. Ил өстендә авыр кара болыт булып асылынып торган ул каргышны куып таратырлык, алып ташларлык иман әле яралмаган. Һәм ул, ихтимал, мәңге яралмас та. Ә яшәргә, тормыш итәргә кирәк. Азмы-күпме нәтиҗәле идарәне ничек корырга соң? Юньле тормышны ничек оештырырга? Гомумән, Рәсәй шартларында моңа ирешү мөмкинме? Өмет, киләчәк бармы, булса, нindирәк? Киләчәк дигәннән, без бит барыбыз да бүгенге көн белән яшәүчеләр. Киләчәк турында, якындагы 5-10 ел турында бар булган гавамның ныклап күпмесе уйлана, планнар кора? Бик азы. «Иртәге өчен ишәк кайгырсын»—бирелдәге миллионнарның тормыш фәлсәфәсе шул! Урыслар үзләре аны: «Будет день—будет и хлеб», диләр. Кремльдәге утопистларның киләчәкне фаразлавы, корган планнары да авыз балланмасмы дип «хәлвә, хәлвә» дип кычкыруга гына охшаган. Реформалар дигән булып алар декорацияләр алыштыралар. Имитация белән шөгыльләнәләр. Киләчәк турында ныклап уйламаган илнең киләчәге юк, миңа калса. Ул йокы дигәнебез, гомумән, мәңгелек кома яки үлем йокысы түгелме?

Илнең йокысын, бәхетсезлеген, булдыксызлыгын анализлаганда төрлечә фаразлыйлар. Уңмады Рәсәй җитәкчеләрдән, диләр. Иртә уңмаган—кич уңмас, кич уңмаган—һич уңмас, дип тә өстиләр. Өлешчә дөрес бу. Әйе, киләләр, кыбырсыган булалар, күтәренке рухта җитди нотыклар тоталар, бәхет әнә кул сузымында гына, тиздән үрелеп алачакбыз, диләр. Ә хакимият дигән өстәл шундый бай, ымсындыргыч, нигъмәтләрдән сыгылып тора. Шуңа өстәп минуты белән куштаннар, үзләре теләп зомбилашканнар, «баш өсте» сүзен көненә җитмеш җиде тапкыр кабатлаучылар урап ала. Бераздан алар начарны тирән яшереп, беренче кешегә яхшыны гына күрсәтә башлыйлар. Потемкин авыллары төзиләр. Иллюзияләр туа башлый. Җитәкчеләрнең хәтсезе киткәнче шул әкият эчендә яшәп ала. Ул җитәкчеләр килгәндә дә, беркайчан да, «иң югары постка басам бит, булдыра алырмынмы?» дип үз-үзләреннән сорамыйлар. Калын тире, тимер нервлар, үз-үзләренә абсолют ышанганлык. Булдыра, ерып чыга алмаслыкларына төшенгәч тә китәргә атлыгып тормыйлар. Абзар себеркесе белән куучы булмагач, нигә ашыгырга ди? Куучылар чыннан да юк шул.

Җитәкчеләр дигәннән. Бәлки, элекке гадәтне яңартып, җитәкчеләрне варяглардан, йә булмаса алманнардан чакырып китерергә кирәктер. Алар камчылап яки бездәге гавамның колагына үзләре генә белгән әфсен өреп ята да, идарә итә дә, тормышны җайлый да белерләр иде. Алар бит ушлы, зиһенле халык белән эш итәргә өйрәнгән. Тик кем генә чакырыр икән аларны? Бүгенге җитәкчеләрме?

## Йокы—беренчел, албастылар—икенчел.

Сүз башы ук йокы, аңкы-миңкелек иде бит. Сорауны тагын икенче якка борып карыйк әле. Әллә соң җитәкчеләр халыктан уңмыйммы? Бәлки, юкка гына җитәкчеләрне тиргибездер? Әйе, халык артык түзем, шуңа өстәп ялкау, кызыксынмаучан, хыялый. Сәясәт белән дә дуслыгы аз. Эчтән генә өстәгеләр бәхет китермәсме әле дип юана ул. Биргәнне көтә. Ә менә шешә белән дуслыгы ныклы. Аракы—оныттыручы, башны комга тыктыручы, коткаручы биредә. Ул үзенә күрә бер мессия.

Аттамы, тәртәдәме гаеп дип күп тапкырлар үз-үзебездән сорарга, баш катырырга мөмкин. Тик сәбәп һәм нәтиҗәләрдә, миңа калса, барысы да ап-ачык. Испан мәкале бу сорауга аек җавап бирә: йокы—беренчел, албастылыр—икенчел. Әйе, махмырлы һәм миңгерәүле йокы илдәге бөтен булган бәлаләрнең туксан процентына беренче сәбәпче.

Шушы урында яңа сорау туа. Уяну, айну кайчан да булса булачакмы? Туксанынчы елларда халык «ятагыннан тора» да башлаган иде кебек. Тик уяу, зиһенле, аңлы һәм аек ил белән идарә итү перспективалары җиңелгә өйрәнгән җитәкчеләрне пошаманга салды гына түгел, котларын да очырды. Болай барса, бераздан аяк очына гына басып йөрисе булмасмы? Иртәме, соңмы, хакимият җәмгыять, халык контролендә калачак бит. Ә империягә ни-нәрсә булыр? Юк, болай ярамый, йоклатырга, яңадан урынга салырга, тирбәтергә кирәк халыкны. Һәм йоклаттылар да. Йокыга тиз бирешә торган кавем шул без. Кем әле анда телевизор тикле телевизордан сәяси тапшырулар алып барып, халыкның күзен, зиһенен ачарга, карашын формалаштырырга омтылды? Куарга кирәк аны! Оппозиция үз урынын үзе беләме, азмыймы? Авызын томалыйк! Һәм кирәк чакта Көнбатыштагы абзыйларга алып күрсәтерлек кенә итеп, кульяулыкка төреп кесәгә салып куйыйк. Митинглар, төрле «килешмәүчеләр» гомумән Русия өчен түгел—резин чукмарларны янә эшкә җигәргә кирәк! Һәм дә бик тә тәвәккәл, җитез булу шарт. Тиз генә йокламасалар, йә бөтенләй йокыдан баш тартсалар нишләрсең?

Уңмый Рәсәй җитәкчеләрдән, диләр. Ә коллыкны бетергән Александр II? Ельцинның да тарихта аның белән янәшә басарга шанслары бар иде. Халык та

уянып беткән, бераз ярдәм иткән булса. Чын сүз ирегeн без шул елларда азмаз күреп калдык бит. Чын, ләкин кыска гомерле оппозиция дә шул дәвердә туды. Милли азчылыклар да берничә елга булса да суверенитет тәмен татып карадылар. Әмма... Абзый махмырдан чирләгән (чын урыс кешесе бит), баш төзәтеп мәш килгәндә, гавам авызын ачып демократиягә сокланган араларда, шома яраннары башта ил гражданнарының кесәләрен (саклык кенәгәләрен) бик яхшылап чистарттылар, аннан соң шулар ук «гадел итеп, беркемне дә кыерсытмыйча» милек бүлделәр, олигарх дип аталучы «иң мөхтәрәм» кешеләрне тудырдылар. Хәрби вәзирләр, төрле «Паша-мерседеслар»лар (Павел Грачевның шул вакыттагы кушаматы) да тик тормады—коньяк чикләрдә тырышып-тырмашып «град»лар, бомбардировщиклар, танклар ярдәмендә ил бөтенлеген саклады— үз халкына каршы геноцид оештырды. Ягъни бар булган демократияне соңыннан эт итеп сүгәрлек, тизәкле себерке белән куарлык иттеләр. Тагын җай чыкмады!

## Алдым–бирдем уены

Ул гына да түгел, шулай салгалап идарә итә-итә, абзыебыз, тәмам мәлҗерәп, килеш-килбәте, кыяфәте белән сиксәненче еллар башындагы «Кадерле Леонид Ильич» рәвешенә калгач, китәргә карар кылды. Әмма китү генә түгел бит әле. Бөтенләй ахмак булмасаң, киткәнче тәхетне тиешле кешегә калдыра белергә дә кирәк. Монысы иң җитдие инде аның. Рәсәй бит бу. Бүген син тәхеттә, ә иртәгә тере килеш ләхеткә дә төшереп куюлары бар. Юк, халык түгел—тагын бер кат таланган булса да. Хакимияткә күптән сусаган ушлы сәяси конкурентлар. Чечня аркасында куллар да терсәктән канда, гөнаһларның чутына чыгышлы түгел. Җыеп әйткәндә, арт як шактый б...клы. Властьне сине яраткан, үзең «кеше иткән» затка калдырмасаң, баш бетте. Ходай сакласын, баш чаба торган урынны әллә кайдан эзлисе түгел, ул Кызыл мәйданда гына.

Менә шулай итеп бездә яңа институт, «яңа демократик форма», яңача мөгез чыгару, илдәге беренче постны тапшыру һәм кабул итү формасы—оятлы һәм хурлыклы приемниклар институты туды. Юри генә күз алдыгызга китерегез: Президент Буш, Ак йорттан китәр алдыннан, властьны демократларга бирмәс өчен, үз урынына, мәсьәлән, командасындагы республикачы Колин Пауэллны тәкъдим итә ди. Законлылык төсмере керсен өчен сайлау оештырган була. Бар булган административ ресурсны кулланып, фальсификацияләрдән дә тартынмыйча, аны җиңүгә китерә. Аңа, аларга анда—Америкада моның өчен нәрсә буласын күз алдына китерү дә кыен.

Президент урыны ул берничек тә чабып барышлый гына бер-береңә «төртешле» эстафета таягы түгел бит. Бездәге андый «эстафетаның» төп максаты курстагы эзлеклелекне тәэмин итү түгел, ә бәлки киткән Олы абзый һәм аның якыннары, яраннары өчен иминлек гарантиясе булдыру икәнен әйтеп торасы да юк.

Мин Рәсәйне монархиягә, монархия дип аталучы дәүләт төзелешенә кире кайтарырга теләүчеләрне хәзер бик аңлыйм. Ул күпкә аңлаешлы, үзенчә чиста максат. Һәм азмы-күпме чиста хакимият. Күз буяп сайлаулар үткәрәсе, фарс оештырасы да юк. Хакимият өчен тарткалаш та юк. «Монарх үлде! Яшәсен монарх!» Ә хәзер олы абзыйлар, зурдан кубып, чырайларына җитдилек чыгарып уен уйныйлар. Президентлык вакытын озайтсалар да, Конституцияне яңабаштан күчереп язарга әлегә тәвәккәллекләре җитмәде. Шулай итеп ике срок үткәч, икенче президентка да Кремльдән китәргә туры килде. Тик еракка түгел, якынга, Ак йортка гына. Бераздан кире әйләнеп кайтыр өчен. Конституциядәге яшерен сукмакны Путин менә шулай тапты. Анда үз кешеңне тәкъдим итәргә, бер срок «ялдан» соң кире кайтырга ярамый дип язылмаган иң.

Халык исә дәшми. Ул риза. Безнең йокы, мокытлык аларга теләсә ничек кыланырга, эшләргә бер яклап та чикләнмәгән карт-бланш биреп тора. Лаек без, җәмәгать, бик лаек шундый идарәгә, хакимияткә. Шундый язмышка.

Күбрәк шул зиһен йокысы, мәнсезлек, битарафлык аркасында Рәсәй белән идарә иткәннәрнең хәтсезе (күбесе булмаса) тарихта сәяси банкротлар булып кереп калдылар. Алар—йә кеше башларын меңләп, миллионлап ашаган тиран, йә бер җебек. Уртачалар, зирәкләр, акыллылар юк чутында. Егерменче гасырны гына алыйк. Илне беренче бөтендөнья сугышына ташлаган, тәхеттән ваз кичеп, бөек тетрәнүләргә юл ачкан Николай II кем? Җавапсыз һәм булдыксыз, җебегән сәяси бер банкрот түгелме? (Тәртипне бар нәрсәдән өстен күргән алман каны ул кешедә кайда булгандыр?) Дөнья тарихында күрелмәгән-ишетелмәгән, бернинди тиңе булмаган 27 миллион корбан биреп «Пирр җиңүе» яулаган, өч дистә ел илне дер селкетеп, асып, кисеп торган, үзебез тудырган тиран-албасты Сталин да—сәяси банкрот. Каш төзәтәм дип күз чыгарган тел бистәсе Горбачев кем? Шулай ук булдыксыз сәяси банкрот. Ельцинны әйттек инде. Миңа калса, «тандем» да, үзе дә сизмәстән, банкротлыкка әзерләнә. Чөнки сөйләнеп кенә булмый, «өйләнергә» дә кирәк. Ә без инде ун ел буе сөйләнәбез. Халыкта да, хакимияттә дәниндидер амнезия. Сөйләнә торабыз, оныта торабыз. Эшкә ашмаган, барып чыкмаган милли проектларның, реформаларның, төрле оптимизацияләрнең санын бүген берәребез хәтерлиме?

Инде хәзер үзебезгә, татарларыбызга да әйләнеп кайтыйк. Зиһен йокысы без фәкыйрьләрдә, миңа калса, «өлкән туган»ныкына караганда да катырак, нәтиҗәләре күпкә фаҗигалерәк түгелме икән? Шулай булмаса, Тукаебыз да моннан йөз еллар ук элек «татар үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән сорау бирмәгән булыр иде бит. Ул, әлбәттә инде, милли якны күбрәк истә тоткандыр. Әмма ләкин шунысын искәртергә кирәк, безнең йокы, ул халәт китергән аңкы-миңкелек, зиһеннәребездәге куе томан бездә бит, теге «туган тиешлебездән» аермалы буларак, ике катлы, ул—куш. Аның беренчесе—урыслар белән уртак социаль булдыксызлык, гражданлык пассивлыгы булса, икенчесе—милли аң дигән зиһен халәтенең, милли уяулыкның ифрат та зәгыйфьлеге, бетүгә таба баруы, ягъни милли нигилизм. Шуның аркасында безнең йокы ике тапкыр хәтәррәк. Социаль булдыксызлык, деградация, акрынлап булса да, барыбер кимүгә таба барачак, ә миллилекне җуя килү, милләт буларак бетү күпчелек очракларда кире кайтмый торган процесс. Албасты дигәнебез исә бар очракларда да шул ук кала—башка чирләре өстенә шовинизм, унитаризм белән дә чирләгән бүгенге клептократик (ягъни караклар идарә иткән), яртылаш банкрот булып та урынында калып килгән Мәскәү хакимияте.

Ә төп банкротлар—барысына да юл куючы, килешүче, миңа калса, ихтыярсыз, горурлыксыз без үзебез. Хакимиятне контрольдә тотарга өйрәнә алмаган, теләмәгән битараф җәмгыять, үзен саклый алмаган милләт банкрот булмыйча ни булсын ди?

**Наил ШӘРИФУЛЛИН**

# ЙОКЛАДЫ ДИП БИРМИЛӘР ОШБУ ҖИҺАНДА МӘРТӘБӘ

*12 февральдә Ижевск шәһәрендә Удмуртия Татар иҗтимагый үзәгенең 23нче пленумы үткәрелде. Сезгә анда Иҗтимагый үзәкнең беренче президенты* ***Мәсгут ГАРАТУЕВ*** *ясаган чыгышны тәкъдим итәбез.*

—Хөрмәтле фикердәшләрем!

Бу пленум Ижтимагый үзәкнең егерме еллык юбилеена туры килсә дә, без бүген бер-беребезне мактап вакыт уздырмыйк. Без милләтебезне үтерүче урыслашу чиреннән халкыбызны ничек коткарып калу турында катгый рәвештә сөйләшик.

Сүз башында залга күз төшерик. Зал Удмуртия төбәкләреннән килгән делегатлар белән тулган. Алар барысы да бәйрәмгә килгәндәй матур итеп киенгәннәр. Аллага шөкер, татар халкының тырышлыгы аркасында тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Димәк, безнең тормышыбыз ал да гөл кебек. Менә бу—айсбергның өсте. Астына карасак, татар халкы, сәяси, икътисади, социаль яктан бик каты кысылган, хәтта ул үзенең ихтыяҗлары турында да бер сүз әйтә алмый.

Узган гасырның 90нчы елларында яулап алынган демократия юкка чыкты. Ә хәзер Россиянең президенты Медведев дәүләттәге Путин башлап җибәргән авторитар режимны тулысынча ныгытты. Шул режим аркасында татарларга милли партияләр оештырырга катгый рәвештә тыела. Безнең телгә хас латин графикасын да язуда кулланырга рөхсәт бирелми, чөнки кириллица аркылы татар халкын урыслаштыру җиңелрәк...

Россия хакимияте, үзенең Конституциясен бозып, христиан динен дәүләт дине итәргә маташа. Россиянең баш побы Кирилл кушуы буенча мәктәпләрдә газиз балаларыбызның йөрәкләренә христиан динен сеңдерә башладылар. Шул ук вакытта мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту өчен бирелгән сәгатьләр киметелде, мәктәп программасыннан «милли компонент»ны сызып ташладылар. Менә бу хәлләр—татар теленә нәфрәт белдерү дигән сүз түгелме? Моны раслап, шуны да әйтергә була: Ижевск шәһәренең мәгариф түрәләренә «татар гимназиясе» дигән сүз ошамады. Алар гимназиягә килеп, шулай дип язылган тактаны кубарып ташладылар. Кубарып алучы: «У нас в Удмуртии нет татарских учебных заведений»,—дип әйтте.

Татарга нәфрәт дәреслекләрдә дә сизелә. 6нчы сыйныф өчен академик Рыбаков язган тарих китабында татарлар учак янында кеше итен ашап утыралар! Чаллы шәһәренең правозащитниклары—кеше хокукын яклаучылар—авторны судка бирәләр. Аларның гаризасын суд карап та тормый.

Россия телевидениесендә, радиосында да татарга урын юк. Татар халкы Калининград шәһәреннән алып Курил утрауларына чаклы яшәсә дә, боларда татарның тарихы, аның әдәбияты турында ләм-мим бер сүз әйтелми. Ә эфирда йөзләгән дулкыннарда кем генә акырмый да кем генә бакырмый. Һәр көнне Россия радиосыннан атаклы кешеләр турында сөйлиләр: кем туган, кем үлгән? Ләкин шул чыгышларда татар фамилиясен ишетергә туры килми...

Удмуртия татарлары радионы ана телендә атнасына 15 минут кына тыңлый. Ул вакыт эчендә җырлыйсыңмы, елыйсыңмы.

Шулай бер көнне Россия радиосыннан урыс халкының сыйфатлары турында

тапшыру бара. Беренче итеп урыс филологына сүз бирәләр... «Русские—великий народ, который обладает могучим языком, уникальной культурой», диде бу. Хәтта азагында «русский мат—лучший мат в мире» дип тә өстәп куйды. Балтыйк буе кешесе шуны әйтте: «Мы провели исследования, русские ничем не отличаются от латышей, литовцов, эстонцев». Бер урыс хатыны болай диде: «Для русского человека характерна вороватость, лень, зависть к чужому добру, пьянство». Азакта сүзне Удмуртия вәкиленә бирделәр. Ул исә шулай дип сөйләп жибәрде: «Я сама—татарка. Но у меня менталитет русский, я люблю русский язык и русскую культуру. Даже могу так сказать, моя подруга живет в Италии. Люди тянутся к ней и копируют ее. То есть, мы, люди из России, распространяем русскую культуру в иностранных государствах.»

Кызганычка каршы, бу хатынны да татар халкы кадерләп үстергән, аякка бастырган бит инде.

Иң куркыныч шунда, балаларны мәктәпкә биргәндә кайсыбер ата-аналардан шундый сүз ишетәсең: «Татар телен укытып баланың башын катырасым килми, ул татар телен кухняда да өйрәнә». Татар балаларының 2 проценты гына туган телен мәктәптә үзләштерүнең бер сәбәбе нәкъ менә шул инде. Калганнары исә урыс мәктәпләрендә укып урыслаша. Әбиләрнең, бабаларның мәктәптән оныклары белән вата-жимерә урысча сөйләшеп кайтуларын ишетеп торабыз лабаса.

Урыслашу чирен бигрәк тә катнаш гаиләләр көчәйтә. Бу бит безгә интернационализмның бүләге. Менә алар йөз дә егерме миллионлы урыс халкына меңләгән балалар үстереп бирәләр.

Шул сәбәпле милли хәрәкәтнең төп максаты—тула оек, галуш кигән кызларны сәхнәдә биетү түгел, менә шушы урыслашу чире белән ныклап торып көрәшүдән гыйбарәт.

Бу эшне кем башкара ала соң? Беренчедән, татар гаиләсе, балалар бакчасы һәм мәктәп. Икенчедән, көчле, эшчән, дәүләт түрәләре алдында биеп тормаган милли оешма. 90нчы елларда бездә әнә шундый халык ихтирам иткән оешма—Татар ижтимагый үзәге эшләп килде. Ул ун ел эчендә татар мәгарифен, мәдәниятен аякка бастыра алды. Россиядә беренчеләрдән булып мәгълүмат чаралары: телевидение, радио һәм газетаны берләштергән татар теле комплексын бар итте.

Дөресен әйтергә кирәк, Удмуртия милли хәрәкәтенең эше елдан-ел саега бара. Милли хәрәкәт учагын дөрләтеп жибәрер өчен безгә иң әүвәл эшчән милли идарә һәм булдыклы лидерны сайларга кирәк.

Башкарылырга тиешле гамәлләр, минемчә, шулар:

1. Радио, телевидение, газета аша бер план буенча урыслашу чиренә каршы көрәш ачу.

2. Мәскәү һәм Удмуртия түрәләренә татар халкының ихтыяжлары турында өзлексез язып тору. Әгәр дә хатлар жавапсыз кала икән, пикетлар оештырырга, митингларда актив катнашырга кирәктер.

3. Мәктәпләрдә татар классларының, балалар бакчаларында татар төркемнәренең санын арттыру.

4. Татар халкының милли үзаңын үстерү өчен вакыт-вакыт конференцияләр, семинарлар һәм башка фәнни чаралар уздыру.

Мин шуңа ышанам, әгәр дә без бердәм булып урыслашу чиренә каршы көрәшкә чыгабыз икән, без аның, һичшиксез, йогынтысын киметә алачакбыз! Һәм моңа бик тиз тотынырга кирәк. Уйнады дип кенә түгел, йоклады дип тә бирмиләр ошбу жиһанда мәртәбә!

*Габдулла Тукай*

## ТАЯН АЛЛАГА

**Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!**
**Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!**

**Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;**
**Ул—рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!**

**Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,**
**Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.**

**Пакь җаның һәм пакь тәнең—барлык вөҗүдең пакь синең;**
**Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!**

**Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;**
**Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!**

**Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!**
**Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!**

# БӘЛӘКӘЙ ТУКАЙ

*Журналның бу саны Тукаебызга багышлап чыгарылганга күрә, «Бәләкәйләр» сәхифәсен бәләкәй Габдуллага—Апушка бәйләргә булдык. Сезгә, кадерле укучыларыбыз, шагыйрьнең «Исемдә калганнар»ыннан кайбер вакыйгаларны өзекләп тәкъдим итәбез.*

## Туган авылым

Минем атам Мөхәммәтгариф Кушлавыч карьясендә (авылында) Мөхәммәтгалим исемле мулланың углы булып, 14-15 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп, анда хәтле көтеп кылырга (укып тәмам итәргә) гадәттә ничә сәнә (ел) кирәк булган булса, шул кадәр торып, карт атасы тере вакытта ук авылыбыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр.

Мулла булгач та өйләндеге бер җәмагате илә берничә генә еллар торгач, җәмагате вафат булып, бер ир вә бер кыз баласы калмыштыр.

Моннан соңра атам, икенче мәртәбә өйләнүе уларак, Өчиле карьясе Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызыны (минем анамны) алмыштыр.

Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала уларак, мин дөньяга килгәнмен.

Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам, аз гына вакыт авырып, тәрке дөнья итмештер (үлгән).

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна нам (исемле) карьянең имамына кияүгә чыкмыштыр...

## Саснага бару

Мин бу карчыкта торган мөддәттә анам да теге муллага үзләшеп житкән булырга кирәк: ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән дәкыйкаләрдә (минутларда) миндә, бала булсам да, бер нәүге шөгур хасил булгангамы (бер төрле сизенү барлыкка килгәнме), нидәндер, мин хәзер дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады—анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, мина чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт бик озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

Әнкәмнең женазасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан, үкереп елый-елый, йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!»—дип, шактый гына жир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (хәтерләвемне) язамын...

## Казанда

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдыртмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле.

Мина әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә иде.

Әти талчокта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда—анысын яхшы белмим. Әни бер дә армый-талмый байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.



Әни Печән базарына кәләпүш чыгарганда, яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Мин байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай байларга барганда, ишек алдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны (павлин) күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу атам-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда мина ач торырга туры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда, шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем—акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк»,—дип, теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине янәдән аңар утыртып, Өчиле карьясенә җибәргәннәр.

## Кырлайда

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган, тәбәнәк кенә, салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган (чыннан да) минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты, мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. Кергәч тә, әнигә хитабән (эндәшеп): «Хатын! Бар, балага катык белә ипи китереп бир»,—дип әмер итте.

Әни дә, дәрхаль (шунда ук) баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа илә (теләк белән) икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин анда чыгып, адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә бер заман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар һәр көн авылның бер башыннан бер башына йөгереп йөреп тә, бу көнгә

кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан әнинен, миңа сагынмалык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар; мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда (бая катык ашаганда күрмәдегем) ике житкән кызлар күрдем.

Боларның берсе—таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе—арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар апайларың: берсе Сажидә апаең, берсе Сабира апаең, күреш»,—дигәч, мин әкрен генә барып кулымны суздым.

Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Сажидә атлы икән. Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән дә таныштым...



## Күңелле чаклар

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты житте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар. Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар илә авыл буенда йөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем. Әгәр көндез кайвакыт уен арасында карыным ачса, тиз генә өйгә кайтып, ян тәрәзәдән генә өйгә кереп, әнинен минем өлешкә калдырган бер җамаяк бәрәнгесе илә бер телем икмәген ашый идем.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше дә калмаганлыктан, без бакчалардагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без дәрхаль (шунда ук) киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мескеннең орышып, теш кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар илә вак балыклар сөзеп ята идек.

## Бәрәңге алганда

Урак бетте, көз житте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәнге казырга вакыт житте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә тугры килмәде: миңа казып чыгарылган бәрәнгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым тунганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай аякны балчыкка күмеп, бәрәңге чүпләгән чагымда, теге бәрәңге казучы аксак Сажидә апай ялгыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып еладым да, соңра җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемә дәвам иттем; ләкин бу юлы аяклар ни кадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

## Абыстайда уку

Беркөнне кич белән әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты, кояш чыкмас борын ук торып чәй эчтек. Чәйне жыештыргач, әни мине кулымнан житәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек. Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган; аның тирә-ягында минем яшемдәге кечкенә кыз балалары күп булганы кеби, шактый житеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богдай арасындагы берничә борчак кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни, иң элек ике бөтен икмәк илә бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.

Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «Әлеп, пи, ти, си, жомыкый»ны, бер дә тарланмыйча, кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә, «әлеп, пи, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарт» та тоттырдылар.

Бу «Иман шарт»ның ижеге белән сүрәсе миңа кыш буена житте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарт» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать «Иман шарт» бетерүгә гыйлавә (өстәмә) буларак, бервакыт абыстай өйдә юк вакытта, бәгъзе (кайбер) шаян кызларның: «Калимәтен таййибәтен, безнең әни бай хатын, изүе тулы тәнкә, борыны тулы...»—дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап (кабатлап) аларны көлдереп йөрер булдым.

## Кырлайдагы икенче көз

Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр. Мин мәдрәсәдә «Һәфтияк» ижеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылыбызның бер бай баласы да булып, ул мине хәлфәсе кебек итеп, чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да, йорт хезмәтләренә дә ярый башладым.

Мәсәлән, иртә белән менеп моржа ачу, аннан соң моржа ябу, мичкә ягар өчен салам көлтәләр бәйләү—һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, бер заман этинең шәриге (мәдрәсәдәге сабакташы) йә дусты булгангамы, ниднәндер, миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде.

Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Әти, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәченне әниенә дә калдыр!»—дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, «ярар» дия торган идем. Ләкин ул күмәч, авылга кайтып житкәнче вак-вак кына капкаласам да, әнигә кала идеме, юкмы—анысын хәтерләмим.

## Кырлай белән хушлашу

Бервакыт, көз көне өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин ян тәрәзә төбендә «Рисалән Газизә» укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә миңа хитабән (эндәшеп): «Әти-әниең кайда?»—диде.

Мин: «Ындырда»,—дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт»,—дигәч, мин тиз генә ындырга йөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра»,—дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр, мөсафир (юлчы) белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына, ниндәндер, мине дә утырттылар вә гадәткә хилаф (каршы) уларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдегез?»—дигән сөаленә каршы мөсафир: «Менә бу баланы алырга килдем»,—диде.

Бу сүздән әти бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул? Ник син алырга килдең?»—дип сөальләр бирә башлагач, мөсафир бу рәвешчә сүзгә башлады:

«Мин—Кушлавыч кешесе. Бу бала—авылыбызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр (хәбәрсез) идек, менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе каенесенең болай кара кешеләр кулында йөрүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел, Җаекта аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм»,—диде.

Мөсафирның бу сүзләренә әтинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте:

«Ярар, менә без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны 3-4 ел ашатып торыйк та, хәзер эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән»,—кеби сүзләр илә бик нык тартыштылар.

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!»—дип куйгалый иде.

Мөсафир Бәдретдин абзый:

«Юк, сез не имеешь право кеше баласын тотып торырга, мин хәзер урядникка әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне подсуд җибәрермен»,—дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар.

Бераздан минем тату тормаган әнием: «Җә, атасы, бирик инде; ахры, кеше баласы бездә булмас, Алла сакласын, әлләниләр күрербез»,—дип үкереп елап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соңра бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, әти дә разый булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми, мине арбага чыгарып утырттылар.

Әти-әни, бичаралар, һәр икесе еглаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әти: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң тәмуг кисәве булырсың»,—дип ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек...



Кечкенә чакта «Фәнзилә» дигән сирәк исем кушканнарына әти-әниемә үпкәләп йөрүем хәтеремдә. Тик үз-үземне белә башлагач, исемемне яратмау юкка чыкты, киресенчә, «акыллы, кызыксынучан, белемгә омтылучан» дигән мәгънәне белдерүче исемне йөртү горурлык икәненә төшендем. Исемем җисемемә туры килсен дип тырышам.

Кояш баеганын, ябалак кар яуганын күзәтергә, авыл урамы буйлап яланаяк йөрергә,кешеләр белән аралашырга, яңа җырлар белән танышырга, китап укырга, үзем өчен кызыклы булган мәгълүматны башкаларга җиткерергә яратам. Тормышымны якын кешеләрсез һәм дәфтәр-каләмсез күз алдыма китерә алмыйм.

Шигырь минем өчен һаман да ачылмаган сер булып кала. Сере ачылса,тәэсире,көче,аһәңлелеге кимер кебек.

*Фәнзилә Мостафина*

## *Якындагы ерак яктылык*

**Күзләрдән эзләргә— бер адым,**
**Эзләрдән күзләргә—чакрымнар.**
**Нәүмизләнеп калган җилләр**
**Керфекләрем арасыннан сытылып чыккан**
**Кайнар тамчыларны саныйлар.**

**Чакрымнарны юкка чыгарырлык итеп**
**Кычкырасы килә...**
**Син якын да кебек, ерак та.**
**Яңа дулкын көйләгәндә**
**Йөрәгеңдә**
**Безнең ешлыкны да югалтма...**

## *Кышта калам*

**Февральнең соңгы көне...**
**Тик кыш әле дәвам итә минем өчен.**
**Бу кышларны ятим калдырырга**
**Җитми көчем.**

**Кичер...**
**Мин беразга кышта калам әле.**
**Соңгы тапкыр**
**Иренемдә салмак кына вальс бии**
**Кышкы яңгыр.**

Кышның аның яңгыры да әллә нинди:
Бозлы, тозлы.
Кар өстенә хисләремне язган идем—
Яңгыр бозды.

Бу яңгырлар яз авазы, ахры,
Тик мин әле кышта калам, аңлар язым.
Бәлки, син дә минем белән бергә
Тагын бераз кышта калырсың?
Мин февральдән рөхсәт сорадым...

***

Ә син горур идең,
Үзең өчен
Горурлыгың белән идең бөек тә.
Артык горур идең,
Җаның белән
Гел еракта идең, биектә...

Ә янәшә генә бәхет дигән
Тылсымлы бер илнең чикләре.
Атлап кына керәсе бит инде,
Горур идең—
Көчең җитмәде.

Ә мин яшим
Шул тылсымлы илдә,
Мин кабыздым бәхет йолдызын.
Син һаман да биектә икән әле...
Юк, син төптә, син түбәндә икән,
Горурлыгың белән ялгызың...

***

Бер ялгызым басып торам,
Вокзал буп-буш.
Тик иренне әчеттереп үбә көзләр.
Качып киткән моң-яфракка ачу итеп,
Җил шыңшый-шыңшый плащымның
Сәдәпләрен өзә.

Аякларым тышауланган бу гасырда,
Җибәрмиләр көзләр үзеннән...
«Ярдәм» диеп пышылдыймы иреннәрем?
Йөз терелгән инде, мең үлгән
Йөрәк...

Билгесезлек офыгына карап,
Әле һаман поезд көтәм.
Үбәргә дип килгән көздән
Иренемне яшерәм дә,
Соңгы сәдәбемне җилгә бүләк итәм...

## *Кышкы өмет*

Күңелемнең тәрәзәсе язга ачык...
Сүнәр-сүнмәс кышкы ялкын

Җылы бирми—
Бармакларны өтә.
Дәфтәрдәге сары таплар санап,
Көннәр үтә:
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Җитәр...
Өченче ай
Өмет уты кар астында,
Тик ул исән.
Кыяр-кыймас кына йөрәк
Көннәр саный:
Берәү, икәү...бишәү...
Исән!

Алдымдагы ап-ак биткә
Сүзләр тезәм.
Монысы соңгы хатым булыр, ахры,
Язган.
Уникенче тапкыр шул ук хисләр,
Шул ук сүзләр,
Шул ук адрес:
Миннән—язга...

Җилгә очкан хатларыма
Җавап көтәм,
Сәламнәрем барып җитте микән?..

***

Тынычлыгын бозып
Тузанланган тәрәз төбенең
Ничә еллык шул тузанга
Исемеңне язам.
Сурәтең дә,
Көлүең дә,
Сүзләрең дә
Тузанланган үткәннәрдә калган.

Тәрәзәдә кышкы яңгыр сызган
Тамчы юлы сиңа илтмәс инде.
Син гаепсез, мин дә хаклы идем—
Гаепләргә хәзер кемне?

Тамчы гына тузаннарны юып,
Бәхетенә юлын яра ала—
Бездә тамчыларның көче юк шул.
Йөрәгемдә исемеңне бозып,
Тузаннарга бирешмәслек
Сүзләр язам:
«Сау бул!..»

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Язмыш**

***Идел үзенә кирәкмәгән бөтен нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камил «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәкләп бөгәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды.*** Шешәнең төбеннән суккалап, хатны җиргә төшерде, хат белән бергә язу кисәге дә килеп чыккач, гаҗәпләнүе тагын да арта төште. Кызыксынудан уттай янган күзләрен язудагы тигез хәрефләргә төшерде. «Хатта нәрсә булуына карамастан, анда язылганнарны үтәргә әзер булсаң гына ачарга рөхсәт»,—диелгән иде язуда. Нәрсә язылса да үтим, дип, ул аны укып чыкты: «Мине шушы адрес буенча таба аласың, эзлә, үкенмәссең».

Моны әһәмиятле фалга юрап, иртәгесен ул хатта күрсәтелгән адрес буенча бу серле язу иясен эзләп чыгып китте. Бәхеткә каршы, хат иясе күрше районда гына яши икән. Идел ярында урнашкан кечкенә генә авылны эзләп табу кыен булмады, тик хат иясен ничек табарга? Ул бит берәр егет яисә кыз, малай-шалай да булырга мөмкин ич. Хатны, бәлки, ачасы булмагандыр? Тик аның нәкъ Камил юлында очравы юкка түгел иде сыман. Ярый, булган-булган, бар да очраклы булсын, дип, авыл кырыендагы беренче өйгә керде. Баласы белән уйнап утырган яшь киленнән башка өйдә берәү дә юк иде. Камил аңа бу вакыйганы сөйләп тә бетермәде, килен кеше көлеп җибәрде. «Урманчы Гали абзый кызы Гөлназдан кала башка беркем дә булмас, ул хыялый гына шуның ише нәрсәне уйлап таба. Урмандагы умарталыкка бар»,—дип, аны озатып калды яшь килен.

Умарталыкка якынлашу белән Камил гаҗәеп моңлы бер җыр ишетеп туктап калды. Тиздән ул бу матур тавыш иясен—зәңгәр күлмәк кигән чибәр кызны да күреп алды.

—Мин килдем,—диде ул кыюсыз гына.

—Мин дә сине көттем.

Кызның чишмә челтерәгәндәй нәфис тавышы аның гүзәллеген тагын да арттыра сыман иде. Алар, бер-берсен күзәтеп, күзгә-күз карашып тордылар. Гөлназ серле генә елмайды да:

—Бу минем бишенче хатым,—диде.—Син хатыма җавап биргән бердәнбер кеше, димәк, син дә минем кебек әкияти язмышка ышанасың. Җирдә бернәрсә дә очраклы булмый. Кешенең ни күрәсе, ничек яшәячәге бар да үзе туганчы ук язып куелган, ди әбием. Мин дә моңа ышанам. Хатны укып мине эзләп тапкансың икән, димәк, син дә миңа ышангансың.

Камил кызның алсу иреннәренә, яшькелт күзләренә сокланып карады. Ул үзен әкият иленә килеп эләккәндәй итеп тойды. Кулын күтәреп, әкрен генә аның чәченнән сыйпарга теләде, тик кулының чәнчеп авыртуына түзә алмыйча кычкырып җибәрде һәм уянып китте. Әле генә Камилнең кулына укол кадаган шәфкать туташының: «Менә, уяндыгыз, авариягә эләгеп, бирегә китерелүегезгә өч көн булды. Ниһаять, күзегезне ачтыгыз, димәк, яшисез»,—дигән сүзләре ишетелде.

—Гөлназ,—дип пышылдады егетнең иреннәре,—мин сиңа ышанам!

**Гүзәлия ТАРХАНОВА**

## Алтын балык

***Идел үзенә кирәкмәгән бөтен нәрсәне ярга чыгарып аткан. Камил «Fanta»дан бушаган шешә эчендә түгәрәкләнеп бөгәрләнгән конвертлы хат күреп өнсез калды.*** Ләкин, хатны шул ук мизгелдә ачып уку теләге Камилне өнгә килергә мәҗбүр итте. Ул калтыранган бармаклары белән хатны шешә авызыннан тартып чыгарды һәм, ни гаҗәп, конверт тышына язылган ике сүз Камилнең зиһенен бөтенләй чуалтты. Үз күзенә үзе ышанмыйча, ул конверттагы шул ике сүзне кат-кат укыды һәм янында кеше булмаса да кычкырып җибәрде: «—Дөрес күрәмме соң мин? Әллә бу хат чынлап та миңа язылганмы? Әллә берәрсе шаярта гынамы?» Калтыранган кулларына каушавы да өстәлгәнгә күрә, күз алдында хәрефләр биешеп торса да, Камил үзендә хатны ачып укырлык көч тапты.—Камил! Кадерлем һәм берданберем!—дип, башланып киткән хат юллары Камилнең башына кан йөгертте. Ул йөрәк тибеше ешаеп, йөзе кызарып киткәнне тойды. Әллә чынлап та берәрсе шаярта инде дип тирә-ягына күз йөртеп чыкты. Ләкин, Иделнең сөзәк ярында балыкчы Камилнең үзеннән башка һичкем юк иде. Кармакларының чиртә башлавын көтеп алҗыгач, бераз аякларын яздырмакчы булып яр буйлап сәяхәт кылып йөргәндә үзе юлыккан шушы хаттагы сүзләр аның күңелен үсендереп, хыялланырга да курыккан хыялларын канатландырып җибәрде.—«Ничә еллар буе күршеңдә генә син дип тилмергән Камиләне үзең дә, күңел күзең дә күрмәгәнгә, ә мин сине үземә каратуның әмәл-чарасын тапмаганга, бәлки, йөрәк януларым басылыр дип, сиңа булган сөю хисләремне Иделләргә салып агызырга булдым. Ә бәлки, балык җене кагылган кармагыңа шушы хатым үзе килеп кабар да...

Амин, шулай гына була күрсен иде дә бит...

Балыкчы буларак түгел, ир-егет буларак хыялыңда кармагыңа килеп кабасы алтын балыкның мин—Камилә икәнен, язмыш дулкыннары шушы хатымны ярга кагып кармагыңа каптырса, бәлки, аңлар идең дә бит...»

Камил үз адресына язылган хатка үзе юлыгуына әле һаман да ышанып бетә алмыйча, хатны тагын берничә кат укып чыкты. Кичә кичтән Камиләнең Идел ярында моңаеп басып торганын да күрде бит югыйсә.—Юләр, шыр юләр,—дип битәрләде үзен Камил. Кычкырып исәнләшсә тавышка балык чиртүдән туктар дип, күрмәмешкә дә салынды бит әле җитмәсә...

Ниһаять, аңа шундый рәхәт булып китте. Аның күңелен берсеннән-берсе ләззәтлерәк тойгылар биләп алды. Хыялындагы алтын балыкның янәшәдә генә икәнен белеп яшәсә дә, ничә еллар буе үзе кütәрелеп тә карарга базмаган күрше кызы Камиләне үзенә гашыйктыр дигән уй, мөгаен, аның башына мәңге килмәс иде.

Ләззәтле тойгылардан һич кенә дә арынырга теләмәгән Камил, шушы мизгелдә чиксез кадерле тоелган «Fanta» шешәсенә хатны кадерләп кенә кире тыкты да, шешәне куен кесәсенә салып куйды.

Идел өстендә түгәрәк дулкыннар хасил булып, кармакларда балык чирткәненә ишарә икәненә дә игътибар итеп тормыйча, Камил язмыш бүләк иткән үз алтын балыгы—күрше кызы Камилә янына ашыкты.

**Фәүзия МӨХӘММӘТОВА.**
*Нурлат*

*Конкурс дәвам итә. (1нче һәм 3нче саннарны карагыз)*




**Ребусны чишсәгез Г. Тукайның шигъри юлларын укырсыз.**

**Зөфәр ХИСАМОВ** *төзеде.*

## «Әһә!» дип башта кем әйткән?

Кайчагында гади генә эш коралына карыйсың да уйлап куясың: «Мондый җайланма башына килгән кешеләрнең беренчесе кем булды икән?» Печән чапканда чалгыма карап шаккатам. Кемдер берәү таяк башына пычагынмы шунда, ә бәлки бик зур булмаган кылычын беркетү һәм шуның белән, иелми генә селтәнеп, яшел үләнне кисеп йөрү мөмкинлеген тапкан бит. Әмма «иң башлы» шәхеснең исемен, күрәсең, беркайчан да белә алмабыз, чөнки андый уйлап табулар бик күптән, бәлки әле язма культуралар пәйда булганчы ук, гамәлгә ашкандыр.

Ә менә фән һәм техника дөньясында төрле төбәкләрдә берничә галимнең бер үк мәсьәлә хакында охшаш чишелешкә килүе тарих битләрендә чагыла. Аларның берсе турында журналыбызның үткән елгы 4нче санында язган идем. Анда Нептун планетасын ике галимнең бер үк вакытта, Ф. Энгельс әйтмешли, «каләм очында» ачуы тасвирланган иде.

Биологиядә шундый очракның мисалы итеп табигый сайланыш тәгълиматының ике инглиз галиме тарафыннан алга этәрелүен атарга була. Аларның берсе дөньякүләм танылган галим Ч. Дарвин, «Бигль» карабында сәяхәте нәтиҗәләрен, биологиянең һәм гамәли селекциянең үз заманындагы казанышларын файдаланып, органик дөньяның тәрәккыят факторларын ачыклый. Аның яшь коллегасы А. Уоллес, Малай архипелагының тереклек һәм үсемлек дөньясын өйрәнеп, шундый ук нәтиҗәләргә килә.

И. Ньютон, классик механикага нигез салучы булу белән бергә, математиканың дифференциаль һәм интеграль хисаплау дигән бик мөһим юнәлешен иҗат итә. Дөрес, Ньютон үз эшен «флюксияләр тәгълиматы» дип атаган, әмма хикмәт исемендә түгел, җисемендә. Галим физика һәм механика мәсьәләләрен чишү ихтыяҗыннан чыгып эшләгән. Чөнки яңа тәгълимат аларны җиңелрәк һәм төгәлрәк хәл итәргә мөмкинлек бирә. Шул ук тәгълиматны аның замандашы, алман (немец) галиме, философ, математик, физик һәм тел белгече Г. Лейбниц та иҗат итә. Бу фәннең хәзерге атамасы аның язмаларында кулланылган. Шунысы игътибарга лаек, Г. Лейбниц үз нәтиҗәләрен И. Ньютонга караганда 28 ел алдан басып чыгара, әмма инглиз галиме 20 ел буена иҗат иткән өч томлык, «Натураль философиянең математик нигезләре» исемле капиталь хезмәтендә һәрдаим үзе иҗат иткән яңа тәгълиматны файдалануын раслый. Шуңа күрә фән дөньясында галимнәрнең икесе дә, И. Ньютон да һәм Г. Лейбниц та әлеге фәннең авторлары булып саналалар.

Юкка түгелдер андый хәлләр. Әгәр дә мәгәр бер үк юнәлештә ике һәм аннан да күбрәк галим затлар ачыш ясыйлар яки яңа тәгълимат иҗат итәләр икән, димәк, бу ачышның иясе яңа фәннең туар вакыты җиткән, күрше фәннәрнең иясе бөтен җәмгыятьнең тәрәккыятен тәэмин итәр өчен аларның тууы кирәк булган.

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1982

**16 октябрь.** ...Бүген Нурсөя баздан алмаларны алып керде. 1 сентябрьдә җыеп алып кайтып, эксперимент өчен берничә килосын базга куйган идек. Әлегә бозылмаганнар. Ике айга якын тордылар тәки. Һәрберсен салфетка кәгазенә төреп, кәрзингә салып, кәрзинен баз идәнендәге бүкәнгә куйдык. Иртәрәк җыйган алмалар яхшырак саклана икән. Соңгыларын 15 көнләп соңрак җыйган идек, аларының күбесе кортлы булды. Соныннан җыйганнарын балкондагы өстәлгә куйган идек, ачыдылар, йомшадылар. Киләчәктә моны истә тотарга кирәк.

**23 октябрь.** Кичә тагын бер авыр хәбәр ишетергә туры килде: абыйның хатыны Рәфига җиңгәчәй кинәт үлеп киткән. Бер атна гына чирләп яткан. Баян җизниләр телефоннан шалтыратты. Аңа әле 44 кенә яшь иде бит. Абый 49 яшендә алты бала белән калды. Балаларының ике кечкенәсе әле укырга да кермәгән. Олысы армиядә. Житмәсә алты баланың бишесе малай. Хәзер анда бөтен авырлык Рәмилә белән абый өстенә төшә инде. Рәмилә әле 8нче класста гына. Тулыр-тулмас 15 яшьтер аңа.

**24 октябрь.** «Дружба народов» журналының 10нчы санында минем «Обида» дигән хикәям басылган. С.Баруздиннан хат килде. Татарчасы—«Рәнҗү». Күптәнге хикәя. 10-12 еллар элек язылган әйбер. Менә соңгы вакытларда язылган әсәрләрне бер шәп тәржемәчедән тәржемә иттерәсе иде. Шәп хикәяләр бар бит минем.

**2 ноябрь.** Кичә «Бөек сер» дигән хикәяне тәмамладым. Соңгы ноктаны кую белән Нурсөягә укып күрсәттем, бик ошатты, күзләре дымланып-дымланып тыңлады. Аннары Казанга семинарга килгән татар теле укытучылары килеп керде. Алар белән озак кына сөйләшеп утырдык. Яңа шигырьләрне һәм әле генә тәмамлаган хикәядән бер өзек укыдым. Ул укытучылар арасында безнең авылдан Мәдинә белән Галимә дә бар иде.

Менә өч көн инде укытучылар килә: әле бер группасы, әле икенче группасы. Барсы да Татарстанның атказанган укытучылары. Барсы да «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен нигә кабат чыгармыйлар диләр. Китап чыгаруны бик җиңел эш дип уйлыйлар бугай. Ә аны чыгару, бигрәк тә икенче басмасын чыгару яңа әсәр язудан да авыррак. Быел кыш көне бик каты чирләмәсәм, шуны тагын бер кат карап чыгып, яңартылган, тулыландырылган икенче басма итеп әзерләп карарга дип торам. Биш-алты елдан соң булса да чыгып куюы бар. Бәлки, ул минем төп китабым булыр. Профессиональ яктан караганда минем үземә шигырьләрем көчлерәк тоелә, ләкин прозам да үзем өчен бик кадерле. Никадәр хикәя генә бар инде минем, ә һәр хикәядә яңа фикер әйтергә кирәк. Зур күләмле әсәр язган кешеләрнең эшләре җиңелрәк. Бер йөреп материал туплап кайттың, характерларның үзенчәлекле якларын таптың—тот та яз.

Бүген балалар өчен бер шигырь язып куйдым. Гомумән, балалар өчен күбрәк эшләргә кирәк. Мин аларның психологиясен яхшы беләм, юмор бар.

*Дәвамы. Башы 1 санда*

**15 ноябрь.** Шактый вакыт көндәлеккә тотынырга кул житмәде. 7сеннән алып 11енә кадәр «Безнең авыл» дигән очерк белән маташтым. Бәйрәм көнне (7 ноябрь) Кояш, Рейн, Шәриф Хөсәенов килгән иде. Ә 13 ноябрьдә Кояшнын туган көненә бардык. Анын 16 ноябрьдә икән туган көне, шимбә көн унайлы дип шул көнне жыйган. Яшь язучылардан Фәүзия Бәйрәмова, Асия Минһажевалар бар иде. Асия Минһажевасы минем иске таныш инде, ләкин үзен танымадым гына. Ул, унынчы классны бетергәч, бераз вакыт мәктәптә укыткан икән, шул чакта минем «Жилкәннәр» чыккан. Шуны укыгач, мина хат язып жибәргән иде. Әлеге мәжлестә дә шуны исенә төшерде: «Туалетка кереп, туйганчы еладым да, сезгә хат язып жибәрдем»,—диде.

Кояшларда Шәриф Хөсәенов та бар иде. Ул вообще кызык кеше икән. Шаяруы-чыны бергә. Ешрак күргән саен ошыйрак бара ул мина. Беренче күргәндә (дачада) тупас адәм булып күренгән иде. Акылсыз түгел. Пародияләре бик үткен. Г.Зәйнашевага, Ә.Атнабаевка язган пародияләре, шулай ук «Көтүче һәм дунгыз караучысы» шәп уйланган нәрсәләр. Сатирик очкын бар анарда. Юморны, сатираны анлый торган һәм тиешле урында куллана белүче кеше буш кеше түгел инде ул. 7се көнне безгә килгәч, кабак бәлеше ашаткан идек, шуны сөйләп көлдереп үтерә язды. Мин әйтәм, черегән кабактан пешергән идек без аны, дим. Ә ул: «Ике бүлмәле квартирым була торып туалетта кундым»,—ди.

Ул безнен арада бердәнбер турысын сөйләүче кеше иде. Һәрвакыт шомартып сөйләргә остарып беткәннәр алдында турысын яручы кеше мәзәк сөйләүче кебек булып чыга икән. Асия Минһажеваларны: «Өстәл башында мулла хатыннары сыман утырасыз, табынны жыешмыйсыз»,—дип кыздырып алды, кузгатып жибәрде. Шаян тон белән үзенен дә жанына тиеп беттек. Кайтканда ул мине фатирга күтәреп менгерде. Чыкканда: «Син дә һаман шушы «хрущевка» читлегендә канатларыңны жәя алмыйча интегәсең. Ә бит ижат кешесенә иркенлек кирәк»,—диде.

**19 ноябрь.** Ике кеше килде. Берсе—профессор Еникеев, икенчесе доцент Билоринский. Нииндидер диссертация өченме, китап өченме, авыруга дучар булып та тормышта үз юлларын таба алган кешеләрнен психологиясе кызыксындыра икән боларны. Ай-һай, бер килеп кенә мона төшенеп була микән? Ни өчен эчүгә бирелмәден? Ничек яза башладын? Сораулар—шундый. Мин аларны башта филологлар дип уйлаган идем. Баксан-күрсән, врачлар икән. ГИДУВнын психиатрия кафедрасыннан. Ә үзләре муеннын умыртка сөяге сыну нинди нәтижәләргә китергәнен, гомумән, минем авыру турында гап-гади нәрсәләрне дә белмиләр. Врачларнын барысы да анатомия үтәдер бит югыйсә.

**22 ноябрь.** Кичә Фаилнен кырыгын уздырдылар. Бардык. 30лап кеше бар иде. Нури Арсланов, Ә.Рәшитов, Ә.Гадел, К.Кәримов, М.Вәлиев, «Чаян»нын редакторы Р.Зәкиев, М.Хужин, Аван Такташ һәм башкалар. Кичке тугыз тулып, унынчы киткәч кенә кайттык. Фаилнен тавышын магнитофонга язып алган булганнар икән, бажасы шул язмаларны тынлатты. Барыбыз да Фаилнен шәп кеше икәнлеген әйтеп, талантынын ин ачылып килгән вакытында үлүенә әрнеп утырдык. Мин дә сүз әйттем. Һәр кешенен үлеме безне бер-беребезгә игътибарлырак булырга кисәтү ул дигән сыманрак. Чынлап та, Фаил үзе исән чакта ижатына карата рәтләп жылы сүз ишетмәде диярлек. Хәзер барыбыз да мактадык. Ә шул сүзләрне исән чакта ишетсә, бәлки, тагы да шәбрәк язар иде. Кешенен унышларын вакытында күрү һәм күрсәтү (үзенә дә, укучыларга да) никадәр мөһим нәрсә. Ә без, берәребез яхшырак әйбер язса, көнләшеп, анын тәгәрмәченә таяк тыгарга маташабыз. «Яшь ленинчы» редакторы Р.Туфитуллова Фаилне балалар әдәбиятында ин көчле язучы иде дип сөйләде Шул ин көчле дигән язучыбызнын сайланма әсәрләрен бирәр чыгарырлар микән? Әллә болар бар да мәжлестә сөйләнгән сүз булып кына калырмы?

Фаилнен балалар әдәбиятында никадәр көчле икәнен әйтә алмыйм, юморда ул чынлап та көчле иде.

**28 ноябрь.** Ничә көннәр инде йоклап булмый. Дарулар да алмый. Иртән кыйналган эт сыман бөтен жир авыртынып торам. Кешеләр, көндез йоклыйсындыр, диләр. Йоклау түгел, күз дә йомган юк көндез. Дару эчеп, ин яхшы йокладым дигән төнне 5-6 сәгать йоклапыла. Алай йоклаган көнне иртән торулары да рәхәт була.

Кай төнне бер сәгать тә йоклап булмый. Нурсөяне-мескенне җәфалап бетерәм. Төнгә кырык мәртәбә торып, әле бер якка, әле икенче якка әйләндерә. Дарулар эчерә. Ул элек йокысызлык дигән нәрсәне вообще белми иде. Хәзер минем кебеккә әйләнеп бара.

**25-26 ноябрь** көннәрендә Мөслимнәр килгән иде. Командировкага, өч кеше. Алар ике көндә дә төнге 12гә хәтле утырдылар. Алар киткән көнне үк Зөфәр килеп керде. Кергәндә үк исерек иде. Өченче көн инде айный алмый. Көненә 3-4 яртыны эчеп бетерә. Йокларга ятмый, тенкәләргә тия. Нурсөя инде сүгеп тә карады. «Синең Әнисән юньле булса, синең нинди икәнеңне белә торып, үзеңне генә җибәрмәс иде. Хәзер син Фәнисне үтерәсең бит инде»,—дип, утырып елады хәтта. Яхшылап та әйтеп карадык. «Зөфәр,—дидем мин дә,—зинһар, бүген эчмә, бүтән түзәр хәлебез калмады». «Ярар, эчмим»,—дип, бер-ике сәгатькә генә шәһәргә чыгып киткән иде, милициягә эләккән. Кемгәдер суккан, шунда ук милициягә эләктереп алып киткәннәр. Ничек чыгарганнар әле. 9 сум штраф түләттеләр, ди.

**2 декабрь.** Бүген Зөфәр кайтып китте, ниһаять. Ишекләрне ябылырлык ясады. Эчүен эчмәсә, кулыннан эш килә дуңгызның.

Ярый инде, хәзер бөтен дөньясы исеректән тора бит.

Бу ун көн эчендә бөтен йокы даруларымны эчеп бетердем инде. Бер нәрсә язылмады. Ярый әле ана кадәр ару гына эшләп алган идем. Нурсөя дә бик арыды. Әле быел өйгә ремонт ясыйсы бар. Ана эләгә бүрәнәнең юан башы.

**9 декабрь.** Өч көн Нурсөя чирләп ятты. Ипигә дә чыга алмады. Әхтәм абый (күрше) ипи, сөт ишеләрне алып кайтты. Галия апа холодец, кыстыбый керткән иде. Нурсөя бик каты чирләгән көнне кичке ашны шулар белән үткәрдек. Менә бүген бераз рәтләнә башладым дип торып йөри башлаган гына иде, кешеләр килеп чыкты. Ижевски авылыннан яшь язучы Михаил Гоголев үзенең хатыны Әлфия, әнисе Нина Михайловна, әтисе Николай Михайловичлар белән.

Бу Миша Гоголев минем кебек муенын сындырган егет. Ул да, егерме яшендә суга чумгач шулай булган. Хәзер егерме алты яшь аңа. Химико-технологическийның 3нче курсында укыганда имгәнгән. Хатыны Әлфия үзе белән бергә укыган кыз икән. Өйләнешкәннәренә ике ел. Бу Миша шигырьләр, хикәяләр яза. 9-10 декабрьдә Казанда яшь язучыларның семинары була, шунда Мишаның да иҗатын тикшерәчәкләр. Бүген семинарны ачу булган. Иртәгә секцияләргә бүленеп, иҗатларын анализлаячаклар. Китап чыгарырга өметләнә. Өр-яңадан укырга кергән. Хәзер Алабуга пединститутында филология факультетында 1нче курста укый. Әле ничектер кызурак канлыга охшаган, утырып җитмәгән. Нурсөя шуның хатынын күргәч өр-яңадан чирли башлады. Дөньяда тагын бер бәхетсез кеше арткан дип уйлады инде ул. Хатыны Әлфия кара гына. Типик татар хатын-кызы. Артык чибәр дип әйтеп булмый, ләкин сөйкемле. Бергәләп фотога төштек.

Шушы көннәрдә «Җилкәннәр җилдә сынала»ның тулыландырылган басмасын эшли башладым. Үзем исән чакта чыгара алырмынмы, белмим, ләкин эшләп куярга кирәк. Матур гына детальләр, онытылган вакыйгалар искә төшә. «Җилкәннәр»дә бит анда тормыш философиясе, яшәү мәгънәсе ачылган. Ләкин тәнкыйтьчеләр аны аңлап җиткермәде. Елга, диңгез, табигать матурлыгы аша әсәрдә Вакыт һәм Пространство төшенчәсе төп герой Фәнияр йөрәге аша уздырылып сурәтләнә, табигать белән кеше гармониясе, чынбарлык белән абстракт төшенчәләр әсәрдә эзлекле рәвештә төп геройның дөньяга карашы кинәя, үсә баруын күрсәтә.

**26 декабрь.** Олы Елга авылыннан (Балык Бистәсе районы) 8нче класс укучылары килде. Педагогик институтта укый торган 5нче курс студенткасы шунда практикада икән, шул алып килгән. Әллә бик оялчаннар инде, бер сорау да бирмиләр. Кайсы язучының әсәрләрен яратып укыйсыз, дигән сорауга да җавап юк. Һәрберсенең кулында минем яңа чыккан китап: «Һәркемнең үз сукмагы». Автограф язып бирдем барсына да. Китаптагы кайсы хикәяләр ошады дигәч, барысы да, дип әйтә алдылар көчкә генә. Димәк, боларга минем әсәрләр түгел, үземне күрү генә кирәк булган. Болар зоопаркка маймыл карарга гына килүчеләр булды.

**31 декабрь.** Елның соңгы көне, соңгы сәгатьләре. Өйдә Нурсөя белән икәү генә. Ул алма бәлеше пешереп йөри. Аңа һәрбер бәйрәмне аяк өсте каршыларга туры килә

инде. Башта минем эшләрне карады, юындырды. Керләр юды, идәнне юды. Иртән 8дә торып басканнан бирле гел шулай аяк өсте инде. Хәзер кичке ун. Телевизорны туктатып торып берничә кешегә шалтыраттым. Яңа ел белән котладым.

Үткән ел мина әлләни уныш китермәде. Дөрес, бераз язылды. Хикәяләр, шигырьләр. Иң зур вакыйга нәрсә булды дип сорасалар, җавап та бирә алмас идем, мөгаен. Хәер, кайвакыт зур вакыйганы бераз вакыт үткәч кенә беләсең. Бигрәк тә язучы хезмәте шул көнне үк бәяләнә торган хезмәт түгел. Кайчакта, иң бәхетле көнем шул булган икән дип, бүген гадәти күренгән көненне искә аласың.

«Җилкәннәр»нең тулыландырылган вариантын эшләп бетереп булмады әле. Кайчак кинәт кенә язасы килми башлый. Өйдә дә тәртипсезлек хөкем сөрә. Квартирны ремонтлыйсы бар. Болай яшәгән юк иде. Һәрвакыт чисталыкка күнеккәч, ремонтланмаган өй дә кәефне җибәреп тора. С.Муллагалиев үзем ремонт ясыйм дигән иде дә, юкка чыкты әле. Дөрес булса, семинарда шигырьләрен бик әйбәт димәгәннәр ана, шуңа кәефе китеп йөри икән. Җайлы гына итеп китап чыгарырга була дип уйлаган иде, ахры. Юкса мин аңа әйттем бит инде, шигырьләрең китаплык юк дип.

## 1983

**2 гыйнвар.** Бүген Әхмәт белән Мәдинә килде. Икесе дә яңа чыккан китапларын алып килгәннәр: «Киек каз юлы», «Узма, гомер». Аларның китабын юдык. Мин дә үземнең «Һәркемнең үз сукмагы»н бирдем. Ике пачка (һәр пачкада 24 китап) алган идек, таратып бетерәм инде.

Яңа елны Нурсөя белән икәү генә каршыладык. 2гә чаклы телевизор карадык та, яттык.

**3 гыйнвар.** Наил килде. Ул хәзер безгә килергә дә курка инде. Килгән саен Нурсөя: «Өйләнмәдеңме әле?»—дип сорый. Кырыкка житеп бара, өйләнми. Мин дә, «Синең урыныңда булсам, өч тапкыр өйләнер идем инде»,—дип ачуын китерәм.

**15 гыйнвар.** Көннәр быел бик җылы тора. Урамда кар юк. Авыл җирендә дә кар юк икән, уҗымнар череп бетәрме инде?

**17 гыйнвар.** «Җилкәннәр»гә тотындым. Ләкин ахырга таба әсәр сүрелә төшкән сыман. Тиешле накал җитмиме? Нәрсәдер шунда. Ә төгәлләргә кирәк. Вакытны бераз алга җибәреп, геройларның язмышын күрәзәлек итеп булса да тәмамлап куясы бар. Бер-ике бүлек кирәк. Мин тормыш чынбарлыгыннан аерылып бетә алмыйм, ахры. Хыялны күбрәк эшкә җигәргә һәм Фәниярны җирдән бераз югарырак күтәрергә кирәктер. Мәңгелек образлар аша. Мәсәлән, дингезнең зурлыгы, күкләрнең биеклеге, офыкларның чиксезлеге керсен әсәргә. Төп юнәлеш табылды. Эшләргә, эшләргә, эшләргә! Дан өчен, мал өчен түгел, җан өчен эшләргә.

**21 гыйнвар.** 9 гыйнвар көнне «Һәркемнең үз сукмагы»на радиодан күзәтү бирделәр. Н.Гамбәров әзерләгән, ахры, тапшыруны. «Кузгалак» дигән хикәяне укыдылар.

М.Вәлиев рецензия язмакчы иде, күренми әле. Әллә язмаска уйлады инде. Шалтыратып сорарга ничектер уңайсыз. Үз әйбереңә үзең сорап рецензия яздыру кебек була.

17есе көнне Илдар Юзеевның 50 яшьлек юбилеена барды Нурсөя. Тәзүчеләр сараена. Бик зурладылар, ди. Башкортлардан Р.Сафин, Ә.Атнабаев, М.Кәримовлар килгән. Чапан, гармун, тәпән белән бал алып килгәннәр. «Юбилеейна чаклы яши алсаң иде»,—ди Нурсөя. Билгеле, тәпән белән бал өчен түгел. Мине дә шулай бер зурлауларын күрәсе киләдер аның. Без дан өчен эшләмибез дисәк тә, дан да, зурлау да кирәк. Дан бит ул эшенне бәяләү. Ә һәр кешенең үзенең җирдә юкка яшәмәвен күрсәтәсе килә.

Бу кышны Нурсөя еш чирли нишләптер. Кайсыдыр көнне (Яңа ел үткәчрәк бугай) бик каты кан басымы күтәрелде. Врач чакырттык. Уколлар кадап киттеләр. Икенче көнне медсестра Әлфия аптекадан үзе дарулар алып, безгә кертеп чыкты. Шуннан соң да шактый вакыт рәтләнә алмый йөрде.

Нурсөя бүген келәм алып кайтты. 1968 сум. Бәяне куя беләләр әйберләргә. Әйдә,

өй матуррак булу начар түгел инде. Аракы эчсән дә бетә ул акча.

«Җилкәннәр»не төгәлләп киләм. Болай ярыйсы сыман. Берәр вакыт тулы килеш чыгарып булсын иде. Юкса повесть геройларының язмышларын сорап аптыраталар. Монда, ичмасам, тулы бер гомер яктыртыла.

**27 гыйнвар.** Өч көн инде чирләп маташам. 25есе көнне температура кинәт кенә күтәрелә башлады. Кичкә 39,3 кә житте. 26сы көнне иртән дә 39,3 иде. Врач чакырттык. Аңынчы инде үзебезнең өйдә булган дарулар белән дәвалана башлаган идем. Бөер котырына бугай. Грамурин эчкән идем. Баш авыртты, Седалгин эчтем. Врач: «Салкын тигән»,—диде. Башта үзләре бер укол кададылар. Аннары антибиотик язды таблеткада. Баш авыртканда эчәргә—пенталгин. Антибиотик аллергия бирмәсен өчен—супрастин. Бөтенесен эчсәң, бик тиз аяк сузарсың.

Бүген хәл бераз арурак. Температура төшеп килә.

Нурсөя «Җилкәннәр»не машинкада баса. Язып бетердем, ниһаять. Нурсөя: «Быел январь аенда чирләмәдең, әйбәт кенә эшләдең»,—дип бик сөенеп йөргән иде. Бах!—кырыкка якын температура. Үзеннән-үзе ыңгыраштыра, житмәсә. Дерелдәтә, калтырата.

Гадәттә кеше эше беткәч йә чирли, йә үлә дип шаярта идем. Юкса әле минем эш тә бетмәгән иде. Бер хикәя яза башлаган идем. Дөрес, ул 3-4 битлек кенә булыр.

**31 гыйнвар.** Бүген лаборантка Тәнзилә анализларны алып китте. Температура өч көн инде әйбәт кенә. Башлаган хикәямне язып бетердем. 29-30 көннәрдә киштәләр куйдырып, вак-төяк ремонт белән маташтык. Солтан абый эшләде. Бик эчми дә икән. Эшләгән вакытында утырып ял да итми. Хәтта тәмәке дә тартмый. «Шабашник» дип карарга өйрәнгәнбез без андый кешегә. Әйбәт шабашник. Андыйлар күбрәк булсын иде әле.

Кичә үзебезнең колхозның парторгы Фоат Җәләев белән Кәрәкәшле авылы парторгы Алмас абый килделәр. Монда ниндидер укуга чакырганнар. Колхозлар турында озак кына сөйләшеп утырдык. Кәрәкәшле авылы (Киров исемендәге колхоз) ул безнең районда алдынгы колхозлардан санала. Кәрәкәшледән укыган кешеләр дә күп чыккан. Минем «Һәркемнең үз сукмагы» дигән китапны бик яратып укуларын әйттеләр. Газета-журналлардан иң беренче синең әйберләрне карыйбыз, диләр. Бу сүзләрдән мин бик очынмадым, әлбәттә. Беренчедән, алар якташлар, ә үз якташың турында күбрәк белергә теләү табигый. Икенчедән, минем янга килгәч минем әйберләрне хурлап утырмаслар бит инде. Минем әйберләрне яратмасалар, килмиләр дә инде алар.

**6 февраль.** Бүген якшәмбе. Тик яту белән шөгыльләнәм. Бер хикәя сюжеты башта йөри йөрүен, ләкин ахыры уйланылмаган әле. Беркөн һич көтмәгән җирдән «Табылдык сумка» дигән хикәя язып ташладым. Тарихы болай: кемдер подъездга ящик белән чүп чыгарып куйган. Күрше Әхтәм абый, мин моны барыбер табам дип, чүпләр арасыннан бер кәгазь кисәге алып кергән. Анда кемнеңдер айлык расходы һәм ничә сум квартирга түләгәнлеге язылган. Шушы идея мина хикәя язарга сюжет бирде. Төп героен детектив китаплар укып җенләнгән малай итеп, вакыйганы кешелеклерәк юнәлешкә борып, хикәя язып ташладым.

Кичә Нурсөя квартирда ремонт ясарга дип тотынган иде, Әхтәм абый бер маляр иярттеп керде. Киләсе атнадан эшли башлармын дип чыгып китте бу. Пычрак туйдырган иде инде. Бусы да Сафуан абый кебек алдап качмаса. Сафуан чучка үзем ремонтлыйм, бер кешегә дә әйтмәгез диде дә юкка чыкты, өч ай инде күргән юк.

Өченче көн врач Флорина Сергеевна белән Әлфия (сестра) килеп киттеләр. Анализларың әйбәт дип әйтергә кергәннәр. Минем анализларның бер дә рәтле булганы юк иде, сөенечләреннән килми түзә алмаганнар инде. Флорина Сергеевна исе китеп йөри иде, минем шушы хәлдә 25 ел буе яши алуыма. Монда бигрәк тә Нурсөянең заслугасы инде, ди. Ул шулай яхшы карап, чиста тотмаса, бу гомер яши алмас идең, ди. Әлбәттә, шулай.

**11, 12, 13 февраль.** Бу өч көндә ремонт эшләре белән шөгыльләндек. Ике кеше—Витя Арбузов һәм Миша Егоров дигән кешеләр белән сөйләшкән идек. Бик начар эшли торган кешеләр булып чыктылар. Түшәмне дә рәтләп агарта алмадылар. Бер олы капчык известь җитмәде. Калын катлам итеп сиптерделәр,

бирәр вакыт башка коелып төшүе дә бик ихтимал. Нурсөя боларның эшен күргәч үлә язды. Безнең бәхетебез җыен алкаш белән тяп-ляплардандыр инде, ди. Обой да ябыштыра белмиләр. Кыек-мыек. Хәзер менә ике көн инде Нурсөя Әхтәм абый белән өйне рәткә кертә. Тигезли, чистарта, ялтырата. Бөтен эшнең бер башыннан үзе эшләшеп йөрде. Иртән җидедә торабыз, төнге уникедә ятабыз. Яткач та йоклап булмый. Кешеләр эшләгәнгә мин арып ятам. Һәр эш эшләткән саен, их, үзем эшли алсам, дип әйтәм инде. Бер читтә борчылып ятудан да кыен нәрсә юк.

Бераз чистарынабыз бугай инде. Өйне ремонтлап бетергәч тын алып булыр, бәлки. Нурсөя дә бик арыды. Аннары китапны басып бетерәсе генә кала. Быел нишләптер эш күп булды. Күзгә кергәннән бирле һич тик торган юк. Әле гараж түбәсен яптырасы бар. Тормышның шундый чүп-чары табылып кына тора. Без, бәлки, артык таләпчәндер дә инде. Кеше эшләгән эшне ошатмыйбыз. Алган киемне дә төзәтми кимибез, эш эшләтсәк, янадан үзебезчә маташтырабыз. Шуның аркасында үзара кычкырышабыз. Кәеф китә. Тыныч кына кабул итәргә кирәк тә бит бөтенесен. Юк,тыныч булып булмый.

Бүген менә 15 февраль. Өйне чистартып бетереп киләләр. Зал ягына 10 метрлы 7 рулон обой алган идек, житмәде. 8 рулон кирәк икән. Йокы бүлмәсенә 12 метрлы 6 рулон кирәк булды. Коридорга 3 рулон керде. Болары киләсе ремонтта күпме нәрсә кирәклеген белер өчен. Хәзер ишек-тәрәзәләрне буйыйсы калды. 3 кило келәй кирәк булды. Обой ябыштырырга.

**18 февраль.** Өйне чистартып бетерәләр дигән идем. Юк, әле бетми. Нурсөя тигез чыкмаган обой башларын кисеп чыкты. Ул урында бордюр ябыштырды. Каралган урыннарын акшарлады. Ай-һай озын һәм кыен ремонт булды бу. Шушы ремонт аркасында бер нәрсә язган юк. Килгән газета-журналларны көчкә укып өлгерәм. «Ялкын»да (№2) «Бөек сер» дигән хикәям чыкты. Бер урынын үзгәрткәннәр.

«Татарстан яшьләре»нең 15 февраль санында биш шигырь басылды. Газета-журналларны күзәтеп баручы кеше: «Фәнис соңгы вакытта күп яза»,—ди торгандыр инде. Ә бит, күп язганда газета-журналларга әйбер җибәрергә вакыт булмый. Язудан туктап торган чакларда җибәрелә күп нәрсә.

Бер уйласаң, кеше бар яклап та матур булыйм дип тырыша икән. Матур булып күренер һәм үзенне үзең яратыр өчен матур кием-салым аласың, өенне ремонтлыйсың, бизисең, чистартасың. Ямьсезлек күңел канатын сындыра торган нәрсә. Һәркөн бер үк стеналарга күзләрең барып төртелгәч, ялыктыра. Шул стеналарны әллә ничек итеп үзгәртеп бетерәсе килә. Шуңарга, ахры, Нурсөяне дә гел куалап торам: әле бер эш, әле икенче эш табам. Иң җенем сөймәгән нәрсә—тәртипсезлек, таркаулык. Ул яктан Нурсөя белән минем карашлар бертөсле. Шуңа аның күршегә керергә дә вакыты юк.

Атнадан артык Нурсөянең урамга чыкканы юк. Ипине-сөтне Әхтәм абый алып кайтып тора. Минем йокы даруларым да беткән. Атна буе йокы такы-токы, тәүлегенә 2-3 сәгать. Төнге 3ләргә чаклы йоклый алмый ятам, аннары йоклап китәм дә бер сәгать чамасы вакыт үтүгә «дерт» итеп уянам. Йокы туйган төсле була. Хәлсезлек. Ауный торгач, тагын бер-ике сәгать йокланыла. Минем уянмыйча ике сәгатьтән артык йоклаганым сирәктер. Арка тишелмәсен дип еш-еш әйләнергә гадәтләнелгән. Нурсөя йокы бүлмәсендә ятса да, мин ана: «Нурсөя!»—дип пышылдауга йокламаган да кебек атылып килеп чыга. Бик сирәк очракларда гына ике тапкыр эндәшәм.

**22 февраль.** Кич белән Лирон, Фәрваз Миннуллин һәм шофер Тәлгать килделәр. Мине Совет Армиясе көне белән котларга килгәннәр. Житмеш сум акча китергәннәр Литфонд исеменнән. Таштан юкә суелган. Бер дә алай бәйрәм белән котлап вакланмый торганнар иде.

**23 февраль.** Кояшлар килделәр. Туган көн белән котларга. Нурсөя гөбәдияләр, күп итеп ашлар пешереп куйган иде. Шампанский һәм бер акны бушаттык. Кичке унынчы яртыга кадәр утырдык. Кояшның 84 ел планына китабын кертмәгәннәр, кәефе китек иде. Китаплар чыгару бигрәк кыенлаша бара.

**27 февраль**. Кичәле, бүгенле «Казан утлары»ның 2нче санын укып яттым. Ә.Баянның «Таш китабы» ошамады. Артык салкын, мудрить итеп язылган. Гомумән,

аның прозасын яратмыйм бугай мин.

А.Гыйлажевның «Тынычлану зарарлы» дигән мәкаләсе бик кайнарланып язылган. Шәп. Ләкин Гыйлажев үзе күтәргән мәкаләдәге кебек үз иҗатында да шундый таләпчән, тәнкыйтькә үпкәләмәүчән микән соң?

Шунда ук хәзерге заман прозасы турында Т.Галиуллиның мәкаләсе бирелгән. Кызыксыз язылган. Язучылардан ачыш көткән кебек тәнкыйтьчеләрдән дә ачыш көтәргә хаклыдыр без. Р.Мөхәммәдиев мәкаләләрендә әллә ни ачыш булмаса да, теле әйбәт, укырга җинел. А.Гыйлажев безнен прозабызның союзкүләм яңгыраш ала алмавы өчен борчыла. Бәлки, монда тәрҗемә эшенең шәптән тормавы да сәбәпчедер? Аннары без күп вакыт икенчел материал белән эш итәбез. Руслар фәлән нәрсә турында язган, безгә дә вакыттыр дип тотынганнан гына оригиналь әсәр тумый. Аязның үзенә дә нәкъ шул оригинальлек житми. Ә бит каләме оста, яза белә. Тормыштагы үзгәрешләрне генә бераз сонгарып тота. Юкса Распутиннар, Быковлар дәрәҗәсенә күтәрелә алыр иде.

**1 март.** Язның беренче көне бик каты салкын. Иртән Казанда 31 градус. Әле гыйнвар-февраль айларында да быел андый суыклар булмаган иде.

Подстрочниклар ясар өчен шигырьләр әзерләдем, беркөн Фәрваз белән сөйләшкән идек. Роза Кожевниковага бирербез, ул тәржемәчелеккә Мәскәүдә укып кайтты бит, дигән иде. Мәскәү мондагы тәржемәчеләрнең эшен алмый инде ул. Шуңа күрә аларга подстрочниклар гына җибәрү хәерле.

Кичә Англия язучысы Урсула Холденның «Узы денег» дигән романын укыдым, бер дә ошамады инде. Безнең татар язучылары да анардан әйбәтрәк язалар дип укыдым. Бер семья тормышы кызыксыз итеп язылган шунда. Алты яшьлек Артурның фикер йөртүләре һич тә балаларга хас түгел. Гомумән, бөтенесе ясалма сөйләшәләр. Чын кешеләр түгел, курчак уены сыман. Безнең әдәбиятка да шундый стиль кереп бара хәзер. Яшьләрдән Әхәт Гаффарда, өлкәннәрдән Әхсән Баянда, урта буыннан Марсель Галиевта күренә бу нәрсә. Язарга материаллары юк. Шуңа символларга тотыналар. Ә.Гаффар үз героена боз чаптыра, ә боз астында берни юк. Ә.Баян Кама елгасыннан әле чибәр кыз ясый, әле суны утка әйләндерә. Символизмга мин каршы түгел. Ләкин ул символ әсәр геройларын күмеп китмәсен. М.Галиевның да «нигезе» бар, өе юк.

**2 март.** Пединституттан ике студент килде. Рәйсә һәм Илсөя исемле кызлар. Рәйсә исемлесе Балтачтан, Илсөясе Биектау районы Битаман авылыннан икән. Икенче курста укыйлар. «Сезнең янга группабыз белән килергә жыенабыз, мөмкинме?»—дип сорарга килгәннәр. 15 мартка дип сөйләштек. Утыра торгач, сөйләшә торгач ачылып киттеләр. Укытучылары турында сөйләделәр. Әдәбият теориясеннән Ф.Хатипов укыта икән. Лекцияләрне шундый кызыксыз сөйли, диләр. Илсөя исемлесе хәтта лекция вакытында йоклап та киттем әле ди. Ф.Хатипов дача күршем. М.Мәһдиев кебек кызыклы итеп сөйләмәсә дә, фикерле зат. Ләкин кешеләр белән бик аралашырга яратмый. Докторлык диссертациясе язган, бәлки, яклар да. Димәк, белеме юк түгел. Ләкин булган белеменне башкаларга бирә белү дә кирәк бит әле.

Бу группаның житәкчесе Әмир Мәхмүтов икән. Ул да Ф.Хатиповтан ерак китмәгән дип көлештеләр. Ә.Мәхмүтов шагыйрь кеше бит инде. Болай үзара сөйләшкәндә шәп кенә сөйләшә. Хәер, мин аны бер генә күрдем, бераз салган иде. Андый чакта барыбыз да Цицеронга әйләнәбез. Кызлар үзләренең Зиннур Зәкәриевич дигән укытучыларын мактап тордылар. Аның безгә дә килгәне бар, мина да ошаган иде ул. «Сезнең хикәяләрдә Зиннур, Зәкәрия исемнәре еш очрый, нилектән бу?»—дип сораган иде. Казан больницасында бер Зиннур исемле җор телле егет белән яткан идек. Хәтерем ялгышмаса, Чистай районыныкы иде бугай. Минем янга житен комбинатыннан, мехкомбинаттан кызлар күп килә, бөтенесен кертмиләр, халат юк дип булса да кире борырга тырышалар иде. Шунда әлеге Зиннур простынясын алып чыга иде дә, кызларга халат урынына бөркәнергә бирә иде. Шул хәтергә уелып калгандыр, күрәсең, хикәяләргә Зиннур исеме кергән. Ә Зәкәриясе безнең белән бер класста укый иде. Янагын булавка белән тишеп, булавка очын авызыннан чыгара иде, аннары лезвие чәйни иде. Шул

«батырлыклары» безне әсир иткән, ахры. Дөрес, ул минем хикәяләрдә андый батырлыклар эшләми.

Әлеге кызларга Рәйсәсенә—«Танышлар арасында», Илсөясенә «Һәркемнең үз сукмагы» дигән китапларны бирдем. Юкса очрашуга киләләр, бер әйберне укымаган булалар. Сораулар бирсәң ык-мык килә башлыйлар.

**3 март.** Көннәр салкын тора. Төннәрен Татарстанның кайбер районнарында 30 градуска хәтле житә. Бүген иртән Казанда 24 иде. Көндезләрен 17-19. Шулай да яз якынлашканлыгы сизелә: көннәр якты, кояшлы.

Бер-ике айдан бакчага барыр вакыт житә. Һава суларга. Казанның һавасы тынга каплана. Бигрәк тә төнлә. Нинди дер завод төнге уникеләрдән соң әллә нинди әшәке ис чыгара, йоклаган булсаң, шул ис йокыдан уята. Мин генә түгел, Нурсөя дә шул искә уяна. Ә күршеләр сизмибез диләр. Аларда нинди организмдыр ул.

Бүген төшемдә Нурсөянең үлгәнен күрдем, акырып-акырып еладым. Алла сакласын, үлә калса, елый да алмам. Аның артыннан ук китеп барырга туры килер. Инде Ходай ул кайгыны күрсәтә күрмәсен. Булганы бик житкән.

**8 март.** Кичә ике генә куплетлы шигырь язып куйдым. Март аенда әллә ни кыйраткан юк бугай. Көннәр әле һаман салкын тора. Төнлә 15-16 бүген. Әле бер атна элек төннәрен 30 ларга житә язды. 6 март көнне Флера (Ирек хатыны) Нурсөяне 8 март белән котлап 6 касә алып килгән. 8 март белән котлап мин Нурсөягә бер шигырь дә язмадым. Кыстыбый пешерештем. Дөресрәге, карап тордым. Кечкенә чакта әнинең коймак пешергәнен карап торырга ярата идем. Бик үк түгәрәк булмаганнары минем авызга кереп чума иде.

Кичә Нурсөя белән ядәч аерышкан идек. Кайсыбыз отса да, берәр кулмәктән. Мин оттым. Соңыннан жәлләп куйдым үзен. Бәйрәм хөрмәтенә аңа оттырасым калган. Алай юри эшли алмыйм шул эшне. Ялагайлыкка өйрәнеп булмый.

**17 март.** Көннәрне жылытып жибәрде әле. Көндезләрен +5-+6 булгалый. Тышта чыпчыклар дәртлерәк сайраша башлады. Песнәк сызгырган тавышлар ишетелә.

Кичә пединституттан 2нче курс студентлары килде. 3 тән 5 кә кадәр утырдылар. Бер егет тә юк араларында. Группада 3 егет бар диләр. Аларны да ияртмәгәннәр. Минем кызлар яратканны белгәннәр, ахры.

Яңа шигырьләрне укыдым. Бик күп сораулар бирделәр. «Танышлар арасында» дигән жыентык барсының да кулларында. Соңыннан автографлар яздым. Нәрсә турында шигырьләр укырга телисез соң, дигәч,барсы да: «Мәхәббәт турында»,— диләр. Мәхәббәтне ничек күз алдына китерәсез, дип сорадым. Берәүләр мәхәббәт ул—тугрылык, икенчеләр—сафлык, өченчеләр—бер-береңә ышану диделәр. Китәсе килми дип, бар, син киенә тор дип бер-берләрен алданрак чыгарга кысташып утырдылар. Шигырьләр укыганда «Кыз озату» дигән шигырьгә иң көчле реакция булгандыр. 25 кеше берьюлы шаркылдап көлде. Тюльпан чәчәкләре алып килгәннәр иде, әллә бирергә кыенсынып, бер кыз ике сәгать буе кулында тотып утырды, шинеп бетә яздылар. Ятрак, колакка ишетелмәгәнрәк исемнәрдән: Әнсәрия, Рухия исемнәре булды. Бәлки, берәр вакыт хикәяләргә кертергә булыр. Арадан мина иң чибәр тоелганы Рәйсә Маннапова (Балтач кызы) булды. Шәп кыз инде, шайтан алгыры. Үзе генә килгән булса, бер кочаклап үпми жибәрми идем инде.

Нурсөя чирләп йөри. Ашказаны төшкәнме, нәрсәдер. Беркөнне телевизорны мастерскойга илткән иде, шунда авырсынган, ахры. Гел мине күтәрүләр дә сәламәтлек өстәми. Фатир икенче катта, лифт юк. Нурсөя мине катлы-катлы киенгән килеш икенче этаждан күтәреп төшерә. Бакчага баргач, тагын күтәрү. Гадәттә, мин кояшлы көннәрне тышта ятам. Кайвакыт көтмәгәндә янгыр ява. Тагын мине күтәреп кертергә кирәк була. Өстәвенә юрган, матраслар чыланмасын өчен йөгерә-йөгерә аларны кертә. Янгыр туктап, кояш чыкса, кабат мине чыгара.

**18 март.** Радиодан минем сүзләргә язылган жырлардан концерт бирделәр.

1. «Иң гүзәл кеше икәнсез». Әхмәт Хәйретдинов музыкасы. М.Галиев жырлады.

2. «Чык юлларга». Сания Әхмәтова музыкасы. Фәхри Насретдинов җырлады. Бу сүзләргә Фәрит Хатипов та музыка язган иде. Аның көен яратып өлгергән идем инде. Мингол Галиев башкара иде. Бу Сания Әхмәтованыкы бик шәп тоелмады.

3. «Синең күзләрдә». Фәрит Хатипов музыкасы. Рабига Сибгатуллина башкарды. «Синең күзләрдә» шигыренә хәзер өч композитор көй язды инде. Берсе Бәхти Гайсин көе. Аныкын бер бәйрәмдә Башкортстан радиосыннан тапшырганнар иде.

4. «Акчарлак». Ганс Сайфуллин музыкасы. Таһир Якупов башкарды. Шактыйдан җырлыйлар инде бу җырны.

5. «Бар ул син эзләгән кеше». Илгиз Закиров музыкасы. Луиза Исламова башкарды. Үзешчән җырчыдыр, мөгаен. Исеме таныш түгел.

Шушы 5 җырны 15 минутлык концертта җырладылар. Әле радиода «Илем чакыра», «Янармын да янармын», «Сиреньнәр» җырының язмалары бар. Өчесенә дә көйне Наилә Зарипова язган. «Илем чакыра»ны Эмиль Җәләлетдинов язмасында бирәләр иде, «Сиреньнәр»не Зөләйха Хисмәтуллина язмасында. «Янармын да янармын» җырын Рафаэль Ильясов җырлый иде. Н.Зарипова бер баянчы белән Р.Ильясовны безгә алып килеп, бу җырны җырлаткан иде. Р.Ильясов ул чакта әле консерваториядә укый иде...

Барлык җырлар арасыннан үземә иң ошаганы «Бар ул син эзләгән кеше».

**26 март.** 22 март көнне Резидә Вәлиева килде. Аның белән киләсе елда чыгарга тиешле китапка кайбер яңа шигырьләр сайладык. Ул минем китапның редакторы. Синең китабыңны редакцияләү рәхәт, үзем сайлап алдым, ди. Хәтта машинкага да биреп маташасы юк, чип-чиста, бер җиренә дә кул тыкмадым, ди.

Бу арада үземнең кәеф юграк. Тән тирләп тора. Бөерләргә салкын тигәндер, ахры. Теге очрашуга килгән кызлар мәхәббәт шигырьләре күбрәк яз дигәннәр иде. Алардан соң өч шигырь яздым әле. Бар да мәхәббәт шигырьләре. Һәр килгән группа өч шигырьлек илһам биреп китсә, начар булмас иде.

Бүген гараж түбәсен ябарга сөйләшергә дип Вәлиәхмәтов Тәлгать килгән иде. Плитәгә дип 70 сум акча һәм минем паспортны биреп җибәрдек Аллага тапшырып. Төп башына утыртмаса.

**29 март.** Бу ике көндә Д.Лондонның «Мартин Иден»ын укыдым. Элек университетта укыганда русчасын укыган бар иде. Татарчага Ф.Миннуллин тәрҗемә иткән. Җөмләләрдә чатаклыклар күп кенә очраса да, әсәре тулаем алганда шәп булгач, андый чатаклыкларга игътибар итми башлыйсың. Шәп әсәр инде. Гали һәм шәп!

Өченче көн авылдан Галимә килде. Авыл хәлләрен озаклап сөйләштек. Заманында минем аңа күз төшеп йөргән иде. Озатырга да барып караган идем, ләкин уңышсыз чыкты. Таза чакта үзем йөрергә теләп тә миңа отказ биргән беренче кыз булгандыр әле ул. Беренчесе, бәлки соңгысыдыр да. Борынына чирткән кешеләр хәтердә озак саклана шул. Шулай, иптәш Яруллин, мине кызлар яраттылар дип бик мактанма, яратмаучылар да булган. Галимә күчтәнәчкә бер бөтен ипи алып килгән. Авыл ипие тәмле инде. Бездә күчтәнәчкә ипи алып килү күптәнге гадәт. Шул хакта бер шигырь язсаң ярар иде. Нинди генә тук заманда да ипи үз кадерен җуймый. Авыл ипие, авыл каймагы.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# М

**МАМИН** Мөхәммәтша Гомәр улы (1905, хәзерге Мордовия респ-касы Зубово-Полянский р-ны Горенка а.—август 1943), әдәбият галиме. Пенза ш. укытучылык курсларын тәмамлый (1921). 1924-30 елларда авыл мәктәбендә эшли. 1933 тә Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый, 1936 дан шунда укыта. Мәкаләләрен, рецензияләрен инде студент булган еллардан бастыра башлый. Һ.Такташның тормышын һәм иҗатын өйрәнә («Такташ поэзиясе», 1941). Бөек Ватан сугышында катнаша. Воронеж ш. тирәсендәге Воробьёвка а. янында һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**МАМИШЕВ** Якуб (19 йөз ахыры, Казан губерниясе Казан өязе Орнашбаш а. дип фаразлана—20 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. 1917 дән Казанда Мөселман социалистлар комитетында, приказчиклар бюросында эшли. «Әл-Ислах», «Кызыл байрак», «Кызыл Армия» г-таларында басылган шигырьләре «Татарча уку» (1915) җыентыгына кергән. М. иҗатына лиризм хас, шагыйрь вәзгыять, тормыш мәгънәсе турында уйлана.

Әд.: Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

**МАННУР** (Маннуров) Шәйхи (Шәйхелислам) Фәрхулла улы (15.1.1905, Казан губ. Мамадыш өязе Тулбай ав.—11.6.1980, Казан, туган авылында җирләнгән), язучы. Казан пед ин-тын тәмамлый (1937). 1921 елдан Себердә: Анжеркалагы шахталарның берсендә хуҗалык бүлеге эшчесе, Андреевка руднигы каршында ачылган татар мәктәбендә укытучы булып эшли. Свердловск шәһ-дә совет-партия мәктәбен тәмамлагач (1924), Тобол округы Тукыз ав-да уку йорты мөдире, Тобол шәһ-дә балалар йорты җитәкчесе, округ комсомол к-ты инструкторы. 1929 елдан Донбасс металлургия з-дында прокатчы, Днепрогэс төзелешендә бетон салучы. 1932-33 елларда Мәскәүдә яши, анда «Эшче» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1933тә Казанга кайта. 1937-38 дә «Совет әдәбияты» ж-лында җаваплы сәркатип. Бөек Ватан сугышы елларында «Сугышчан чакыру», «Алга, дошман өстенә!», «Ватан бәхете өчен» кебек фронт г-талары хәбәрчесе. 1946-48 дә Татар опера һәм балет т-рының әдәби бүлек мөдире. М. беренче шигырьләре 1923-24 елларда Себер һәм Уралда чыккан газета-журналларда басыла башлый. «Чуен ташкыннар» (1930) поэмасында язучы беренче бишьеллык эшче-ударниклары образын тудыра. Авыл хуҗалыгын күмәкләштерү темасы «Гайҗан бабай» (1934) һәм «Меңнән бер кичә» (1935) поэмаларында чагылыш таба. Татар әдипләре арасында Бөек Ватан сугышы темасын яктыртуда «Казан кызы» (1946) поэмасы да мактаулы урын алып тора. 1960-70 елларда М. нигездә проза жанрында гына иҗат итә. М.Җәлилгә багышлап «Муса» (1968, 2 басма 1975; русчага тәрҗемәсе М., 1983) романын бастыра. Үзенең авылдашлары, балачак дуслары тормышыннан алып «Агымсуларга карап» (1974; русчага тәрҗемәдә «Глядя на текучие воды», 1991) автобиографик повестен тәмамлый. Балаларга адресланган шигырьләр һәм поэмалары тупланган «Нәниләргә, дәүләргә» (1965), «Кызларга һәм малайларга» (1984) җыентыклары бала психологиясенең четерекле якларын, аларның әйләнә-тирә тормышны ничек кабул итү үзенчәлекләрен аңлап иҗат итүе белән аерылып тора. М. халыкчан тел бизәкләренә бай хикәяләү стиленә ия булган каләм остасы буларак таныла. Ул А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, Т.Г.Шевченко, Ш.Руставели, Джамбул әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почет Билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1951; Күңел йомгагы. 1 кит. К.,1968; 2 кит. К., 1971; Уткүз. К., 1986.

Әд.: Закир М. Туган як һәм әдип кадере //Казан утлары. 2005. №1; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Абҗабар

Абҗабар авылы Арча районында, район үзәге Арча шәһәреннән 8 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Кәче авылыннан—5, Казан шәһәреннән 57 чакрым ераклыкта урнашкан.

Абҗабар атамасы күп кенә тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә телгә алына.

Арча юлы өстендәге Абҗабар авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. 1602—03 еллардагы мәгълүматларны туплаган Казан өязенең теркәү кенәгәсендә (писцовая книга) авыл атамасы һәм шул ук исемдәге елга еш искә алына.

Д.А.Корсаков хезмәтендә авылда 36 ясаклы крестьян һәм 25 керәшен татары яшәве әйтелгән. 1766-1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында күрсәтелгәнчә, Абҗабар авылы Аты суының уң ягында урнашкан, анда ясаклы керәшеннәр һәм поляк милләте кешеләре яшәве әйтелә. А.Артемьев хезмәтендәге мәгълүматларга караганда, авылдагы 19 хуҗалыкта 72 ир-ат һәм 74 хатын-кыз көн иткән. Халык ярлы булган. Йон тетү, итек басу кебек һөнәр белән көн күргәннәр. Бу очракта Мөхәммәт Мәһдиевнең авыл атамасын даими рәвештә Атҗабар дип язуы аңлашыла. Авыл халкы, димәк, «атлар ябарга» яраткан. 1898 елда авыл Абҗабар дип искә алына. К.П.Берстель китабыннан күренгәнчә, Абҗабарда 144 татар кешесе яшәгән.

Гомәр Саттаров Абҗабар топонимының нигезендә Габделҗаббар дигән кеше исеме ята, дип яза. Татарларга гарәп теленнән кергән Габделҗаббар исеме «бөек кодрәтле алла колы» мәгънәсен белдерә. Башлап Габделҗаббар исемле татар нигез салганга, авыл аның исеме белән аталган. Сонрак бу авылга руслар килеп урнашкан һәм Габделҗаббар атамасы Абзябар рәвешен алган.

## Адав-Толымбай

Адав-Толымбай авылы Буа районында, Буа шәһәреннән 3, Тәтеш пристаненнән 43 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы тарихи чыганакларда искә алына.

Сембер губернасы авылларын исәпкә алган белешмәдә (1859 ел мәгълүматлары буенча) Иркүл буена утырган авылдагы 42 йортта 200 ир-ат һәм 202 хатын-кыз яшәгәнлеге телгә алына. Анда мәчет эшләгән.

Биредә 1900 елның 14 апрелендә язучы һәм әдәбият тәнкыйтьчесе Гомәр Толымбай (Гумер Тулумбайский, Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов, 1900—39) дөньяга килгән.

Авылның оешуы турында халык ике вариантта йөри торган легенда-риваять сөйли.

Ике кеше (ни өчендер туган якларыннан сөрелгәннәр һәм кире кайтырга

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

ярамаган)—берсе Толымбай, икенчесе Илбай—яшәргә урын эзләп Зөя суы буена килеп утыралар. Якындагы урманда бүрәнә әзерләп, торырга өй салалар. Алар балык тотып, урманнан җәнлек аулап көн күргәннәр.

Бервакыт ауга чыккач алар бер бай кеше очраталар, танышып китәләр һәм шул кеше ярдәме белән хәзерге Толымбай авылы урнашкан күл буена килеп төпләнәләр. Бу бай аларга йорт салырга, гаилә корып җибәрергә булыша һәм күршедәге Черкен авылы кызларына өйләндерә.

Легенда-риваятьнең икенче вариантына караганда, әлеге кешеләрнең берсе Адав исемле чуаш, икенчесе Толымбай исемле татар була. Авылның атамасы да соңгысының исеменә мөнәсәбәтле дип әйтәләр. Авылда татарлар һәм чуашлар яши. Ләкин язларын Зөя елгасы ярларыннан ташып, өйләренә су кереп аптыратканга, алар Кондыз күле дип аталган күл буена килеп урнашалар. Менә шушы урыннан авыл башланып киткән дип сөйлиләр. Авылда татарлар һәм чуашлар яшәгән. Чуашларның кирәмәт урыннары әлегә кадәр сакланып калган.

Элек авылны Сөүш (Сүеш—село Сюеш) дип йөрткәннәр, чөнки авыл янында тагын Сөүш-Сүеш дип исемләнгән торак пункт та булган. Шуннан соң тагын Яна Сөүш-Сүеш исемле авыл да барлыкка килә. Өч авыл вакытлар узу белән бергә кушылып, Адав-Толымбай дип йөртелә башлый.

1859 елда авылда мәчет салынган. 1884 елда мәчет каршында мәктәп эшли башлый. 1905 елда патша ирек турында манифест игълан иткәннән соң, элек христиан дине кабул иткән чуашларның байтагы яңадан мөселман диненә кайта. Нәтиҗәдә, авылда икенче мәчет барлыкка килә. Чуашларның калганнары да мөселманлыкка күчмәсеннәр дип курыккан хакимиятләр авылга рус гаиләләрен күчереп утырталар. Авылда чиркәү салына һәм ул тиз арада эшен башлап җибәрә. Шулай итеп, бүгенге Адав-Толымбай XX йөз башына өч милләтле авылга әйләнә.

Совет хакимияте елларында мәчет һәм чиркәү җимертелә. Олылар телендә Мәчет урамы атамасы гына сакланып калган.

Авылның урыны тормыш итү өчен җайлы. Каршыда гына зур күл, Зөя суы да ерак түгел. Урманнарда имән, каен, карама, усак, өрәнге үсә, шомырт, балан, чикләвек куагы, миләш еш очрый. Җәнлекләрдән куян, төлке, бүре, бурсык, ас, кыр казы, көртлек, суер, боҗыр, кыр тавыгы, үрдәк, ләкләк, сусар, кондыз һ.б. аулаганнар. Күлләрдә кәрәкә, сазан, чуртан, кара балык, алабуга, бәртәс, җаен һ.б. балыкларны тотканнар.

Зөя буендагы калдырып киткән урынны халык Атау йорты дип йөртә.

Адав-Толымбай—бай табигатьле авыл. Аның бер ягында нарат урманы, икенче ягында катнаш урман—Авыл урманы. Авыл урманы буенда Зөя суы ага. Җәй көннәрендә авыл халкы Зөя буена балык тотарга, ял итәргә бара. Зөянең саерак урынын Шарлавык дип атыйлар. Халык шунда су коена.

Югарыда әйтелгәнчә, авылда татарлар һәм чуашлар көн күрә.

Авыл янындагы күлләрнең берсе аеруча матур һәм серле. Серле дип әйтүнең мәгънәсе шунда, ул бормаланып авылны чолгап алган һәм һәр бормасына исем бирелгән. Мондый күл, әлбәттә, елга иске юлын калдырып киткән урында була һәм көнчыгыш төбәкләрдә аны юлак дип йөртәләр. Күлнең тәмамланган урынын Тамак дип атыйлар, Алмакай дип аталган төше дә бар. Алмакайның ярлары ком гына һәм шунда олысы да, кечесе дә су коенырга, кызынырга килә. Күлнең икенче бер башы авыл яныннан ук үтә (бер урам кырыеннан). Яры комлы булмаса да, монда да су коена торган урын бар. Күлнең бер тармагы «п» хәрефе ясап аерылып чыккан. Аның бер ягы кырны бүлеп уза, икенче ягы Алмакай янында урнашкан урам башындагы 13 йортның бакчаларын икегә бүлеп үтә һәм кире Алмакайга барып тоташа. Аны халык Кече күл исеме белән йөртә. Элек-электән авыл халкы Алмакай һәм Күл уртасындарак урнашкан бер урынга кер чайкарга йөргән. Бу урынны Төпсез уба дип атыйлар. Аның бүрәнкә шикелле тишеге бар һәм ул кешене йотарга мөмкин, имеш. Бу урында кеше батса, үле гәүдәсен дә алып булмый икән.

Авылның иң изге урыннарыннан саналган җире—Иске зират. Анда Әхмәр

бабай исемле изге кеше кабере әле дә сакланган, аның тирәсе матурлап тотып алынган.

Хәзерге вакытта авылда ике катлы урта мәктәп, авыру балалар өчен махсус мәктәп һәм интернат эшли. Төрле авыллардан килгән балалар шунда торып укыйлар. Татар һәм чуаш балалары аерым классларда, татарлар татарча, чуашлар урысча укыйлар.

Авылда ике мәчет бар. Берсе әле 1996 елның җәендә генә ачылган. Икенчесе мәдрәсә булып калган. Инде 3 ел буе бу мәдрәсәгә яше дә, карты да укырга йөри. Аларны Буадан мулла килеп укыта. Укучылар барысы да бик теләп, күңел белән йөриләр.

## Адай

Адай авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмарадан 18 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Зур Сәрдек авылыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан,

Адай авылы халкы июнь ае башында күршедәге Купка, Аш Бужи, Зур Сәрдек, Сәрдекбаш, Уразай, Кара Елга, Олыяз, Югары Казаклар, Түбән Казаклар авыллары белән бергәләшеп Йассы болын җыены үткәргән.

Авыл артык зур булмаган, салмак агышлы Бөре суы буена утырган. Авылны икегә бүлеп, челтерәп, йөгерек инеш ага. Авыл моннан күп еллар элек инешнең югары агымында утырган булган, ә хәзерге урынында элек марилар яшәгән дип сөйлиләр.

Авыл халкы тиз генә күбәеп китү аркасында, йорт салу өчен тигез урын житмәгәнгә күрә, кинәшкәннәр дә, инеш буйлап бераз түбәнгәрәк күчеп утырырга булганнар. Яңа җиргә иң элек Адай-хан исемле аксакал төшеп урнаша, аңа башкалар да иярә. Бу урында яшәгән марилар исә: «Киттек, киттек»,—дип, Бөре елгасының түбән агымына, суның икенче ягына чыгып нигез салалар. Ул авылны хәзер Китәк дип атыйлар. Болар риваять кенә булсалар да, ихтимал, күпмедер дөреслек тә бардыр.

Тора-бара авыл шактый зурайган. Ул ике мәхәлләгә бүленгән, ике мәчет эшләгән. Мәхәлләләрнең берсе суның бирге ягында, икенчесе—аргы ягында булган. Яманаты чыккан 1930 елларда мәчетләрнең манаралары киселгән, кайсын мәктәп, кайсын хуҗалык биналары итеп үзгәрткәннәр.

Адай атамасының килеп чыгышын Гомәр Саттаров болай аңлата: «Кукмара һәм Актаныш районнарындагы Адай авыллары атамасының нигезендә Адай дигән борынгы төрки кеше исеме ята. Бу авылларга Адай исемле кеше нигез салган булырга тиеш».

Авыл уртасында Изгеләр чишмәсе челтерәп ага. Авыл халкы аны карый, чистартып тора. Авыл уртасында ук тагын ике кое бар, алар янәшә урнашканнар. Берсен Сәхабетдин коесы дип, икенчесен Матур кое дип йөртәләр. Икенчесе бик матурлап һәм бизәкләп эшләнгән.

Әчи чишмәсенең суын халык яратып эчә. Аннан түбәндәрәк Кортлы чишмә челтери.

Авылда тарих музее юк, ләкин халыктан җыелган элекке эш кораллары, бизәнү әйберләре, тәнкә-чулпылар Зур Сәрдек лицей-мәктәбе музеена тапшырылган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# АНЫҢ ТОРМЫШЫ—ТЕАТР...

Берәр танылган шәхеснең исеменә күз салсаң, шундук аның эшләгән эшләре, иҗаты күз алдына килә. Шәүкәт ага Биктимеров икән—Әлмәндәр карт, Равил Шәрәфи икән—Әҗәл, К. Тинчурин театрының әйдәп баручы артисты Наил Шәйхетдиновның хезмәте исә, иң беренче чиратта Хуҗа Насретдин роле белән тасвирлана. Чөнки бу образны аннан да яхшырак ачкан, җиренә җиткереп уйнаган артистны мин хәтерләмим. Ул—иҗатчының төп «уен картасы». Бу персонаж аның иҗатының иң югары ноктасы.

1980 елда Равил ага Тумашев «Хуҗа Насретдин» пьесасын сәхнәләштерә. Төп рольгә нишләптер ул чактагы танылган артистлар Г. Нуруллинны да, Х. Мәхмүтовны да, Р. Мифтаховны да билгеләми режиссер, нәкъ менә Н. Шәйхетдиновка тукталырга була.

Чирмешән районының Лашман авылында туып-үскән егет иң беренче иҗади чирканчыгын мәктәп сәхнәсендә ала. Соңыннан, ике ел колхозда ат җигеп эшләгәч, университетка керермен дип Казанга барса, үтә алмый. Яшәр өчен үз икмәген төзелештә эшләп таба. Очраклы гына күргән игълан кәгазе аның бөтен тормышын икенче юлга кертеп җибәрә. Ул шуның буенча барып, театр училищесына укырга керә. Өстендә, әтисе алып биргән кирәгеннән артык зур плащ була егетнең. «Әти, миңа бик зур бит бу», диеп тә карый үсмер Наил. «Казанга баргач үсәрсең, таман гына булыр»,—ди ата кеше. Шулай итеп, озын плащын сөйрәп авылдан киткән Наил артистлык юлын сайлый.

Ачлы-туклы булса да, нинди бәхетле булган икән студент чаклары! Өстәвенә курсташларын кемнәр диген әле! Булачак татар сәхнәсенең учагын дөрләткән Х. Җәләй, Н. Әюпов, В. Хөснетдиновалар. Дөрес, әле болары соңрак. Кемнәр укыта диген син яшьлекләре ташып, каннары уйнап торган шәкертләрне! Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Ш. Сарымсаков, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Х. Уразиков, СССРның халык артистлары Ш. Биктимеров, Г. Шамуков, Россиянең халык артисткасы Ш. Әсфәндиярова. Нинди исемнәр, җәмәгать, нинди курсташлар, нинди мөгаллимнәр! Андый шәхесләрдә укуның зур бәхет булганлыгын соңыннан гына—тормыш тәҗрибәң арткач, фикер йөртүең киңәйгәч кенә аңлыйсың.

Гәүдәгә зур булмаган, какча гәүдәле артистның Хуҗага билгеләнүенең сере нәрсәдә икән соң? Миңа калса, дөньяга гаҗәпләнеп, хәйләкәр очкыннар чәчеп, шул ук вакытта миһербанлык белән карауны күзләре сәбәпче булгандыр. Шул чактагы театрның баш режиссеры, Г. Тукай премиясе лауреаты Равил ага Тумашев та Хуҗа Насретдин күзләре бит бу дигәндер. Һәм ул ялгышмаган.

Театр училищесында укыган һәрбер шәкерт, Отеллоны да, Гамлетны да, Хәлилне, ягъни төп рольләрне уйнарга хыяллана. Хатын-кызлар, әлбәттә, Дездемонаны, Диләфрүзне, Зөбәйдәне күзаллый. Шунысы кызыклы, Наил абыйның үзе әйтүенчә, әллә ни хыял дингезләрендә йөзмәгән, «ни бирсәләр, шуны уйнадым, роль сорап йөрмәдем. Ләкин нинди генә образ булмасын, төп геройны ул, икенче пландагы персонажмы, йә булмаса эпизодик рольме, намус белән җиренә җиткереп эшләргә тырыштым», ди ул. Бу инде танылган артистның эчке дөньясының чисталыгына ишарә ясый. Дөрестән дә, күп еллар бергә эшләү чорында, мин аның роль теләнеп төрле интригаларга катнашып йөргәнен хәтерләмим. Иң күбесе, әсәрне укыгач: «Миңа шул рольне бирсәгез рәхәтләнеп уйнар идем, ничектер холык-гадәте бик якын», дип кенә куяр иде. Һәм чыннан да, үзенә эләккән персонажның характерын ул шәп итеп ача белә иде. Үткән гасырның сиксәненче елларында безгә бер бригадада

С. Шәкүровның « Саф күңелгә тап төшми» драмасы белән шактый гомер гастрольдән-гастрольгә йөрергә туры килде. Наил абый авылның бик әшәке кешесен—бүре Авзалын уйный. Ул бу образны шуның хәтле мәкерле, хәйләкәр һәм явыз итеп ачты ки... Спектакльдән соң таныш-белешләре дә шикләнеп карыйлар иде ана. Шикләнмәс жиреннән шикләнерсен, тормыштагы игелекле, ярдәмчел Наилнең бөртеге дә калмаган ич бирedә! Мин үзем дә остазымнан кызыксынып: «Наил абый, үзен бик тәртипле кеше, бу кара күнелле адәмне уйнарга кыен булмадымы соң?» дип сорадым. «Нишләп кыен булсын!? Булмады! Нәкъ шундый адәм үзебезнең авылда бар иде»,— дип куйды. Танылган артистларыбыз Ринат Мифтахов, Сания Исмәгыйлева, Марсель Жаббар, Наил Шәйхетдиновлар уйнаганга микән, сугыш темасына багышланган бу әсәр сәхнәдән төшмичә бик озак еллар барды. Ни кызганыч, шушы күренекле шәхесләребез уйнаган спектакль берниндә язмада да сакланып калынмады. Юкса, чын профессиональ югарылыкта куелган спектакль иде ул. Режиссеры гына кем диген—Празат Исәнбәт! «Менә кемнәр белән эшләргә туры килде миңа», дип үзем дә горурланып куям.



*Н. Шәйхетдинов Хуҗа Насретдин ролендә (уңнан икенче).*

...Наил абый театр училищесын тәмамлагач, элеккеге «күчмә»гә эшкә чакырыла. Юллар, юллар, юллар... Очсыз-кырыйсыз юллар. Бу юллар кая гына илтеп житкерми яшь артистны. СССР дигән дәүләтнең кайсы төбәгенә барылмый калды икән? Үзе генә дә ярты Жир шары хәтле бит ул СССР дигән ил! Шунысы сәер, театрга килүенең беренче көннәреннән үк Наилгә күбрәк өлкәннәр, картлар ролен бирәләр. Әйтик, «Кыр казлары артыннан» спектаклендә күнел әрнүләрен тирәнгә яшергән серле Әкбәр, И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» драмасында, дөньяның кимчелекләренә битараф булмаган мәрхәмәтле Хәмзин, Т. Миннуллинның «Үзебез сайлаган язмыш»ында барсына да баш иючe, куркаграк Нариман һәм башка бик күп әсәрләрдә төрле холыклы образлар тудыра ул.

Наил абый комик рольләрне оста башкаручы артист буларак та халык алдында танылды. К. Гальдониның «Ике хужаның хезмәтчесе»ндә—Панталоне, Т. Гыйззәтнен «Башмагым»да—Зыя бай... Саный китсәң бик күп инде алар. Ә менә Г. Зәйнашеваның «Гайфи бабай, өйлән давай!» ында төп рольне—Гайфине башкарып, тагын бер мәртәбә тамашачы мәхәббәтен казанды. Үткән гасырның 90 нчы елларында куелган әсәр бүген дә гөрләп бара. Инде әллә ничә артист алмашынды, тик Наил ага Шәйхетдинне генә берәү дә алыштыра алмый. Аның Гайфие, намуслы татар карты, сугышлардан орденнар тагып кайткан солдат. Тормыш иптәшесез калгач, кызы төрле хатыннар табып өйләндерергә тырыша. Ләкин Гайфи аларның берсен дә кабул итә алмый. Чөнки бу хатыннарны йә байлык, йә картның хәрби пенсиясе генә кызыксындыра. Төрле хәйләләр табып Гайфи алардан котыла бара. Йә психик авыруга сабыша, йә сәрхүшкә салыша. Ләкин, очраклы гына, картлар йортында яшәүче бер карчыкны очраткач, ул шундук үз итә аны. «Сезнен тавышыгыз, сезнең төсегез мина газиз хатынымны хәтерләтә, сез аның сеңлесе булырга мөмкин. Чөнки ул да ачлык елларында әтиәнисез калып, приютта үскән иде»,—ди ул. Шулай итеп, үзенә ошаган, күнеленә хуш килгән хатын-кызга тәкъдим ясый. Наил абый Гайфи ролен бик яратып уйный. «Бу картта мин үземнең бабамны күрәм. Мәрхәмәтле дә, төрле кыенлыклардан оста чыга белүче үткен карт та иде ул», ди.

Күптән түгел, Н. Шәйхетдинов тагын бер зур әсәрдә, ул да булса Ш. Камалның «Хажи

әфәнде өйләнә»сендә Хаҗины уйнап Казан халкын шатландырды. Ул уйнаган Хаҗи бик хәйләкәр, мут булып күз алдына килеп басты. Заманында бу рольне Татарстанның халык артисты Ринат ага Мифтахов башкарган иде. Наил абый да, мин дә ул спектакльдә элек тә катнашкан, рольләр уйнаган кешеләр. Әле дә хәтердә, Хөснетдин ролен ул бик үзенчәлекле итеп, яңгыравыграк тавыш белән уйный иде. Әле мин белмәгән тагын бер роле дә бар икән аның. Шушы әсәр үткән гасырның 60 нчы елларында ук куелган булган. Анда ул, гашыйк шагыйрьне башкарган. Хәзер менә өченче тапкыр шул әсәр сәхнәләштерелде. Иң беренчесен, Татарстанның һәм Россиянең сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Р. Тумашев куйса, 1980 елда исә аны күренекле режиссерыбыз П. Исәнбәт кабат чыгара. Өченче тапкыр исә, 2010 елның декабрендә Россиянең атказанган артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Заһидуллин тарафыннан дөнья күрде. Хаҗи роле Наил аганың чираттагы бер уңышы.



*«Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән бер күренеш.*

Наил абыйның мин: «Хезмәт хакы да әз, туйдырды инде театр да», дип зарланганын хәтерләмим. Ул гомере буе Кәрим Тинчурин театрына тугры калды. Өстәвенә хатыны Миннегөл ханым да һәрвакыт янәшәсендә булды. Бүгенге көндә дә театрда склад мөдире булып хезмәт итә. Кызлары Миләүшә дә әтисе юлын сайлады. Танылып баручы артистка, Г. Камал театрында эшли. Үзе гастрольгә мазар китсә дә, кечкенә кызы Сөмбелне калдырырга, тәрбияләргә дә кеше бар. Әби-бабасы оныклары өчен вакытларын да, көчләрен дә кызганмыйлар. Фигуралы шуугa әле берсе, әле икенчесе баланы алып чыгып китә. Наил абый барсына да ничек өлгерәдер, әллә көнгә биш вакыт намаз уку булышамы? Күпләргә үрнәк ул бүгенге көндә. Артист кешегә, әлбәттә, сәламәтлек бик кирәк. Яхшы артист пенсиягә чыкмый бит ул. Хәленнән килсә, уйнавын дәвам итә. Елына әллә ничә гастрольләре дә булып тора. Юл йөргәндә иң мөһиме—тазалык-саулык.

Наил абыйның шәхси тормышына кагылсак, мине сокландырган яклары шактый җитәрлек. Кыш буе ул, бер генә хоккей уенын да калдырмый, мөкиббән китә инде, шуңа чаба. Гастрольгә чыкса, шуны карар өчен телевизор эзләп китә! Җәй көне исә Идел ярына урнашкан бакчасында казына. Мунчасы да ижатчының көн аралаш ягыла, туганнары белән өйләре гел тулып, шаулап тора. Үз-үзенә бикләнеп, аралашмыйча яши алмый, тынгысыз кеше ул. Сәхнәдә дә, тормышта да гел хәрәкәттә. Шактый гына кире кеше булса да, кешеләргә әшәкелек кылганы юк аның. Шәхсән үзем күтәрелеп, бүтәннәргә каты бәрелгәнен хәтерләмим. Аның тагын бер күркәм сыйфаты бар—дус-ишләренә, хезмәттәшләренә ярдәмчел.

Театрда эшләү дәверендә халык алдында кәмит артист булып кына түгел, психологик драмаларда да үзен зурдан танытты. И. Грекованың «Тол хатыннар көймәсе»ндә—Фәрит, «Имансызлар»да—Гатаулла, «Шәмсекамәр»дә—Хәсән, «Яшь йөрәкләр»дә—Сәйфулла һәм башка дистәләгән образлар тудырды. Артистның театр сәнгатен үстерүгә куйган олы хезмәте дәүләтебез тарафыннан «Татарстанның атказанган артисты»(1982), «Татарстанның халык артисты» (1987), «Россиянең атказанган артисты»(2000) дигән исемнәр белән бәяләнде. Наил ага Шәйхетдиновның сәхнә осталыгы елдан-ел камилләшә барып, яшь буын артистларына да үрнәк булып тора. Килеп киңәш сорасаң, беркайчан да булышмыйча калмый ул. Аның һәр тудырган образы юмор белән сугарылган, төрле холыклы затлар чагылдырылган. Аларның күп төрле сыйфатларын табып, дөресен әйтим, шуны сәхнәдә уйнау, җиңел түгел. Ул уйнаган рольләр елата да, уйландыра да, яшь аралаш көлдерә дә. Тамашачы аны артист буларак үз итте, аның уйнаганын карарга килүчеләр елдан-ел ишәя генә бара.

**Рәдиф СӘГЪДИ**

## Сәрвәр Әдһәмованың тууына 110 ел

Язучы һәм тәржемәче Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова 1901 елның 5 апрелендә Оренбург губернасының (хәзерге Чиләбе өлкәсе) Троицк шәһәрендә мөгаллим гаиләсендә дөньяга килә. Алты-җиде яшендә әнисеннән татарча укырга-язарга өйрәнә. 1911-1914 елларда туган шәһәрендә өч сыйныфлы кызлар мәктәбендә, ике ел дәвамында татар мөгаллимәләре әзерли торган хосусый мәктәптә, аннары исә Троицк кызлар гимназиясендә белем ала. 1920-1923 елларда Томск шәһәре университетының медицина факультетында укый, бер үк вакытта 1921 елгы ачлык чорында Идел буе авылларыннан җыеп китерелгән ятим балалар йортында тәрбияче һәм мөгаллимә булып эшли. Шунда эшләгәндә балалардан сәнгать-театр түгәрәге оештырып, алар өчен «Авыл тормышыннан бер күренеш» исемле кечкенә генә сәхнә әсәре яза. Язучының беренче иҗат тәҗрибәсе булган бу пьеса соңыннан, 1924 елда, Казанда аерым китап булып та басылып чыга.

1923 елның көзендә Сәрвәр Әдһәмовага йөздән артык баланы туган якларына озата бару бурычы йөкләнә. Шул рәвешчә ул Казанга килеп чыга һәм бөтенләйгә шунда төпләнеп кала. Берьеллык юридик курсларны тәмамлаганнан соң, җиде-сигез ел дәвамында (1924-1932) әүвәл Татарстан Мәркәз крәстиян йорты каршындагы юридик бүлекнең мөдире булып эшли, аннары «Крәстиян гәзите» идарәсенең газета укучыларына консультация бирү бүлеген җитәкли.

Казанга күчеп килү, әдәбият-сәнгать кешеләре, язучылар, шагыйрьләр белән якыннан аралашу, 1924 елда күренекле татар язучысы Кави Нәҗми белән гаилә тормышы башлап җибәрү Сәрвәр Әдһәмованың әдәби иҗат эшенә тартылуына хәлиткеч йогынты ясый. 1924 елда ул «Хәзер бул!» дигән икенче пьесасын иҗат итә, соңга таба балалар өчен шигъри һәм чәчмә әсәрләр язарга керешә. Шул елларда аның әдәби тәржемә өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге дә башлана. М. Горькийның барлык төп әсәрләре, Л. Толстойның хикәя-повестьлары, А. Пушкинның прозасы, чит ил классик әдәбиятыннан Д. Дефоның «Робинзон Крузо»сы, Д. Свифтның «Гулливер лилипутлар илендә»се, бертуган Гриммнарның мәшһүр «Әкиятләр»е татар укучысына нәкъ менә С. Әдһәмова тәржемәләре аша барып ирешәләр. Илленче еллар ахырында әдибә зур иҗади дәрт һәм тырышлык белән казакъ язучысы Мохтар Әуэзовның зур күләмле «Абай» роман-эпопеясын турыдан-туры казакъчадан тәржемә итү белән шөгыльләнә. 1957 елда әсәрнең Казанда басылып чыгуы татар әдәби тәржемә өлкәсендәге зур бер казаныш итеп бәяләнә.

Сәрвәр Әдһәмова—утызынчы еллардагы репрессияләр чорында совет режимы тарафыннан бер гаепсезгә рәнҗетелгән шәхес тә. 1938 елның 4 гыйнварендә аны «халык дошманының хатыны» буларак кулга алалар (ире Кави Нәҗми ярты ел алданрак кулга алынган була). Шул ук елның 11 августында махсус кинәшмә әдибәне, Җинаятьләр кодексының 58 нче маддәсенә таянып, ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән хөкем карары чыгара. Язучы Себернең төньяк төбәкләренә тоткын итеп озатылып, ике елдан артык урман кисү кебек авыр эшләрдә эшли, кышкы салкыннарда аяккулларын өшетеп җәфалана. 1940 елның 16 октябрендә кассация тәртибендә аның «эше» яңадан каралып, ул гаепсез табыла һәм иреккә чыгарыла.

Казанга кайткач, Сәрвәр Әдһәмова тәржемә эшләрен дәвам иттерә, дистәләрчә рус һәм дөнья әдәбияты классикларының әсәрләрен татар укучысына җиткерә. Гомеренең соңгы елларында ул замандашлары турында истәлекләр, мемуарлар, документаль әсәрләр дә яза.

Сәрвәр Әдһәмова 1978 елның 10 ноябрендә Казанда вафат була.

## Рәшит Гәрәйнең тууына 80 ел

1931 елның 15 апрелендә Татарстан Республикасының Минзәлә районы Малтабар авылында туып-үскән шагыйрь үзенең иҗатын тулысы белән диярлек авыл, аның кешеләренә, табигатенә, матурлыгына багышлый. Сугыш китергән авыр афәтләр, балачак күзәтүләре, үсмер егет кичерешләре аша гәүдәләнеп ул чорның фаҗигасен тагын да тулыландыра төшә.

Р. Гәрәй башлангыч белемне туган авылында ала, урта мәктәпне күрше Күзкәй авылында тәмамлый. Белемгә сәләтле булуы аңа 1949 елда Минзәлә педагогика техникумын төркемдәшләреннән алданрак тәмамларга мөмкинлек бирә. Шушы елларда ул үзенең беренче шигырьләрен иҗат итә. Алар «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында, яшьләрнең «Үсү юлы» альманахында, көндәлек матбугатның башка басмаларында дөнья күрәләр.

1948-1950 елларда Р. Гәрәй Минзәлә районының Иске Мәлкән һәм Чебенле җидееллык мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Иҗат эше белән ныграк шөгыльләнәсе килү сәбәпле, ул 1950 елда «Яшь Сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасының Минзәлә төбәгендәге үз хәбәрчесе вазыйфасына алына.

1951-1953 елларда Р. Гәрәй Совет армиясендә хезмәт итә. Биредә дә ул иҗат итүен туктатмый. Шуның нәтиҗәсе булып 1952 елда Казанда аның «Беренче хисләр» дигән тәүге шигырь җыентыгы дөнья күрә.

Армиядән кайткач Р. Гәрәй 1954-1959 елларда Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтында белем ала. Аннан соң 1980 елга кадәр «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналының шигърият бүлегендә, берничә ел Татарстан китап нәшриятында мөхәррир вазыйфаларын башкара.

Соңгы елларда исә ул бары тик язучылык эше белән генә шөгыльләнә. 1981 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Р. Гәрәй бары тик үзе күргән, кичергәннәрне генә язарга ярата. Шуңа күрә дә авыл, аның кызыклы кешеләре, гадәт-йоласы иҗатының төп тематикасы булып тора, шигырьләре укучыларда туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә зур роль уйныйлар. Ул ике дистәгә якын китап авторы, 1960 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Р. Гәрәй гомеренең соңгы елларында туган авылында яшәп иҗат итә һәм 1999 елның 22 июнендә вафат була.

## РӘХӘТ САГЫНУ, ТАТЛЫ САГЫШ...

*Әйләнәм дә шулай, мин әйләнәм,-*
*Бер минут та җирне ямьсезләмәм.*
*Дөрлим! Сүнәр көннәремне беләм,-*
*Шуңа мәнә җырга әверелэм.*

Рәшит Әхмәтҗанов

...1995 елның 5 гыйнвар таңы кайбер кешеләргә, әйтерсең лә, яман хәбәр житкерер өчен атты: Рәшит Әхмәтҗанов вафат. Кинәт булган бу авыр югалтуны кабул итеп бетерергә күңел әле әзер түгел... Нибары берничә көн элек кенә шау-гөр килеп редакциядә («Казан утлары» журналында) Иске елны озату мәҗлесе ясаган идек. Кайбер очракларда күңелнең алдан күреп, ниндәндер хәвефләнгән чаклары булса да, берни сизмичә, шулай зурлап, бер табын артына жыелышып, моңлы җырлавын тыңлап, әйтерсең лә, без аның белән хушлашканбыз. Юкса, башка гадәти эш көннәрендә журнал мәшәкатьләре белән ыгы-зыгы киләбез дә, бер-беребез белән саубуллашырга да онытып өйләребезгә таралышабыз...

Ул көннән соң инде дистә еллар узган. Татар шигърияте̣ндә үзгә холык-фигыльгә ия булган, сурәтләү-фикерләрен үзләренчә бирә алган яна заман шагыйрьләре үсеп чыкты. Аларның бала чагын Рәшит Әхмәтҗанов шигырендәгечә «кырлар буйлап ачлык кумаган», «төшләрендә ап-ак шикәр күреп уянмаганнар»... Аларның Алсулары да Такташ Алсуы кебек түгел, үз заманы Алсуы... Дөньяга карашлары, танып белүләре өлкән агайларыныкы кебек үк булмаса да, шөкер, татар шигърияте әдәби жанр буларак «догасын тапмаган әрвахтай» кагылып-сугылып йөрүгә дучар ителмәгән, Р. Әхмәтҗановча әйтсәк:

*Үз каныңнан сүзләр ясый-ясый,*
*Йә, җиңелме шигырь сөйләргә!*

***

Шагыйрь—үз чорының елъязмачысы. Талантлы шагыйрьләрнең туу елларына күз салсаң, чор белән, дәвер белән ниндидер табигый тәңгәллек барлыгына инанасың. Такташ шигырендәгечә, нәкъ менә шул елларда кирәк булган аның тууы, дип уйлыйсың.

1941 елның 14 апрелендә сугыш башланырга нибары өч ай калганда дөньяга килә Рәшит Әхмәтҗанов. Сугыш китергән афәтләр авырлыгының бер башы өлкәннәр жилкәсенә ятса, икенчесе—ачлык-ялангачлык, үксезлек-ятимлек булып сабыйлар йөрәгенә сырыша...

*Камылларны сыйпап узды кояш.*
*«Без дә монда!»—дидек,—ишетмәде.*
*Кайтсак, табан бозга ябышканчы*
*Сугыш биклəп торды ишекләрне.*

Әйе, сугыш аларның иннәренә бик иртә чыбыркы салдыра, кулларына көрәк-балта алдыра. Шахта-күмер базларына төшеп күмер вата, таш чыгара алар...

Ташлар белән үзгә танышлыгы да үсмер егетнең Әлмәттә ташчы булып эшләгәндә башлана. Үз хәленең нindилеген сөйләп ташларга күп шакырга туры килә аңа. Көннәре авыр, газаплы эштән катыланырга, тупасланырга тиешле кебек булса да, Ходай биргән талант гамьле шигъри моңга әверелеп, шагыйрь кулы аша үткән ташка да җан иңеп, әлеге чуер ташлар киләчәктә язылачак «Биш таш» поэмасына нигез булып яталар.

*Таш дисеңме? Ташны бит мин каты димим.*
*Әллә башка катылыклар күп күргәнгә.*
*Сине уйлап уелам да һәм кинәттән*
*Нәфис чәчәк булып калкам мин бер мәлгә.*

* * *

Шагыйрь—үзенең иҗатында балачагы, үткәне-бүгенгесе турында язмый кала алмый. Тик ничек итеп яза бит?! Шагыйрь, аның шәхси тормышы—күпмедер дәрәҗәдә иҗатының яратылышы, гәүдәләнеше дә. Тиккә генәме борынгы заман төрки шагыйре Низами:

*Чорлар үткәч сорасаң: Низами кайда?—дип,*
*Җавап бирер һәр шигырем: ул—монда,—дип*

язганмы!

Әгәр шагыйрь мәхәббәттә мең кат үлеп, мең кат терелмәсә, бер үк вакытта хисләренең колы һәм падишаһы була алмаса:

*Җирдән эзлим, күктән эзлим, күптән эзлим,*
*Шуны белеп әйлән-бәйлән уйный гөлләр,*
*Төнлә авыр. Төнлә елый әллә кемнәр?*

---

*Хәбәр җибәр, көләргәме, еларгамы?*
*Әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?*

—дигән юллар туа алыр идеме?

Рәшит Әхмәтҗанов эчке дөньясын шәрран ачып салып дус булырга теләүчеләр белән хис бүлешеп яшәүчеләрдән түгел иде. Үтә яшерен хисләрен яман күзләрдән, яман сүзләрдән тел-бизәкләргә төреп шигъри сурәт тудыру өчен саклагандыр күрәсең. Шунадамы, ул шигърият бакчасында аерым бер түтәл булып яши алды. Шигырьләрендәге бик үк гадәти булмаган көтелмәгән борылышлар, фикер-сурәтләүләрендәге табышларны кемдер, бәлки, кабул итеп тә бетермәгәндер. Тик аның иҗаты нәкъ менә шул гадәти булмавы, шигырьләренең нindидер бер көйгә, моңга көйләнебрәк язылуы, халык-авыз иҗатына тартым булуы, табигыйлеге белән үзенә җәлеп итә дә.

***

Милли аң, халыкчанлык өлкәнрәк буын шагыйрьләре иҗатының төп темасы, милләтпәрвәрлекнең бер сыйфаты буларак аларны бәйсезлек, азатлык яуларга мәйданнарга алып чыкты. Көрәш мәйданында шагыйрь бар икән—анда инде шигырь туа. Дәүләт эшлеклеләренең мәйданда барган вакыйгаларны йомшартып, дулкынланган халыкны бераз тынычландыру өчен тоткан нотыклары вакытлар узу белән көчен югалтып онытылырга да мөмкиннәр, ә шагыйрь каләме белән язылган тарих чорлар аша да «Идегәй» дастаннарыдай халык күңелендә янара, Исхакый әсәрләредәй кадерле була ала.

... 1991 елның май ае. Илдә барган сәяси кайнарлыктан, әйтерсең лә табигать

тә, үзенең табигый торышын үзгәрткән: башка елларның май аена караганда күпкә кызу. Бер төркем милләтпәрвәрләр ирек даулап Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан итәләр. Иреккә юл ярганда көрәш алымнары төрле була. Әнә, Рәшит Әхмәтҗановның әле таң алдыннан гына язган шигыре халык төркеме өстеннән ярып уза:

*Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча,*
*Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.*

Әлеге көрәш мәйданында туган шигырьләр «Ачлык мәйданы» поэмасына әверелеп, инде ничәмә-ничә еллар буе йокымсырап ятып, югала баруга дучар ителгән халыкны да уянырга мәҗбүр итте.

Р. Әхмәтҗанов, гомумән дә, поэма жанрын яратып иҗат итүче шагыйрьләрдән, алар аның иҗатының аерым бер өлешен билән тора.. Шигъриятнең гаять катлаулы, авыр бу төренә алынырга күпләр базмый. «Аучылар кибетендә», «Карачкы», «Язлар быел соңга калды», «Карга каргышы» һ.б. поэмаларын иҗат итеп ул үзен шагыйрь буларак тагын да ачып, танытып кына калмады, дастан-поэмаларның татар шигъриятенә никадәр кирәклеген дә исбатлый алды.

Тәүге шигырьләр җыентыгын университетта укыган чагында ук кулына алган шагыйрьнең үзе исән чагында дистәләгән китабы дөнья күрә. Бәлки әле алар тагын берничә дистә булыр, томлыклары да чыгар иде... «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиягә лаек була... Бәлки әле тагын да мәртәбәлерәк бүләкләргә ия булган булыр иде... Вафатыннан соң шагыйрьнең иң яхшы шигырьләрен туплаган «Сайланма әсәрләре» («Рухият» нәшрияты, 1988), «Сәфәр ае» («Татарстан китап нәшрияты», 2001) исемле китабы басылып чыкты.

Иҗатының башлангыч чорында ук Хәсән Туфанның фатихасына ирешкән шагыйрь Олуг Шигъриятне таный белгән каләмдәшләренең ихтирамлы карашын, иҗатына хөрмәтен, шәхес буларак аңлауларын тоеп яши. Күренекле язучы Марсель Галиевнең аңа багышланган язмасын ачам:

«Әгәр ана Күк иясе:

—Шигъриятнең пәйгамбәре итәм, калган гомереннән ваз кичәсенме?—дисә, ул сүзсез риза булыр, халык бәгыренә тәнгәл килгән чын шигърият хакына җирдә бүтән мәңге кабатланмаячак гомерен корбан итәр иде...»

... Халык бәгыренә тәңгәл шигърият... Ул үзе дә якын иткән кешеләренә ничектер бер үзенчә матур итеп «багърем» дип дәшә иде...

...Бары тик шигърият белән генә яшәп, бөтен барлыгын, яшәешен шигъриятькә багышлаган Рәшит Әхмәтҗановның арабыздан киткәненә дә инде уналты еллап вакыт узган. Бер караганда әллә ни күп тә түгел кебек...

Шат күңелле, җор телле, кабатланмас бу шагыйрьне уйлаганда, иҗатын хәтердә яңартканда, күңелне татлы сагыш, рәхәт сагыну билән ала.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА.**

## ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

Татарстан Министрлар Кабинетында Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы коллегиясенең узган елгы эш йомгакларына һәм 2011 елга билгеләнгән бурычларга багышланган утырышы булды. Анда төп доклад белән агентлык җитәкчесе М. Моратов чыкты. Ул үз чыгышында халыкның гаммәви мәгълүмат чараларына ышаныч белән каравын, әбүнәчеләрнең газета-журналларга игътибары арта башлавын билгеләп үтте. Болар исә җәмгыять белән хакимият арасында нәтиҗәле диалогны тәэмин итү өчен бәрәкәтле җирлек булып тора.

Коллегия утырышында катнашкан Президент Р. Миннеханов журналистларны хакимият эшчәнлегендәге объектив җитешсезлекләрне кыюрак күрсәтергә, кискен проблемаларны ачканда гадел булырга, аларның асылын төрле яклап аңлатып бирергә, заманча үтемле алымнар белән эш итәргә чакырды. Ә бюджет ярдәме мәсьәләсенә килгәндә, республика җитәкчесе болай диде: «Дәүләтнеке булган гаммәви мәгълүмат чараларын бер агентлыкка җыеп берләштерү аларны икътисади кризис чорында саклап калырга ярдәм итте. Шул ук вакытта дәүләт һәм муниципалитетлар гаммәви мәгълүмат чаралары активыннан акрынлап аерылырга тиеш. Бу—бик катлаулы эш. Әмма бөтен дөнья шушы юл белән киткән. Россия Президенты матбугат чараларын хосусыйлаштыру бурычын куйды, һәм без бу юнәлештә актив эшләргә тиеш. Шәхси-дәүләт хезмәттәшлегенең уңышлы үрнәге итеп «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясен күрсәтергә була. «Татмедиа»ның да киләчәктә үз стратегик партнеры булачак дип ышанам».

Киңәйтелгән коллегия утырышында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры А. Сәлимгәрәев, «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры И. Әминов, «Эфир» телекомпаниясе директорлар советы рәисе А. Григорьев, «Спорт тапшырулары» генераль директоры В. Кикнадзе (Мәскәү) чыгыш ясады.

Соныннан Президент Р. Миннеханов республика гаммәви мәгълүмат чараларының нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән вәкилләренә дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Утырышта ТР Президенты аппараты җитәкчесе Ю. Камалтынов, ТР Муниципаль берәмлекләр берлеге җитәкчесе М. Шакиров, шулай ук республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре катнашты.

## ТЕЛ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДА

Министрлар Кабинетында Премьер-министр Илдар Халиков җитәкчелегендә татар теленә өйрәтүнең торышы һәм аның методологиясен камилләштерү перспективалары мәсьәләсе буенча киңәшмә узды.

Анда Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Президентның эчке сәясәт мәсьәләләре буенча идарә башлыгы А. Терентьев, Мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов, югары уку йортлары ректорлары, татар теле һәм әдәбияты буенча дәреслекләр һәм укыту-методик комплектлар авторлары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты.

Киңәшмәдә Мәгариф һәм фән министры А. Гыйльметдинов милли (татар) мәгариф системасы үсешенең төрле этаплары турында хисап бирде, татар телен һәм әдәбиятын укытудагы проблемалар һәм аларны хәл итү юллары турында сөйләде.

Фикер алышуда ТР мәгарифне үстерү институты ректоры Рәис Шәйхелисламов, Чаллы дәүләт-педагогика институты ректоры Фәйрүзә Мостафина, КФУ профессоры, ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми секретаре Дания Заһидуллина, ТР Фәннәр академиясенең милли мәгариф теориясе һәм тарихы үзәге баш фәнни хезмәткәре Марат Лотфуллин катнашты.

Премьер-министр Илдар Халиков, фикер алышуга нәтиҗә ясап, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерү буенча конкрет чаралар комплексын эшләүне йөкләде.

## ТУКАЙ ДӨНЬЯ ГИЗӘ

Мәскәүдә А. С. Пушкин исемендәге Дәүләт музеенда Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган «Мин мәңгелеккә омтылам» дип аталган күргәзмә ачылды. Чараны ТР Мәдәният министрлыгы, Мәскәүнең Мәдәният департаменты, ТРның РФдәге вәкиллеге, Мәскәү төбәге татарларының милли-мәдәни автономиясе һәм Мәрҗани фонды оештырды. Күргәзмәдә Г. Тукайның шәхси әйберләре һәм үзе исән вакытта ук басылып чыккан китаплары да куелган иде.

## ТӨРКИ ТЕЛЛӘР КӨНЕ ДӘ БУЛЫР!

Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясе гомумтөрки бәйрәм—«Төрки мәдәният һәм тел көне» булдырырга ниятли. Әлеге тәкъдим белән ассамблея төрки дәүләтләр җитәкчеләренә, ЮНЕСКО, ТӨРЕКСОЙ, төрки илләрнең халыкара һәм иҗтимагый оешмаларына, төрки халыкларга мөрәҗәгать итте. «Төрки мәдәният һәм тел көне» төрки рух сакланган дөньяның һәр төбәгендә бәйрәм ителер, төрки мәдәниятне саклау, үстерү һәм танытуга, дөнья мәдәнияте хәзинәсен баетуга өлеш кертер дип көтелә.

Төрки мәдәниятләр көне беренче тапкыр 2009 елның 20 июнендә Казакъстанда үткәрелгән иде. Аны оештыруда Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясе һәм күп кенә төрки халыклар вәкилләре катнашты. Ел саен халыкара дәрәҗәдә уздыруны законлаштыру өчен билгеле бер көн сайлау мәсьәләсенә килгәндә, хәзерге вакытта төрле карашлар бар. Кайберәүләр аны Шәһитләр көненә туры китерү яклы, әмма Шәһитләр көне—ул искә алу көне, ә «Төрки мәдәният һәм тел көне» бәйрәм итеп үткәрелергә тиешле.

Яңа бәйрәмне «Төрки халыклар көне» яки «Төрки халыклар бердәмлеге көне» дип атарга теләүчеләр дә юк түгел.

Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясе «Төрки мәдәният һәм тел көне»н ел саен май аеның өченче шимбәсе һәм якшәмбесендә ике көн рәттән оештырырга тәкъдим итә. Бу бәйрәмнең беренчесен Төрки илләр Парламент ассамблеясе, ТӨРЕКСОЙ, башка дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар ярдәмендә төрки дөньяда танылган җәмәгать эшлеклеләре, сәнгать коллективлары катнашында үткәрергә кирәк дигән фикер белдерелә. Бәйрәм оештырылган очракта аны берьюлы дөньяның төрки халыклар яшәүче бөтен төбәкләрендә уздыру һәм гаммәви мәгълүмат чараларында яктыртуга зур урын бирү көтелә.

## ТУГАННАРДА КУНАКТА

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров Бакуда, Татарстанның Әзәрбайҗандагы даими вәкиллегендә татар диаспорасы вәкилләре белән очрашты. Очрашуда татар җәмәгатьчелеге, республика татар иҗтимагый оешмалары (Әзәрбайҗанның «Туган тел» татар мәдәнияте җәмгыяте, «Татарстан» иҗтимагый берләшмәсе, «Яшьлек» татар яшьләре үзәге һәм башкалар) әгъзалары һәм җитәкчеләре, шулай ук фән һәм сәнгать эшлеклеләре катнашты.

Ринат Закиров үз чыгышында бөтен дөньяда татар хәрәкәтләрен һәм җәмгыятьләрен бергә туплау буенча Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты алып бара торган эш хакында сөйләде.

Ринат Закиров билгеләп үткәнчә, Әзәрбайҗан этник татарларга тормыш итү өчен иң кулай төбәкләрнең берсе. Бу әзәри һәм татар халкын уртак этномәдәни һәм дини тамырлар, гореф-гадәтләр бәйләве белән аңлатыла, боларның барысы да халыклар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр өчен яхшы җирлек тудыра.

«Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә яшәүче әзәриләр, Әзәрбайҗанда гомер итүче татарлар кебек үк, үзләрен икенче ватаннарында кебек хис итә»,—диде Р. Закиров. Аның сүзләренә караганда, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты Әзәрбайҗандагы татар хәрәкәтләре һәм оешмаларының барлык башлангычларына теләсә нинди ярдәм күрсәтергә әзер. Бу җәһәттән Бакуда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара конференция үткәрүне, шулай ук Әзәрбайҗанда Сабан туен бәйрәм итүне мисалга китерергә мөмкин.

Р. Закиров фикеренчә, Татарстан Президенты Р. Миннехановның Әзәрбайҗанга визиты икътисади мөнәсәбәтләр һәм мәдәниятара элемтәләрдә сыйфат ягыннан яңа мөмкинлекләр ачачак. Якын көннәрдә Әзәрбайҗанда гамәлгә ашырылачак мәдәни проектларның иң көтеп алынганы—республикада татар мәдәнияте үзәген булдыру. Әлеге идеяне Татарстан һәм Әзәрбайҗан президентлары да хуплады.

## «МӘГЪРИФӘТ» ГАЗЕТАСЫ ЮБИЛЕЕ

Шул уңай белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин редакция коллективына котлау юллады. Анда мондый юллар бар: «Татарстан Республикасы мөгаллимнәренең һәм укучыларының көтеп алган һәм яраткан газетасы «Мәгърифәт» чыга башлауга 20 ел тулды. Редакциянең барлык хезмәткәрләрен һәм укучыларын шушы юбилей белән чын күңелдән котлыйм.

Сез изге максатка—яшь буынны милли рухта тәрбияләүгә, аның белем офыкларын киңәйтүгә, туган телебезне үстерүгә турыдантуры хезмәт итәсез. Заман укытучыларын һәм укучыларын яңа технологияләрдән, программалардан һәм проектлардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Киләчәк—белемле,

алга омтылучан, кыю, зирәк яшьләребез кулында. Сез—шушы яшь буынны әзерли торган абруйлы, дәрәҗәле басма.

«Мәгърифәт» сәхифәләре аша Татарстан мәктәпләре, югары уку йортлары, фән һәм әдәбият-сәнгать үзәкләре эшчәнлеге, мәгариф өлкәсендәге инновацион үзгәрешләр һәм танылган мәгариф хезмәткәрләре эше даими яктыртылып бара. Илебез күләмендә киң янгыраш алган «Киләчәк» проектын гамәлгә ашыруда да мөгаллимнәребез өчен ышанычлы ярдәмче, ә укучыларыбыз өчен мәгълүмат чишмәсе булырсыз дип ышанам.»

### ЯҢА УРАМ ИСЕМНӘРЕ

Казан шәһәр Думасы Совет районының Альберт Камалиев һәм Җиңү проспектлары арасында барлыкка килгән яңа урамга күренекле татар композиторы, җәмәгать эшлеклесе, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, СССРның һәм Татарстанның Дәүләт бүләкләре иясе Нәҗип Җиһанов исемен бирү турында карар кабул итте.

Вахитов районының Идел яры буйлап Киров дамбасыннан елга портына кадәрге арада урнашкан урамга археолог галим, тарихчы, профессор Альфред Халиков исеме бирелде.

Идел буе районындагы «Таулар-3» торак комплексының «М-16А» микрорайонында барлыкка килгән яңа урамга медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Әбүбәкер Терегулов исеме бирелде.

### ГАРӘПЛӘР ИЛЕНДӘ

Февраль аенда Татарстан делегациясе Кувейтта булып кайтты. Дәүләт эшлеклеләре белән бергә анда артистларыбыз да барды. Кувейтның 50 еллыгы уңаеннан биредә Татарстан сәнгать осталарының концерты булып узды. Концертта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең бию төркеме, җырчылар Ф. Каһиров, А. Хәйри, Э. Кәлимуллина, концерт гармуннарында уйнау остасы Р. Вәлиев һ. б. катнашты. Концерт залының фойесында татар милли костюмнарыннан, зәркән әйберләреннән күргәзмә оештырылган иде. Тамашачыларга шулай ук Казан турында фильм да күрсәтелде. Концертны җирле телевидение яздырып та алды. Анда катнашкан һәр артистка чыгышлары яздырылган лазер тәлинкә һәм фотолар бүләк ителде. Гомумән, Татарстан делегациясен җирле хакимият һәм Кувейт халкы бик җылы каршылады.

### КАЛӘМДӘШЕБЕЗГӘ ЫШАНЫЧ

Татарстан Президенты Указы белән, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы «Сөембикә» журналы редакциясе» директоры **Ләйсән Юнысова** Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы итеп расланды. Каләмдәшебезгә бу эшчәнлегендә дә уңышлар телибез.

***

2011 елның 14 февралендә язучы, журналист, Татарстанның атказанган Мәдәният хезмәткәре **Рафис Әхәт улы Гыйззәтуллин** 56 яшендә вафат булды.

2011 елның 10 мартында шагыйрә, публицист **Миңлебикә Рәхмәтулла кызы Фәйзуллина (Бикә Рәхимова)** 72 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*


*Беренче биттә:* Тукай портреты. Рәссам **Шакир Закиров** эше.

*Дуртенче биттә:* Казанда шигырь бәйрәме.

*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам...*

Г. Тукай





КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)